# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Газинур МОРАТ. SMSтан юлланмаган юллар. *Шигырьләр*. ....3
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Галәм гөле ташны ярган... *Повесть*. ....8
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Күңелнең җегендә моң-мәкам ярала. *Шигырьләр*. ....36
Фәрит ИМАМОВ. Вакытсыз вакыт... *Фантастик роман*. ....40
Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ. Нугай йорты. *Садактагы ун кыйсса*. ....77
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Үксезләр. *Повесть*. ....97


КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ


Гаврил АНДРОСОВ. Узу кирәк утның үткеленнән... *Шигырьләр*. *(Якутчадан Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре)*. ....129


ЯҢА ИСЕМНӘР


Айгөл АБДРАХМАНОВА. Син – каһвә. *Хикәя*. ....132

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....136

*Фотоархив*: Газинур Морат тормышыннан мизгелләр. ....138


«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ


Зиннур ХӨСНИЯР. Доктор Байчурин. *Хикәя*. ....140
Нурания ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА. Йөрәкнең дүрт кылы. *Хикәя*. ....148


«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ


Рәдиф СӘГЪДИ. Мәгарә. ....156


БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ


Шаһинур МОСТАФИН. Янып яшәлгән гомер. ....160


ТАРИХ


Булат ХӘМИДУЛЛИН. Алтын Урда цивилизациясе һәм аның мирасы. ....173


СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ


Замандашлары Сәгыйть Сүнчәләй турында *(Зөфәр Рәмиевнең кереш сүзе белән)*. ....179


ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ


Йолдыз МИҢНУЛЛИНА. Чана юлы – ком. Кытыршы... *Шигырь*. ....184
Фотоархив: Фәрваз Миңнуллин тормышыннан мизгелләр. ....185

*Музейларыбыз*: Айзилә САБИРОВА. Туфан Миңнуллин музее. ....186

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Газинур МОРАТ әзерләде*. ....187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
(«Огни Казани»)
№ 8 (1162) 2019

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (өлкән бухгалтер).
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.07.2019, график буенча 31.07.2019, басылып чыгу вакыты 9.08.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2092. Тираж 4390.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Газинур
Морат

# SMSТАН ЮЛЛАНМАГАН ЮЛЛАР

## Туйра

Зилзиләләр изеп узсалар да,
Туйра сыман басыйк тураеп...
Тукай бездән ерагайган саен,
Якыная барсын Тукайлык.

## 2019 ел, 16 гыйнвар

Карадан да кара чорларда да
Якты эзләр кала сызылып...
Кара урманны да кичәрбез күк,
Илһам моңнарына сыгынып.

## Җыру әйтү

Җыручы җыру әйткәндә,
Сәхнәләрдә томандыр.
Гел заманча кылансак та,
Асылыбыз моңдадыр.

## Сүз тәме

Сүзләрнең дә үз гамьнәре була,
Үз тәмнәре – ачы, татлысы.
Иң татлысы – Ирек...
Ә ачысы?
Ә ачысын безгә татыйсы.

---

Газинур МОРАТ (1959) – *шагыйрь, публицист; «Төнге әверелеш», «Кош хокукы», «Ике икең биш була» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Бәлки әле...

Байлар тарих яза.
Дөнья, әйдә,
Алардан да бераз сабак алсын.
Бәлки әле, байгуралары да
Түргә элми башлар чабатасын.

## Сөйләк

Хаксыз илдә хак тарих та
Әверелә сөйләккә.
Бу дөньяда яшәп була
Гел дә ялган сөйләп тә.

## Кумирлар шәһәре

Табынучылар юк монда –
Һәркем идол, асылда...
«Йолдыз»лар чират торалар
Космопорт кассасында.

## Җилән

Әлләкемлек килешмидер,
Таҗ торса да башында.
Без – Тукайның җиләненнән
Чыккан кавем, асылда.

## Ура-патриот

Үтереп мактый ул илен,
Әллә белми чаманы,
Әллә илен базарда ук
Сатаргамы чамалый?

## Nurieff

Үз илендә мөртәт булды,
Дөнья итте тантана.
Хак Үзе канат куйгандыр
Оча торган татарга.

## Уен

Яшәүләре – уен гына, дигәч,
Сабыйланып, йөрдек уйнап та.
Балачагы белән җитәкләшеп
Бара кеше гомер буйлата.

## Төш вә өн

Төшләнәм дә бугай, – картаела.
Түнеп барам, ахры, төнемә...
Ни йөзләрең белән китмәк кирәк,
Син гүзәлне күр дә өнеңдә?!

## Бердәмлек көне

Кыршаулы калебкә
Җиһан
Бер тулпарлык арандыр.
Ирекле халыклар гына
Бердәм була аладыр.

## Татарча язу

Яугир ирләр тарих яза –
Дәүләт кора. Төзи кала.
Әтрәк-әләм әләк яза –
Хәрабәләр
аунап
кала...

## Янәшәлек

Һәрбер чатта ир яманлап
Яшәгән хатыннар бар.
Һәрбер чорда патша мактап
Яшьнәгән акыннар бар.

## Кышка керү

И аппагым, йөрәгемә
Өр дә кайнар тыныңны,
Таң калып бер тыңлыйк әле
Кышкы аклык тынлыгын.

## Өлгерү

Гомерләр көзгә авышкач,
Моңая игеннәр дә.
Без бер башка исәябез,
Башаклар иелгәндә.

## Эпитафия

Фәрештәнең канат җиле
Тыныңа капты мәллә?
Үлемсезлек каян килсен,
Фани булмаса бәндә...

## Яңа ел

Иске елны кире әйләндереп
Кигәч, булдык янә өр-яңа.
Кызык эзләп яшәү үзе кызык
Бу кызыгы качкан дөньяда.

## Көпчәк мәсьәләсе

Тирмәсеннән чыгып кичә генә,
Имла таный башлап көчкә генә,
Тәгәрмәчне уйлап тапкан кавем
Патент даулар Тарих көпчәгенә.

## Шаян ТВ

Дәүләт агайлары дулашканда,
Безнең мәсләк, ахры, бер генә:
Шаярсак та, җитди карый белик
Газиз әнкәйләрнең теленә.

## Фәнис Яруллин

Җилкәннәрне җилләр сынаса да,
Кешеләрне сыный зилзиләләр.
Фанида да сират кичкән шагыйрь
Исәпләнә булыр изгеләрдән.

## Язны көтү

Безнең Чал Инеш тә инде
Төш күрәдер яз турында, –
Авыр сулап ята сулар
Кышкы тынлык хозурында.

## Песнәк

Ул да оча...
Бәлки, җылыда да
Кышлый алыр иде кышларны.
Куеныңа алып җылыт, аклык,
Туган җиргә тугры кошкайны.

## Талант

Кешечә телне белмәсәң,
Эт кебек өреп була.
Талантны да түбенәчә
Эчеп бетереп була.

## Иске җыру

Күке килеп корып бирмәс
Ала карга оясын...
Өч татар дүрт фирка төзеп,
Ду китерә дөньясын.

## Сәхнә

Зурлыгы да, хурлыгы да монда
Гел үтәли тора күренеп.
Сәхнә – ахак кискә-бүкәне дә,
Бәллүр тәхете дә күңелнең.

## Тулган ай күк...

Күңелдә, мәтәлчек атып,
И кинәнә бер бала.
Гомер генә, тулган ай күк,
Түгәрәкләнә бара.

## Питрау

Әллә сайрар кошларның да
Сыза микән илһамы, –
Дөнья дәррәү тынып калган –
Сәер мәле җиһанның.

## Үз туксаның...

Йөзгә төрләнгән илдә
Үз
Туксаның булсын туксан.
Халыкның игез улыдыр
Әлмәндәр белән Туфан.

## Вәгазь

Акландык та, вакландык та,
Тапландык та һәм... тандык.
Инде пакьләнсәк тә ярый,
Җанны аятькә манып.

## Бал корты

Бер тамчы дегет тә җитә
Туздырырга оябызны.
Ә без бераз балландырыйк
Гел ачыган дөньягызны.



Фирүзә
Җамалетдинова

# ГАЛӘМ ГӨЛЕ ТАШНЫ ЯРГАН...

ПОВЕСТЬ

Алар өчәүләп бер җан иясенең әҗәлен көтәләр. Икесе – хатын-кыз, берсе – ир кеше. Газраилнең шулай озаклавына эчләре поша, билгесезлек эчке кичерешләрен кыл урталай бүлә: борчулары әле йөзләренә бәреп чыга, әле өмет аша тынычлык иңгәндәй була. Минутлар еллардай озак үтә. Кайчакта вакыт бөтенләй туктап калгандыр күк тоела. Сәгатькә күз салалар да уфтанып куялар, яктылык шәйләнә генә башлаган тәрәзәгә караш ташлаган саен тагын да яманрак пошыналар...

Ходай Тәгалә аларның һәммәсенә гомер биргән. Бер гомер! Аны һәр өчесенең дә ахыргача яшисе килә. Юк, юк, азагы хакында бүгенгә берсенең дә уйларга теләге юк. Һәрнәрсәнең ахыры булган кебек гомер дә чикле. Моны белмиме алар? Беләләр. Тик яшәү һаман ымсындыра! Шуңа ерак юллар үтеп, чит-ят шәһәрнең аулак почмагындагы бу шомлы бинаны эзләп тапканнардыр да...

Яшисе килүдән Рәйханиянең тәннәре тартыша. Кан басымы күтәрелә. Иртә таңнан кызарган күзләре тәрәзәдән энә очы кадәрле яктылык эзли. Көткәндә таңы да озак ата шул... Төне дә нигәдер дөм караңгы булды. Әле генә тышта тонык зәңгәрлек шәйләнә башлады. Якты күк йөзендә кара болытлар сарылып-сарылып йөзделәр. Чиксез биеклектә гүя кара түшәм хасил булган иде...

Өч җан иясе бер-берсенең күзләренә карашып алалар да сүзсез генә аңлашалар кебек. Аннан өчесе дә янә газаплы тынлыкка чумалар. Анда – эчтә кемдер әҗәл белән тартыша. Алар өчәүләп аның үлгәнен көтәләр...

– Сез кайсы яклардан? – дип сорый Рәйхания пышылдап кына янындагы чандыр хатыннан.

– Бөгелмәдән. Үзегез?

– Чаллыдан.

Ир-ат сүзгә кушылмый. Ап-ак чыраен көрәктәй куллары белән уып-уып җибәрә, шулай борчуыннан арынырга теләгәндәй, тыштан тыныч кыяфәт чыгарып, тын гына утыра бирә.

Рәйхания урыныннан кузгалып, тәрәзә янына барып басты. Анда тәрәзә пыяласына кагылып, канатларын ипле генә җилпеп, бер кош очып үтте.

«Ходай кошка да туйганчы очар гомер биргән!» – дип уйлады хатын. Кош тонык зәңгәрлеккә кереп югалганчы, ул аның артыннан томырылып карап калды.

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА (1960) – *шагыйрә, прозаик; «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Ничек бәхетле ул кош!.. Сәламәттер, мөгаен. Көне караңгы, дип тә тормый, һаман биеклеккә тартыла.

Аннан күзе хастаханә каршындагы асфальт юлга төште. Анда таң һәм дә тәрәзәдән сирпелгән сүрән ут яктысында ташны тишеп чыккан космея чәчәге күзенә чалынды. Һәм хатынга бераз җиңел булып китте. Тырышканда яшәргә дә мөмкиндер, бәлки, дип уйлады.

– Космея – галәм гөле, – дип пышылдады хатын, аңа тәрәзә аша күз нурларын түгеп. – Ташны кыл урталай ярган түгелме?

Коридорда яшь кенә шәфкать туташы күренде. Әйтерсең, канатлы фәрештә иде ул. Карашлар аңа төбәлде. Ашыгып килгән җиреннән кыз туктап калды, өч кеше утырган эскәмиягә борылып төбәлеп торды да ары китеп басты.

– Ул исәнме? – дип сорады карашлар. Шәфкать туташы җавап бирмәде. Алар өчәүләп бер-берсенең күзләренә карашып алдылар. Дәшүче булмады.

Эш сүзләрдән узган инде. Алар өчесе дә тормышның иң нечкә, менә өзеләм, менә өзеләм дип торган тотрыксыз җебенә эләгеп торалар һәм... берәүнең әҗәлен көтәләр иде.

– Их, үлмәсен иде бу кеше! – дип куйды Рәйхания. – Аның да яшисе киләдер бит... Кемнеңдер баласы лабаса ул да.

– Хода бәндәләре үлемгә хөкем ителгән шул... Җан чыкканда, яшәү турында уйламыйлардыр... Менә безгә кирәгрәк, ахрысы, яшәү дигәне, чөнки без бу хакта әле фикерли алабыз... Әлегә...

– Әлегә... – дип кушылды Рәйхания хатынга.

Бу сүзләрне әйткәндә, тавышы гына түгел, уйлары калтыранып куйды.

Хатын моны сизептерме, моңсу елмайды.

– Борчылмаска иде ничек тә, борчылып кына берни дә кылалмабыз бит инде хәзер, – диде. – Буласы булган...

Аннан төбәлеп:

– Сез эшли аласызмы соң? – дип сорады. Рәйханиягә кыен булып китте. Үзеңнең эшкә дә яраксыз икәнлегеңне җиде ятларга да фаш итеп тор инде менәтерәк...

– Юк. Хастаханәдә үтте соңгы айларым, – дип артык басым ясамыйча, теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды ул.

– Ә үзегез?

– Эштән бер көн дә туктамадым. Операцияләр вакытында гына бераз бүленергә туры килде... Башыңа төшкәч, башмакчыга әверелмичә хәлең юк икән шул, – дип тирән көрсенде янәшәсендәге хатын.

Ул моңсу карашларын бер ноктага кадап, сүзсез торды да янә дәвам итте:

– Мин үзем ятим үстем. Әле үсмер энем дә янымда. Күз-колак кирәк. Әниебез үлгәндә, аңа биш яшь кенә иде. Үземне кайгыртып, баланы ташласам, мәрхүмә әнкәй рәнҗер, дип курыктым. Авыр кичердек әнкәйнең үлемен. Энем көн-төн елады. Хәер, һаман да тавышы ишетелмиме дип, сузылып ятып, җирне тыңлап йөри. Аны оныткандыр да инде ул, авыр кичерешләре, бәлки шулай гадәткә әверелеп киткәндер. Каберенә төшергәч тә, бер уч туфракны картлар башта энемнән салдырганнар иде...

Тек-тек басып килгән аяк тавышлары игътибарны үзенә җәлеп иттеме, кинәт тын калдылар.

– Ә сез теге үлеп ятучының кем икәнен белмисезме? Ир-ат микән ул, хатын-кызмы? – Рәйхания кулындагы кәгазьләрен актара-актара килүче шәфкать туташыннан шулай сорап куйды.

– Ир-егет. Авариядән соң китерделәр, – диде шәфкать туташы һәм кирәкле кәгазен табып алганга сөенгәндәй, каршыдагы бүлмәгә кереп китте.

Хатыннар янә авыр сулады. Ир-ат та уфтанды.

– Үлмәсен иде ул, ә? – дип сораулы карашын хатынга текәде Рәйхания.

– Анысы Ходай кулында. Мин дә шулай телим. Тик өчебез дә аның тизрәк күз йомганын көтәбез түгелме?.. – Ул үз сүзләреннән курыккандай калтыранып куйды. – И Ходаем, балалары бардыр... Хатыны... Бәлки әнисе дә исәндер... Ничек күтәрерләр бу хәсрәтне? Йа Аллам...

Рәйханиянең хатынга кушылып бик күп сүзләр әйтәсе килде. Кеше хәсрәтләре эченнән, Әҗәл тырнагы арасыннан бәхет тә, сәламәтлек тә табып булмаячак, дип уйлавын сиздерергә теләде.

– Әйе, өчебез дә аның үлемен көтәбез шул... – дип пошынды хатын янә. – Монысы чынбарлык. Кайсыбызның бәхете җиңәр, түлке. Эчтән генә һәммәбездә дә бер өмет яна. Шул өмет китерде бит инде безне монда.

Әлегәчә бер сүз дәшми утырган ир кинәт җанланып:

– Яшисе килә шул, шайтан алгыры! – дип куйды. Үзе һаман көрәктәй куллары белән битләрен сыпырды. Күзләренә үк төшеп торган кепкасын өскәрәк күтәрә төште.

«Яшисе килә!» – дип кабатлады Рәйхания дә эчтән генә. Гүя ул янындагы хатынның да: «Яшисе килә!» – дигәнен ишетте.

Аларның барысының да яшисе килә иде. Шуңа өчәүләп берәүнең әҗәлен көтәләр иде...

Киеренке тынлыкта киндердәй ак йөзләре тартышып алгандай булды. Бу халәттән ничектер качарга кирәк иде.

– Сез кайда эшлисез соң? – дип сорады Рәйхания сиздерми генә янына шуыша барган хатыннан.

– Үз эшемне ачтым мин. Эшмәкәр. Башмаклар сатам. Күз алдына да китермәссез ничекләр чабып йөргәнемне! Бөерләрем юклыгын бөтенләй онытkan кеше кебекмен... Көн аша больниска шуларны юдырырга да йөрисе булмаса, уйлап та карамас идем әле, биш эшне берьюлы ачар идем... Бер дә начарны уйламаска тырышам. Сөйләгән сүзләр, уйлаган уйлар ДНК молекулаларында язылып бара, ди. Физиклар раслаган. Нәселеңә зыяны төшәргә мөмкин икән. Ә яхшының начары булмый аның.

Ул шешенгән аякларына карап елмаеп куйды. Аннан:

– Сез дә шулай бу хакта уйламаска тырышыгыз. Яшәп бетерергә кирәк тыныч кына, барыбер бер үләсе ич. Үлемнең нәрсәсеннән куркасың соң аның?.. – диде. – Әнә, яшәп бетермичә дә үләләр бит әле... Авария, диме? Соңгы сулышын аласын белсә, юлга чыгар идеме, бичаракаем?

Килешкәнлекләрен белгертеп, бердәм баш чайкап куйдылар.

– Үлемнән куркам шул. Минем яшисем килә. Балаларым бар бит, – диде Рәйхания кыенсынып кына. Тәнемне чир басканнан бирле, бәбекәйләремне ана назына туендыра алганым юк. Тормыш та күбрәк үз өсләрендә. Һаман мине кызганалар, яшәвемне телиләр. Ятимлектән котлары оча, белсәң...

– Ирегез бармы соң?

– Бар. Ул да борчыла. Еш кына эчеп тә кайта. Синең кайгыдан эчәм, ди.

Хатын эчке иңрәвен сиздермәскә тырышып тирән итеп сулады. Аннан:

– Минеке дә шулай башлады... аннан ташлап китте. Башкага өйләнде. Яшь, чибәр кәләш тапты. Ирләргә авыру хатын кирәкми. Чирле хатынга түгел, авыру балага да түзә алмый аларның күпчелеге. Минем дә балаларым икәү. Бәләкәйләр әле... Шулай һәр якты иртәне, кояшны күрүем өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт укып яшәп яткан көнем менә, – дип авыр язмышының почмагын күрсәтеп алды.

Икесе дә беравык сүзсез тордылар. Һәр икесе дә үзенекен уйлады. Икесенең

дә күзләрендә мәхәббәт һәм нәфрәт очкыннары кабынып киткәндәй булды. Алар бу мизгелдә берәүнең әҗәлен көтеп утыруларын да онытып җибәрделәр кебек...

– Кичердегезме сез аны?

– Кемне? – дип гаҗәпләнеп сорап куйды хатын.

– Иregезне...

– Үч алалмагач, кичерергә кирәк. Һәркемнең гомере бер генә. Ул да аны үзе теләгәнчә яшәргә хаклы бит. Авыру хатын өстенә карап газапланырга тиеш дип кайда язылган? Аннан, каенанам да кешеләргә: «Авыру хатын белән нишләсен инде ул?» – дигән. Яман сүзне тиз ишеттерәләр.

Дөрес әйтәм микән, дигәндәй, ул үз сүзләреннән үзе шикләнеп, күз чите белән генә Рәйханиягә карап куйды. Бу сөйләшү Рәйханиянең дә йөрәк җәрәхәтен яңарткандай булды. Күз алдында котсыз исем йөрде, азгын шәүлә буталды. Ул гаҗәпләнү аша катгый җавабын җиткерде:

– Кайда, дисезме? Күңел дәфтәренең намус дигән битендә. Ә балалар? Аныкы түгел мәллә?

– Аларны ач та, ялангач та итмәдем. Яшим бит әле мин, үлмәгән. Энем дә буй җитеп килә. Бер-бер хәл була калса, ташламас, Алла боерса. – Хатын көрсенүле тавышын басарга теләп: – Аны Аллаһы Тәгалә кичермәдеме икән әллә, дип тә уйлыйм инде... Машинасы белән баганага барып кергән. Хәзер әнисе карый, инвалид коляскасында утыра... – дип әңгәмәгә һәркем тоярдай тирән газаплы тавыш белән йомгак ясады.

Һәм өстәде:

– Сез яшь бит әле. Бик күркәм күренәсез. Яшәргә тырышырга кирәк...

– Күркем бар да, бүркем юк дигәндәй, яшьлеге бар да соң аның, сәламәтлеге юк... – дип тирән пошынды Рәйхания.

Шул мәлдә коридорга шәфкать туташы килеп чыкты. Ул ашыга-ашыга тезелешеп утырган өчәүгә күз йөгертеп алды да, нидер оныткандай, беркавым уйланып торды.

– Хафизова, – дип эндәште аннан. – Йә, кайсыгыз Хафизова сезнең?

Рәйхания торып басты.

– Әйдәгез минем белән. Хәзер тагын бер анализ бирәсегез бар. Үлеп ятучы белән сезнең кан тәңгәллеген тикшерергә кирәк, – диде шәфкать туташы һәм үзе килгән якка борылып, эре-эре алдырып китеп барды.

Рәйхания урыныннан торып баскан көе катып калды. Тез буыннары калтыранды, теле кипкәнне тойды. Ян-ягындагы юлдашларына төбәлде. Икесенең дә табигый халәте үзгәргән: көнләшүдән туган салкын хисләр аларның төсләренә бәреп чыккан иде. Шуңа ул күзләрен челт-челт йомгалап тик карангалап торды, бер сүз дә әйтә алмады. Башында: «Менә бит без кешеләр ничек! Беребез өлешенә беребез кергән кебек кыланабыз...» – дигән уй калыкты. Кайчакта берсен-берсе сүзсез тоя торган кешеләр дә гомерләре бизмәнгә салынган мәлдә аңлашу җаен таба алмыйлардыр, мөгаен. Әйтерсең, палата эчендәге кеше нәкъ менә Рәйхания өчен үлеп ята. Әйтерсең, башка беркемгә дә түгел, гомерен һәм дә бөерен аңа гына бүләк итеп калдыра...

Нишләтәсең, кайгы-хәсрәтнең дә, шатлык-куанычның да йөзгә чыкканын белә иде ул. Ә көнләшү хисләрен йөздән укып булуына исә әйтсәләр дә, ышанмас иде. Югыйсә, бөерне кулга тоттың да китеп бардың түгел, операция өстәлендә наркоздан айнымаган затлар күпме?! Аллам сакласын...

Хатын инде бу бозлы карашлардан сискәнеп, ник килгәненә үкенә дә башлаган иде. Алданрак белсәң, янәшәңдә генә берәүнең үлеп ятуы хакында ишетмәс өчен дә килмәссеңдер төсле тоелды.

– Ул үлдеме әллә? – дип сораганын сизми дә калды Рәйхания.

– Без ул үлмәсен өчен бик тырышабыз. Иң дәрәҗәле табибларыбыз аның янында. Тик дөнья хәлен белеп булмый... Аллаһ язганнан узу безнең кулдан килми. Аптырамагыз, бары тик алдан хәстәрлек күрүебез инде. Аннан анализларыгызны да алдан әзерләргә кирәк.

– Яшәсен иде, – диде Рәйхания сызланып. Үзе, шәфкать туташы артыннан калышмаска тырышып, аягының калтыравын җиңеп, кызу-кызу атлады, куркудан адымнарын саташтырды, хәлсезлектән чайкалып-чайкалып китте.

– Әйтеп торам бит анысы Ходай кулында, дип...

Шәфкать туташы аңа яратып борылып карады:

– Бер белмәгән кешене кызганасызмы әллә? – дип сорады.

Рәйхания башмаклары чыштырдавын басар-басмас тавыш белән җавап кайтарды:

– Кызганам дию генә аз, үзәгем өзелә. Әнисе, балалары күз алдыма килә. Сез кызганмыйсыз мәллә?

Шәфкать туташының тавышы аермачык ишетелде:

– Гомеребез тоташ кызганыч хәлләр эчендә шул. Ярдәм итә алсак, моннан да зур бәхет юктыр безнең өчен.

Рәйхания аның матур күзләрендә өмет чаткылары чагылуын күрде. Күңеленнән «...ярдәм итә алсак...» дип кабатлавын белде. Ачык йөзләре, тәмле телләре белән дә дәвалыйлар, дип белми әйтмиләрдер алар хакында. Күпме кешенең күзен ача бу табиблар. «Байлык бер айлык, сәламәтлек зур байлык» икәнне монда эләкми торып төшенгән затлар бар микән?

Сәламәт кешеләр арасында эшләүчеләрнең адәм башына төшкән мондый хәлләрне ишеткәннәре дә юктыр. Бу ак халатлылар... юк, юк, күк катыннан төшкән фәрештәләрдер болар... Ак канатлы фәрештәләр...

– Туганнарыгыз арасында сезгә ярдәм итәргә теләүче табылмадымы? –дип сорап куйды шәфкать туташы сүзне икенче юнәлешкә борып. – Гадәттә, бер-берсенә кандаш туганнар ярдәм итә. Йә аталар – улларына, аналар кызларына бирә, диимме...

Рәйхания кемнәндер бөер алып буласын әлегәчә башына да китермәде, шуңа ул «юк» дигәнне белгертеп баш селкеде. Аннан:

– Әтием дә, әнием дә вафат шул инде, – дип куйды.

***

Рәйхания нидән шулай чирләп китүен һич аңлый алмады. Әби-бабалары авылның озын гомерлеләре исемлегендә иде. Йөзгә җитәр-җитмәс дөнья куйдылар. Әбисе, мәрхүмә: «Сиксәндә сиксән аз гомер шикелле күренде, инде туксанга җиткәч, анысы бөтенләй дә яшәмәгән кебек тоела башлады», – дип пошынып-пошынып куяр иде. Әти-әнисе дә, Аллага шөкер, яшәмәделәр түгел. Туганнары да сау-сәламәт. Нәсел ныклыгы аңа җиткәч, кыелып кына төште нигәдер. Бозымнан диючеләр дә аз түгел. Шайтани затлар тарафыннан җил искәнен чамаласа да, монысын Аллаһы үзе генә белә... «И Ходаем! Бу җәзаң миңа ни гөнаһларым өчен икән соң?» дип төн кичкән чаклары да ешайды. Хәер, кай яклап карасаң да, чир аңардан көчлерәк булып чыкты. Ак йөзен сары алды. Бу чирнең ип-исән кешеләрдә кинәт кенә нидән, ни сәбәпле килеп чыгуы да бер Аллаһыга гына мәгълүм. Табиблар да аптырашта. Үз вазифасын сәгать кебек төгәл үтәп торган бөер, кинәт, корыган көзге яфрактай кибеп бетсен инде!..

Шулай да дәвалану язмыштан килә, Аллаһы Тәгаләдән ризалык иңсә, шифасы

һичшиксез тиячәк, диләр. Еш кына кеше җиңүләр, җиңелүләр турында башына да китерми. Алышка чыкмаган ла инде ул. Барыбер кискән агач күк егып кына салды чир Рәйханияне. Бүрәнәдәй шешкән аякларын күреп югалып калды. Авыл медпунктында диспансеризация узганда, табиблар әйткәнгә бик игътибар итмәскә тырышты. Тора-бара хәлсезлек басты, берөзлексез кан басымы күтәрелүгә аптырап, хастаханәгә китте. Аны Камал Абрамович дигән өлкән яшьтәге табибка беркеттеләр. «Табибның өлкәне, адвокатның яше яхшырак», дип үзалдына куанып куйды ул. Анализлар бирергә куштылар. Шунда ул коточкыч хәбәр ишетте: үзенең гарипләр исемлегенә теркәләчәген белде. Болай гына да түгел, аллы-артлы операцияләр көтә булып чыкты.

Камал Абрамович бик ачык сөйләште. Әле күп тапкырлар очрашырга туры киләчәген искәртеп куйды. «Авырулар төрле була, күбесе үтеп китә, эзе дә калмый хәтта. Ә сездәгесе – гомерлек сынау. Беркайчан да, берничек тә үтмәячәк», – дип хатынның күңеленә шөбһә салырга да өлгерде. Үзенең яртылаш татар баласы икәнен дә искә төшереп алды. Әтисе яһүд, ди. Тик яһүдләрдә милләтне ана ягы билгели, ана кайсы халыкныкы булса, бала да шуларныкы, ди. Камал Абрамович моның белән горурлана да шикелле: аның әнисе бик эшлекле, тәҗрибәле табибә булган. Ул әнкәсенең юлын дәвам итүче, аның тормышка ашыра алмаган хыялларын чынбарлыкка ялгаучы, һәм улын да ак халатлылар сафларын ишәйтүгә, игелекле һөнәргә әзерләүче бик кызыклы шәхес икән. Рәйхания боларын колак чите белән генә тыңлады. Бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты, дияргә дә мөмкиндер. Ә менә гомерлек гемодиализга берегеп яшәргә туры киләчәген белү аңа коточкыч авыр тәэсир итте.

– Нәрсә соң ул гемодиализ? – дип, бик җитдигә санамыйча гына сорашасы иткән иде дә... Табиб аңа ярым фәнни, ярым китап телендә аңлаткач, коты очты. Ничек диде әле ул? Болай диде Камал Абрамович:

– Узган гасырда бөерләрдән башка гына канны агулы матдәләрдән чистарту юлын уйлап тапканнар. Өмете өзелгән авыруларны да бу методика ярдәмендә яшәтеп, саклап калып була...

– Ничек? – дип сорап куйганын сизми дә калды Рәйхания. Табибның калын күзлек пыяласы тирләп киткәндәй тоелды, үзе исә тагын да катлаулырак итеп аңлатуга күчте. Рәйхания дә барыбер берәр нәрсә төшенми калмам әле дип, игътибар белән тыңлавын белде.

– Авыруның кан плазмасы һәм дә натрий тозы, калий, магнийдан торган препаратлар аша сыгылмалы, үткәрүчән өслек кулланабыз без. Тишекләре үлчәменә карап, ул теләсә кайсы молекуланы үткәрә яисә тотып кала ала. Кан шунда чистартыла һәм авыруның тәненә шул ук система белән яңадан кертелә.

– Бик җайсыз икән, – дип сүз кушкандай булды Рәйхания мондый хәлне бөтенләй дә күз алдына китерә алмыйча.

– Әйе, җайсызлыгы җитәрлек, – дип дәвам итте Камал Абрамович, юка гәүдәсен җыера төшеп. – Без – табиблар, бу эшкә башкача һичбер чара калмаганда гына алынабыз. Чөнки авыруга әлеге халәткә ияләшүе дә җиңелдән түгел. Сау-сәламәт кеше булып җир өстендә йөгереп йөр дә кинәт гомереңне ниндидер аппаратка бәйлә имеш... Икенчедән ашау-эчү мәсьәләсендә чикләүләр күп. Күтәрергә-төшерергә ярамый. Өеңнән, үз клиникаңнан еракка китә алмыйсың, башка шәһәргә барасың икән, түләргә кирәк...

– Җитәр, әлегә калганнарын сөйләми торыгыз, башкача хәл итеп булмасмы... – дип, өметенә ышанып әйтте Рәйхания.

– Белмим шул, донор табу мөмкин хәл түгел диярлек... Сез, мөгаен, шуңа

ышанасыздыр... – Табиб башындагы ак чепчигын рәтли-рәтли чал кашларын күтәреп сөзеп карады да карашларын идәнгә күчерде.

– Әйе, ышанам...

– Ышанырга кирәк, әлбәттә...

Гаҗәп тыныч холыклы, мөлаемлыгы бөтен йөзенә чыккан табибның болай җылы сөйләшүе Рәйханиянең күңеленә сизелер-сизелмәс өмет чаткысы салды. Мондый да киң күңелле табиблар булганда, үлми калырга да мөмкиндер, шәт, дип уйлады.

Ул хастаханә ишеген япканда, ни тере, ни үле түгел иде. Автобустан авыл башына җиткәнче үк төшеп калды. Офыкларга тоташкан озын юл буйлап әле атлады, әле йөгерде. Борылып, арыш басуына кереп китте. Күкчәчәкләрне битенә куя-куя иснәде. Алардан балачак исе, кайчандыр Фоаты үзенекенме, этисенекенме эләктереп, бүләк иткән ачкылтым «Шипр» исе килә, әйтерсең лә бөтен басуга хушбуй сипкәннәр иде. Аларның нәни сырлы таҗларына иреннәрен тигезде. Күңеле тулды... Йомшак җылы җил, үз көенә генә исә-исә, аның яңаклары буйлап тәгәрәгән күз яшьләренең эзләрен киптерде... Күз яшьләреннән дә гүя үтеп баручы җәй сагышы тама, күкчәчәкләр шуның шаһитлары иде...

Үзе дә сизмәстән, күккә күтәрелеп карады: анда алтын кояш яна. Нурлары күз яшьләрен киптерерлек. Тик карашлары янә җиргә текәлде. Рәйхания үз-үзенә боерды:

– Йә, күтәр әле башыңны! Тау башында туган кыз бит син! Кая китте соң әле таулар горурлыгың? Син бит аларга үзәнлеккә төшкән саен башыңны югары күтәреп төбәлеп тора идең. Соклана идең. Тирә-юньдә тау башында утырган авыллар башка юк та иде ләбаса. Шуңа ул авылны Тау оясы дип атаганнардыр да.

Рәйханияләрнең өй артыннан төшеп киткәч тә, колхоз басулары башлана. Шунда ел да борчак чәчәләр иде. Кузакларның тулышып өлгергән чорында этиләре арбага салып кочагы белән капка төпләренә кайтарып бушатыр иде аны. Фоат килеп җиткәч, яшел кузакларны ярып, борчак ашый-ашый кич утырган чаклары аеруча күңелле. Ул кузакларга ияреп күкчәчәк, тукранбаш, киндер, башкалары да кайтыр иде. И исләре шуларның! Хатын борын тишекләрен киереп иснәп куйды. Каяндыр больница исе килеп бәрелгәндәй булды, күзләреннән яшь сытылып чыкты.

– Син биргән «Шипр»дан тәмлерәк болар, – дип шаяртты Рәйхания бер тапкыр.

Фоатының битләре кызарып чыкты:

– Балачакны һаман искә төшермә инде, – дип куйды ул җилкәләрен җыера төшеп. – Менә, иснә, яраткач, бер олау ич тукранбашлар, – дип кызның борынына бер уч печәнне якын ук китерде дә иңнәреннән кочып алды. Рәйхания кыенсынып кына аңа тартылды. Иң татлы мизгелләр шушы түгел микән? Ул бу хисләр мәңгелек дип уйлаган иде дә... Баксаң, хәтер генә мәңгелек икән... Дөрес, ул ишеткәннәрен иренә һич кенә дә сиздерми. Озын теллеләрнең сүзен җил урласын берүк... Имеш Фоаты ул хастаханәгә кереп яткач, йомры Серафима янына барган... Имеш төн кунарга өйгә дә кайтмаган... Тукта, Сима кайгысымы аңарда? Кеше хәсрәте белән яшәр чагы түгел. Үз хәле хәл. Кирәкмәгәнне күп уйласаң, бөгелеп кенә төшәрсең... Сәламәт чагы түгел лә...

Хатын яман уйларыннан арынырга теләгәндәй, күкчәчәкләр төшкән кулъяулыгын алып күзләрен авырттыра-авырттыра сөртте. Тик уйлар аны ычкындырырга җыенмый иде кебек. Үтми торган күңел җәрәхәтләре дә, үтми торган авырулар да була икән шул. Моннан соң беркайчан да күкчәчәкләрнең баллы, чиста, саф исләрен исни алмаячакмы инде ул? Әнә бит, елы да ничек килде: июль-август буена яуган тоташ яңгырлар бал кортларын да хафага салды. Бер килограмм бал җыю өчен өч йөз чакрым ара үткән нечкәбилләрне дә санламый

бу кеше дигәнең. Чөнки басу-кырларга эләккән агу, ашламалар сәбәпче, ди быелгы бал юклыкка. Ояларына очып кайтып җитә алмаганнары да бик күп, ди бит бахырларның. Әллә чиргә дә шул агулар юл ачып җибәрде микән? Моннан соң аның бар дөньясын дару, хастаханә исе басачакмы инде?.. Дару исе... Ничек яратмый ул бу исне... Чөнки аның яшисе килә! Мәхәббәте хакына яшисе килә иде...

***

Шифаханәдән кайткач, ул сер яшереп тормады. Хәленең бик үк хәерле түгеллеген бөтен авыл ишетте. Бөтенесе ул көнне үз өендә яңалык итеп чарасыз бер үк җөмләне кабатлады: «Рәйханиягә бөер кирәк икән!»

Тик кайлардан аласы соң аны? Бөтен әйбер сатыла, дип яшәгән көннәрдә һичберкайдан юнәтеп булмый торган хаҗәтләр дә чыгып куя икән бу тормышта.

Авылдашлар, тирә-күршеләр бер-бер артлы хәл белергә килде. Чәй табыны янында һаман бер үк сүзләр сөйләнде:

– Алып кына бирә торган әйбер булса, кем кызганыр иде икән, ә...

Әлбәттә, өендә балалары да, ире дә юатырга тырышты. Теләсә нинди хәлдән чыгу юлы барыбер була ул, диделәр. Берәр чара табылмый калмас әле, диделәр.

Ире исә үз бөерен бирергә ризалашты. Ничек җанын җәрәхәтләсә дә, яратуы хак икәнне белә иде Рәйхания, бу хәбәрне Фоатның үз авызыннан ишеткәч, күңеле тәмам йомшады.

– Сыңар күз белән яшәп буламы? Була. Сыңар колак белән? Алай да була. Димәк, зарар юк. Аллаһ бит безне дә парлы итеп яраткан. Тик синнән башка миңа тормыш юк, аппагым, – диде ул. Әлбәттә, кызмача иде. Борчуы җаныннан ташый иде. Барыбер иренең кайгыртучан тавышы күңелен күтәреп җибәргәндәй тоелды:

– Безгә дә бер кояш чыгар әле, матурым, – дип кабатлады ул.

Шулай да алар иртән иртүк торып, дәваханәгә барырга килештеләр. Кан анализлары туры килеп куйса, белмәссең, дип сөенде Рәйхания. Нигә туры килмәсен икән? Алар бер-берсен бала чактан ук күреп алдылар лабаса. Бер-берсенә шул бер күрүдә тартылдылар. Нәни кызчык әбисенә ияреп, ниндидер йомыш белән кергән иде Фоатлар өенә. Шул көздә алар мәктәпкә, беренчегә укырга бардылар. Икесе ике сыйныфка эләгүдән ул көнне мәктәптән кәефләре төшеп, борчылып кайттылар. Тик дәрес беткән саен тәнәфес дигән нәрсә була икән. Алар моның өчен олы җиз кыңгыраугa күңел түрләрендә рәхмәт хисләрен саклап йөрттеләр. Тәнәфестә Фоат исемле малайның сиздерми генә бантигыннан тартып үтеп китүе дә җанына никадәрле рәхәтлек тутыра, иңнәренә канатлар үскәндәй тоела иде. Юк, юк, сүз сөйләшергә икесе дә ояла иде әле ул чакта. Шуңа да арадашчы-бантикларны ул алыштырып кына торды. Димәк, күзе минем бантикларга төшә икән, дип уйлады. Апасы район үзәгенә барган саен аңардан:

– Йә, сеңлем, бу юлысы ни алып кайтыйм үзеңә? – дип сорый иде.

– Чәчүргеч-бантик, – дип куя иде кыз, оялып кына.

– Һаман чәчүргеч булмый инде, әйдә, бу юлысы этәч-конфет алыйм мәллә? – ди апасы аны үртәгәндәй. Кызның бит алмалары тагын да кызара төшә, ул тагын:

– Чәчүргеч, бантик ал, конфет кирәкми миңа, тешем сызлый, – дип алдаша.

И самими балачак! Шунда ук күкләр билгеләгән язмышны тоемлаганнар ласа алар...

Хатын сискәнеп китте. Тәрәзәгә күз төшерде: кич җиткән икән инде. Офыкта тыныч кына шәфәкъ алсуланып килә. Ул тонык караңгы юрганын җир өстенә җәя иде. Кичке караңгылыкны яратмый башлады Рәйхания. Шом арта кебек ничектер. Шул хакта бирелеп уйлагангамы, ишек ачылганын да, ябылганын да ишетмәгән менә.

Иренә ияреп кергән күршесе Володяны күргәч, уңайсызланып китте. Әлбәттә, икесе дә кызмача иде. Сүзләр үзеннән-үзе авыру бөер ягына борылды.

– Бөер кирәк диген, ә? – дип озак кына алдындагы кырлы стаканга карап утырды Володя һәм өлгереп калыйм, дигәндәй, ашыга-ашыга йотып җибәрде, башындагы кепкасын битенә үк төшереп иснәде. Аннан яңалык ачкандай:

– Бөерне табып була аны. Һәр кешедә икәү ич ул. Миндә дә икәү, – дип куйды.

– Үземнекен бирәм мин Рәйханиягә, – диде Фоат. – Иртәгә үк больниска барабыз. Алсыннар да куйсыннар әйдә. Икебезгә бер пар бөер белән яшәрбез әле ничек тә. Үлмәбез, шәт. Бары – бергә, югы – уртак, дигәндәй... Барыбер миңа Рәйханиядән башка тормыш юк.

– Анысы, дөнья бетмәс... – дип көлемсерәде күршесе.

– Дөнья хәзер үк бетте инде минем өчен. Иртәгә үк барабыз. Алыгыз гына, икесен бергә алсагыз да, сүзем юк, тик хатыным яшәсен генә, диярмен.

Күршесенең күзендә бер сорау тотылып калды кебек. Ул кашларын җыерып, тиз-тиз:

– Әллә ярамаска да мөмкинме? – дип куйды.

– Бик мөмкин, ди шул...

Күрше тәмам уйга төште. Кепкасын баш өстенәрәк күтәреп сыңар кулы белән чәчләрен сыпырып алды да чигә чәчләре тирәсендә бармакларын уйнатып, кашынып торды.

– Ярамавы да ихтимал, дисең алайса...

– Белмим инде, табиблар шулай, диделәр.

Шулчакта Рәйхания табынга бәрәңге өстенә ит тезгән, пар бөркелеп торган табак чыгарып куйды.

– О-о-о! – дип сузды симезлегенә чыдый алмыйча бүксәсе чалбарыннан бүлтәеп чыккан күршесе, күңеле булып. – Ит күргән юкка биш былтыр. Һава белән туенып торган көннәрем... Ай, рәхмәт! Әйдә сал, Фоат, тагын берне шул хөрмәткә!

Фоат чәркәләргә ачы су койды. Володяның бу сый-хөрмәткә күңеле тәмам йомшады.

– Рәйхан, туктале, син, ашыкмале, – диде ул хатынны туктатып. – Тыңла әле син мине. Син минем Фоатны хөрмәт иткәнне беләсең. Без бит аның белән яшьлектә куян куып тоткан егетләр! Кем булдыра шуны! Безнең монда илле грамм җиффәргәнгә карап фикер йөртмә син!

– Куян тотканнар имеш... Анда да шул илле грамм үз эшен эшләгәндер инде, – диде Рәйхания тыныч кына көлемсерәп.

– Куян кадәрле куянны куып тоттык бит, ә, Фоат! Үзең аш пешереп чакырдың лабаса, Рәйхан, оныттыңмыни син безнең яшьлекне, ә? Безне илле грамм болай исертми иде әле ул чакта, ә! Эчмәгәч тә ашамагач, бу дөньяның ни кызыгы бар?

«Сау-сәламәт чакта кеше исәнлекнең кадерен белми шул инде», – дип эчтән генә фикерләде Рәйхания.

Хатынның чыгып барганын чамалап ир янә аңа табан борылды:

– Әгәр дә мәгәр иреңнең бөере ярамаса, борчылмассың, яме! Синең кебек кешегә чи ит кисәге жәлме, ә? Бирәм. Гиппократ оныкларына әйт: алсыннар минем бөерне. Подарить итәм, пнимаешь. Истәлеккә-бүләккә. Миңа берсе дә җитеп ашкан аның! Берсе сиңа булсын, әйдә, рәхәтен күр!

Ир чәркәне каплап куйды да тәлинкәдә табынга чыккан суган кисәген иснәде. Кул аркасы белән һаман авызын сөртте. Үзе һаман сөйләнде:

– Яңа хуҗалар властька килгәч, тараканнар үлеп бетте, пнимаешь... Ә без әле яшибез. Без таракан түгел, пнимаешь... Шуңа үлмибез без. Бер бөер белән дә

яшәрбез. Бирәм берсен, Рәйхан. Сиңа бөер бирмәскә мин идиот штоли? Фоатны хөрмәт иткәнем өчен дә бирәм мин аны сиңа. Әйтергә була: подарить итәм. Әйе, истәлеккә, бүләккә... Мәңге хезмәт итсен үзеңә! Үлмә генә пнимаешь...

Рәйханиянең үксеп-үксеп елыйсы килеп китте. Күңеле тулышып ташыды. Аңа әле бүген үк бөер кирәкми, бүген әле аңа сүз дә җитә иде. Ә ул сүзне һич тә өмет итмәгән җирдән исерек Володя әйтте. Күрше хакы – Тәңре хакы, дип бер дә белми сөйләшмиләр икән шул.

Рәйханиянең хәзергә берни турында да уйлыйсы килми иде. Бүген килми иде. Бу кадәрле катлаулы эштә нидер фаразлау, ниләргәдер өмет итү һич мөмкин түгел. Аннан бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, кем белә, әллә Володя чынлап та сөйлидер...

Володяны ике улы ике ягыннан җитәкләп алып чыгып киткәч тә, Рәйхания бик озак керфек какмый өметле уйларга бирелеп ятты. Димәк, мине бу афәттән коткарырга берьюлы ике кеше аягын киенгән, димәк, ул кадәр үк борчылмаска да кирәктер, дип фикер йөртте. Үзе өчен бөерен генә түгел, җанын ярып бирергә әзер торган Володяга төне буена рәхмәтләр укып чыкты.

Икенче көнне аны совхоздагы халык җыенына чакырдылар. Рәйханиягә монда үзе турында сүз булмый калмас кебек тоелды. Ярдәм дә итәрләр. Чөнки аның хәлен бөтен авыл белә ләбаса. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, акча җыю очраклары да булып кына тора. Ә бистәдә әле янгын, әле су басу дигәндәй... Кешеләр битарафлык күрсәтмәде әлегәчә, ярдәмләшеп яшәделәр.

Җыелыш озак барды. Ләкин сүз ниндидер формаль мәсьәләләргә кайтып калды. Җитмәсә, һәммәсе озак-озак сөйләргә тырышты. Хәтта җитәкчеләрнең берсен бүлдереп:

– Ун минутлык чыгышны утыз минутка сузуны Сез үзегез ничек аңлыйсыз соң? – дип кисәтү ясап, бүлдермәкче дә булдылар.

Тегесе дә аптырап калмады:

– Өч нөсхәдә иде ул минем язганнарым, өчесен дә укып чыктым менә, – дип җаваплады. Аннан:

– Ун минутка сүз сыймый бит, – дип куйды.

Рәйхания игътибар белән тыңлап утырды: чыгышында «тиеш»ләр күп иде. Шулай тиеш тә, болай тиеш имеш... Ләкин профком рәисе күреп торды: үзеннән һәм Рәйханиядән кала, аны башка тыңлаучы булмады кебек. Артык проблема кирәкмени кешеләргә? Җыелышлар, гадәттә, өстәгеләргә хисап бирү өчен генә үтүчән. Дәфтәрләрдәге баганаларга билге кую өчен генә.

Үз-үзенә аклау табып урамга чыкканда, кояш карт наратлар артына ук кереп поскан: әллә нинди битарафлык аша салкын гына нурлана иде. «Җылытмый да, сүнми дә, ул да бичара минем хәлдә мәллә соң?» – дип уйлап куйды хатын.

Беренче күрүе түгел аның профком рәисен. Күп очракта ул башын икенче якка борып, нидер исенә төшергәндәй мыгырдана-мыгырдана, кызу-кызу үтеп китә, янәсе, менә нинди эшем кешесе! Шулай да үз-үзләрен мәҗбүр итеп булса да, аңа күпләр баш иярга мәҗбүр. Кайчан очраса да, зәһәрлек аша ялтыраган күз карашлары чагып-чагып ала. Бу хәлгә эчтән генә елмаю аша караучылар да бар, чөнки авылда моңарчы бу вазифаны кем башкарганны белүче дә юк иде. Авыл халкының йомышын гамәл белән үтәделәр, кирәк икән ярдәм иттеләр. Ә монда коры сүз...

Профком рәисе нотыгын тәмамлап эре форматлы кәгазьләрен папкасына салганда, залга күтәрелеп карады. Берничә хатын-кызның күрсәткеч кыстырып почта тартмасыннан яңа килгән журналны япканнарын күрде. «Берәү дә

тыңламады микәнни мине?» – дип уйлап куйгандай тоелды ул җыелышны ябык дип белдергәндә. Ир-атлар һаман чыга-керә йөреп торды.

Арыган, йончыган йөзле кешеләр, бер-берсеннән качкан бүреләрдәй, тиз генә таралышып та беттеләр. Рәйхания аларга иярде. Булмады... Бүген бит авылда аның хәсрәтеннән дә тирәнрәк каза юк. Тик авыл җитәкчелеге моңа күз йомды. Хәсрәтең эчеңә сыймаса да, ай-һай салып йөрүдән ни фәтва? Хатын шулай уйлады.

Ул урамга чыкканда, каеннарның чал башларын бөгә-бөгә җил исә иде. Дөнья шул бу, агач-куакларга да җиңел түгелдер, дип уйлап алды. Бу җыеннан күңелендә әллә нинди ямьсез тойгылар, шикләнүләр калды. Бер төркем ир-ат сөйләшә-сөйләшә алдыннан атлады. Рәйхания ирексездән аларга колак салгалады:

– Әнә, Ил башы җәнлекләрне бик яратам, ди. Леопардлар белән кочаклашып фотога төшкән, – диде берсе.

– Их, кешеләрне дә шулай яратсын иде ул, – дип куйды икенчесе.

Рәйхания нигәдер үзен бу галәмдә япа-ялгызы калгандай хис итте. Шул мәлдә Володя күз алдына килеп басты. Төкерми дә, йөрми ул җыелышларга. Үз сүзе сүз аның. Үзенеке дөресрәк... Ул да бераз авырып тора икән әле.

– Остеохондроз тотып алды, – ди хатыны. – Минем ир авырый белә инде ул: караватка гына менеп ята, юрганын үзе ябалмый, бичаракаем... – дип урамны яңгыратып көлә Маргарита. Үзе һаман яңа итәгенә күз төшереп алгалый. Хәле хәл булса да моны сизеп тора Рәйхания.

– Котлы булсын! Тагын да яңаларын насыйп итсен Аллаһ, – дип, телен көчкә әйләндереп әйтергә тырышты ул. Кемнең кайгысы нәрсәдә бит? Маргарита исә һаман үзенекен сөйләде:

– Нәфислегеңә ышанып, базардан юбка алып кайтып китәсең, киеп карасаң котың чыга: мичкәне төреп куйган кебек тәмам...

Сүзне озайтырга теләмәде Рәйхания. Маргарита да үз күчәре тирәсендә 180 градуска борыла-әйләнә атлап ары китеп барды.

Кичке якта Рәйханияләргә Володя үзе килеп керде. Фоат кайтып җитмәгән иде әле.

– Остеохондрозның аның файдасы да бар, тоз утыра да муен калыная, күпме тунасалар да, баш өзелеп төшми аннары, – дип сөйләнде хатынына ишарәләп. Имеш, өеннән талашып чыгып киткән. Исерекнең калын тавышыннан туядыр инде Маргаритасы да. Ир:

– Радио кычкырып сөйләсә дә ярамый, туктатып куйсаң да ярамый, – ди. Янәсе, хатынга ничек тә ярап булмый. Еш кына Володя баштан зарлана. Хатыны исә:

– Илдә дуңгыз гриппы чыкканнан бирле башы авырта аның, – дип төрттерә.

– Кемнең аягына, кемнең бугазына басалар бу илдә, пнимаешь... Минем бәхет булмады: боларның икесе дә хатын аяк астында. Суверенлык бирмәсәң, китәм, дим. Бөтенләйгә, дим. Бер күрергә тилмерерсең, дим. Ышанмый сүземә, пнимаешь. Сине генә күрми чыдармын әле, арка чокырымны гомерем буена да күргәнем юк, ди. Әйдә, ярар, Рәйхан, илле грамм сал да, мин киттем, – диде ул баскыч төбеннән үтми генә тукмак борынын кул сырты белән ышкып җибәргәч. – Бөер – синеке, борчылма! Подарить итәм, пнимаешь... Гиппократ оныкларына әйтерсең, алыгыз да куегыз, диярсең. Рәхәтен күр әйдә... Истәлеккә-бүләккә...

Шулай да авыл җыеныннан соң, ул төне буе йокламады. Илбашына «Бөер табарга булышыгыз! Минем дә яшисем килә!» дип кыска гына хат язып салды. Җөмләләре бик кыска булса да, бик озак язды хатны. Аны кемдер табып бирүенә бер дә ышанмыйча, күңелен тынычландыру өчен язды. Чөнки ул җавапны алдан ук белә: хат килсә дә, хәтта аны ачып укырга да теләмәс иде. Хәер, хәзер үк ул почтальонның капка төбендәге әрҗәгә газеталар салып китүенә битараф инде...

***

Фоат белән алар иртүк юлга кузгалдылар. Шулай да хатын сизде: ире нидәндер шомлангандай, бик ачылмый гына сөйләшә. Вакыт-вакыт эчке ярсуы тышка бәреп чыга иде. Әлбәттә, Рәйхания аның хәлен бик яхшы чамалый, уколдан да коты очкан ир затына операция дигән сүз мәхшәр булып күренәдер. Үз хаҗәтең төшеп, мәҗбүрият алдында торганда да, коточкыч бит әле ул. Ә монда хатының өчен корбан буласы. Икебез дә гарип калсак, нишләрбез, дип тә көенәдер.

Ул юлларны бөтенләй дә күрмәгәндәй, машинасын куалый. Рәйхания вакыт-вакыт:

– Ашыгасың, кадерлем, өлгерәбез ләбаса, – дип куештыра. Ир аны ишетми дә кебек. Ул алга чаба. Бераз баргач кына телгә килеп:

– Тизрәк барып җитәсем, сине тизрәк терелтәсем килә, – дип җаваплый.

Анализлар тапшыру бүлмәсенә дә алдан Фоат үзе кереп китте. Нәтиҗәләрен коридорда әрле-бирле йөренә-йөренә көтте. Рәйхания янына утырып:

– Менә күрерсең, бөтенесе дә шунда хәл ителер, гомер буена икебезгә бер юрган, бер түшәк дигәндәй, без икебез бер кеше кебек инде, бер уйласаң, – дип аны юатып алырга да җай тапты.

Фоат хәтта кайчак Рәйханиянең күз яшьләрен күргәндә дә сөенә: аңа хатыны яши кебек тоела иде. Авыру газапларына яшисе килү ләззәте кушыла да җанын тыелгысыз сулкылдата. Моны карап тору иргә җиңел түгел, шулай да бу халәттә ниндидер билгесез өмет чагылышы бар иде шикелле.

– Бөтенесе дә хәл ителер, менә күрерсең... – дип кабатлады ул янә.

Тик... бу анализлар Рәйханиягә куаныч китермәде: кан күрсәткечләре чагышмый, диделәр.

– Ничек инде, без егерме ел бергә яшибез ласа, бер түшәктә йоклап, анализлар туры килмиме? – дип ачу-үпкәсен белдерде ир шәфкать туташларына. – Вәйран башны хәйранга калдырып андый сүз әйтмәгез әле сез безгә...

Шәфкать туташы иңбашларын сикертте.

– Бәлки берәр туганыгыз ризалашыр? – дип үз тәкъдимен кертте аннан ак халатлы кыз. – Кызыгыз, улыгыз да ярый...

«Кызыгыз, улыгыз» дигән сүздән хатынга йөрәгендәге иң нечкә кыллар өзелеп киткәндәй тоелды, күкрәк турысы кысылып куйды. Эчтән генә: «Аллам сакласын! Алар өлешенә керергә язмасын», – дип кат-кат тәкрарлады. Күзләренә яшьләр тулды, үкси-үкси елаудан тыела алмады.

Фоат аны юл буена тынычландырып кайтты:

– Борчылма, Володя бар бит әле безнең. Үз теле белән әйтте ләбаса: «Синең өчен җаным җәл түгел», – диде. Ә син яшь сыгасың. – Фоат инде баягы капкынга эләккән тычкан халәтеннән ычкынган, сөйләшүдән туктамый, бераз кәефе дә күтәрелгәнгә охшап тора иде. Хатын моны сизенсә дә, сүз әйтмәде, күңелен җәрәхәтләмәскә булды. Барды, карышмады, һичшиксез яраячак, дип ышанды. Ни дисәң дә, хатынына башлап ярдәм кулы сузды. Тик чир упкыныннан тартып алырга хәленнән килми икән, тагын нишли алсын инде ул? Анализлар ярашмаганга ул гаепле түгел ләбаса...

– Әле бит Камал Абрамович бар. Ул барыбер ярдәм итәчәк! – дип, эчке өметен уятып куйды хатын.

Теге шомлы таңда, берәүнең әҗәлен көткәндә, шәфкать туташы шундый өмет уятты бит аңарда: «Бер-берсенә әгъза бирүчеләр әз түгел, бәлки берәр туганыгыз ризалашыр?» – диде.

Рәйханиянең күз алдында һаман шул соры хастаханә диварлары, берәүнең әҗәлен көтеп утырганда, һич үтмәс минутларга уралган ямьсез хатирәләр бөтерелде.

***

Ул чакта Рәйхания шәфкать туташыннан шактый мәгълүмат белешергә өлгерде. Үзен кызыксындырган сорауларны биреп калырга тырышты. Ул беркүпме тын гына утырганнан соң:

– Үлгән кешенең бөерен күчереп утырту әллә ничегрәк инде үзе. Кыргыйларча диимме? – диде.

– Нәрсәсе кыргыйларча? Табибыбыз «Кеше алырга әзер икән, бирергә дә каршы булмаска тиеш» дигән гыйбарәне еш куллана. Америка профессоры шулай дип әйткән, ди. Дин кешеләре дә моңа каршы килми, ди. Фанилыктан китеп баручы зат үз гомеренең бер кисәген кемнеңдер гомеренә ялгап калдыра икән – бу начар түгел бит инде. Икесенең дә үлеп китүеннән кемгә файда соң? Ләкин алдың да куйдың түгел шул, бу бик четерекле мәсьәлә. Тикшерүләр, анализлар...

– Яраган очраклар бармы соң? – дип сорап куйды Рәйхания бик белергә теләп.

– Нишләп булмасын? – диде шәфкать туташы. – Әнә коридорда стенд эленеп тора. Анда барысы да кемнеңдер бөере аркасында яшәп ята.

Рәйхания чит бөер куйдыручыларның, хәтта егерме биш елгача гомерләре озаюын, аларның бөер эшчәнлеген җайга сала торган дарулар эчеп булса да, тормыштан өзелми яшәп ятуларын белде. Стендтагы ир-атлар да, хатын-кызлар да фоторәсемнәрдә шат чырайлы, алар һич кенә дә авыру кешеләргә охшамаган иде. Аның күңелендә өмет чаткылары уйнап алды.

– Хәзер сез коридорда көтеп торыгыз, анализлар әзер булгач, чакырырбыз. – Шәфкать туташы бу сүзләрне бераз кырысланып әйтте шикелле. Рәйханиянең сораулары әле тагын да күп булса да, артыгын сорашырга кыймады. Әкрен генә коридорга хәсрәттәшләре янына чыгып утырды. Ишекләр ачык булгангамы, кабинетта ниндидер аппаратлар эшли, аларның тигез ритмы гел йөрәк тибешен хәтерләтә иде.

– Әллә теге кеше терелдеме? Йөрәге эшләп киттеме әллә соң? – дип куанып сорады хатын.

– Юктыр...

– Йә, ни дип әйттеләр?

– Ни әйтсеннәр инде, анализлар алдылар да чыгарып җибәрделәр, – дип кәефсез генә җаваплады Рәйхания.

– Их, бу кеше гомере! Ничек кызганыч!

–Үлмәсен иде ул, мин шуны гына телим хәзер, – диде Рәйхания күршесенә теләктәшлек белдереп.

– Үлмәсен... – дип кабатлады ир заты.

Ә чынлыкта алар иртә таңнан өчәүләшеп берәүнең үлемен көтәләр иде...

***

Кызының көне буе үз тирәсендә бөтерелүен Рәйхания үзенчә юрады. Мине кызгана, балакаем, бер-бер чара табылмас, дип куркадыр, мөгаен, дип фикер йөртте. Төсе качкан тәмам. Сүзләрен дә санап кына сөйләшә. Ашау-эчүенең дә рәте китте.

– Ник бер дә кәефең юк соң, балам? – дип назлап кына кызының чәчләреннән сыпырды Рәйхания. – Уеңны кычкырып әйт, йөрәгеңне талап ятмасын.

Ул кызының дәрьядай төпсез күзләренә төбәлде. Ул күзләрдә исә ана хәсрәтенең

шомлы күләгәсе генә түгел, әллә күпме наз да чагыла, айның ундүртенче кичәсе кебек нурлы йөзеннән яктылык сирпелә иде.

Таңсылу үксеп елап җибәрде. Керфек очларыннан тәгәрәп төшкән энҗедәй яшь бөртекләрен ана учлары белән сөртеп алды.

– Елама, балам, Ходай кушмаган эш булмас. Үлмәскә язган икән, бөерсез көенчә дә яшәтә ул Аллаһы Тәгалә... Һаман бер балык башы инде: туйдырдым сезне дә...

– Әнием, – диде кыз, – рөхсәт ит сиңа үз бөеремне бирергә.

Рәйхания баскан урынында чайкалып куйды:

– Ни сөйләгәнеңне беләсеңме, балакаем? – диде ул, күзләрен зур ачып.

– Беләм... Мин барып белештем. Мөмкин, диделәр. Безнең кан төркеме дә, башкалары да туры килә. Стендта эленеп тора анда: бер ана кызына үзе донор булган.

Рәйхания бермәл тын ала алмый торды. Көчкә үзен җыеп:

– Их, балам... Әни кеше йөрәген бирергә дә ризалашыр ул. Әллә син моны бик җиңел хәл дип белдеңме? – дип куйды.

– Синең авыруың безгә дә рәхәт түгел.

– Түгелдер дә соң... Мин моны рөхсәт итә алмыйм, кызым... Синең әле яшисең бар. Кияүгә чыгасың... Бала табасың... Авыру хатын беркемгә дә кирәк түгел ул.

– Мин кияүгә чыкмаска да риза, әнием, син генә терел. Сәламәт булсаң, яныңда ярдәм итеп яшәве күпкә рәхәтрәк.

– Ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы, балам? Бу хактагы уйны башыңа да кертмә, яме! Ә миңа ярдәм итүче табылыр. Әнә, Рәшит абыең бар. Аның белән каннарыбыз туры киләдер. Володя да риза, ди бит...

Рәйхания кисәк борылып үз бүлмәсенә кереп китте. Караватына ятып битен колак мендәре белән каплады һәм тыела алмыйча, тавышсыз гына үзен-үзе өзеп елады. Гүя җаныннан моңарчы җир өстендә бер генә кеше дә кичермәгән иң ачы күз яшьләре сыгылып чыкты. Менә бит нинди хәлгә куйды ул балаларын! Үзе ни хәлгә калды? Менә бит нинди фаҗига язылган аның язмышына.

Ул кызын күтәргәндә, үтереп лимон ашыйсы килүен, туган көнендә җеп өзәрлек хәле булмаса да, шатлык-куанычта коенуын – җир өстендә өр-яңадан, яңача яши башлавын, йокысыз төннәрен, күкрәк сөтен имезгәндә, нарасыеның ирен читләреннән аккан ап-ак сөткә наз тулы, бәхетле күзләр белән яратып карап торуын, бәгырь җимешенең җиргә сак кына басып тәпи атлап китүен, «әннә» дип теле ачылуын, могҗизалы экиятләр тыңлый-тыңлый тирән йокыга талуын, кара күлмәк, ак алъяпкычын килештереп киеп, беренче кат мәктәпкә баруын күз алдына китерде. Инде институтны да уңышлы тәмамлап чыкты, эш кешесе булды менә... Ана кеше өчен баласыннан да кадерлерәк җан иясе юк шул җир йөзендә!

Ә кызы мәрхәмәтле... Шунысы үкенечле түгел: олы җанлы, кешелекле балалар калдырып китә икән лә җир өстенә... Хәер, улына әллә ни аңлатып тору кирәкмәде. Үзе дә әнисенең җанын бимазалап артыгын теләк белдермәде. Шулай да бик боек йөри, дөньядан рухы сүнгән кеше кебек. Әле беркөнне генә улының машинасын куйганда, арт белән коймага бәрелә язып калуыннан коты чыкты. Кызы:

– Әни, ник карап торып үзеңне бетерәсең? Син бит барыбер аңа ярдәм итә алмыйсың. Аннан йөрәк авырта, дисең... – дип шелтәләде.

– И-и, кызым, минем йөрәгем юлда сезнең алдыгыздан йөгерә бит шулай, – дип пошынып җавап бирде Рәйхания.

Хатын үз уйларыннан сискәнүдән бөтен гәүдәсе белән җыерылды. Ничек инде, ул үләргә җыенмый лабаса. Медицина алга киткән бу дөньяда аны гына күрәләтә үтермәсләрдер, шәт? Шул мәлдә карашына ышыкланып, Камал Абрамовичның өметле җөмләләре узгандай булды: «Яшиләр бит әле. Сез дә яшәрсез...»

***

Рәйхания нигәдер иртә уянды. Йокы күлмәге өстеннән кофтасын иңнәренә салып, йортка чыкты. Тирә-күршенең көтү куганын, сыерларның иренеп кенә мөгрәвен, кызларның чиләкләрен чыңлатып, суга чишмәгә төшеп китүен, ишегалдындагы тал башында оя корган кошның салмак аваз чыгарып, чи-чи килүен ишетте. Дөнья яңа көнгә әзерләнә иде. Дөнья яши иде... Иртәнге хәрәкәт аның күңелендә яшәү чаткыларын тергезеп җибәргәндәй булды. Ирексездән балачагындагы матур хыяллары биләмәсендә калды.

...Рәйханиянең әнисе ул көнне мышный-мышный песи аягына бинт урап утырган кызын күреп гаҗәпләнеп куйды.

– Нигә урыйсың син аны? – дип сорады.

– Аягын җәрәхәтләгән, – дип җавап бирде кыз, күтәрелеп карамыйча гына.

Мәче дә кызның итәгенә сузылып яткан да тәпиен алга ук сузып, Рәйханиянең ураганын тик кенә күзәтеп утыра иде. Шунда кыз катгый карарга килде: «Шәфкать туташы булачакмын»...

Тик аңа сатучы булырга язган иде. Шәфкать туташлары әзерләү училищесына имтиханнарга соңга калдыгыз, диделәр. Үртәлә-үртәлә авылына кайтып китте.

Сатучылыкка укырга кирәк дигән карарга килгәнче, тагын бер елга якын вакыт үтеп киткән иде инде. Дөресрәге, бабасы каршы төште:

– Мизан янында гадел була алырыңа ышансаң гына бар, кызым, – диде. – Нәфсене җиңә алганнар һөнәре бу. Гөнаһка нибары бер адым...

– Үз авылдашларыма андый явызлык кылмам бит инде, бабакаем, – дип көлде кыз.

Сатучылыкка укып бетерүгә, Фоаты армиядән кайтып җитте. Ә бу һөнәр бик тә кирәкле булып чыкты. Алар урнашкан совхоз кибетендә сатучыны лаеклы ялга озатканнар иде.

***

– Хафизова, сез кайтып китә аласыз. Кан анализларыгыз күрсәтүенчә, бу кешенең бөерен организмыгыз кабул итәргә җыенмый. Кан ойый да китә, бернишләтер хәл юк, – диде шәфкать туташы Рәйханиянең хәленә керергә тырышкандай.

– Ә аларга ярармы соң? – Хатын хәсрәттәшләренә төбәлеп, җайсыз сорау биргәнен сизмичә дә калды. Аннары уңайсызланып кына: – Ә бәлки, үлем түшәгендәге кеше үзе терелер, – дип куйды.

– Ә бәлки... – дип кабатлады ак халатлы кыз. – Без могҗизаларга Кыш бабайдан бүләк көтүче балалардай ышанабыз. Тик кайчакта өметләребез акланмый шул... Табиблар, шәфкать туташлары өчен үзләре дәвалаган затларны исән-сау күрүдән дә зуррак бәхет юк. Моны сез, кешеләр, беркайчан да аңлый алмассыз. Бу кичерешләрне тоюдан бөтен дөньябыз тулылана...

Рәйхания аңарга сокланып карап куйды. Чибәрлегенә дә, ичмасам, бер күз дә төшермәгән әлегәчә. Зифа буена, башлыгы тагын да яктыртып күрсәткән зур зәңгәр күзләренә аклык ничекләр килешкән! Өчесенең күз алдында, үлеләр һәм тереләр дөньясы чигендә сакчы фәрештәдәй басып тора ул.

Шәфкать туташы янә кулындагы кәгазьләрне актарыштырып, арадан берсен өскәрәк тартып чыгарды һәм:

– Иванов, – дип эндәште. – Әйдәгез минем белән. Карап карыйк, сезнең анализлар ни күрсәтер икән...

Ир көрәктәй куллары белән битен сыпырып төшерде дә шәфкать туташына иярде.

– Һәркемнең яшисе килә! – дип куйды Рәйхания, башмакларын пакетка сала-сала.

– Һәркемнең яшисе килә! – дип кушылды чит хатын.

Алар өчәүләп берәүнең үлемен көттеләр һәм өчесенең дә яшисе килә иде... Инде менә икәү генә калдылар. Рәйханиягә ничектер аеруча җиңел булып китте. Әлеге минутта яши бит әле ул! Үлмәгән. Үз аяклары белән больнистан чыгып бара әнә. Ә калганы барыбер без уйлаганча түгел, Аллаһы Тәгалә кушканча булачак.

Рәйхания чыкканда, Фоаты машинаны кабызып көтеп тора иде инде. Ул хәлне шунда ук аңлады.

– Димәк, сиңа язмаган ул бөер, – диде дә радионы ачты.

Шомлы тавыш нindидер күңелсез хәбәр җиткерергә тырыша иде: Иделнең кайсыдыр тармагында балыклар үлгән. Анализлар күрсәткәнчә, суда сульфат, фенол һәм марганец артып киткән, ди.

– Кешеләр табигатькә яхшы мөнәсәбәт күрсәткәнгәдер инде монысы, – дип куйды Рәйхания авыр уйларыннан аерылырга теләп.

– Җәй көне бик эсселәрдә бер булды бит мондый очрак, суда кислород җитмәгән, диделәр. Табигать үзе гаепле, диделәр. Әле дә шундый бер-бер хәл килеп чыккандыр...

– Аңламассың бу дөньяны, – дип авыр сулады хатын.

Икесе дә бер мәлгә сүзсез бардылар. Машина кайчакта тигез генә юырта, вакыт-вакыт чокыр-чакырларга төшеп киткәли.

– Ашыктырма, – ди, Рәйхания иренә табан борылып.

Ул шул арада уйларына бикләнеп, сәер тынлыкка чумды. Табигать матур шулай да, дип сокланды машина тәрәзәсе аша. Табигатьтән аерылып яшәргә язмасын. Гаилә белән табигатькә чыгарга яраталар иде алар. Шуңа бакчаны да Чулман буеннан алдылар. Йорт тирәсендәге мәйдан да җитәрлек югыйсә: ун сутыйга бәрәңгесен дә, кишер-чөгендерен дә, кыяр-помидорын да утырталар. Ә Чулман буендагысын җиләк-җимеш бакчасы иттеләр. Шашлык пешерергә мангал куйдылар, утырып ял итәргә беседка кордылар. Күршеләре: «Тәмам шәһәр кешеләренә әйләнеп беттегез инде!» – дип көнләшү тулы күзләр белән карады. Әллә шуларның зәһәр күзе тиде микән соң? Хәзер барысы да бетте микәнни?

Ир хатынының эчке халәтен тоясы, уен беләсе килүдән тизлекне арттыруын да сизми.

– Бу өмет тә киселде, – дип уйлыйдыр ул. – Чиратта Володя инде...

***

Табиблар хәзер УЗИ аппаратларын үзләре белән йөртә икән. Алдагы елларда да алар аны районнан авылга алып килгәннәр иде. Ишетте Рәйхания ишетүен, әллә ничек, аяклары шешенүне авыруга санамады бер дә. Ак халатлы бу фәрештә дә кешеләрнең сәламәтлеге өчен ниләр эшләүләрен шактый озак сөйләде.

– Шунысы кызганыч, кешеләр соңгы чиккә килеп җитмичә торып, үзләренең авырулары хакында белмиләр, дөресрәге, үз-үзләренә игътибар итмиләр, – диде ул. Хастаханәгә юллама да биреп калдылар.

Рәйханиягә кыен булып китте. Ул, нигәдер, мин генә шундыйрактыр, дип уйлаган иде. Үзеңне ничек шул хәлгә төшерергә мөмкин, дип көенде. Аны район клиникасындагы табибка яздырган шәфкать туташы чын-чынлап ачуланды лабаса: «Бу хәтле игътибарсыз булырга ярамый, балалар хакына дип тә яшәргә тырыша кеше», – диде.

Менә хәзер инде ул кая кушсалар, шунда бара, ни сорасалар, шуны эшләргә

әзер иде. Медицина ничек кенә үсеш-үзгәреш кичермәсен, авырулар саны гына кимеми. Ни өчен шулай бу? Чирен яшергән – үлгән, диләр, һәммәсе дә үзләре гаепле микәнни?

Чир бит һавадан иңгәндәй, көтмәгәндә ябырылды. Көтмәгәндә аяктан екты. Кемнең үзен чирле дип хис итәсе килсен? Әлбәттә, Рәйханиягә дә моның белән килешү җиңел булмады.

Әнә бит Камал Абрамович әйтеп тора, операция ясатып, башкаларның бөерен куйдырсаң да, могҗизага ышанырга ярамый, ди. Бу бик күп дарулар, дәвалану курслары, хастаханә ятаклары дигән сүз. Әле организм чит әгъзаны кабул итәме, юкмы? Күп очракта кире кага, ди шул.

Рәйхания сырхауны урын өстенә ятып кичерергә җыенмый, көрәшәчәк ул, ихтыяр көчен туплап үзен-үзе җиңәчәк барыбер. «Минем яшисем килә!» – дип кабатлады ул эчтән, иреннәрен тешләп.

***

Рәйханиянең Фоатны очратмаса, кәефе кырыла торган иде. Фоаты да шулай: мәктәп коридорында һаман кызны күзләде. Ә беркөнне дәресләр беткәч тә, алар физкультминутка чыктылар. Шунда малай аның кулына кәгазь кисәге тоттырып өлгерде, Рәйхания йөгереп кереп тә китте.

Кызның бөтен тәне буйлап ток үткәндәй тоелды. Учын йомарлаган килеш, иңбашларын сикерткәләп, ләззәтле мизгелләр кичереп утырды.

«Шулай да ни язды икән соң?» дип, бөтен кыюлыгын югалтып, әкрен генә учын ачты. Бөгәрләнгән кәгазь кисәген туздырып җибәрде. Анда чалыш-чолыш хәрефләр белән: «Әйдәгез, иртәгә районга барып кәртечкәгә төшәбез. Рамилә белән Фәнсөяргә дә әйт», дип язылган иде. Кыз бермәлгә ушын җыя алмыйча торды. Ул башкарак хат көткән иде түгелме? Ул хатка сибелеп яткан хәрефләр дә башкарак мәгънә җиткерергә тиеш иде шикелле...

Шулай да Рәйхания районга барырга кызларны күндерде. Февраль аеның кояшлы, якты бер көнендә алар фотога төшәргә җыенып, авылны чыгып киттеләр. Язга авышкан көндә олы юл көзгедәй ялтырый. Урыны-урыны белән тайгаклыклар барлыкка килгән. Ә кояш, алар чыркылдаша-чыркылдаша көлешкәнгә яратып карагандай, иксез-чиксез нурларын коя. Алар Рәйхания белән Фоатны урыйлар, урыйлар... малай белән кыз бер-берсенең күзләренә дә тоташ нур булып күренәләрдер төсле...

Фоат әле кыш суыгы китеп бетмәсә дә, башына кепка киеп алган. Рәйхания дә юка йон яулыгын чәчләрен чыгарып бәйләп куйган. Юк, юк, туңмыйлар шикелле бер дә. Рамилә белән Фәнсөяр генә үзләренә күрә генә түгел, калын башлыклары өстеннән башларына капюшоннарын да ябып куйганнар хәтта.

Алар ул көнне дүртәүләп фоторәсемгә төштеләр. Иң алга Рәйхания белән Фоатны утырттылар. Ике кыз артка басты. Фоат кепканы, Рәйхания яулыкны салмады. Арттагы кызлар исә яланбаш калып, чәчләрен төзәтештерделәр. Акчаны дүрт фото өчен дә Фоат түләде. Көзен колхоз кырында бәрәңге алган өчен биргән гадел хезмәт хакын җыеп куйган иде. Хәтта егетләрчә: «Менә кирәге чыкты ичмасам», дип горурланып башын арткарак ташлап, борын чөйгәндәй итте.

Ә кайтышлый алар ике әфлисун сатып алдылар.

– Кабыгын пәке белән урталай кисик без аның. Аннары ике ягыннан җепкә эләктерәбез дә җим салып куакка эләбез. Кошларга бер дигән җимлек булачак... – диде Фоат, яңалык уйлап тапкандай.

– Әйе шул, баш та соң үзеңдә, ә язын җирдә череп бетәчәк ул, – диештеләр кызлар да куанышып.

Шулай да бу сәфәр кошларга бер бәйрәм ясар өчен сәбәпче булды. Шуңа сөенеп туя алмадылар. Ул бәхетле чаклар – күңел хәзинәсе. Авыл баласы беркайчан да үзен генә уйламый шул. Менә аның хакында да кемнәрдер кайгыртырга тиешле көннәр килеп җитте. Күзе түбән, күңеле сүрән чагы Рәйханиянең...

***

Рәшит сеңлесенең хәлен белергә бу араларда гадәттәгедән ешрак керештерде. Бер урамда торалар, аралары да әллә ни ерак түгел. Әбиләренең сүзе колагына эленеп калган шулай да. Ничек дия иде әле ул? «Кыз туганыңның өенә кагылып хәл белешергә өлгермәсәң, түр тәрәзә турында һич югы чыбыркыңны шартлатып уз, – ди иде. – Кылны кырыкка ярырдай вакытыңда да онытма». Рәшитнең баш мие әбисенең алтын җөмләләрен таркатырга кереште. Туганлык төшенчәсе үз җаеңны караудан өстенрәк шул. Әбисе хәйләкәр карчык булды: һәрчак Рәйханиянең хәлен Рәшиттән, Рәшитнең хәлен сеңлесеннән сорашты. Туганлык җепләре өзелеп китмәсен, янәсе...

Бу юлысы да сүз тагын чир турында сөйләшүдән башланып китте.

– Әллә соң, сеңлем, мин дә барып карыйммы икән? – дип куйды ул үзе дә сизмәстән.

– Барасыңмы соң? Белмим инде...

Рәйхания күңеле үзенә ярдәм итәргә җыенган кешеләрнең барысын да эчтән читкәрәк этәрә. Тик үз-үзенә каршы килеп булса да, теле һаман ярдәмгә чакыра иде.

Шулай да иртүк торып, алар анализлар тапшырырга районга юл тоттылар. Рәшит Фоаты кебек үк иртәдән кәефсез, үтә дә борчулы иде. Авыз ачып бер генә сүз дә сөйләшмәде. Рәйхания аңа таба ялгыш кына башын борды: сулу алуы ук дөрес түгел, киң кырлы кепкасы астыннан куркынган күзләре елтырый. Аларны кан алган. «Ай Аллам, нигә бара инде бу бала?» дип уйлады ул.

Хастаханәнең ни икәнен белмәгән ир-ат өчен моны Рәйхания бик табигый хәл дип кабул итте. Иректә баштан йә кемнең пычак астына кереп ятасы килсен соң? Гарип калсаң?.. Аллам сакласын... Шушы хакта уйламый гына бер чарасыз адымга барып буламы?

Рәйхания үзе дә дәшми генә баруын белә. Абыйсы машинаны тизләтә төшә. Тәрәзә аша арыш басуыннан күкчәчәк, мәтрүшкә исләре борынга бәрелә. Инде районга да кереп киләләр.

– Нишлисе булыр инде, сеңлем, аннары? – Рәшит кулын рульдән ычкындырып, беренче җөмләсен әйтте.

– Гөлсәрия белдеме?

– Юк. Әйтергә батырлыгым җитмәде...

– Каршы килсә?.. Гаиләдән уза алмассың бит...

Ир дәшмәде. Чигәсендәге кан тамырлары тартышып куйды. Гадәттә машина түбәсенә тия язган башы рульгәчә иелде, үзе дә мескен бер затка охшап калгандай тоелды. Мондый хәлдә җаның үкчәңә төшәр... Рәйханиянең аны ихластан кызганудан йөзенә эссе бәрде.

– Әллә соң кире борылыйкмы, абый? – дип, тирән әрнү аша иңрәде.

– Юлга чыктык бит инде... Бүген каршыда торган мәсьәләне хәл итәргә кирәктер инде, бер башлагач...

– Ә иртәгә...

– Иртәгәсе көн Ходай кулында әле ул...

Рәшит сеңлесе артыннан юаш кына адымнар белән лаборатория коридорыннан алга атлады.

– Тагын бер пациент алып килдегезме? Егет таза күренә. – Шәфкать туташы йөзенә канәгатьлек төсе чыгарып, Рәшиткә төбәлде.

– Абыем ул минем...

– Абыегыз... Димәк, ярап куюы да бар.

Бу сүзләрдән Рәшитнең йөзеннән кан качты. Адымнарын саташтырды. Кәнәфигә килеп утыргач та, дерелдәп-калтырап торган бармакларының агач урындыкка батып керердәй булып ябышуыннан шәфкать туташы үзе дә куркып калгандай тоелды.

– Бераз тынычланыгыз... Югыйсә, энәне ычкындыруыгыз мөмкин. Ә кан тамырлары белән шаярырга ярамый... Болай да качарга гына тора алар...

Рәйхания исә теге чакта үлеп ятучы затны уйлады. Белде микән ул әҗәлен өч кеше көтеп утырганны? Белмәгәндер шул. Моны белсә, һичшиксез, куркуыннан терелер иде... Тегеләрнең берәрсенә бөерен биреп, гомерен бүләк итеп, бакыйлыкка күчкәндер инде, бахыр... Берәүнең әҗәлен көткәндә, хәсрәттәшенең телефонын алган иде дә шалтыратырга йөрәге җитмирәк тора әле нигәдер. Бәлки, операцияләрдән соң больницадан да чыгарга өлгермәгәндер...

Хәер, үзе дә моннан бер-ике ел элек җир өстендә шундый хәлләр дә булуын белсә, куркуыннан үләр иде, мөгаен. Ә чарасызлыкка килеп төртелгәч, курку дигәне дә кача икән...

Әнә абыйсы аның хакына бар эшен ташлап килде, канын да кызганмый хәтта... Туган туган инде, ни дисәң дә. Хатынның күзләренә яшь төелде.

– Еларга ярамый! – дип кисәтү ясады ул үз-үзенә. – Җебемәскә кирәк! Абыйның болай да катлаулы халәтен, борчуларын тагын да тирәнәйтү дөрес булмас...

Ул арада палатадан, кан тамырына мамык каплаган кулын өскә күтәреп, Рәшит тә килеп чыкты. Аның куркуы әле бетмәгән, йөзе ап-ак, күз тирәләре тартышып-тартышып ала иде.

– Аллага тапшырдык, сеңлем...

– Бераз көтәргә туры киләчәк. Әнә өстәлдә газет-журналлар, караштыра торыгыз, вакыт тизрәк үтәр... – Шулай диде дә сары чәчләре чепчигы астыннан бөдрәләнеп чыккан, зур зәңгәр күзләреннән илаһи яктылык, ак халаты аша да биленең нечкәлеге, нәзакәтлелеге чалымланган яшь кенә кыз бала, үзенчә киңәш бирүче кыяфәтендә ак ишекле бүлмәгә юнәлде.

Рәшит газет-журналлар актарыштырды, тик алардагы хәбәрләрнең берсе дә башына кермәде. «Әллә кеше аңламаслык итеп яза башлаганнармы соң?» дип үз-үзенә гаҗәпләнде ул. Вакыты да барыбер озак үтә, минуты елларга тиң иде. Әлбәттә, күңел төпкелендә бер яшерен өмет яши, менә хәзер шәфкать туташы килеп чыгар да: «Сезнең каннарыгыз туры килми, бернишләр хәл юк», дияр кебек иде...

Газапларның тагын да тирәнәйгән бер мәлендә яшь чибәр шәфкать туташы күренде. Ул Рәйханиядә янә өмет чаткысы кабыза алганына сөенгәндәй:

– Булды бит, ниһаять, анализларыгыз туры килә. Бер-берегезгә теләсә кайсы әгъзагызны бирә аласыз, – дип, озын ак коридорны балкытып елмайды.

– Теләсә кайсы әгъзаны?.. – дип кабатлады Рәшит, калтырануын баса алмыйча.

– Юк инде, бөерне, йөрәкне, мәсәлән...

Ир Рәйханиягә күтәрелеп карады. Ул да борчудан коелып төшкән кешегә охшап тора иде. «Сөенечнең эзе дә юк, нигә болай бу?» – дип аптырап уйлап алды абыйсы.

Алар сүзсез генә машинага юнәлделәр.

Юл буена ир үзе караган киноларны исенә төшерә-төшерә, операция өстәлендә яткан ир егетләр кергән кадрларны барларга тырышты.

– Б-р-р... – дип башын селкеп куйды ул кинәт. Рәйхания аңа ни булганын белергә теләп күтәрелеп караса да, ир дәшмәде, машинаның тизлеген арттырды. Күз алдыннан шуышкан кадрлар коточмалы иде. Әллә нинди алагаем эре аппаратларга тоташтырылган әрвах белән бер халәттәге җан ияләре, ак халатларын кан чуарлап бетергән җитди докторлар, аларның кан чәчрәгән күзлек пыяласын сөртеп кидерүче, яру-кисү коралларын кулларына тоттырып торучы шәфкать туташлары, кайчы-пычакның шакы-шокы килүе... Пычрак мамык, марля... Бу хакта сеңлесенә ни әйтә алсын инде ул? Пычакны егет чактан сөймәде, кесәсенә пәке тыгып та йөргәне булмады, бу эшкә дә һич кушыласы килми: аягы тартмый, күңеле теләми иде аның.

– Аллага тапшырдык, сеңлем, – дип куйды ул янә уйларыннан аерылмый гына.

– Аллага тапшырдык, абый...

***

Кайтып керүгә Рәйханиянең тәрәзә төбендәге гөлләргә күзе төште. Әллә ничек боегып калганнар шикелле. Яраннарның да, идәндәге фикусның да яфраклары бөгәрләнеп торгандай тоелды. Чирләп киттеме әллә алар да? Табакка салып чиста су белән чүпрәк алып килде.

– Ни булды сезгә, гөлкәйләрем? – дип, назлы тавыш белән яратып эндәште. Үзе әкрен генә һәр яфракка тукталып тузаннарын сөртте. Чү! Кем килеп бара? Җиңгәсе ич! Әллә нинди, чабышка чыккан атлардай ярсыган, ярсуы алланып бит алмаларына укмашкан эре гәүдәле хатынны күргәч тә, Рәйханиянең йөрәгенә шом төште. Бөтенесен аңлап, белеп торса да:

– Берәр нәрсә булды мәллә, Гөлсәрия апа? – дип сорады.

– Сиңа нидер булган... инде безгә нидер булуын телисең... – диде ул һәм эре кара бизәкле халат кесәсеннән кульяулыгын алып күзләрен, борынын сөртештерде.

– Минем билгеле инде... берегездән дә яшермәдем бит... Хәер, чирне ничек яшерәсең, ди аны?

– Шулаен шулай, Рәйхания, чирен яшергән үлгән, ди. Тик син безнең гаиләгә тимә инде, яме! Ике бала шул бер аталарына карап тора. Икесенең дә институтларда укыйсы килә. Түләүсез нәрсә калды соң хәзер? Беләсең: үземнең дә исәнлегем әйле-шәйле. Аннары нишләрбез без? Гаиләгә тагын бер гарип артудан синең дә сәламәтлегең алга китмәс...

Рәйхания артыгын өметләнмәгәненә куанып та куйды.

– Үзе барды бит... Мин сорамадым... Моны үзем дә теләмәс идем, – дип җиңгәсен юатырга тырышты.

– Ул барыр. Ир-атның аның эш беткән. Гаилә кайгысы юк аларда, эткәләп-төрткәләп тормасаң... Ә безне кем ашатыр аннары? Абыең – кара эш кешесе. Кулында балта-пычкы, кирпеч-измә... Өстәл артында утыручы түгел ләбаса, беләсең... Нәселгә тагын бер гарип арттырмакчысыңмы?

– Гарип калмый, диләр бит табиблар. Бер бөер белән кеше шулай ук яши, диләр.

– Алар әйтер, җаным. Ни дисәң дә, пычак тигән тән дөрес түгел инде ул... Балаларны кеше итәсе бар. Үзе дә гомере буе авыр эштә. Гәүдәсе генә алыптай аның, эчтән черек, бичара. Ир-ат сиздермәскә тырыша да соң... Ярар, күңеленә авыр алма, тимә син безгә, яме!

– Сөйләштек бит инде, җиңги. Кара ачуыңны эчкә йот. Үзе барды, дим, минем ни гаебем соң монда? Аннан минем хәлгә дә кер. Күреп торасың: ябышырга салам эзләгән чагым. Авырганын да белмичә кинәт үлеп киткән кеше бәхетледер дә ул. Ә миңа андый бәхет язмаган. Газапланырга, дару исенә исереп яшәргә

язган. Абыйның ризалашып кан бирергә баруы мине бер генә көнгә булса да, борчуларымнан арындырды. Арыган, таушалган җанымны ял иттерде. Шуның өчен дә иксез-чиксез рәхмәт аңа...

Гөлсәрия чыгып киткәч тә, Рәйхания ни уйларга белми бик озак исәңгерәп утырды. Инде ул болай да он иләгәндә дә, пәрәмәчләрен мичкә куйганда да, авыру хакында гына уйлый иде. Хәтта чишмәгә дә өч литрлы банканы сеткага салып, аягына галош киеп бара... Гомердә булмаганны! Ялт итеп йөри безнең Рәйхания, дип, кайчандыр, сокланып карый иде бит аңа авыл халкы. Ә чишмәнең суын шифалы, диләр. Тутык кран суы түгел шул инде ул, ни дисәң дә...

Рәйхания: «Үз сеңелесе минем хәлгә калса, нишләр иде икән бу җиңги?» дип, аны гаепләргә тырышып карады. Уеннан кире кайтып: «Ул да хаклы лабаса, гаиләсенең бөтенлеге өчен көрәшә икән, бәлки сокланырга кирәктер», дип фикер йөртте. Шулай да ага-җиңгә кулына калырга язмасын, дип белми әйтмиләрдер... Туган энесенә тамчы үпкәсе юк аның. Ике бармак арасына ит үсми барыбер. Ничек кенә, ни рәвешле генә уйласа да, аның хәлен җиңеләйтерлек бер генә җеп калды – ул Володя иде.

Володя соңгы араларда шактый ешлады: илле грамм исә аның теленә генә түгел, аякларына да чыга иде. Рәйхания, капка ачып озатканчы, кеше-кара күрүдән оялды. Эчертә, дип авыл өстенә даныңны сатсалар тагын... Туйга-сыйга эләкте тәмам... Ә икенче яктан, шул зур бистәдә бер кеше дә аңа «Борчылма, сиңа үз бөеремне бирәм», дип килмәде. Шуңа да кире борып чыгара алмый ул аны. Сораганы, үтенече нибары илле грамм лабаса. Күбрәк Фоаты барында килергә тырыша. Икәү бөер хәлләрен сөйләшеп, шәфәкълы кичне караңгы төнгә кертеп җибәрәләр.

***

Рәйханияне төне буена йокы алмады. Абыйсының шәүләсе күз алдында йөри сыман. Авыл җыены исенә төшә. Кызы, улы, Фоаты... Һәммәсенең ярдәм кулы аңа таба сузылган кебек. Төрле-төрле сәбәпләр аларны ярдәмнән читләштерә. Димәк, язмыш шулай куша. Ник? Ә бит аның яшисе килә! Теге салкынча иртәдә, бер кешенең әҗәлен көткәндә, ул дөньяга яңадан тугандай булды. Әйтерсең, әлегәчә һава суламыйча яшәгән. Теге космея-галәм чәчәге аңарда ниндидер, әлегәчә бөтенләй дә таныш тоелмаган якты өмет уятты. «Ташны тишеп чыктым мин дә, чәчәк атам бит менә. Син дә яшәргә тырыш!», дия иде шикелле. Әйтерсең ул чишмәләр челтерәвен, кошлар сайравын бүген генә ишетте. Бу иртәдән соң җир өстендәге барча төшенчәләр дә мәгънәсен үзгәртте. Һәммәсе дә сәламәтлек дигән гап-гади сүзгә килеп тоташты. Сәламәт кешегә боларның мәгънәсенә төшенү өчен вакыт җитми, ә ул югалса, шуңа сарыф ителәсе вакытны үкенеч басып китә икән. Үкенеч! Үкенеч! Ничек күп алар үкенечләр! Тукта! Нишләп үкенеч булсын әле! Яшәлгән кадәр гомерен ул җаны теләгән сөйгән яры белән кичте. Уллары бар, кыз үстерделәр. Йорт төзеделәр. Тынычлап, гөрләтеп яшәп китәсе генә калган иде дә... Бәхет дигәне кителде дә куйды.

Аңа операцияләр ясаган профессор Камал Абрамович үз күреп киңәш бирде:

– Бөер күчереп утырту бик четерекле мәсьәлә. Аны хәл итү мөмкинлеге бик азларга эләгә. Елга унбиш-егерме кешегә тәтегән икән, бу – авыру халыкның бер проценты да түгел. Ышанма син аңа. Гемодиализ – котылгысыз. Бөереңне юдырырга йөрисе булачак барыбер, – дигән иде. – Курыкма, яшисең әле! – дип тә өстәде.

Профессор хаклы булып чыкты.

Әлбәттә, Камал Абрамовичның шулай үз итеп сөйләшүенең Гиппократ антына

һич катнашы юк. Фоаты аны майлаган-җайлаган иде. Бозау ботлары да, казүрдәкләр дә шул тарафка карап очты... Хәер, башыңа хаста килсә, малыңа талау килер, дип белми әйтмәгәннәрдер... Рәйхания уйлап чыгармаган ла моны.

Камал Абрамовичның әлеге гадәтен белгәнгә ришвәт мәсьәләсен көн тәртибенә куеп, профком җыелышы да уздырып караганнар имеш.

– Искиткеч зур сарай төзеп чыктың, улыңа, кызыңа затлы фатирлар алып бирдең, бу кадәр үк ярамас, ахыры яхшы бетмәве бар, саграк бул, дигәннәр. Хәрам бик яман нәрсә ул, дигәннәр.

Ә Камал Абрамович аптыраудан ярымпеләш башын кашып торган да:

– Кем әйтә хәрам дип? Һәр кирпечем рәхмәттән салынган минем. Беркемнән бер тиен сораганым юк, рәхмәт әйтеп, үзләре кесәмә салалар икән, бу ничек хәрамга әверелсен соң? – дип, сорауга сорау белән җавап биргән, ди имеш.

Юк, юк, табибын һич тә гаепләргә җыенмый Рәйхания. Ул гына түгел, кешеләрнең барысы да табибларга ниндидер бүләк бирмәсәң, рәтләп карамаулары да мөмкин, дип уйлый шикелле. Хәер, ак халатлылар үзләре дә шулайрак фикер йөртми микән?.. Әйдә, Аллаһ каршында һәркемнең үзенә җавап тотасы ласа. Аннан биргән беткән. Хәердән китсен. Ярдәме тигән бит, ни дисәң дә. Ни дисәң дә, төп ышаныч, өмет Камал Абрамовичта. Әле тагын да шуның янына барасы. Ә бәлки гомер азагынача әллә ничаклы хаҗәтең төшәр...

Шунысы гына эчен пошыра: авыру көенчә мал асравы бер дә җиңел түгел шул. Ярый, улы ярдәмчел. Хәзер инде ул шактый эшне үз өстенә алды: мал абзарларын чистарта, идәнгә саламын җәя, печәнен сала. Сыер саварга да өйрәнде. Тик әтисеннән абзарга эчке бик ясатты. Дус-ишләренә сыер сауганын бер дә күрсәтәсе килми, хатын-кыз шөгыле дип саный.

Башка эшләрдән алай кыенсынмый, үзенә бер төрле канәгатьлек белән эшли. Анысы апасы шәһәрдән кайтмый калган көннәрдә генә ләбаса инде. Ә шәһәргә эшкә әле ул күптән түгел генә күченде. Таңсылуның үзенең дә күңеле ияләшмәгән. Әнисеннән дә озакка аерыласы килми шикелле. Җомга кич кайтып та җитә.

Әтисе:

– Син үзеңне кара, кызым, монда әниең янында без бар, кирәк эштә булышабыз, – дисә дә, аерым утраудай җирдә яши алмас иде Таңсылу. Әнисе шушы хәлдә булмаса, әле бер хәер. Ә бу хәлендә аны бер атнага түгел, бер сәгатькә дә калдырып китә алмас кебек ул. Көтмәгәндә шәһәргә күченүе дә мәҗбүрият аркасында гына. Һич уйламаганда, бухгалтериягә эшкә чакырдылар. Бүгенге заманда эш табу җиңел түгел. Шуңа да әтисе дә, әнисе дә тәкъдимне кире какмаска кушты.

– Минем авырудан арынып торырсың, сау-сәламәт кешеләр янында башкачарак булыр, бераз сулыш алырсың, балам, – диде Рәйхания, кызы өчен ихластан шатланып.

Ул белә: кызы аның авыруы аркасында балачагын күрмәде. Әни генә үлмәсен дип, дер калтырап яшәде. Мәктәптән очар кош кебек атылып кайтып керер иде дә сумкасын ишек төбенә атып, бүлмәләр буйлап әнисен эзләп йөгерер иде.

– Мин исән, кызым, кан басымын төшердем менә. Рәхмәт инде бу дару уйлап табучы затларга, – дия-дия кухняга юнәлерләр иде икәүләп. Өстәлдә чәйнек чыжлап утыра, алюмин табада коймаклар йөзә. Үзенә майлы ризык ярамый. Ә кызының сыйланганын карап утыру ничекләр рәхәт!

Рәйхания тәрәзә аша зәп-зәңгәр күкләргә төбәлде. Абау! Кояш көлеп тора, күк читенә эленгән нәни генә болыттан тамчылар сибелә түгелме? Хатын: «Аһ шушы ак болыт булсаң икән ул!» дип уйлап куйды. Кызының һәммә борчуын юып алыр иде, күңелендәге ташны эретер иде бит...

Гаиләсен үз авыруына каратып кына яшәтәсе килми Рәйханиянең. Тик башка чара юк, нишләсәң дә, барча җепләр чиргә килеп тоташа.

Инде менә буй җитте Таңсылу. Дуслары кичләрен клуб юлын таптый. Танго, полька, вальс, татар, рус биюләрен биергә өйрәнәләр. Урамнардан җырлашып узалар. Ә кыз беркая да чыкмый. Ул курка: клубтан кайтып җиткәнче әнисе үлеп китмәгәе... Калыр аннары үкенечкә... Ә еллар үтә тора. Рәйхания үзе дә: «Утырып кала күрмәсен инде бу бала», – дип борчыла. Борчуы елдан-ел тирәнәя. Кызының язмышына авыруының йогынтысы барлыгын белмимени ул?!

***

Рәйхания зал ягында газетлар караштырып утыра иде. Хәзер ул вакыты кысан чагында да вакытлы матбугатка күз салгалый. Медицина өлкәсендә бер-бер ачыш ясамаганнармы, бер-бер яңалык юкмы, дип һәр язманың башын карап чыга. Медицина алга бара, һәм ул кешеләрне һәммә чирдән дәваларга сәләтле булачак, дип ышана. Әле ул алгарышлар хакында язып кына өлгерә алмаганнардыр, әлбәттә, һичшиксез язачаклар, дип уйлый. Фотолар арасыннан Камал Абрамовичны эзли. Бер-бер яңалык җиткерер кебек тоела.

– Уз әйдә, Володя. Уз, туганкаем.

Зал ягында өстәлгә шапылдап каты җисем килеп утырганны ишетеп, Рәйхания колакларын шомрайтты. Стаканның стаканга тигәне, ирләрнең бердәм:

– Рәйхан өчен! – дигәнен искәрде.

– Нишлисең, бәла көтмәгәндә килә шул. Ә шулай да борчылырга кирәкмәс. Минем бөерләр икәү ич. Хәзер инде яшь чак түгел, көрәшкә чыгасы юк. Мич башында ятарга аның берсе дә җитеп ашкан. Бирәм мин берсен Рәйханга! Әйе, подарить итәм. Истәлеккә-бүләккә. Рәхәтен күрсен әйдә!

Фоатының стаканнарга хәмер койганы ишетелде.

– Бүләк итәм дисең дә... ышанып буламы соң сиңа, Володя?

– Йә, әйт, кайчан минем ялган сөйләгәнем бар? Менә хәзер үк китә алабыз. Күрәсеңме, күлмәктәге күбәләкне! Исләре китсен Гиппократ оныкларының. Интеллигент дисеннәр!

– Юк та инде. Барыбер җиңел хәл түгел. Кесәдән генә алып бирәсе булса икән.

Володяның янә үз кирәген эзләп килеп җитүенә бераз күңеленнән ризасызлык белдереп, пошынып та куйды Рәйхания. «Сәрхушлыгы артыкка китте бугай, исеректән нидер өмет итү дөрес микән соң?» дип, үз-үзен битәрләп тә алды.

Залны дер селкетерлек калын тавыш белән җыр башладылар: «Расцветали яблони и груши...»

«Боларның эш беткән», – дип фикер йөртте хатын. Боларга бер дигән сәбәп булды минем чир. Рәхәтләнеп эч кенә!

Ул арада ишек бар куәтенә ачылып, аннан Маргарита килеп керде.

– Глянь, чье делается-то! Эт җан! Син бүген дә мондамы? Бөер бирә имеш! Аннары кем карар үзеңне?

Маргаританың чыелдык тавышы бөтен өйне тутырды. Әйтерсең, ирен җинаять өстендә тотты. Ул тавышта ризасызлык та, хуҗаларны гаепләргә тырышу да, канәгатьсезлек тә бар иде.

Яннарына кыенсынып кына Рәйхания чыкты.

– Глянь чье делается! Рәйхан, син өйдәмени? Ник куып чыгармыйсың боларны? Ник бар ясап ятасың өеңдә? О-о, күбәләк таккан имеш... Килешә инде бик... Каян табып кидең әле ак күлмәгеңне, ә? Әнә рәис килгән иртүк: ирең тагын эшкә чыкмады, ди. Рәйханнар йорты тирәсендә бутала, ди...

Бу сүзләр Рәйханиянең күңелен тырнап үткәндәй тоелды.

– Ярар, кызма әле, Рита! – дип сүзгә кушылды ир. – Кызмале син алай. Кешеләргә ник болай үрә карыйсың, кадерлем. Менә үзеңә дә бөер кирәк булды, ди. Кем бирә сиңа? Ә болай Фоат, һичшиксез, бирәчәк. Син – миңа, мин – сиңа, пнимаешь! Гиппократ оныклары ала да куя...

– Бирәм, бирәм... – дип сүзне җөпләде Фоат.

Маргаританың саллы йодрыгы өстәлгә килеп төште. Стаканга стакан тиеп чыңлаган тавышка буйсынып, ярым буш шешә чайкалып китте.

– Рәйхан, китер әле шуңа бер стакан! Әйдә, кызма, Риточка, салып бирәм сиңа да. Юкка гына сине «Рита-информ» дип йөртмиләр авылда... Ишетми каласыңмыни инде бу хәлне?!

Рәйхания шкафтан алып, кырлы стаканны өстәл өстенә куйды. Володя ашыгып ачы су койды. Маргарита стаканга үрелгәндә, янә янап алырга өлгерде.

– Бирермен мин сиңа бөер! Ә гаилә нишләргә тиеш? Болай да гарип бит инде син! Алкоголик! Сыгып алырлык булгансың ич...

– Йә инде, кызма инде, Риточка! Агу йоткан заттыр син, әй... Миндә икәү бит алар. Бирәү генә булса, кызганыр да идең... Икенең нәрсәсен кызганасың?

Хатын стаканны җәһәт кенә каплап куйды да сүзен дәвам итте:

– Сыра эчә-эчә әллә берсе эшләми дә торгандыр анда. Врачка барган кешеме син, ә? Йөрисең шунда гомер уздырып, чабата туздырып.

– Ник барыйм, үзең врачтан һич ким түгелсең лә, шулай бит, Рәйхан?! – Ир Рәйханиягә күз кысып алды.

Рәйхания ни дип әйтергә дә белмичә ишек яңагына сөялеп, тамашаны күзәтте. Кешеләр турында һаман яхшы уйлап, нинди хәлләргә төште ул. Тагын ялгыштымы инде? Башлап үзләре тәкъдим итәләр ләбаса... һәм кыен хәлдә калдыралар. Рәйханияне дөньяның бер тинтәге итеп бетерделәр тәмам барлы-юклы бөерләре белән.

Ул арада Маргаританың йөзенә кызыллык йөгерде. Ирен мизгел эчендә якасыннан эләктереп алды да ишеккә таба алып китте. Володя карышты:

– Җибәр, Риточка! Әйдә, синеңчә булсын! Рәйхания табар әле, берәрсендә бәлки өчәүдер ул? Кем тикшертеп торган аны... Ә, Фоат, син аптырама, хатын-кызның теле – беркайчан да тутыкмас кылычы ул аның... Кытайлар шулай әйткән....

Ир сөйләнә-сөйләнә, әвеш-түеш килеп, хатынының йодрыгы астында ишек ягына атлады.

– Гафу итегез мине, Рита. Үзе тәкъдим итеп килде бит... Бәлки ярамаган да булыр иде әле. Тикшертмәдек тә бит. Борчылма, зинһар...

Ишекне япкач та Маргаританың яңгыравык тавышы тынмады:

– Йөрисең шунда урам ташын шомартып... Исерекбаш...

Ак күлмәк, ак чалбар киеп, ак күлмәгенә кара күбәләк таккан, аягына арты ертык галошлар кигән ирнең хатыны йодрыгы астында тузан дуылдатып кайтып баруы эчке елмаю уятса да, Рәйханның иреннәре тораташтай каткан иде. Ул, башын аска иеп, хәсрәт диңгезенә баткан Фоатына күз төшереп алды. Икесе дә бер сүз дәшмәделәр. Хәер, ни дип дәшәсең? Анысы да монысы, бер йомырка ватылды дигәндәй, тагын барып чыкмады... Шуңа һәммәсе сүзсез дә аңлашыла иде.

***

Язның бөреләргә тулышкан җылы, кояшның нурларын көлтәләп кенә койган бер мәлендә Фоатны армиягә озатты Рәйхания. Кулъяулыкларга уралып, бер-берсенең иңнәреннән кочышып, җырлашып йөргән егетләр капка төпләренә җиткән саен йөрәге урыныннан кубарылды. Тәрәзәдән качып кына, егетләр

уралган кулъяулыклар арасыннан үзе чиккәнен эзләде. Тапты. Нәкъ Фоатның күкрәк турысында иде анысы. Күңеле булды. Күңеле тулды. Ә җыр ул хисләрне тагын да тирәнәйтә, җанга моң-сагыш өсти иде:

Әнкәй, ашың пешкән чакта
Балаларың җыелыр.
Алар булып, мин булмасам,
Канлы яшең коелыр...

Егетләр бу юлысы һәр өй каршысына тукталдылар, һәр өйгә керделәр. Артларыннан чапкан бер көтү бала-чага йортта басып калды. Аларны куып таратырга тырышучыларның куйган көчләре җилгә очты.

Өйдә әти, әни бар, әби, бабай бар, егетләр шулар белән саубуллашып чыктылар. Әни-әбиләр алар җанына мәрхәмәт салырга, аталар көч-гайрәт өстәргә, ил картлары тәҗрибә уртаклашырга өлгерде. Рәйханиянең күзе Фоатта булды. Әтисе үз итеп аның җилкәсеннән какты. Бабасы – зур яуларны кичеп кайткан юка бәдәнле карт: «Смирно! Үрә кат!» дип команда бирде һәм «Бервакытта да шәлперәймә», – дип теләген әйтте. Егет үрә катты.

– Әни, мәрхүм, минем кулымны онга мандырып матчага куйдырган иде. Имеш, шулай итсәң, исән-сау әйләнеп кайтасың... Дөрестер, ут эченнән дә кайттым бит менә, – диде карт, көләчлеген йөзенә чыгарып.

– Мин ипине тешләдем, әни шуны сандыгына салды. Мин кайтканны көтеп торачак ризыгым... – дип, сүз кырын киңәйтеп җибәрде Фоат.

Әлбәттә, егетнең бабасы каршында нарат кук төп-төз торуы Рәйханга да ошады. «Тормыш бөгәргә теләгәндә дә шәлперәймә!» дип кабатлады кыз да һәм бабасына яратып карап алды.

Фоатына исә аерылу гаме, ил саклау гаме кергәнлеге сизелеп тора, егет олыгаеп киткән иде.

– Иртән мине озатырга килерсеңме? – диде егет, чыгып барганда җай табып.

– Килермен.

Ул төнне егетләр йокы күрмәде. Рәйхания белән очрашырга Фоат көчкә җай тапты. Капка төпләренә килеп сызгырганны көтеп кенә торган икән кыз да. Егет янына уктай атылды. Аның күзләре кызарган, еш-еш йөрәк тибеше ишетелеп тора иде.

Ул кич айлы, болытсыз иде. Иләс җил сүз җыя, аларны тарата-чәчә, гашыйкларның күңеленә кагыла, чәчләрен чуалта, уйларын тарката иде. Беренче мәртәбә Фоатның кайнар иреннәрен тоюдан һушын җуйгандай булды кыз. Татлы иде бу кич. Табигать дулкынланып яз халәтен кичерә. Тирә-юньдә яшь каен яфраклары лепердәшә, аларның хуш исе башларны әйләндерә, сулыш юлларын киңәйтә...

Ә җыр якыная бара:

Аерылабыз, аерылабыз,
Аерылабыз, каласың...
Мин киткәчтен кемнәр яклар
Син – сандугач баласын...

– Миңа кушылып китәргә кирәк булачак, Рәйхан. Якынлашалар әнә. Йә, әйт, син мине көтәрсеңме?

– Көтәрмен.

– Дөньясына ут капса дамы?

– Су басса да...

Иреннәре янә иреннәргә үрелде. Ә җыр инде тәмам янәшәдә үк ишетелә иде...

Иртәгесен егетләрне алып китәсе машина бөтенесе дә җыелып беткәч кенә килде. Аналар күз яшьләрен тыя алмады. Рәйханиянең бабасы – күпне күргән ил карты әйтте:

– Безнең Армия тел-теш тидерерлек түгел, җәмәгать. Армия яхшы армия булмаса, бу егетләрдә шундый оптимизм була алыр идеме? Һаман кыйнап тора торган армиягә беркемнең дә барасы килмәс шул...

Хатыннар күз яшьләрен сөртеп, кулъяулыкларын кесәләренә шудырдылар...

Рәйхания дә халык арасында күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып басып торды. Күзләре очрашканда, алар икесе дә өнсез калгандай, хәрәкәтсез затларга әвереләләр иде.

«Көтәрсеңме?» – дип сорый иде күзләр.

«Көтәрмен, кадерлем», – дип җавап бирә иде Рәйхания.

Машина кузгалып китте. Күпләрнең бәгыреннән иң-иң газизләрен кубарып алып, алга ыргылды ул. Егетләр карандаш чәчте. Бу аларның: «Безне онытмагыз, хат языгыз!» диюе иде. Рәйхан да иелеп бер карандаш алды һәм башы әйләнүдән чайкалып китте. Аерылу тойгысы күкрәк читлеген әрнетеп кыскандай тоелды. Иреннәрен тешләп гәүдәсен турайтты. Әбисе исенә төште. Ул аның бабасын нәкъ шушы урыннан яу кырына озатып калганын белә иде...

***

Алар икәүләп берәүнең әҗәлен көтәләр... Рәйхания куырылып куйды. Ул көтми инде, ишектән кош тоткандай, үзе дә аңлый алмый торган куанычтан тәмам исереп чыгып бара. Коридорның яртысына җиткәч нидер онытып калдырган кешедәй кинәт кире борылды. Хәсрәттәшләре янына килде.

– Сезнең исемегезне дә сорамаганмын бит. Менә шундый таркау бер җан иясенә әйләндем инде мин хәзер...

– Әйе шул. Гөлнар булам. Ә сез?

– Рәйхания.

Хатын аңа гаҗәпләнү тулы күзләре белән шактый текәлеп торды да:

– Ә нигә сез шулхәтле шатланасыз? Соңгы өметне югалту куанычмыни инде ул? – дип сорап куйды.

– Белмим. Үзем дә белмим. Бәлки, операция дигән сүздән туйгангадыр? Бәлки, күңелем чит бер кешенең үлемен кабул итәргә теләмидер? Аның бөере миндә йөрүен теләмидер...

– Бәлки... – диде хатын һәм башын аска иде.

Ул арада коридорда янә шәфкать туташы күренде.

– Иванов, керегез әле безнең янга.

Ир кеше көрәктәй куллары белән янә йөзен, башын сыпырып төшерде. Үзалдына:

– Шайтан алгыры! Яшисе килә шул! – дип пышылдады.

– Сез миңа телефоныгызны бирмәссез микән?

Исәңгерәп утырган хатын сумкасыннан блокнотын тартып чыгарды. Тигез итеп саннарны бер рәткә урнаштырды. Язулы битне шатырдатып ертып алды да Рәйханиягә сузды:

– Шалтыратыгыз!

– Уңышлы булсын. Кайсы ягы хәерле, шулай хәл итсен Аллаһы Тәгалә...

– Амин!.. Яхшылыкны көтәргә кирәк шул аны. Әгәр дә борылып китмәсә...

Рәйхания соңгы җөмләгә һич игътибар итмәстән, өстендәге тауны селтәп аткандай бер җиңеллек тоеп, ныклы адымнар белән алга атлады. Урамда аны Фоаты көтеп тора. Күз алдында нык таҗлы космея – галәм чәчәге, үзләрендә дәвалаучы табиб Камал Абрамович, кызы, улы буталды. Әҗәл белән көрәшеп ятучы ир заты да, агымлы шәфкать туташлары да, сакал-мыеклы илгә бер хирург та кайлардадыр томан арасында юкка чыктылар шикелле тоелды. Ул алга атлый иде. Хәзерге мәлдә авыруын да оныткан иде.

Фоаты аны аптыраулы карашлары белән каршылады:

– Нигә кош тоткандай елмаясың? Берәр өметле сүз әйттеләр мәллә? – дип сорап куйды.

– Әйтмәделәр. Минем анализлар ярамады, каннарыбыз туры килмәде, ойый да китә, ди, теге кешенең канын кабул итәргә дә организм әзер түгел, күрәсең...

– Табиблар шулай, дидеме?

– Шулайрак әйттеләр инде. Ә теге кеше, шөкер, минем алда үлмәде. Бәлки терелеп тә китәр әле. Ни дисәң дә, имәндәй ир бит. Әнисе, хатыны, балалары бардыр... – Хатын тынып калды. Аннан өстәде: – Менә минем өчен барыгыз да ничек чәбәләнәсез. Ул да кеше бит...

Фоаты тамак кырып кына куйды. Юлдагы сикәлтәләрне урап-урап үтәргә тырышып җилдерүен белде. Шактый сүзсез барганнан соң:

– Һаман кешене кызганасың, матурым, үз хәлең хәл икәнне бер дә чамаламыйсың инде син, – дип, хатынының кулын сыңар учына кысты. – Нишләрбез инде хәзер?

– Үлмим мин барыбер. Аллаһыдан гомер сорармын. Аннан Камал Абрамович әйтте бит, иң ышанычлысы – гемодиализ диде. Мәшәкате күп, әмма яшәргә мөмкин, диде. Иртәгә үк аның янына барырбыз. Башка берни дә эзләмибез, тоташтырыгыз мине шуңа, диярмен. Мин Сезгә ышанам, соңгы өметем сездә, диярмен. Минем яшисем килә, диярмен.

***

Фоаты армиядән кайткан ул язда каен яфракларын җилбер-җилбер китереп җылы җил исте. Тузганак чәчәкләрен җыйган бер бала-чаганы кисәтте Рәйхания:

– Бу – җил чәчәге, өзмәгез сез аны, югыйсә җил генә түгел, давыл чыгарырсыз, – диде. Тик иртә язда кайсы кыз баланың кулына чәчәк тотып карыйсы килмәсен икән? Шулай да давыл чыкмады, йомшак җилбер җиле белән бәхет, куаныч алып килгән яз булды ул. Чөнки аның Фоаты кайтты! Кайткач та, кич Рәйханияләргә килде. Тәрәзә аша өй эчен күзәтте. Әбисе артка чүккән, бабай бөкшәя төшкән, әти-әнисе дә шактый таушалган кебек күренде. Ә Рәйхания менә пешкән кура җиләге! Йөзләреннән алсулык бөркелә, иреннәре дә калынаеп киткән: үзенең балачактагы алсу бантигын хәтерләтеп торалар.

Рәйхания дә янына чыгуга егеткә игътибар итте: зур куллар, киң җилкә... Йөзендә гамь арткан сыман... Тагын да чибәрләнгән...

Фоат инде армия хезмәтен үтеп, лаеш шулпасы ашап кайткан, дөнья күргән егет иде. Беренче очрашуда ук алар өйләнешеп авылдан чыгып китәргә карар кылдылар. Туйларны да озакка сузмаска булдылар. Нининдидер яшелчә совхозы барын ишетеп беләләр, имеш анда эшче куллар җитешми, ди...

Инде ул чаклардан соң ни гомерләр үткән. Күпме җилләр искән. Алар Рәйхания белән Фоатның бәхетле дә, борчулы да көннәрен үзләреннән ерагайтып алып китеп торганнар. Тагын менә язның йомшак җилләре баш өстендә җилферди. Ниләрне искә төшерергә тели соң ул? Гомер бер генә дип искәртмәкчеме? Яшәүдән туярга ярамый, димәкчеме? Юк, юк, тормышны яратып яшәде Рәйхания. Бөтен җаны-тәне

белән, күңелендәге юшкыннарны күз яшьләре белән юа-юа яратты. Ирен яратты. Ә теге җилбәзәк хатыннан калган юшкынны юып ташларга аңа Маргарита ярдәм итте. Володяны гаилә буразнасыннан чыгара язган Люся хакында сөйләштереп алган иде авыл. Җаен туры китереп Рәйхания шуны искә төшерде.

– Үзеңнеке дә туры юлдан гына йөрүче түгел, кичергәнсең бит, – дип куйды.

– Ә мин бу хәлне башыма да кертмәдем. Нигә ниндидер әтрәк-әләмнәр өчен исәнлегемне исраф итим әле мин, кем тәртәдән чыккан, шул кайгырсын, – диде дә рәхәтләнеп көлде Маргарита. Авыр минутында, сәламәтлекне уйлыйсымы, ирнеме, дигәндә, бу сүзләр Рәйханиягә ныклы терәк булды. Уйлары чалшаеп киткәндә, хәзер Маргаританы гына исенә төшерә. Һәм яшисе килә аның. Сусавын басарга чишмә эзләп килгән юлаучы шикелле үз сукмагыннан бара да бара. Әле дә шундый ук халәт кичерә. Авыруы катлаулана, сәламәтлеге какшый төшсә дә, яшәүдән һич тә бизгәне юк аның.

***

Рәйхания төнлә уянып уйланып ятты. Нигә керде аның төшенә теге космея – галәм чәчәге? Таҗларын катырып күккә үрелгән көенчә, һаман тәпиләрен кыскан ташны күрмичә дә басып тора. Ул да тере җан бит. Тоя. Түзә. Яши.

Иртүк торып Камал Абрамович янына барасы бар. Аның хәзер бер генә өмете калды. Камал Абрамович аның соңгы ышанычы. Ә ул мәрхәмәтле. Бер кат та аңа: «Юк. Булмый» дигән сүзләрне әйтмәде. «Сез әле яшәячәксез!» – дип ышандырды. Шушы бер сүз аны иң катлаулы хәлләрдән, иң авыр сынаулардан алып чыкты. Рәйхания инде хәзер, беркемнән берни өмет итмичә, табибын тыңлап яшәргә риза иде... Фоаты гына исән булсын. Балалары гына сау булсын.

Тукта! Ул бит әле Гөлнарга шалтыратмады. Вәгъдә иткән иде ләбаса. Кинәт өчәүләп берәүнең әҗәлен котеп утырган мәлне исенә төшереп, бөтен тәне куырылды. Кулы телефонга үрелгәндә, җиңелчә калтырый иде. Аны өстәл почмагына шудырып, сукыр кычыткан төнәтмәсе эчте. Янәдән телефонны алып, хатынның номерын җыйды. Үзе: «Безнең өчебез арасында иң бәхетле заттыр инде бу», дигән эчке көнләшүен куарга тырышты.

– Алло, Гөлнар!

– Исәнмесез, Рәйхания. Тавышыгыздан таныдым сезне.

– Сез хастаханәдән чыкмагансыздыр, дип шалтыратмый тордым...

– Кермәдем дә әле. Теге кешенең бөере беребезгә дә насыйп булмады шул. Аны баш миеннән алдарак үлгән, диделәр табиблар. Ә үле әгъзаны күчерү мөмкин түгел, ди. Шундый хәлләр дә очрый икән...

Рәйханиянең төсе бетте. Ничек инде? Әгъза була торып, аны беркемгә дә куярга өлгермәсеннәр инде? Табиблар гаепле түгел шул инде монысына. Теге кеше дә кызганыч, үлгән икән барыбер дә...

Гөлнар исә үзенекен сөйләде:

– Миңа Камал Абрамович исемле бер докторның адресын бирделәр. Бик гыйлемле табиб, ди. Теге ир дә, Иванов идеме әле фамилиясе, шуңа барам, диде. Кулы алтын, ди. Операцияләре һәрвакыт уңышлы чыга, ди...

– Минем табиб ул. Килегез әйдә, – диде Рәйхания гаҗәпләнү катыш горурлану аша. Һәм кинәт хәле җиңеләеп киткәндәй тоелды. Сабыр гына эчтән: «Минем яшисем килә!» дип пышылдады. Бу аның үз табибына янә бер кат әйтәсе сүзләре иде.



Сания
Әхмәтҗанова

# КҮҢЕЛНЕҢ ҖЕГЕНДӘ МОҢ-МӘКАМ ЯРАЛА

## Иман таммас димә

Нинди бизмәннәрдә үлчәдең син
Намусың һәм даның-малыңны?
Үлчәү тәлинкәңнең кайсы басты,
Һәм кайсына суздың кулыңны...

Сиңа вөҗдан сукыр бер тиенме,
Байлык-маяң – килер көнеңә?
Ата малы – бала даны, диеп,
Хөкем чыгардыңмы дөнеңә?

Катыйль булдың, татар, үз-үзеңә,
Күндәм тезләндең бит тезеңә!
Еллар аша ничек багарсың син
Телсез «әпә»ләрең күзенә?

Гафу итми тарих сатлыкларны,
Чияләнеп төен төйнәлә.
Җиде түгел – җитмеш буынында
Кара сакал булып сөйрәлә.

Хет бер тамчы иман таммас димә,
Татарлыгың кысып учласаң...
Син халкыңны санга сукмадың, ди,
Әл-Халиктан[1] курык ичмасам.

[1] Әл-Халик – Аллаһның 99 исеменең берсе, бу дөньяны бар итүче дигәнне аңлата.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА (1962) – *шагыйрә; «Оч иреккә, җырым!», «Пар алма», «Гәрәбә» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

## Чорыбызның бөегенә

*Чын шагыйрь, Иман биеклегеннән торып, дәверләр аръягына сүз йомгагын чөя алган икән, аны дәвер ызаннарында кузы калган учак көле арасыннан Вакыт кайтып күтәреп ала да Мәңгелек бишегенә сала.*

Марсель Галиев. «Шигърият рухы»

Минем сүзем – Сиңа хак-бәянең
Киләчәктән бары алхәбәре.
Минем хисем – сүз кодрәтең танып
Табынуның бары беркадәре.

Синең сүзең – балбаллардан башлап,
Хак иманга кадәр китергән юл.
Синең хисең – Чатыр тауның җилен
Бөек симфония иттергән кыл.

Шам кылычтай сизгер тынлы ул кыл –
Мәнсез сүзне теләә орынмыйча…
Үчлеләрне үчектерә килдең,
Фикерсездән зекер соранмыйча.

Таш атканга, аш та, таш та түгел,
Каләм белән бәрдең, сын катарлык.
Син бер адым алдан әйтәсең гел –
Әүлиялек көчең шаккатарлык.

«Атилланың горур оныклары –
Татарларым», диеп язган каләм,
Тел рухына Милләт рухын баглап,
Килер буыннарга илтә сәлам.

Саф «Догалы еллар» аятеннән
Күпме бөекләрнең рухы шаттыр.
Башкаларны күккә чөя-чөя,
Үзең онытылдың, дию хактыр.

Синең исем чорлар аша калкыр,
Сүз-сүрәңнән балкыр милләт йөзе.
Синең сүзең – гасырларны кичеп,
Көчен җуймас Пәйгамбәрләр сүзе.

## Юлчылык

*Шагыйрь Рәмис Аймәткә*

Ерак сәфәр безне якынайтты,
Дуслаштырды шигъри юлчылык –
Төрки дуслар дәшкән зур мәҗлескә
Ике шагыйрь киттек юл чыгып.

Казакъ даласында казандык без
Иман биеклеген яңадан.
Балбал ташлар җиргә ныграк иңде
Без китергән сәлам-догадан.

Синең янда насыйп булды миңа
Дан-хөрмәтнең бер уч җылысы.
Чиккән калфак, болгар читегемә
Баш иделәр кече-олысы.

Уздык икәү хисләр алкышында
«Ефәк юлы»дигән келәмнән.
Әхмәт Ясәвинең төрбәсенә
«Тимерказык» бакты галәмнән...

Төркестанның шигъри мәйданында
Шагыйрь дуслар алды уратып.
Очкын булып тамды татар сүзе,
Кардәшлекне канда уйнатып.

Көнчыгышның гамен сискәндереп,
Яңгырады татар шигыре.
Төрки тамырларга куәт бирде
Яңа буын татар шагыйре.

«Татар түгел – бары татар гына!»
Шушы сүздә мең-мең хаклык бар.
Шигъри түгел, төрки мәйданында
Өмет баглый безгә халыклар.

## Бу мин!

Күңелне кузгатты иртәнге шау кояш,
Талчыккан канатлар җанлана иңемдә.
Кемгәдер – бигайбә! Тик гафу сорамыйм...
Үземә хыянәт италмыйм бүгенгә.

Ымсынам кабаттан күкләрне кочарга,
Дәртем дә, дәрман да бу юлга җитәрлек.
Күңелнең җегендә моң-мәкам ярала –
Юл чыгар алдыннан догалык итәрлек.

Бу очыш соңгысы булса да үкенмим,
Гарешкә төбәлдем: «Мең шөкер! Мең рәхмәт!»
Кисәтеп, өн килде: «Канатың көймәсен!
Кыйблаңны үзгәртмә, килсә дә кыямәт».

Канатлар, киерелеп, җил көчен сынады,
Бирелгән карардан ваз кичү икеле.
Мин, янып төшсәм дә, бәхетле китәрмен,
Очышта җан биргән чал бөркет шикелле.

## Мамыксыз заман

Каз өмәсе якынлашса,
Күңел никтер боега.
Почмакка өйгән мендәрләр
Рәнҗегән күк тоела.

Искә төшә каенанамның
Бастырганы мендәргә,
Баллы-майлы фатихасын
Юллап килер көннәргә.

Бәби мендәре китерде –
Оныкларына бүләк.
Бисмиллалы булсыннар дип,
Изге теләкләр теләп.

Уйлыйм-уйланам да шулай,
Сызлана бәгырькәем.
Әй мендәрем, мендәр генәм,
Бетте шул кадеркәең.

Ясалма түшәк-ястыкта
Яссыланды күңелләр.
Гадәтләр яши-яшәвен,
Тик самими түгелләр.

Халкымның күңел бизәге –
Чигүле мендәр тышы –
Музейханәләрдә генә
Дан-дәрәҗә тотышы.

Хәтер сандыгын тузгыттык,
Саналмыйк дип зәвыксыз.
Әллә шуңа күңелләр дә
Шырпылымы – мамыксыз.

Алыштырдык бәз сүрүне,
Заманадан калмаска.
Ясалма түшәктә шыткан
Буын килде алмашка.

Әй мендәрем-мендәркәем,
Кузгаттың күңелемне,
Искә төшердең минем дә
Мәңгелек түгелемне.

Каурыйларга җан кермәс ул,
Канат кушып утырып.
Куйыйм булачак оныкка
Мамык мендәр тутырып.

## Сагынмаклык

Җылы тәннәреңдә тузсын диеп,
Бүләк иткән идем йон күлмәк;
Күпме генә киде, әниемнең
Төсе булып калды бу бүләк.

Билләре дә инде таман гына –
Олыгаям мин дә отыры.
Якасына, җете төсләр сайлап,
Бизәк чиктем төннәр утырып.

Арчалардан алган читек белән
Бәрхет калфак кисәм килешер.
Күлмәгемә (әллә яшькә?) күрә
Ыспай гына атлап килешем.

Бисмиллалап, саклап кына киям,
Әни сыман, бары кешелеккә.
Яшел күлмәк – сагынмаклык төсе,
Һәм мәрсия... минем яшьлеккә.

## Алтыным

Яшьлеккә бит ялгышулар килешә:
Мин алтынны тиңләгәнмен көмешкә.
Син – өлешкә чыккан диеп, көмешем,
Үзем язган язмыш белән килештем.

Хаталандым, үз-үземнән алдандым,
Ялгышуым яши-яши аңладым.
Кичер мине, сиңа бераз кичектем,
Ярый әле, ярый, соңга калмадым.

Ул югалган еллар өчен үч итеп,
Яшим, димим, үземне яшь хис итеп,
Юк, сагынмыйм тәүге гашыйк чагымны –
Көзге учак дөрли-дөрли кабынды.

Авыз иттек соң өлгергән алмадан,
Гашыйк булдык бер-беребезгә яңадан.
Хак бәяне бирде бүген акылым:
Көмеш түгел, син минем саф алтыным!

Фәрит
Имамов

# ВАКЫТСЫЗ ВАКЫТ...

ФАНТАСТИК РОМАН

* * *

Южный бистәсе башкарма комитетына тайга өстендә төтен күренү турында хәбәр иттеләр. Төтен чыккан урын шул тирәгә урнашкан Күчкән Сала авылыннан түгелме икән, дигән шик тә белдерде хәбәр итүче. Дөрес, шундый ерак арадан төгәл урынны чамалау кыен. Шуңа күрә, хәлгә ачыклык кертү өчен, урман хуҗалыгы җитәкчелегенә шалтыраттылар. Алар Күчкән Сала белән рация аша элемтәгә керергә азаплансалар да, булдыра алмадылар. Бу элемтә чарасы инде менә берничә көн эшләми. Мондагы аппаратураны белгечләр кат-кат тикшереп карасалар да, бернинди гаебен тапмадылар. Элемтәнең теге башындагы аппарат көйсезләнгән, күрәсең. Әлегә кадәр белгечләрне анда җибәреп тикшертергә мөмкинлекләре булмады. Махсус техникадан башка анда барып керсәң, тиз генә чыгармын, димә.

Урманда янгын чыгу бик күп бәла-каза китерә. Әгәр вакытында чарасын күрмәсәң, киң мәйданнарга җәелеп, соңыннан аны сүндерү өчен көч һәм чыгымнар таләп ителә. Шуңа күрә бу вакыйга турында кичекмәстән Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына җиткерделәр. Ә мондый очракларда, устав кушканча, якындагы янгын сүндерү частена һәм югарыдагыларга хәбәр бирелергә тиеш.

Гадәттән тыш хәлләр буенча край комитеты башлыгы урынбасары Игорь Добровның бик мәшәкатьле чагына туры килделәрме, аның тавышында ризасызлык галәмәте сизелде:

– Ул авыл белән элемтә бардыр бит? Белешегез! – диде җитәкче, шуңа да башыгыз эшләми дигән шикелле киная белдереп.

– Бөтен хикмәт тә шунда шул, Игорь Ильич. Алар белән рация аша гына элемтәгә чыгарга була. Ә ул, үч иткәндәй, инде менә берничә көн эшләми. Нишләргә белгән юк, – дип аклана башлаган инспекторны Добров тиз туктатты.

– Мин хәзер сезгә барып, рациягезне дә көйләп йөри алмыйм бит инде. Үзегез җаен табыгыз, элемтә урнаштырыгыз. Бу эшкә посёлок башкарма комитетын җәлеп итегез. Берничә километр ераклыктагы авыл белән элемтә дә урнаштыра алмагач, нишләп утырасыз анда? – диде югарыда утыручы түрә, һәр сүзе саен үзенең өстенлегенә басым ясагандай.

Инспектор ник хәбәр иткәненә үкенде. Тик беркая да барып булмый. Юкса

*Ахыры. Башы узган санда*

андый-мондый җитди хәлләр килеп чыкса, ник устав кушканча эшләмәдегез дип, җавапка тартып куюлары да бар. Шуңа күрә ул бары тик аклангандай:

– Күчкән Сала бездән бер-ике генә түгел, 50 чакрымлап ераклыкта... Посёлок башкарма комитеты бу хакта хәбәрдар инде, – дип авыз эченнән ботка пешерде.

Телефонның теге башында, озак кына көттергәннән соң, бераз йомшарган тавыш белән:

– Ярар, берәр нәрсә уйларбыз. Безнең белән элемтәдә торыгыз, – диделәр дә трубканы куйдылар.

«Берәр нәрсә уйлау» өчен күпме вакыт таләп ителәчәге билгесез. Һәрхәлдә, ишеттеләр дә чыгып йөгерделәр түгел. Андагылар ашыкмый. Югарыдан торып, башкаларга әмер биреп утыруы гына җиңел ул. Ә эшкә килеп төртелгәч, әле теге, әле бу сәбәп чыгып кына тора. Шуңа күрә инспектор аларның тиз генә кыймылдый башлауларына өмет тә итмәде. Чыннан да, берәр сәгать узганнан соң гына, край комитеты идарәсеннән кабат шалтыратып, Күчкән Сала тарафына вертолёт җибәрелүе турында хәбәр иттеләр.

Хәзер вертолёт анда барып, янгын урынын төгәл ачыклап, монда хәбәр иткәнче һәм янгын сүндерү командасы чыгып китеп, анда барып җиткәнче шактый вакыт узар әле. Ул арада ут тагын да киңрәк мәйданга җәелергә мөмкин...

Тагын ярты сәгать үттеме икән, телефоннан Добровның дулкынланган тавышы ишетелде:

– Күчкән Салага җибәрелгән вертолёттан бернинди хәбәр дә юк. Анда барып җиткәч, пилот элемтәгә чыгып, чыннан да, посёлокның януы турында әйткән. Бераздан соң, вертолётка астан аталар, дигән. Шуннан соң элемтә өзелгән... Сезнең ул авылда нинди кешеләр яши?

– Татар авылы ул. Алар бу тирәгә йөз еллар элек килеп урнашканнар. Буыннан-буынга күчеп килгән егерьлар, урманчылар яши анда. Тату яшиләр. Бик дустанә, кунакчыл халык...

– Дуста-а-а-нә?! Кунакчы-ы-ыл?! – дип, каһкаһә белән көлде элемтәнең теге башындагы әңгәмәдәш. – Вертолёт кадәр вертолётка атып, аны бәреп төшерсеннәр дә... Шул да булдымы кунакчыллык?! Бу бит... Бу – зур ЧП, экстремизм... террор!!! Бу хакта кичекмәстән Федераль куркынычсызлык хезмәтенә хәбәр итәчәкбез...

Сөйләүченең дулкынланудан тавышы карлыкты. Аның еш-еш сулыш алуы хәтта телефон трубкасыннан да аермачык ишетелде. Шунда ук пыяла чыңлаган һәм «голт-голт» су эчкән тавыш кушылды.

– Бүтән яңалыклар юкмы? – дип сорады бераздан инде шактый тынычланган Добров.

– Алдан сезгә җибәргән мәгълүматтан башка берни дә белмибез. Рация һаман эшләми, – дип җавап бирде инспектор.

Ә тагын бер сәгатьтән вакыйга булган урынга ОМОН подразделениесе сугышчылары белән ике вертолёт җибәрелүе турында хәбәр иттеләр. Южный посёлогының МЧС бүлеге һәм җирле полиция хезмәткәрләреннән торган кечерәк отряд та, кыен юл шартларында йөрүгә җайлаштырылган «Урал» машинасына төялеп, Күчкән Салага юнәлде. Посёлок башкарма комитеты рәисе Павел Кондратьев үзе белән ике урынбасарын да алып, «Патриот» машинасына утырып, алар артыннан шул тарафка юл тотты.

* * *

Күчкән Саладан эвакуацияләнгән карт-корыларны һәм хатын-кызларны урман эченәрәк озаткач, Харрас белән Андрей засадага урнашу өчен җайлы урын карый башладылар. Шулчак һавада гөрелте ишетелде. Бу вертолёт тавышы икән. Аны күргәч, Харрасның күңеленә җылы йөгерде. Вертолётны, аларның хәлләрен ишетеп, «Олы җир»дән җибәргән булулары мөмкин. Каядыр барышлары гына дисәң, очып кына узар иде. Ә бу берничә мәртәбә очып әйләнде. Калкурак урында торгач һәм бу урыннарда агачлар да сирәгрәк булгач, Харрас егетләренә ул ачык күренде.

– Кемнәр икәнен аңламассың. Аерым билгеләре дә күренми. Немецныкыдыр, мөгаен. Күзәтеп, безнең координаталарны билгеләп йөри, мәлгунь. Моны бәреп төшерү – күктәге карганы атып төшерүдән дә җиңелрәк. Кая, манчыйк әле үзен, – дип, егетләргә endәште, очкычны игътибар белән күзәткән Андрей.

– Ашыкмагыз! – диде, эшнең нәрсәдә икәнен чамалап алган Харрас.

Тик ничәнчедер мәртәбә очып әйләнгәндә, вертолётка нәрсәдер булды. Аннан сузылып кара төтен чыкты һәп очкыч аска мәтәлде. Бераздан еракта тонык кына шартлау тавышы ишетелде.

Димәк, фашистлар якында гына. Вертолётны бәреп төшерделәр бит. Ярый ла, пилот «Олы җир»гә хәбәр итеп өлгергән булса. Хәер, вертолёттан хәбәр булмагач, андагылар эшнең нәрсәдә икәнен үзләре дә сизенергә мөмкин. Ярдәм җибәрмичә калмаслар. Тик алар килеп җиткәнче күпме вакыт узар? Ничек булса да фашистларны шуңа кадәр тоткарлап торырга туры киләчәк... Харрас әнә шулай уйланды. Фашистларның кайчан һәм каян килүен чамалар өчен Хәмитне авыл ягына күзәтче итеп җибәрде ул. Егетләр җайлы урын сайлап, оборонага ятып кына өлгергәннәр иде, агачларга ышыклана-ышыклана, Хәмит йөгереп килеп тә җитте. Дулкынланудан еш-еш сулап:

– Харрас абый, киләләр... Мин аларны күрдем. Алар... алар сугыш вакытындагы немецлар киеменнән. Башларында каска, һәрберсенең кулында автомат... Алар берничә генә түгел, бик күп, Харрас абый, – диде.

– Ерактамы әле?

– Агачлар арасыннан күренүгә, сезгә хәбәр итәргә йөгердем. Алар бик ерак түгел. Ләкин акрын киләләр. Биш-ун минуттан монда булырлар...

Харрас тирә-якта мылтыкларын тотып ятучы авылдашларына күз салды.

– Әзерләнергә! – дип команда бирде ул, кулындагы «Сайга» карабинына патроннар магазинын куеп.

Аның әмерен чылбыр буенча арырак ятучыларга тапшырдылар. Әле тегендә, әле монда «Әзерләнергә!» дигән авазлар яңгырады.

Чыннан да, дүрт-биш минут та узмагандыр, инеш үзәненә төшә торган ачыклыкка агачлар арасыннан автомат тоткан җиде-сигез кеше килеп чыкты. Алар инешкә таба берничә адым атлагач, тукталдылар да як-якка карангалап, нидер сөйләштеләр, инеш аша кайсы тирәдән чыгарга икән, дип киңәшләштеләр булса кирәк. Ул арада агачлар арасыннан тагын зур гына берничә төркем чыкты. Уң һәм сул якта да унар-унбишәр кешедән торган төркемнәр күренде.

Засададагылар өстәрәк булганга, алар уч төбендәге кебек күренә. Хәтта санарга да мөмкин. Тик хәзер санап торыр вакытмыни?! Солдатларның оборонада ятучыларга караганда берничә мәртәбә күбрәк икәнен болай да чамаларга була.

Бераз якынрак килсеннәр дә, минем команда буенча гына атарсыз, дип, чылбыр буенча тагын бер әмерен җибәрде Харрас. Ерак привалдагы Зөфәр

сөйләгән хәлләргә һәм немецларның тракторны шартлату турында Әлфирә әйткәннәргә вертолётны бәреп төшерүләрен үз күзләре белән күрү дә өстәлгәч, Харрас соңгы көндә булган гаҗәп вакыйгаларга ышана башлаган иде. Шуңа күрә «партизан отряды командиры» ролենә чынлап кереп баруын үзе дә сизмәде.

Разведкадан килгәч, аның янәшәсенә яткан Хәмит:

– Харрас абый, ә без аларга чынлап атарга тиеш булабызмы? Мылтыклар чын патрон белән корылган бит. Әгәр үтерсәк?.. – дип сорады.

Гаҗәпләнүдән егетнең күзләре зур булып ачылган иде. Ул әлегә бернәрсә дә аңламый. Хәер, барысын да җентекләп аңлатып торырга вакыты да булмады бит. Бу гайре табигый хәлләр аңлаткан очракта да һәркемнең башына тиз генә барып ирешерлек түгел. Засадада ятучы ир-атларның берсе дә хәлнең никадәр җитди икәнен аңламыйдыр әлегә. Шуңа күрә Харрас сүзне артык озайтып тормады:

– Хәмит, әгәр без атмыйбыз икән, алар безгә атачаклар һәм кызганып тормаячаклар. Вертолётны ничек бәреп төшергәннәрен үзең дә күрдең бит. Аларның да автоматлары чын патроннар белән корылган. Шуны аңла, – диде.

Ул арада немецлар, уңайлы урыннар сайлап, күн итекләре эченә су кермәсен өчен сакланып кына, инешнең бирге ягына чыга башладылар. Бу урында су сай һәм ул җәелебрәк тә ага.

Харрас карабинын уртадан килүче бер солдатка төбәде. Әле атарга иртәрәк. Бу якка чыгып, бераз якынрак килсеннәр. Шулай да әзерләнә торырга кирәк.

Менә солдатларның күпчелеге судан чыкты. Җиргә нык-нык басып, күн итекләрендәге суны һәм ләмне койдылар да, саклык белән генә үргә күтәрелә башладылар. Атарга вакыт җиткәнен чамалады Харрас. Тик команданы ничек бирергә белмичә, аптырап калды. Аннан кинәт, «пли!» дип, урманны яңгыратып кычкырып җибәрде. Бу сүз аның башына кинәт килде. Кайсыдыр кинода ишеткәне бар иде. Мондый чакта аннан да кулайрак команда булмас, дип фикер йөртте Харрас. Сүз кыска һәм мылтыктан очып чыккан ядрә шикелле үк кискен яңгырый. Засадада ятучылар, әйтерсең, әлегә кадәр бөтен гомерләре буена шушы команданы гына үтәп яшәгәндәй, бөтенесе бергә залп бирделәр.

Алдан килүче җиде-сигез фриц шунда ук егылды. «Афәрин! Егетләр төз ата», – дип уйлап куйды Харрас, кабат атарга әзерләнеп.

Беренче залп фашистлар өчен көтелмәгән иде. Бик озак вакыт бер мәртәбә дә ату тавышы ишетелмәгәч, уяулыкларын югалткан солдатлар кинәт кузгалган ядрәләр өермәсеннән паникага бирелделәр. Автоматларыннан тәртипсез ата-ата чигенә башладылар. Инеш аша да сакланып кына түгел, кем ничек булдыра ала, шулай йөгереп чыкты. Инде икенче залп яңгырады. Качып баручыларның биш-алтысы кабат җиргә капланды. Икесе, су юлын буып, инешнең нәкъ уртасында ятып калды.

Каты давыл тиз туктар, дигәннәр борынгылар. Фашистлар чигенеп, каршыдагы агачлар арасына кереп күздән югалгач, берара тынлык урнашты. Яңа гына булып узган хәлләрне егетләрнең күпчелеге төш кебек кенә кабул иткәндер: кеше үтерделәр бит! Харраска да җиңел түгел: атарга әмерне ул бирде. Әйтергә генә ансат! Мылтык күтәреп, тере кешегә ат инде син! Тыныч тормышта бу җинаять булып исәпләнә. Тик... Ә бу очракта ул бүтәнчә нәрсә эшләргә тиеш иде соң?..

Янәшәдә ятучы Хәмит, аның икеләнгән уйларын сизгәндәй:

– Харрас абый, ә безне кеше үтергән өчен хөкем итмәсләрме? – дип сорап куйды.

Кешегә төбәп, беренче мәртәбә тәтегә басканчы, Харрас бу хакта үзе дә икеләнә иде. Тик баштанаяк коралланган фашистларны күргәч, алар тәртипсез атышканда, баш очыннан сызгырып узган ядрәләр тавышын ишеткәч, каршыга килүчеләрдән рәхим-шәфкать көтү мөмкин түгеллеген аңлады. Шуңа күрә Хәмиткә дә:

– Кайгырма, җавабын үзем бирермен. Син аларны җәллим дип, һавага атып ятма тагын. Юкса алар сине җәлләп тормаслар, – диде...

Бу хәлләрдә үзләрен иң ышанычлы тотучылар Зөфәр белән Андрей булгандыр, мөгаен. Зөфәр фашистларны якыннан күргән һәм «каты кулларын» үз җилкәсендә татыган кеше буларак, алардан рәхим-шәфкать көтми. Шуңа күрә ул җәлләмичә атты. Аларның тәгәрәп җан бирүләрен күреп сөенде генә. Иң мөһиме: бу беренче бәрелештә үз якларыннан беркем дә зыян күрмәде. Ә Андрей?.. Андрей өчен фашистларга каршы көрәшү – аның көндәлек эше. Аңа барысы да табигый. Фашистлар һөҗүм итә, ә алар кире кага. Аның мондый бәрелешләрне күп мәртәбә башыннан кичергәнлеге әллә каян күренеп тора. Үз-үзен тотышыннан, һәр хәрәкәтеннән сизелә. Ни сәбәпле һәм кемнәр арасына килеп кергәнлеген уена да кертеп карамый ул һәм бик теләсә дә моны булдыра алмас иде.

Бу «партизан отряды»нда, ничектер, барысы да, хәтта үзен командир дип таныштырган Камалов та, сугыш стратегиясен бик начар белә, дигән уй туды Андрейда. Шуңа күрә ул мөмкинлекләрне кулыннан ычкындырмыйча, инициативаны үз кулына алгалады. Менә хәзер дә игътибарны гел үзәккә генә юнәлткән «партизаннар»га үзенең стратегик бурычларын куйды.

– Флангларга игътибарны көчәйтергә. Фашистлар ике яктан әйләнеп узып, чолгап алмасын, – дип кычкырды ул, ауган агач артына поскан җирennән як-якка карангалап.

Чыннан да, як-яктан үтеп, тылга төшсәләр, чолганышта калган ике дистәдән артык кешене кырып салу берни дә тормаячак боларга. Монысын хәрби эштә аз гына да тәҗрибәсе булмаган Харрас та бик яхшы чамалады. Янәшәсендә яткан Хәмиткә кулы белән төртеп: «Сул як флангка бар әле. Анда көч азрак, ахрысы», – диде ул. Аны-моны абайлап җиткермәгән Хәмит, бөтен гәүдәсе белән тураеп басты да сул якка юнәлде. Кирәк бит, нәкъ шул чакта фашистлар, икенче атакага күтәрелер өчен, каршы як агачлар арасыннан чыгып киләләр икән. Автомат тырылдап куйды. Нибары бер-ике адым атларга өлгергән Хәмит, сөрлегеп киткәндәй булды һәм җиргә чалкан ауды. Харрас аның янына шуышып килде. Егетнең авыз читеннән кызыл тасма булып кан агып чыкты. Ул Харраска тутырып карап, ни өчендер елмаеп куйды: «Харрас абый, аңла... минем кешеләрне атып үтерәсем килми», – диде дә күзләрен йомды. Светлана шуышып килгәндә, ул үлгән иде инде. «Партизаннар» арасында бу – беренче югалту. Хәмитнең йөзенә Харрасның күз яше тамды. Ләкин озаклап хискә бирелеп торырга вакыт юк. Фашистлар өерелеп кабат һөҗүмгә күчте.

– Авылдашыбыз Хәмитнең җанын кыйган фашист илбасарларына ут ачыгыз! – дип кычкырды ул бар көченә.

Әле тайгага чыгып китәр алдыннан гына «төрмәдән качкан җинаятьчеләр» дип сөйләнгән Харрас ни өчен хәзер «фашист илбасарлары» диде? Ни өчен, чыннан да, җинаятьчеләрнең өстендә киноларда гына күреп белгән немец фашистлары кием – боларын уйлап торырга вакыт юк иде. Мылтыклар һәм карабиннар шартлады, автоматлар тырылдады, каршыга килүче фашистларның тагын берничәсе егылды, «партизаннар» арасында да яраланучылар бар, ахры, ыңгырашкан тавышлар ишетелгәли. Кыскасы, мәхшәр купты.

Фашистлар алай тиз генә чигенергә җыенмый. Алар кайда үрмәләп, кайда шуышып, атышлар кимеп торганда йөгереп, засадада ятучыларга һаман якыная баралар. Шунда Фоат, оборонада ятучылардан иң яше, түзмәде: «Минем үләсем килм-и-и», – дип, урыныннан сикереп торып, урманга йөгерә башлады. Әлегә кадәр мондый мәхшәрне күрмәгән егетнең нервлары түзмәде.

– Ты куда? Час убьют ведь! – дип кычкырды аның артыннан Андрей.

Ләкин Фоат аның соңгы сүзләрен ишетмәгәндер дә. Берничә мизгелдән ул җирдә ята иде инде. Светлана аның ягына шуышты. Тик озак та тормады, кире әйләнеп килде. «Үлгән», – диде ул яшьләренә буылып. Бу партизаннар арасында корбан булучыларның икенчесе иде.

Ә сугыш кызганнан-кыза гына барды.

* * *

Левин яшь галимнәрнең әлегә кадәр фән өлкәсендә ат уйнаткан тәҗрибәле гыйлемияләренең дә теше үтмәслек «вакыт-пространство» мәсьәләсендә шундый тәвәккәл адым ясауларына сокланмыйча булдыра алмады. Аның уенча, фән юлыннан нәкъ менә шундый фидакарьләр атларга тиеш тә инде. Ләкин ул артык хискә бирелә торганнардан түгел. Шуңа күрә, йомшаклык күрсәтеп, Сергей Поповның аркасыннан кагып мактарга ашыкмады. Киресенчә, төпченеп, сорау артыннан сорау яудырды:

– Бәлки, сез мине тормышка ашмастай, булмаган эшләрегез белән шаккатырырга тырышасыздыр? Гамәлләрегезнең чынлыгына тизрәк ышандыру өчен, ул лабораториягезнең кайда икәнлеген дә әйтерсез, бәлки? Әгәр сер булмаса, – диде ул.

Сергейның икеләнеп калуы йөзенә чыкты. Ул карашын түбән төшерде. Әйтергәме-юкмы дип, бераз уйланып торгач кына, сүзен дәвам итте:

– Әйе, сер! Чыннан да, дәүләт тарафыннан сер итеп сакланырга тиешле, «секретно» келәймәсе сугылган яшерен полигонда алып барылды эксперимент. Ләкин безнең остазыбыз буларак, киңәшләрегезгә мохтаҗ икәнлегебезне танып һәм киләчәктә эшләрне бергә дәвам итәчәгебезгә өмет баглап, сездән яшерен эшебез юк. Тыңлагыз, сөйлим. Фәнни экспериментларыбыз федераль куркынычсызлык хезмәтендә зур кызыксыну уятты һәм безне алар үз канатлары астына алды. Ә аларның нинди җитди оешма икәнлеген чамалыйсыздыр? Монда финанс һәм матди кыенлыклар турында сүз дә булырга мөмкин түгел...

Левин яшь галимнең күзләренә сынап карады. Ләкин аннан нинди дә булса алдау, күзгә төтен җибәрү галәмәте сизмәде.

– Федераллар кызыксынды, дисез инде?.. Әйе, алар – бик җитди... Анда эшләүчеләр юк-бар белән кызыксынмас. Димәк, экспериментларның үзләре өчен файдалы ягын күргәннәр?..

– Александр Васильевич, безне федералларның нәрсә уйлаулары кызыксындырмый. Иң мөһиме: алар безгә мөмкинлекләр тудырды, финанс мәсьәләсендә ярдәм иттеләр. Ягъни алга куйган максатыбызны тормышка ашыру өчен шартлар тудырдылар. Безгә шунысы бик җиткән.

Яшь галимнең әнә шулай җиңел һәм берьяклы фикер йөртүе Левинны уйланырга мәҗбүр итте. Чыннан да, федераллар эшкә тыгыла икән, аның үзләренә файдалы ягын күргән булулары ихтимал. Ә моны һәрвакыт та яхшыга гына юрап булмый. «Вакыт машинасы» уйлап табылган очракта, ул узган заманнарга яисә киләчәккә экскурсиягә барып, сәйран кылу өчен генә файдаланылырмы? Фәндә нинди ачышлар гына ясалмасын, аларның күпчелеге

сугыш максатларында кулланылган. «Вакыт машинасы»н да шушы язмыш көтә. Атом-төш энергиясен уйлап тапкач та, нәкъ шулай була. Егерменче гасырда атомның квант теориясенә нигез салган танылган физик Нильс Бор, атом энергиясенең гаҗәеп җимергеч көчкә ия булуын аңлап, аны тыныч шартларда гына файдалану өчен ничек кенә көрәшмәсен, атом-төш коралы барыбер уйлап табылган. Хәзерге вакытта ул җир йөзендә кешелекне юк итәргә сәләтле иң куркыныч коралларның берсе булып исәпләнә. «Вакыт машинасы» уйлап табылса да, кешелеккә зур зыян һәм фаҗигаләр китермәс дип, кем әйтә ала? Александр Васильевичны бигрәк тә әнә шул борчый иде.

– Әгәр сезнең ачышлар, чыннан да, гамәлгә ашарлык булып, аның нәтиҗәләре белән федераллар кызыксына башлаган икән, моннан кешелек өчен инде аяныч нәтиҗәләргә дә ерак калмаган дигән сүз. – Левин яшь галимгә янә бер мәртәбә сынаулы караш ташлады да, сүзен дәвам итте. – Шуны белегез, фән өлкәсендә эшләгән галимне үзенең гыйльми ачышларының нәтиҗәсе уңышлы чыгу гына кызыксындырырга тиеш түгел. Җәмгыять, кешелек алдында җаваплы булуыгызны да онытмагыз, – дип тәмамлады ул сүзен.

Яшь галимгә аның бу сүзләре ни дәрәҗәдә тәэсир иткәндер, анысы мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, фәндәге зур җиңүләре белән рухланган егетне «кешелек алдындагы җаваплылык» кебек сүзләр генә максатыннан чигендерерлек түгел иде.

– Сүз дә юк, Александр Васильевич, безне, беренче чиратта, гыйльми эшләребезнең нәтиҗәсе кызыксындыра. Безнең хезмәт ул, кайберәүләр уйлаганча, коры формулалар гына түгел. Ул безнең өчен фәндә иҗат белән шөгыльләнү. – Сергей берара сүз таба алмыйча торды. – Фәнни иҗат ул безнең өчен.

– Фәнни иҗат... фәнни иҗат, – дип үзалдына үртәлгәндәй сөйләнде Левин.

Ул яшьләрне бик яхшы аңлый. Һәр яңалыкны зур дулкынлану белән кабул итә торган чаклары. Романтика. Яшьлектә ул да кичерде андый хисләрне. Хәзер кая китте ул чаклар, дип сагынып сөйләргә генә калды.

Александр Васильевич, уйларын куарга теләгәндәй, кулын селтәде. Хәтта карашы яктырып киткәндәй булды.

– Һәм кайдарак урнашкан инде сезнең ул лабораториягез? – диде ул, кинәт кенә ачылып.

Сергейның кашлары сикергәләде. Остазына туры карамаска тырышып, башын читкә борды. Нәкъ менә шушы сорауга җавап бирергә теләмәве әллә каян күренеп тора.

– Әһә, аңлашылды, монысы сер, димәк...

Левин кычкырып көлде.

– Александр Васильевич, безнең сездән яшерен бер генә серебез дә юк, тик...

– Нәрсә, «серне беркемгә дә ачмаска вәгъдә бирәм» дип, кул куяргамы? Китерегез ручка, журнал...

– Юк инде, Александр Васильевич, аңа ук барып җитмәбез. Ләкин барыбер бу хакта беркемгә дә тишмәвегезне сорыйбыз. Юкса, безгә бик тә, бик тә хәтәр булачак...

– Аңладым! Хәтәр генә түгел, эшләрегез бөтенләй хөрти булачак. Ярар, сүз бирәм, серне беркемгә дә чишмәячәкмен.

– Безнең лаборатория-полигон тайга эчендә урнашкан. Ачык һавада. Сез «Граф Елисеев» дигән агач эшкәртү предприятиесен ишетеп тә белмисездер инде?

– Тукта, тукта, «Граф Елисеев», дисезме? Ник белмәскә, беләм. Минем дустым, кайчандыр бергә белем алган курсташым Сазонов җитәкләгән урман

хуҗалыгы карамагында ул. Геннадий Николаевичның аның хакында сөйләгәне дә бар иде.

– Ул конспирация өчен генә агач эшкәртү предприятиесе булып исәпләнә. Чынлыкта, әллә кайчан эшләп килгән бу предприятиене федераллар сатып алды. Безнең лаборатория шуның территориясендә төзелде. Әйе, кешеләр дә, урманчылар да аны агач эшкәртү предприятиесе дип белә. Күз буяу өчен, ара-тирә борыс, такта телгән булалар, фанер ясыйлар. Ә болай анда «вакыт машинасы» эшли...

Левин бу сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Тик Сергейның ихластан сөйләве йөзенә чыккан. Димәк, «вакыт аша күчеш теориясе» гамәлдә тормышка ашкан булып чыга инде.

– Сез аны сынап карадыгызмы әле? Вакыт машинасын, диюем?..

– Әлегә без вакыт аша күчеш ясамадык. Ләкин вакыт тоннеле барлыкка китердек.

– Вакыт аша күчмәгәч, тоннель барлыкка килгәнен каян беләсез?

– Пространствоның халәтен билгели торган приборларыбыз бар. Аларын да үзебез уйлап таптык. Ягъни безнең тәҗрибәләр көчле ясалма гравитация кыры булдыруга нигезләнгән. Галәмдәге «кара упкын»нарны исегезгә төшерегез. Ул урыннарда көчле гравитация кыры тәэсиреннән пространство һәм вакыт кәкрәю үзлегенә ия. Галәмдә аның нәтиҗәсе шулкадәр көчле була ки, «кара упкын»нар хәтта яктылыкны үзенә йота. Юк, ул каядыр югалмый. Чынлыкта, яктылык нурлары туры юнәлештә хәрәкәт траекториясен үзгәртеп, гравитация кыры тәэсиреннән хасил булган цилиндр формасындагы «упкын» күчәре тирәсендә әйләнә башлый. Ә тыштан күзәтүчеләргә ул күренми, алар аны куе томан хасил булган кебек күрәләр.

– Әгәр дөрес аңласам, сезнең приборлар пространствода «кара упкын»нарга хас шундый халәтне күрсәттеләр инде, шулаймы?

– Әйе, Александр Васильевич, сез бик дөрес аңладыгыз. Пространствоның андый халәтен без берничә сәгатькә кадәр саклый алдык хәтта.

Сергей Попов менә без нәрсәгә дә сәләтле дигәндәй, башын горур гына чөеп куйды. Яшь галимнең үзләре башкарган гыйльми эшләренең нәтиҗәсеннән зур горурлык хисләре кичерүе күренеп тора. Тик аның үзен шулай тәкәббер тотуы үзе дә фән өлкәсендә ат уйнаткан Левинга аз гына да тәэсир итмәде. Һәрхәлдә, галим буларак кына түгел, тормышта да зур тәҗрибә туплаган остаз Сергей әйткәннәрдән егылып китмәде. Хәтта шатланмады да булса кирәк. Киресенчә, кыяфәте җитдиләнде. Маңгаендагы сырлары да тирәнәйгәндәй булды. Бу аның киеренке уйларга бирелүен күрсәтә.

– Ә сез андый вакыт тоннельләрен пространствоның теләсә кайсы урынында барлыкка китерә аласызмы? – дип сорады Левин, озак кына эндәшмичә торгач.

– Идарә пультыннан бер-ике километр ераклыктагы диаметрда, теләсә кайсы урында, вакыт тоннелен барлыкка китерергә мөмкин.

– Шул тоннель аша теләсә кем узган заманнарга күчә ала инде, димәк?

– Әлбәттә!

– Һәм шуннан соң тоннель ачык вакытта кем дә булса узган заманнарга күчмәгәндер, дип ышанып әйтә аласызмы?

– Александр Васильевич, сезнең соравыгыз бераз көлке яңгырый. Тайга уртасында бер-ике чакрым гына түгел, дистәләгән чакрым ераклыкта сыңар кеше очратмассың.

– Әгәр шундый вакыт чоңгылына урманчылар, егерьлар туры килсә?..

– Бер кеше югалудан гына тарих тәгәрмәчендә әллә ни зур үзгәрешләр килеп чыкмаячак. Хәер, тирә-як урманчылыкларда кеше югалган, дигән хәбәр ишетмәдек алай-болай.

– Артык ваклану дип кабул итмәгез, тагын бер нәрсә белән кызыксынуны кирәк саныйм. Пространствода вакыт тоннеле барлыкка китерелгәч, аның аша бер яклы гына күчеш буламы? Әллә?..

– Ике яклы!

– Димәк, хәзерге заманнан узган заманга күчкән шикелле, ул замандагы кешеләр, яки тереклек ияләре безнең заманга да күчә ала?

– Ишек ачылгач, керергә дә, чыгарга да мөмкин булган кебек инде, Александр Васильевич, – дип көлеп җавап бирде Сергей.

– Әгәр ул заманнардан безнең заманнарга күчкән булсалар?

Сергей иңнәрен сикерткәләде:

– Гафу итегез, без ул заманнардан күчәргә ярамый, дип, вакыт тоннеле «ишеге» төбенә сакчы куя алмыйбыз бит инде. Очраклы туры килгән тереклек ияләре булса, әлбәттә, күчүләре ихтимал. Кешелек тарихында андый хәлләр булгалаган. Очраклы вакыт тоннеленә эләгеп, кинәт юкка чыккан кешеләр турында тарихта күп сәхифәләр бар. Ул вакыт упкыннары табигый һәм шулай ук киләчәк заман галимнәре ясалма рәвештә китереп чыгарган булулары да бик мөмкин.

– Болай төпченүемнең сәбәбе бар, дускай. Ә беләсезме, күптән түгел сезнең эксперимент полигоны урнашкан ул урман хуҗалыгы җитәкчесеннән мин нинди сүзләр ишеткән идем? Алдагы очрашуларның берсендә ул миңа браконьерлар урмандагы кыргый хайваннарны исәпсез кыралар, кайбер хайваннар «Кызыл китап»ка кертелгән, бетү чигендәгеләре дә бар, дигән иде. Ә соңгы сөйләшү вакытында, ничектер, сирәк калган кайбер хайваннарның сәер генә артып китүе турында сөйләде. Шул искә төште дә, шикләнеп куйдым...

– Без вакыт тоннеле барлыкка китергәч, элекке заманнардан тереклек ияләре күчмәгәнме, димәкче буласызмы?

– Күчеш ике яклы, дип үзегез әйттегез түгелме? Ә кайсы чорга көйләгән идегез вакыт тоннелен?

– Безнең теория буенча, күчеш вакыты аралыгын гравитация көче белән барлыкка китерелгән вакыт өермәсенең радиусын үзгәртү юлы белән көйләргә мөмкин. Анысын без әлегә тулысынча хәл итеп бетермәдек. Вакыт тоннеленең икенче башы чама белән узган гасырлар уртасында ачылырга тиеш. Хәзергә без узган вакытка артык тирәнгә күчә алмыйбыз. Вакыт аралыгында мондый чоңгыл барлыкка китерү өчен көчле гравитация кыры тудырырга кирәк. Моңа безнең техник ресурслар чыдамаячак.

– Менә сез, «тулысынча хәл итеп бетермәдек» дисез, «чама белән» дисез, җитди фәнни эшләрдә мондый төгәлсезлекләргә урын булырга тиеш түгел, минемчә. Юкса аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

– Вакыт кыса, Александр Васильевич. Килешү озак вакытка төзелмәгән иде. Безне болай да баш өстендә торып диярлек эшләтәләр. Хәзергә иң мөһиме – нәтиҗә. Ә калган вак-төяген алга таба да җиренә җиткербез.

– Вак-төяк, дисез инде алай булгач?.. Тик, Сергей, шуны онытмагыз: фәндә вак-төяк юк. Бөтенләй әһәмиятсез булып тоелган нәрсәләр дә кешелек өчен көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин...

Санаторийда Сазонов белән ванна процедуралары алып ятканда, Левин әнә шушы сөйләшүләрне исенә төшергән иде. «Әгәр экспериментлар уңай нәтиҗә

бирсә, без сине борчыган нәрсәләрне хәл итә алачакбыз. Ул вакытта син фән әһелләреннән зарланудан туктарсың», – дигән сүзләре дә Сергей белән ике арада булган шушы әңгәмәне күздә тотып әйтелгән иде. Аның уенча, чыннан да, киләчәктә «вакыт машинасы» ясалса һәм ул тыныч шартларда сынауны уңышлы үтсә, тайгада кыргый хайваннар күпләп үрчегән элекке заманнарга күчеп, вакыт тоннеле аша аннан хайваннарга бу заманнарга күчү мөмкинлеге тудырылса, Сазонов әйткән проблеманы җиңел генә хәл итеп тә булыр иде.

* * *

Фашистларның бишенче һөҗүмен кире кайтарганда, «партизаннар» ягында бер дистәләп сугышчы гына калган иде. Кырылды егетләр. Засадада ятучыларны немецлар автоматлардан атып кына ала алмаган булырлар иде. Гранатомёт белән алдырдылар. Егетләрнең шактые граната кыйпылчыгы тиеп харап булды. «Партизаннар» күпләп һәлак була башлагач, Андрей отряд командиры Харрас янына шуышып килеп: «Теге яктагы гранатомётны шартлатырга бер генә гранатагыз да юкмыни соң?» – дип ялварып сорады. Харрас: «Юк шул», – дигәнне белдереп, башын гына чайкады.

– Запаста, ичмасам, бер граната да тотмавыгыз начар. Булса, берәр партизанны җибәреп, дөмектерер идек ул ут ноктасын, – диде дә шуышып кире китте Андрей.

Тайга уртасында фашистлар миномётлардан файдалана алмый, ә менә гранатомёт чынлап куркыныч тудырды «партизаннарга». Посып кына атып яталар. Харрасның мәргән егетләре аның атучысын үтерә торалар, аларны икенчеләре алмаштыра. Гранатомётны шартлатмаган көе, ул бәладән котылырмын, димә.

Фашистлар каршы яктагы агачлар арасына кереп китеп, бераз тынычланып торган арада, Светлана Андрейның яраларын бәйләргә кереште. Алар шунда сөйләшеп тә алдылар.

– Эх, Светлана, белсәң иде, бу сугышның ничек туйдырганын. Менә ничә еллар кан белән үлемнән башканы күргән юк, – диде Андрей, авыр сулап.

Светлана, эш белән мавыккан кыяфәттә, бинтны чорнавын дәвам итте. Әле очрашуларына аз гына вакыт узса да, ул егетне инде әллә кайчаннан беләдер кебек. Үзендә аңа карата ниндидер рухи якынлык тойды. Тәне күп урыннан җәрәхәтләнеп, имгәнеп бетсә дә, ташып торган рухи көч, киләчәккә өмет тойды ул аның сүзләреннән. Гомумән, Светлана көчле рухлы кешеләрне ярата. Ул балалар йортында үсте. Дөрес, матди яктан һәрчак тәэмин ителгән, тамагы тук иде. Ләкин балалар йортында тәрбияләнүчеләргә ата-ана назы, туган-тумача игътибары җитми. Тормышта килеп туган кыенлыклар алдында сыгылып төшкәндә, ул һәрчак «их, нишләп минем бертуган абыем булмады, ни өчен шундый чакларда яклап калырлык туганым юк икән», дип уйлый иде. Шуңа күрә киләчәктә янәшәсендә көчле кеше булуын теләде.

Медицина училищесын тәмамлагач, ул да кайда эшләрмен икән, дигән уй белән янды. Бергә укыган курсташларының күпчелеге шәһәрдә эшкә калды. Терәге, ярдәм итүчесе булганнар «җылы урын»нарга урнаштылар. Шул чакта ничектер тайга эчендәге ерак бер татар авылына фельдшер кирәк икән, дип ишеттерделәр. Дөрес, ул шунда ук чыгып йөгермәде. Бөтен якларын уйлады. Чөнки ул авылны белгән кешеләр, тайга эче, кыргый төбәк, мәдәният үзәкләре юк, дип кисәттеләр. Ләкин Светлананы яшьлек романтикасы җиңде. Мондаябышып ятар туган-тумачам юк, бәхетем шундадыр, бәлки, дип, тәвәккәлләп барырга ризалык бирде. Монда да бер ялгызы, анда да...

Күчкән Салага килеп эшли башлау баштарак җиңел булмады. Ләкин үз эшен яратып башкаручы, өлкәннәрне хөрмәт итүче бу тырыш кызны җирле татар халкы бик тиз үз итте. Тагын шунысы да бар: авылга килгәнче бер авыз сүз татарча белмәгән кыз берничә айдан татарчаны әйбәт кенә сукалый башлады. Берәр елдан бөтенләй татарлашып бетте. Үзләренә карата мәрхәмәтле, гореф-гадәтләрен ихтирам итүче кызны ничек яратмасыннар инде! Тик, кая барсаң да, бер кояш, дигәндәй, насыйп булган яр гына һаман күренми. Авылда яшьләр юк диярлек. Бәйрәмнәрдә, ял көннәрендә, әти-әниләре янына «Олы җир»дән кайткалаучылар була булуын. Светлананың күңелен яулардайлары гына юк. Ялгыз каенга кош кунмас, дигәннәре шул буладыр инде.

Андрейның яраларын бәйләгәндә, Светлана шуларны уйлады. Менә хәзер аның белән ачылып сөйләшеп китәр иде, тик алар икесе ике дөнья кешеләре шул. Вакыт-вакыт ул аны жәлләп тә куя. Әгәр чын дөресен сөйләп бирсә, син бит бөтенләй икенче заман кешесе, дисә, аңлармы икән? Юк, аңламас, мөгаен. Ул аны күзалдына да китерә алмаячак.

– Җиңү көненең тизрәк килеп җитүен барыбыз да бик тели, – дигән булды Светлана, исәпсез-сансыз уйларын читкә куарга тырышып.

– Кайчан булыр икән инде ул җиңү, Светлана, ә? Илебездә яшәүче һәркемнең иң бәхетле көне булыр иде ул, шулаймы? – дип хискә бирелде Андрей.

Бу сүзләрне әйткәндә, аның күзе очкынланып киткәндәй булды. Дулкынлануы хәтта тавышында сизелде.

– Ә мин җиңүнең кайчан киләсен беләм.

Светлана, хәйләкәр генә елмаеп, Андрейга күз сирпеп алды.

– Карале, синдә күрәзәлек сәләте дә бармыни?

– Әйе. Мин бөтен нәрсәне дә алдан беләм! Әйтимме, кайчан җиңәчәкбез фашистларны?

– Әйтеп кара.

– Ямьле май аенда!

– Нишләп майда?

– Чөнки мин язның шул аен яратам. Ул бөтен кешегә дә бәхет китерә торган ай.

Светлана, артыгын ычкындырдым бугай дигәндәй, кинәт кенә карашын читкә алды. Ләкин Андрей кызның уңайсызланып калуына игътибар да итмәде. Аның үз уйлары.

– Светлана, ә синең ирең бармы? – дип сорап куйды ул кинәт кенә.

– Юк.

– Ә егетең?

– Ирем дә, егетем дә юк. Ә ник сорыйсың аларны? – диде кыз.

– Мин сине беренче күрүемдә үк ошаттым.

Светлананың бите алсуланды. Ул оялып, йөзен читкә борды. Аңа беркем дә, беркайчан да болай әйткәне юк иде. Нәрсә дип җавап бирергә белмичә, әле яңарак кына бәйләгән бинтны рәтләштергән булды ул. Бары тик бераздан соң гына:

– Ә үзегезнең хатыныгыз бардыр бит? – дип сорарга батырчылык итте.

Андрейның йөзе күзгә күренеп җитдиләнде.

– Бар иде... Хатыным – Татьяна, кызым – Галя... Бомба шартлап, өсләренә йорт җимерелгән...

Андрейның күзләреннән мөлдерәп яшь чыкты. Ул сәламәт кулы белән күзләрен сөртте.

– Кызганыч!

– Эх, Светлана, белсәң иде күңелемдә фашистларга карата нинди нәфрәт уты янганын?! Мин сугышның беренче көннәреннән генә түгел, беренче сәгатьләреннән үк сугышам бит инде. Брест крепостеннан. Немецлар басып кергәч, кулга корал тотып, крепостьны сакладык. Мин хәтта гаиләм – хатыным һәм кызым белән саубуллашмыйча да калдым. Без яшәгән йортка бомба эләккәнен һәм аның шартлап җимерелгәнен соңыннан ишеттем...

Гаиләсенең шундый фаҗигале язмышы турында сөйләү Андрейга бик авыр иде, билгеле. Ләкин аның мондый халәте озакка бармады. Күп сынаулар кичереп, авырлыклар күреп чыныккан хәрби кеше үзен тиз кулга алды.

– Светлана, фашистларны җиңгәч, әйдә бергә булыйк. Ризамы? – диде ул, кызның әлеге тәкъдимне ишетеп, гаҗәпләнүдән тагын да матурланып калган зур зәңгәр күзләренә карап.

Һәр минуты гына түгел, һәр мизгеле үлем сагалап торган шушындый шартларда тәкъдим ясау гади акыл ирешмәслек гамәл булса да, бу сүзләр Светлананың күңелендә әйтеп бетергесез хисләр тудырды. Менә шушы минутларда аның Андрейны кочаклап аласы һәм чын дөреслекне сөйләп бирәсе килә иде. Кайгырма, сугыш инде күптән бетте, без инде күптән тыныч тормышта яшибез. Бу гайре табигый хәлләр ялгышлык кына, йә саташу гына. Берничә көннән барысы да җайланыр. Безнең егетләр ул фашистларны җиңәрләр, шул арада «Олы җир»дән ярдәм дә килеп өлгерер, бәлки. Һәм без синең белән берәр көннән, йә берәр атнадан кавышырбыз, чәчләрне чәчкә бәйләрбез, дип аны юатасы, сөендерәсе килгән иде. Тик ни өчендер, авыз ачып, ул сүзләрне әйтә алмады.

– Риза, – дип пышылдады Светлана, ләкин ул сүзләрне Андрей ишетмәде дә. Ул кызның карашыннан гына да аның риза икәнлеген аңлады. Кулларын зур учларына алды.

– Ә беләсеңме, Светлана, без бик бәхетле булырбыз... – диде.

– Әйе... Әлбәттә...

Андрейның иреннәре калтыранып куйды. Ул үбәргә теләгәндәй, йөзе белән кызга таба омтылды. Күңелендә туган хисләр өермәсеннән кыз да бөтен дөньясын оныткан иде. Менә хәзер, тагын бер мизгелдән, булачак ләззәтне кичерә башлагандай ул күзләрен йомды. Ләкин шул чакта, аларның икесен дә сискәндереп, каршы яктан автомат тырылдап куйды. Засадада ятучылардан кайсыдыр авыр ыңгырашып, Светлананы ярдәмгә чакырды. Кыз ашыгып, шул якка шуышты. Фашистлар чираттагы һөҗүмгә күчте.

* * *

Алар кайда? Нинди юнәлештә барырга? Менә атна-ун көн инде Мартинга шул сораулар һаман тынгылык бирми. Төп көчләр белән элемтә югалды. Кыска дулкында эшли торган «Фредрих» радиостанциясе ярдәмендә радист штаб белән элемтәгә чыгарга күпме генә тырышмасын, берни дә барып чыкмады. Ул резисторын боргалап, кыска радиодулкыннар белән шыплап тулган эфирны «капшады», юкка «Ирма... Ирма... Ирма...», – дип, кат-кат таныш исемне кычкырды. Тик җавап ишетелмәде. Гомумән, эфир әлегә кадәр ул белмәгән ят авазлар белән тулган. Аларны тыңлап, берни дә аңламаган радист үзен бөтенләй икенче дөньяга эләккәндәй хис итте.

Бу хәл Мартинны да тәмам өметсезлеккә төшерде. Хәзер ул немецларның төп көчләре кайда икәнлеген чамалый да алмый. Бәлки көнчыгышка яки көнбатышка бик ерак китеп өлгергәннәрдер? Ләкин ул ишеткән соңгы

мәгълүматларга караганда, бу мөмкин түгел. Ә рус армиясе кайда? Гомумән, фронт сызыгы кайсы тирәдәрәк икән?.. Барысы да кинәт кенә юкка чыкты. Ун көн элек, эсэсчы гаскәриләр корпусы белән командалык итүче оберштурмбаннфюрер Эрдман әмере буенча, тайгада качып ятучы һәм үзләренә тынгылык бирмәүче партизаннарга каршы җибәрелгән эсэс ротасы инде менә ничә көннәр эзәрлекләргә тиеш партизаннарны таба алмый.

Моннан берничә көн элек әсирлеккә төшкән партизаннан да төгәл җаваплар алып булмады. Дөресен әйткәндә, партизан алар урнашкан лагерьга көтмәгәндә үзе килеп чыкты. Моңа кадәр тайгада бер кеше очратмаган эсэсчыларда бу хәл, әлбәттә, зур өмет уяткан иде. Мартин үзе теләсә кайсы тоткыннан теләсә нинди мәгълүматны «кысып» чыгарып була дигән фикердә. Тел ачтыра торган андый ысулларны яхшы белә ул. Ләкин киребеткән бу әсир авызыннан бер файдалы нәрсә дә тартып алып булмады.

Мартин аны, ялган мәгълүмат биреп буташтыру өчен, партизаннар махсус җибәргән диверсант түгелме икән, дип тә шикләнде. Болай уйлауның үзенә күрә бер сәбәбе дә бар иде. Әсирнең планшетыннан карта табылды. Иң кызыгы шунда: партизан аны Мартинга үзе тәкъдим итте. Өстәлгә җәелгән штаб картасыннан берни дә аңламаган булып кылангач, кыр сумкамда үземнең картам бар, шуннан аңлатып бирәм, диде. Чыннан да, ул картадан бернәрсә дә яшермичә аңлатты. Әнә шул вакыттагы үз-үзен тотышы шик уятты да инде Мартинда. Башка сорауларга җавап биргәндә, «белмим», «юк» дип, кыска гына җаваплар белән чикләнгән, йә бөтенләй эндәшмичә, туры җаваптан качкан әсирнең картадан күрсәткәндә ни өчен теле ачылып китте? Бу хәл психологик яктан бернинди гадәти кысаларга сыймый. Әсирлеккә алынган беренче көнендә үзен «Мин – татар», дип атаган бу кешене партизаннар җибәрмәдеме икән, дигән уй нәкъ шул чакта килде дә инде Мартинның башына. Картадан күрсәтеп, аларны үзләренә уңайлы урынга алып килерләр дә алдан әзерләнгән засадага эләктереп, тар-мар итәрләр. Урман эчендә сугышу гади нәрсә түгел. Алдыңны-артыңны уйлап эш итмәсәң, монда баштанаяк коралланган булуың да ярдәм итмәячәк. Партизаннар хәйлә белән алдыра. Аларны моңа өйрәтеп торасы юк. Хәйләле сугыш алымнарының аяныч нәтиҗәләрен берничә мәртәбә үз тәҗрибәсендә татырга туры килде Мартинга. Авызы бер пешкәч, өреп кабарга өйрәнде.

Ә соңрак гауптштурмфюрерның иң ачуын китергәне шул булды: алданрак кулга алынган рус әсире белән бергәләп, бер төндә тоткыннар качып китте. Бу хәл аны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Ул кабат партизанның кыр сумкасыннан алынган картаны ныклап өйрәнә башлады. Оберштурмфюрер Гансны да ярдәмгә чакырды. Озаклап уйлана торгач, картаның тәртибенә төшенделәр. Партизаннар лагере төньяк юнәлештә, якынча 30 чакрымлап ераклыкта гына урнашкан. Әсирләр качып китүгә үк, Мартин шул партизаннар ягына «марш-бросок» ясарга дигән карарга килде. Нибары бер кечкенә генә өе булган урман аланында күпме ятарга була?! Хәрби эштә иң куркынычы – билгесезлек. Ул солдатларның психологиясенә тискәре йогынты ясый. Араларында ризасызлар да күренгәли инде. Кычкырып әйтмәсәләр дә, Мартин моны күңеле белән сизә һәм соңгы вакытларда тезгенне кысыбрак тотарга тырыша. Юкса, мондый чакта эчтәге таркаулык тышкы дошманнарга караганда да куркынычрак.

Шуңа күрә ул хәзер дә икеле-микеле уйларын үзенең кул астындагыларга сиздерергә тырышмады. Бәлки, чыннан да, партизаннарның төп көчләре шул

картада күрсәтелгән урындадыр? Лагерьга килеп җитәрәк, алдан разведка җибәреп, шул урыннарны капшап, тикшереп караргадыр. Аннан соң хәйләле юллар белән отрядны чолгап алып булыр. Партизаннарның барыбер аның солдатлары кебек баштанаяк коралланмаганлыгын яхшы белә Мартин. Күбесендә иске винтовкадыр, иң яхшы дигәндә, немецлардан трофей итеп төшерелгән берничә автоматлары бардыр инде. Алар белән генә әллә ни ерак китеп булмый.

Партизаннарның шул төп көчләрен тар-мар итсәләр, күз күрер, хәрәкәттәге армия белән элемтәгә чыгу мөмкинлеге турында да уйларга булыр иде...

Менә бүген Мартин ротасы партизаннар лагерена килеп җитте. Ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, лагерьда беркем дә юк иде. Аны бер кат миномётлар белән утка тоткач, лагерьның ике ягыннан бәреп кергән эсэсчыларны, сәлперәйгән бер картны исәпләмәгәндә, буш урамнар һәм буш йортлар каршы алды. Партизаннар кайсы тарафка китте, дигән сорауга, картлач ялганлап җавап бирде. Монда инде Мартин нәкъ шул моментта кайтып кергән разведчиклар күрсәткән тарафка кузгалырга әмер бирде... Картка җәзасын бирергә дә онытмады.

Алар авылны чыгып, урманга кереп барганда, тагын бер көтелмәгән хәл килеп туды. Өстән сәер тавыш ишетеп, башын күтәреп караган иде, анда вертолёт күреп, Мартин берара сәерсенеп калды. Биноклен кулына алып, күпме генә күзәтсә дә, очкычта ул бернинди аңлашылырдай билге күрмәде. Үзләренең гаскәрләре сугыш шартларында вертолётлардан файдаланмый. Фронтта истребительләр һәм бомба ташлаучы самолётлар гына кулланыла. Чөнки вертолётларны теләсә нинди коралдан атып бәреп төшерергә дә мөмкин. Алар үзләрен акламый. Бу руслар җибәргән вертолёт булырга тиеш. Партизаннар үзләрен эсэсчылар эзәрлекләвен хәрәкәттәге армиягә хәбәр итеп өлгергәннәрдер дә, тегеләре разведкага шуны җибәргәннәр, күрәсең.

Вертолётның бернәрсәдән курыкмыйча, үзен хуҗаларча тотып, оятсызларча астан гына очып йөрүе Мартинның җен ачуларын чыгарды. Истребительләр дә күренми бит шул чакта! Бу энә карагы аларның җиленнән дә мәтәлеп төшәр иде.

Ниһаять, Мартинның сабырлыгы төкәнде. Вертолёт өченче мәртәбә әйләнеш элмәге ясап, баш очыннан гына узганда, солдатларына «Фоя!» дип әмер бирде. Шуны гына көткәндәй, солдатлар бердәм рәвештә автоматларыннан ата башладылар. Берара тоташ ату тавышларыннан тирә-як яңгырап торды. Озак та үтмәде, вертолётның бер ягыннан кара төтен бәреп чыкты. Очкыч чайкалып куйды һәм әйләнә-бөтерелә, мәтәлчек атып, ерак кына түгел агачлар арасына төшеп күздән югалды. Бераздан шул тарафтан тонык кына шартлау тавышы ишетелде, агачлар өстеннән кара төтен көлтәсе сузылып чыкты.

Үз эшләреннән канәгатьләнү хисе кичергән солдатлар берара шатлыклы авазлар чыгарып алдылар. Әле тегендә, әле монда «Гут, гут!» дигән сүзләр ишетелде. Ләкин озаклап, хискә бирелеп торырга вакыт юк. Мартин «Штиле!» дип кычкыргач, алар бердәм тынып калды. Гауптштурмфюрер солдатларга партизаннар белән көрәштә шушы беренче җиңүләре уңаеннан саран гына котлау сүзләре әйтте. «Хайль Гитлер!» дип тәмамлады ул сүзен. Бу юлы аның алга сузылган кулы, фюрерны олылаудан бигрәк, хәзер кайсы юнәлештә барырга кирәклекне күрсәтте кебек. Һәм алар кабат юлларын дәвам иттеләр.

* * *

Зөфәр засадада ятучы авылдашларын күздән кичерде. Нибары сигез кеше калган. Дөрес, фашистлар да күп кырылды. Инеш үзәне аларның мәетләре белән тулган. Андрей, немецлар чигенеп торганда, үлгән солдатлар янына шуышып барып, биш-алты автомат алып килде. Дүрт граната да эләктергән. Монысы әйбәт булды. Юкса, патроннары бетү ягында иде. Соңгы һөҗүм вакытында, снарядлары беттеме, әллә башка сәбәп беләнме, немецларның гранатомётлары атудан туктады.

Харрасның ботына граната ярчыгы тиеп яралангач, отряд белән командалык итүне участковый Рафаил үз өстенә алган иде. Ләкин аның сугыш тәҗрибәсе юк, килеп туган кискен хәлләрдә тиз генә гамәл кыла алмый. Шуңа күрә командаларның күбесен Андрей бирә. Хәрби уставта каралганча, дәрәҗәсе дә югарырак булгач, ул моны табигый дип саный.

Әгәр болай дәвам итсә, бу көч белән позицияне озак саклый алмаслары көн кебек ачык. Зөфәр шуңа кайгыра иде. Үзләрен кырып салып, тайга эченәрәк кергән авыл кешеләрен эзләп тапсалар, эш харап! Немецлар, карт-коры дип җәлләп тормаячаклар, аларны да юк итәчәкләр. Мондый күп югалтулардан соң, аларның ачулары чиктән ашкандыр, тыныч халык белән ерткычларча кыланачаклар...

Кич җитеп, урман эченә караңгы төшкәнче, ничек тә позицияне кулдан ычкындырмаска кирәк. Немецлар караңгыда урман эченә борын тыгарга базмаячаклар. Бәлки бөтенләй авылга чигенерләр. Зөфәр бу хакта Андрейга һәм Рафаилгә дә әйтте. Тегеләр килештеләр.

Немецлар чираттагы һөҗүмне башлаганнар гына иде, урман эченнән чыгып, Камил һәм алдан ук үзләре белән калырга теләк белдергән дүрт хатын засадада ятучыларга килеп кушылды. Барысының да кулларында карабин. Зөфәр аларны күргәч, сөенде дә, көенде дә. Камил янына шуышып барып: «Ник авылдашларны калдырып киттегез, сине аларга җаваплы итеп билгеләделәр бит», – дип, аркадашын битәрли башлаган иде, Камил: «Без аларны тайгага тагын да эчкәрәк керттек, аннан эзләп таба алмаячаклар. Монда, аңлавымча, сезнең дә хәлләр хөртиләнә бара. Ярдәм кирәк», – дигәч, Зөфәр килеште. Аларның килеп җитүләре бик урынлы булды. Мондый чакта кораллы биш кеше – зур ярдәм.

– Фашистлар ягыннан да, безнең яктан да югалтулар бик зур. Көрәш бик каты. Ничә һөҗүмне кире кайтарганбыз – исәбен дә югалттым. Ә алар һаман, сукыр чебен кебек, ябырылып өскә килә, – диде Зөфәр. Аннан соң: – Төз атыгыз. Үз-үзегезне саклагыз, – дип өстәде дә үз позициясенә шуышты.

Тагын ике яктан да көчле пулялар яңгыры ява башлады. Мылтыклар шартлавы, автоматлар тырылдавы, чит телдә акырган-бакырган авазлар, кемнәрнеңдер ыңгырашуы, ярдәм сорап ялваруы – барысы бергә буталып, тоташ кыргый авазлар җыелмасына әверелде. Тагын мәхшәр купты.

Сугышның иң кызган чагында, кемгәдер ярдәмгә ашыккан Светланага очраклы пуля тиде. Үзе дә саксызлык күрсәтте: яткан урыныннан күтәрелә төшеп, якын гына араны йөгереп үтмәкче иде. Тик бер-ике адым атлауга, күкрәгеннән тотып, җиргә капланды. Бу хәлне күреп алган Андрей ярдәмгә ашыкты, ләкин үзе дә сакланырга кирәклеген онытты. Светлана янына килеп җитәргә нибары бер адым калгач, аның янәшәсенә чалкан егылды. Зөфәр тиз

генә алар ягына шуышты. Ни кызганыч, Светлана шунда ук җан биргән. Ә Андрей исән иде әле. Ул күзләрен ачып, Зөфәргә эндәште:

– Минем гимнастёрка астарына әти-әниемнең адреслары язылган кәгазь һәм хатыным белән кызымның фотосы яшерелгән. Зинһар өчен, сугыш беткәч, шуларны эзләп табып, минем кайда, ничек һәлак булганымны аларга сөйләгез.

Аннан соң башын Светлана ягына борып:

– Эх, Светлана, менә без хәзер мәңгегә бергә инде, – диде дә күзләрен бөтенләйгә йомды.

Зөфәрнең бите буйлап кайнар яшь тәгәрәде. Әле берничә көн элек кенә танышкан булсалар да, алар туганнар кебек якынайганнар иде. Нәкъ менә шушында, үзенең күзалдында җан биргәнен күрү өчен иңнәрендә күтәреп алып кайттымыни соң ул Андрейны «Ерак привал»дан?!

Немецлар бусында тиз генә чигенергә уйламадылар да. Алар да тиздән кич җитәсен һәм аңа кадәр «партизаннар»ның позицияләрен ала алмасалар, үзләренә кыенга туры киләчәген чамалыйлар булса кирәк. Шуңа күрә, әле үрмәләп, әле аягүрә басып, засадада ятучылар өстенә саранча шикелле ябырылдылар. Хәзер инде аларны зур югалтулар да куркытмый иде булса кирәк. Позициядә санаулы гына партизан калганын аңлап алдылар. Берничәсе хәтта уң як флангтан тылга үтмәкче булып, сиздермичә генә читкәрәк каерды. Ярый әле Зөфәр вакытында күреп алды да, немецларның үзләреннән үк алган ике гранатаны бер-бер артлы өсләренә томырды. Каршыдан инде якынга ук килеп җиткән фашистларга мылтыгыннан атуын дәвам итте. «Болай булса, тиздән кул сугышына күчәргә туры килмәгәе», – дип уйлады ул.

Тик шунда гаҗәп хәл булды. Урман эченнән камуфляжлы кешеләр йөгереп чыктылар да, «ур-ра» кычкырып, фашистларга ябырылдылар. Боларның «Олы җир»дән килгән ОМОНчылар икәнен Зөфәр шунда ук аңлап алды:

– Иптәшләр, безгә ярдәм килеп җитте. Теләсә ничек тәртипсез атышуыгызны туктатыгыз, юкса үзебезнекеләргә тидерүегез бар. Бары тик яхшылап төзәп кенә атыгыз, – дип кычкырды ул.

Ике яктан ут астында калган фашистлар, нишләргә белмичә, ары-бире йөгерделәр. Алар арасында көчле буталыш башланды. Ә оборонада торучы Күчкән Сала егетләре төзәп атып, аларны әкренләп «чүпли» тордылар. Исән калган фашистларның күпмедер өлеше, көньякка борылып, куа килүчеләргә автоматлардан ата-ата, агачлар арасына кереп шылды. Ике дистәгә якыны коралларын ташлап, кулларын күтәрде. ОМОНчылардан берничәсе һәм позицияләрдән торып баскан Күчкән Сала ирләре, әсир төшкәннәрне саклап калды. Дистәләгән ОМОНчы урманга кереп качкан фашистларны эзәрлекләп киттеләр. Урман эчендә әле тегендә, әле монда автомат тавышлары яңгырады.

* * *

Икенче көнне Күчкән Сала авылы гөжләп тора иде. Монда кемнәр генә юк! Южный посёлогыннан килгән гадәттән тыш хәлләр инспекторыннан башлап, ашыгыч рәвештә ил башкаласыннан чакыртылган төрле министрлык вәкилләре, гадәттән тыш хәлне тикшерү өчен оператив рәвештә оештырылган эш төркеме, хәрбиләр, янгын сүндерүчеләр, медицина хезмәткәрләре, юристлар, Федераль куркынычсызлык хезмәте агентлары һәм, әлбәттә, һәрнәрсәдән сенсация эзләргә яратучы журналистлар – авыл читендәге мәйданны сырып алган. Шуларга өстәп, авыл читенә ике вертолёт төшеп «кунаклаган», дистәләгән машина, зәңгәр һәм кызыл путалы микроавтобуслар тезелеп киткән... Бу кадәр

техниканың бирегә берьюлы җыелуы авыл тарихында беренче мәртәбәдер, мөгаен. Кыскасы – мәхшәр!

Берәр сәгать дәвамында ана – кызны, ата улны белмәгән шундый шартларда әрле-бирле йөргән халык, ниһаять, тынычлана төште. Федераллар һәм көч структуралары вәкилләре артык кешеләрне авыл читенә кудылар. Ә чирек сәгатьтән, хәрбиләрдән торган тере чылбыр, чебен дә үтеп керә алмаслык итеп, авылны әйләндереп алган иде. Кирәгеннән артык әрсезләнеп, артыгы белән кызыксынучы журналистларны да шул тыгыз кыршау читенә кудылар.

Бер яктан Эчке эшләр министрлыгы тикшерү эшләрен җәелдереп җибәрсә, икенче яктан Федераль куркынычсызлык хезмәте вәкилләре, бу хәл бары тик алар тармагына гына кагыла дигән сылтау белән, дилбегәне үз кулларына алмакчы булдылар. Аннан соң вакыйганың кайсы тармакка ныграк кагылганын ачыклаганчы, тикшерү эшләрен бергә алып барырга дигән нәтиҗәгә килделәр.

Беренче чиратта, Күчкән Сала авылы кешеләренең һәрберсен аерым чакырып, сорау алдылар. Бигрәк тә Зөфәргә һәм авыл башлыгы Харраска тыгызга туры килде, аларны көне буе сораулар белән тинтерәттеләр. Харрас яралы булганлыктан, аны реанимация машинасына кертеп салганнар иде. Сораштыру табиблар күзәтүе астында барды.

Кичен үлгән фрицларның гәүдәләрен бөркәүле ике зур машинага төяп, кайсыдыр хәрби базага алып китәргә җыена башладылар. Андрейның кем булуын ачыклагач, аны да шулар рәтенә куйдылар. Зөфәр аны: «Ул бит фашистларга каршы көрәштә һәлак булган совет офицеры. Күчкән Салада гына калдырыгыз. Үзе белән янәшә торып көрәшкән һәм һәлак булган авылдашларыбыз янына җирләрбез», – дип күпме генә ялынмасын, аның үтенечен канәгатьләндермәделәр. Андрейның үләр алдыннан Светланага карап: «Эх, Светлана, менә без хәзер мәңгегә бергә инде», – дигән сүзләрен исенә төшерде Зөфәр. Исән вакытта аз гына аралашып калсалар да, алар арасында җылы мөнәсәбәтләр урнашып өлгергән, күрәсең, дип уйлаган иде шул чакта. Ә хәзер, үлгәч, аларны аермакчы булалар. «Инде җәсәдләрегез бергә була алмаган икән, якты рухларыгыз оҗмахта янәшә була күрсен!» – дип теләде Зөфәр.

Яралы күчкәнсалалыларны Южный бистәсенә алып кайтып, хастаханәгә салдылар. Алар арасында граната ярчыгы тиеп, боты яраланган Харрас та бар иде. Каралты-курасыз калган авыл кешеләрен шулай ук, автобусларга төяп, «Олы җир»гә алып киттеләр. Зөфәрнең дә йорты янган. Тик гаиләсен Южныйга озатса да, ул үзе берничә көнгә Күчкән Салада калып торды. Һәлак булган авылдашларын соңгы юлга озатышасы бар иде шул.

Ике көннән фашистларга каршы көрәштә һәлак булган Күчкән Сала кешеләре белән хушлашу митингы булды. Барлыгы уналты кешене, шәһәрдәге хәрби гарнизоннан чакыртылган солдатлар мылтыклардан залп биреп, хәрбиләрчә соңгы юлга озаттылар. Чыгыш ясаучылар күп булмады. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан килгән вәкил һәлак булганнарның барысын да медальгә тәкъдим итәчәкбез, дип вәгъдә бирде.

Ә тагын бер көннән авыл чит-ят кешеләрдән бушап калды. Иң ахырдан Федераль куркынычсызлык хезмәте вәкилләре китте. Алар соңгы эшләре итеп, Күчкән Сала авылының олысына-кечесенә, «авылда булган бу вакыйгаларны сер итеп сакларга» кушып, шул таләп үтәлмәгән очракта, җинаять җаваплылыгына тартылачаклары турында кисәтеп, кул куйдырдылар. Кемнәр кемнәр, федераль хезмәттәгеләр анысын җиренә җиткереп башкара

белә. Шулай итеп, Күчкән Салада булган бу гайре табигый вакыйга тикшерү документларына «Үтә яшерен» мөһере сугылып, җиде йозак артына бикләп куелды.

* * *

Мартин күзләрен ачты. Ул башта бернәрсә дә аңламый торды. Хәер, хәтерләсә дә, килеп туган хәлгә дөрес бәя бирә алмас иде. Ничектер, барысы да ул уйлаганча булып чыкмады. Башта, шактый вакыт, партизаннарның эзен таба алмыйча интегеп йөрделәр. Урмандагы һәр агач төбе саен качып яталардыр, дип уйлаган Мартин өчен бу гаҗәп тоелды. Урман эченә шактый ерак кереп тә, бер партизанны да очратмауларын ул аларның үтә дә хәйләкәр булуыннан күрде, моны үзләрен бармак арасыннан йөртү дип кабул итте. Ачудан, балаларча үҗәтлек белән эзләвен белде. Ниһаять, тырыша торгач, эзләренә дә төшкәннәр иде...

Засадага килеп чыгып, беренче мәртәбә атышуда ук шактый солдатларын югалттылар. Партизаннар сайлап җыйган мәргәннәр диярсең, барысы да төз ата. Бер генә пуляларын да бушка җибәрмиләр. Ләкин ут нокталарына караганда, алар артык күп булырга тиеш түгел иде. Яхшы коралланган күпсанлы эсэсчылар өчен, аларны гына юк итү кыен булмаячак, дип фикер йөртте Мартин. Партизаннар хәйләләп, капчыкка тыгарга җыенмыйлармы икән үзләрен, дигән уй гына бераз куркытты аны. Каршыга аз гына көч куеп, аларның уяулыкларын киметерләр дә ике яктан уратып, тылга төшеп, «һоп» капчыкның авызын бәйләп тә куярлар. Аннан соң әсирлеккә төштем, дип сана...

Хәрби эшкә өйрәтелмәгән партизан чирүенә әсирлеккә төшүне Мартин оят, гарьлек, түбәнлек дип саный иде. Дөньяда тиңе булмаган, ныклы дисциплинага ия Вермахт армиясе солдатлары, өстәвенә эсэсчылар, ничек итеп, аз гына да хәрби әзерлекләре булмаган бер чирүгә әсир төшсеннәр соң?! Ә үзен хәрби тоткын хәлендә бөтенләй күзалдына китерә алмый иде ул. Шуңа күрә хәстәрен алдан күрүне кирәк санады, чолганышта калмас өчен, төп көчләрне өч өлешкә бүлеп, засадада ятучы «партизан»нарга каршы баручылардан тыш, берничә взводны ян-якларны сакларга куйды.

Засадада ятучылар аларның һәр һөҗүмен кире кайтара тордылар. Өсләренә сибелгән пуля өермәсенә түзә алмыйча, ачык үзәндә күпсанлы мәетләрен калдырып чигенделәр эсэсчылар. Тегеләр уңайлы позициядә шул. Качып ятучы партизаннарга ерактан атып тидерү мөмкин түгел, ә якын килә башласалар, ачык урында аларны кырып кына салалар. Һәр һөҗүм саен ян-якка куелган төркемнәрдән солдатлар алып, төп көчне тулыландырып торырга туры килде Мартинга. Аннан соң ярты көн үтеп тә, флангларда дошман күренмәгәч, бөтен көчне һөҗүмгә куйды. «Баштан ук шулай кирәк булган», – дип, эчтән генә үз-үзен битәрләп тә алды әле. Чөнки югалтулар бик зур иде.

Дөрес, берара өстенлек Мартин солдатлары ягына да күчкән кебек булды. Үзләрендә гранатомёт барлыгын искә төшереп, аны эшкә җиктеләр. Партизаннар позициясендә гранаталар төшеп шартлый башлагач, бинокль аша күзәтеп торган Мартин теге якта ыгы-зыгы купканын тиз шәйләде. Ул кабат солдатларны атакага күтәрде. Бу соңгы һөҗүм булырга тиеш. Һәм анда үзләренең җиңәчәкләренә Мартинның аз гына да шиге юк. Ул хәтта һөҗүмгә ташланыр алдыннан солдатларының «кәефен күтәрү өчен» гомуми флягадан солдатларга йөзәр грамм «шнапс» та бүлдереп биргән иде.

Бусында позициягә барып җитәргә аз гына калды. Соңгы чиктә партизаннар

утына түзә алмыйча, җиргә ятарга мәҗбүр булдылар. Артта, куш агач төбендә бинокль аша һөҗүмнең барышын күзәтеп яткан Мартин юкка гына «Ауфштехен!» «Форвардс!» дип, тамагын ертып акырды. Үз-үзләрен саклау инстинкты җиңде: солдатлар, кайда мүкәләп, кайда шуышып чигенергә мәҗбүр булдылар. «Сугыш кыры»нда тагын үле гәүдәләр генә сибелеп калды.

Аларның сафы сирәгәйгәннән-сирәгәя. Алдагы һөҗүмгә күчкәнче, бераз тагын гранатомёт белән «куркытып алырга кирәк», дип уйлады Мартин. Моның бер уңайсыз ягы да бар икән: теге яктан төз атып, гранатомёт артында ятучыларны чүпләп кенә торалар. Мартин позицияне дә алыштырып карады, барыбер файдасыз. Партизаннарның бик оста снайперлары бар, ахрысы. Аткан һәр пулясын нәкъ урынына тидереп кенә тора. Шуңа күрә гарнатомёт артына ятарга атлыгып торучы юк.

Бу очракта ике мәртәбә аттылармы икән, гранатомёт көйсезләнде. Ни сәбәптәндер, механизмы сафтан чыкты. Мартин тизрәк көйләргә дип, куркытып, кычкырып әмер бирсә дә, корал бүтән телгә килмәде. Инде җиңәбез дигәндә генә, коралның хыянәте Мартинның җен ачуларын чыгарды. Ул: «Бевеге зих дас фуле швайн!» дип сүгенә-сүгенә, солдатларны кабат һөҗүмгә куа башлады. Берничәсенә дагалы итеге белән типкәләп тә алды. Юкса кич җитеп килә. Көндез җиңә алмаган партизаннарны төнлә җиңү турында уйлыйсы да юк. Киресенчә, иялəнгән урманда төнлә белән алар үзләрен иркен хис итәчәкләр. Таңга кадәр эсэсчыларның аз гына калган сафын тар-мар итеп куюлары да бар.

Алдан – ут, арттан командирларының чыбыркылавын күреп, нишләргә белмәгән, тәмам ярсыган солдатлар һөҗүмгә ташланды. Засадада ятучылар позициясенә ерак та калмаган иде. Тагын бер талпыныш һәм күп корбаннар бәрабәренә булса да, «биеклек» алар кулына күчәчәк...

Шулчак көтелмәгән хәл булды. Һөҗүмчеләрнең тылыннан, кулларына автоматлар тоткан, барысы да бертөрле коңгырт, яшел төсләр төшерелгән камуфляжлы киемнән бер зур гына төркем килеп чыкты да, ут яудырып, саранчалар шикелле аларның өстенә ябырылды. Бу хәлдән аптырап калган эсэсчылар паникага бирелеп, ары йөгерделәр, бире йөгерделәр. Мартин аларны юкка гына тәртипкә чакырып маташты. Куркудан нишләргә белмәгән солдатлар аны ишетерлек хәлдә түгел иде. Өстәвенә, нәкъ шул чакта партизаннар үзләре яткан позициядән торып, «ур-ра» кычкырып, атакага күтәрелделәр. Нишләргә белмәгән эсэсчылар янәшәдәге куе агачлар арасына кереп качты. Ээрлекләүче партизаннар һәм камуфляжлы хәрбиләр алар артыннан ташланды.

Шунда Мартин үзенә таба йөгереп килүче бер партизанга пистолеттан атмакчы булып төбәгән иде. Артыннан килгән партизанны шәйләмичә калган. Анысы мылтык түтәсе белән башына орды. Мартин шуннан берни дә хәтерләми. Ул аңын югалтып егылды...

* * *

Менә хәзер Мартинның һушына килүе. Тирә-якны караштыргач, ул башта берни дә аңламыйча торды. Башы бик нык авырта. Кулы белән тотып караган иде, аны бинт белән ураганнар. Теге партизан приклад белән җәлләп сукмаган булырга тиеш.

Соңыннан аңлавынча, Мартин нindидер тар гына бүлмәдә, кушеткада ята булып чыкты. Аның янында ак халатлы бер ир һәм хатын-кыз. Тагын да яхшылап карый торгач, Мартин үзе ята торган урынны машина фургоны түгелме икән, дип фаразлады. Монда бөтен нәрсә актан. Мартин әлегә кадәр

беркайчан да күрмәгән приборлар, җиһазлар бар. Медицина машинасы булырга тиеш. Партизаннарның үзләрендә болай җиһазландырылган санитар машиналар булу шикле. Димәк, аларга ярдәмгә хәрәкәттәге армия частьлары килеп җиткән. Фронт сызыгы шулай якын булды микәнни?..

Аның уянганын күреп, ак халатлы санитарлар якынрак килделәр. Ир заты рус телендә ниндидер сорау бирде. Мартин аңламады, әлбәттә. Тәрҗемәче Хартман юк шул монда. Ул партизаннарга каршы соңгы һөҗүмнәрнең берсендә һәлак булды.

Телләрен аңламаса да, Мартин санитарларның йөзендә усаллык күрмәде. Усаллыктан бигрәк, нәрсәгәдер гаҗәпләнү, аптырау чалымнары бар иде аларда. Санитар хатын, ап-ак нәфис куллары белән үрелеп, аның башына уралган бинтны капшап, рәтләштергәләп тә куйды хәтта. Шулчак Мартинның борынына ниндидер хушбуй исе килеп бәрелде. Мондый исне Берлин урамында йөргәндә, парфюмерия кибетләре тирәсендә сизгәне бар. Концертларга барган чагында хатыны Амалиянең дә киемнәреннән шундый хуш-исләр килә иде. Мартинның сугышка кадәр булган тыныч вакытлары исенә төште. Совет хатын-кызлары фронтта да ислемай сибенеп йөриләрме икәнни, дигән уй йөгереп үтте аның күңеленнән.

Ак халатлы ир кесәсеннән чыбыксыз телефон трубкасы алып, нәрсәдер әйтте. Ярты минут уздымы икән, ишек ачылып, аннан ике солдат керде. Тик аларның киемнәре әлегә кадәр Мартин күреп белгән совет солдатларыныкына бер дә охшамаган иде. Бәлки, медицина ярдәме күрсәтә торган берәр подразделениенең үзенчәлекле формасыдыр, дип уйлаудан уза алмады ул.

Солдатлар аны җайлап кына носилкага салдылар да, икесе ике яктан күтәреп, машина фургоныннан алып киттеләр. Урамга чыгуга ук Мартин үзенең кайда икәнлеген чамалады. Партизаннарны эзәрлекләп йөргәндә, алар миномёт утына тоткан партизан лагере тирәсе бу. Тик ул чактагы буп-буш авыл бүген гөрләп тора. Ерак кына түгел ике вертолёт төшеп утырган. Әлегә кадәр ул бер мәртәбә дә күрмәгән әллә нинди искитмәле зур-зур машиналар тезелеп киткән. Ә иң гаҗәбе: шул техника тирәсендә тыз-быз чабышучы хәрбиләр барысы да ыспай киенгәннәр. Формалары да, Мартин уйлавынча, рус офицерлары киемнәренә бер дә охшамаган. Үзләренә әсирлеккә төшкән совет офицерларын да, солдатларын да күп күрергә туры килде аңа. Алар, гадәттә, пычранып беткән киемнәрдән, йөзләре берничә көн кырынмаган була иде. Ә болар?.. Яңа гына энә-җептән чыккан, үтүкләнгән чиста киемнәрдән. Боларның окопларда ятып сугышучылар түгеллеге тышкы кыяфәтләреннән үк кычкырып тора.

Әллә соң ул партизаннарны эзәрлекләп йөргән арада, инглизләр белән американнар «икенче фронт» ачканнармы? Бу хакта югары командованиедә күптән сөйләнәләр иде. Бәлки, болар Америка солдатлары һәм офицерларыдыр? Алай дисәң, әле кайчан гына эсэсчылар корпусы белән командалык итүче оберштурмбанфюрер Эрдман, офицерларны җыеп, икенче фронтның ачылачагына шик белдерүе турында сөйләгән иде. Кем-кем, ул алдашуга юл куймас. Димәк, болар американнар да, инглизләр дә түгел. Ә кемнәр соң?

Солдатлар аны носилка белән зуррак машина фургонына керттеләр. Анда шулай ук ыспай киемле бер офицер һәм гадәти костюм-чалбардан, галстуклы бер адәм утыра иде. Каршыларында ниндидер экранлы аппарат. Андыйны Мартинның бөтенләй күргәне юк. Алар кергәндә, офицер шул

аппаратның экраныннан нәрсәдер күзәтә һәм вакыт-вакыт бармаклары белән каршысындагы төймәле тактасыман яссы әйбергә баскалап ала иде.

Солдатлар Мартинны кушетка кебек урынга куйдылар да чыгып киттеләр. Офицер белән гадәти киемдәге кеше үзара русча сүз алышкач, офицер немецчага күчте. Немец телендә ул төртелеп тормыйча, тоткарлыксыз сөйләшсә дә, Мартин анда ниндидер ят акцент сизде.

– Кәефләрегез ничек, господин офицер? Бик сызланмыйсызмы? – дип башлады рус офицеры сүзен.

Карале, нигәдер бик йомшак сөйләшә әле бу, дип уйлады Мартин ирексездән. Безнең төп частьларның кайда урнашканын әйттерергә инде моның исәбе. Тик Мартин бернинди мәгълүмат бирергә җыенмый. Әгәр үлә икән, ул бөек Рейх империясе солдаты булып, башын югары тотып үләчәк.

– Күреп торасыз, баш тишелгән. Бу хәлдә кәеф ничек булырга мөмкин? – диде ул, сорау тонына ярашлы тынычлык сакларга тырышып.

– Гафу итегез! – дип, түбәнчелек белән эндәште аңа офицер. – Сугыш бит! Андый хәлләр булгалый. Сез минем берничә соравыма җавап бирә алырлык хәлдәме?

Әсирләр белән сөйләшкәндә, үзе тәкәллефләнеп торырга яратмаган Мартинга совет офицерының болай йомшак сөйләшүе сәер тоелды, әлбәттә. Ул әсирләрдән сорау алганда, гадәттә, әдәплелек күрсәтеп тормый, кискен сораулар бирә, зәһәр генә сүгенеп тә җибәргәли, кулларын, аякларын эшкә җиккән чаклары да булгалады. Андый эшләргә үзенең генә көче җитмәсә, ярдәмгә башкаларны чакыра иде. Ә бу әнә ничек гуманлы булып кылана! Телне бик тиз ачтыра торган үтемлерәк ысулларны ахырга калдырмакчыдыр, бәлки? Башта матур сүзләр белән майлап карарга җыенадыр?.. Юк, алай гына алдыра алмассыз! Мартин – чиста «ариец»! Бөек Бисмарк токымыннан ул!

Күңеленнән шулай уйланса да, кирелегеп тышка чыгармады Мартин:

– Соравыгыз ниндидер бит? Сорап карагыз, җавап бирергә тырышырмын, – диде ул, мөмкин кадәр тынычлык саклап.

– Исемегез ничек? Кайда һәм кайчан тудыгыз?

– Болар бик җиңел сораулар. Рәхәтләнеп җавап бирәм, – дип башлады сүзен Мартин.

Ул офицер каршындагы өстәлдә үзенең документлары ятканын күргән иде инде. Офицер аларны берничә мәртәбә кулына алып караштыргалады да хәтта. Димәк, ул аның кем икәнен болай да белә. Соравы да сүз җае өчендер, мөгаен. Андый гына әһәмиятсез сорауларга җавап бирергә авырыксынмый Мартин. Инде бер сөйли башлагач, тулырак мәгълүмат та бирә алам дигәндәй, үзенең бала чагын, яшьлек елларын, гомумән, хәрби темага бөтенләй кагылышы булмаган нәрсәләрне дә сөйләп ташлады. Аларын офицер тыңлап тормас, үзен ярты сүздән бүләр, дип уйлаган иде. Юк, бик игътибар белән тыңлады. Ахырда, тамагы кипшереп, Мартин үзе сөйләүдән туктады. Су сорап алды.

Сөйләвен дәвам итәр дип, аңа текәлеп утырган офицер, Мартин кабат бер кәлимә сүз дә әйтмәгәч, тамагын кыргалады да чираттагы соравын бирде:

– Гер гауптштурмфюрер, сез хәзер ничәнче гасырда һәм ничәнче елда яшим, дип уйлыйсыз?

Моны сорау булудан бигрәк, үзеннән көлү дип кабул итте Мартин. Мылтык түтәсе белән баш чүмеченә бәргәч, акылына зыян килгән дип уйлый, күрәсең. Беренче сорауга җавап биргәндә, үзен «ычкынган» кеше кебек тотты микәнни? Бәлки аңа, чыннан да, юләр булып кыланыргадыр? Артык җитди сораулар биреп,

тинтерәтмәсләр иде, ичмасам. Калган гомерен психиатрия диспансерында, тилеләр арасында... Ләкин андый түбәнлеккә төшү түгел, ул хакта уйларга да оялды Мартин. Ул – офицер, ахыргача бөек фюрерына тугрылыклы булып үләчәк...

– Ә сез үзегез ничәнче ел дип уйлыйсыз?

Мартин каһкаһә белән көлде. Ләкин аның бу халәте каршысында утыручыларны артык гаҗәпләндермәде шикелле.

– Бу – егерме беренче гасыр, 2030 ел, – диде тыныч кына, әлегә кадәр эндәшмичә утырган кунак киемендәге галстуклы адәм.

Көләләр! Үзеннән оятсызларча көләргә җыеналар.

– Аңлагыз, гер гауптштурмфюрер Мартин, сез хәзер, чыннан да, 2030 елда. Сугыш беткәнгә дә 85 ел инде, – дип дәвам итте галстуклы адәм.

– Партизан мылтык түтәсе белән башыма оргач, мин сиксән елдан артык һушсыз ятканмын, дип әйтмәкче буласызмы?

– Юк, алай дип әйтмим. Сез, чыннан да, әле моннан ике көн элек кенә яраланып, һушыгызны югалттыгыз.

– Соң?.. Шулай булгач?.. 2030 елның нинди катнашы бар монда?

Каршыда утыручылар тагын үзара русча сөйләшеп алдылар. Алар да офицерга нәрсәдер аңлатырга тырышты бугай.

– Сез ниндидер могҗиза белән нәкъ менә 2030 елга килеп эләккәнсез...

– Сез... Сез алдашасыз. Моның булуы мөмкин түгел! – дип кычкырып җибәргәнен Мартин үзе дә сизмичә калды.

– Әйе, булуы мөмкин түгел. Мин моны үзем дә башыма сыйдыра алмыйм... Ләкин күреп торасыз... булган.

Менә хәзер генә, шушы кеше әйткән сүзләрне күңеле белән кабул итәргә теләгәндәй, Мартин уйга батты. Аның каршысында ышанмастай нәрсәләр сөйләп утыручы бу ике кешенең максаты нәрсәдә? Мистика! Әкият! Кайвакыт оста итеп сөйләсәләр, әкияткә дә ышанырга була. Кечкенә вакытта Мартинга әбисе дә әкиятләр сөйли иде. Билгеле, ул вакытта кечкенә Мартин аларга чын күңеленнән ышана иде... Ә болар? Шулай күрәләтә мыскыл итеп торалар икән, моннан соң ул аларның бер генә соравына да җавап бирмәячәк.

– Гер гауптштурмфюрер Мартин! – Рус офицеры Мартинның документын өстәлдән алды да күзләренә якын китереп карады, исемен тутырып әйтте. – Гер Уильям Фредерик Мартин, үзегез өчен сугыш беткән, дип уйлагыз. Дөресендә, ул безнең өчен дә күптән бетте. Моннан 85 ел элек фашист Германиясе, үзенең җиңелгәнлеген танып, берсүзсез капитуляция ясады. Адольф Гитлер да күптән капут... Алар барысы да тарихта гына калдылар...

– Ялган! – дип ярсып кычкырды Мартин һәм торырга кузгала башлады.

Аны кулларыннан тотып тынычландырырга тырыштылар. Хәтта ярдәмгә солдатларның берсен чакырып керттеләр. Бераз тарткалашкач, Мартин хәле китеп, урынына ауды. Аның маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Офицер, сулы стаканны алып, Мартинның иреннәренә якын китерде. Бер-ике йотым су эчкәч, Мартин тынычлангандай булды.

– Гер Мартин, ышанырга авыр булса да, кабатлап әйтәм, без сөйләгәннәр барысы да чынбарлык... Сез моннан ике көн элек үзегезнең сугышчыларыгыз белән тыныч кына яшәп ятучы авылга бәреп кергәнсез. Һәлак булучылар шактый... Тыныч шартларда бу җинаять дип атала.

– Сез нәрсә?! Мине – бөек Вермахт армиясе офицерын, «истинный ариец»ны җинаятьче дип атамакчы буласызмы?

– Һичшиксез, җинаятьче! Фашистик Германия үзе дә хәрби җинаятьләре

өчен Нюрнбергта узган халыкара суд каршында җавап тотты инде. Сугыш утын кабызып җибәргән фашист башлыклары барысы да үзләренә тиешле җәзаны алдылар... Хәер, болары үткәндәгеләр... Тарихта гына калды.

– Мин – офицер! Югары командованиенең боерыгын үтәп, партизаннарга каршы сугыштым.

– Хәрби шартларда бу шулай бәяләнсә дә, тыныч шартларда кеше үтергән өчен җинаять җаваплылыгы каралган. Россиянең гамәлдәге кануннары буенча, күрәләтә торып бер яки күбрәк кешенең сәламәтлегенә зарар китерүче яисә аны үтерүче хөкем ителә.

Мартин эндәшмәде. Ул – тирән уйда. Бу кешеләрдән ишеткәннәр аның акылына сыешлы түгел иде.

– Без баштан сезне исән калган солдатларыгыз белән шунда ук Германиягә озатмакчы идек. Ләкин җинаятьләрегез ни дәрәҗәдә авыр икәнлеген ачыкламыйча торып, моны эшләмибез. Вакыйга бөтен детальләренә кадәр өйрәнелгәч, һәркемгә тиешле җәзасы билгеләнгәч, сезне туган илегезгә озатачакбыз. Ләкин бу сез җәзасыз каласыз, дигән сүз түгел. Халыкара җинаятьләрне тикшерү суды аша без Россиядә чыгарылган суд карарын үз илегездә үтәтүгә ирешәчәкбез...

Әллә башындагы яралардан, әллә инде яңа гына ишеткән сүзләрдән, Мартин күзаллары томалана башлавын сизде. Ул инде алга таба сөйләшер хәлдә түгел иде.

* * *

Санаторийда тыныч күңел белән ял итеп яткан көннәрнең берсендә иртә белән Левинга үзе эшли торган фәнни-тикшеренү институтыннан шалтыраттылар. Ашыгыч рәвештә консилиум җыярга булганнар икән. Аның ише чаралардан гыйльми киңәшмә җитәкчесен читтә калдырганнары юк. Монысында да искәрмә булмады. Левинның санаторийга сәламәтлеген ныгыту өчен киткәнлеген белсәләр дә, чакырырга булганнар. Әле алай гынамы, чакыруы да килсәң ярый, килмәсәң дә була кебек кенә түгел, ә мәҗбүри, диделәр. Ни сәбәпле җыялар – анысы турында ләм-мим бер сүз әйтмәделәр. Димәк, җитди сәбәпләре бар.

Левин тиз генә әйберләрен җыештырды да, саубуллашып чыгарга дип, дусты Сазоновның ишеген какты. Әле иртәрәк булса да, ул – «табигать баласы», бу вакытка кадәр йокы симертмәс, уянгандыр инде, диде.

Ялгышмаган булып чыкты. Сазонов уянган, юынып, кырынып, киенеп тә куйган хәтта. Аның таң тишегеннән аяк өстендә булуы башка көннәрдә дә гадәти күренеш иде. Ул иртә торып, йә гимнастика ясый, йә балконга чыгып, тирә-якка карап хозурлана, еш кына беренче каттагы йөзү бассейнына төшеп, үзе әйтмешли, «су процедурасы» ала. Ә бүген, әнә, андый күнегелгән режимны бозарга уйлаганмы, «парад киемнәрен» үк киеп куйган.

– Бәйрәмгә җыенасыңмы? – дип башлады сүзен, хәл-әхвәлләр белешкәч Левин.

– Китәм, дускай. Калган вакытны миннән башка, үзеңә генә ял итеп бетерергә туры килер. Ашыгыч рәвештә эшкә чакырдылар. Саубуллашып чыгу өчен уянганыңны гына көтә идем. Синең бит таң аткач та тормыйча, иркәләнеп ята торган гадәтең бар. Борчыйсым килмәде.

Ахиренең төртмәле сүзенә Левин аз гына да үпкәләмәде. Елмаеп кына куйды.

– Мин дә китәм. «Покой нам только снится», дигәндәй, мине дә эшкә

чакырып шалтыраттылар. Консилиум, диләр. Гыйльми киңәшмә! Истә-оста юкта, кемнең исенә төшкәндер, белмим... Ә сине нәрсәгә чакыралар?

Сазонов кулын селтәде дә кычкырып көлде:

– Кемнәрдер саташа башлаган. Урманда фашистлар күренә, диме шунда? Ахырзаман!

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Левин кушылып көлә башлаган җиреннән кинәт кенә җитдиләнеп, сагаеп калды:

– Фашистлар күренгән, дисеңме?

– Әй, андый тилемсәләр һәр җирдә дә берән-сәрән очраштыргалый инде ул.

– Син миңа фашистлар турында әйткәч, минем башыма бер уй килде әле. Безне ялдан бүлеп, эшкә чакыруларының сәбәбе икебезнеке дә бер түгелме икән?

– Ягъни? Сездә дә бармы әллә шундый юләрләр? Аңлатыбрак сөйлә әле, дускай.

– Юк, бездә юләрләрдән бигрәк, артык акыллылар күп. Менә шулар кайчак акыллары аркасында мөгез чыгарып куялар да инде. Мин хәзер эшнең нәрсәдә икәненә бераз төшенә башладым кебек. Сиңа барысын да җентекләп сөйләргә вакыт тар. Соңыннан иркенләп аңлатырмын. Ә хәзергә саубуллашыйк та һәркем үз юлына китеп барсын.

...Александр Васильевич институтның киңәшмәләр үткәрелә торган кече залына килеп кергәндә, консилиум башланган иде. Ул үзенең «исемле» урындыгына таба үткәндә, тирә-якка күз салды: залда институт директорыннан, берничә гыйльми хезмәткәрдән, ике-өч бүлек мөдиреннән тыш, кайчандыр институт хезмәткәрләре булып, «яшьләр бунты» шаукымы белән киткән яшь галимнәр һәм тагын өч-дүрт таныш түгел кеше бар иде.

Левин керде дип, чыгышларны өзеп, киңәшмәнең көн тәртибе белән таныштыруны кирәк санамадылар. Аның сәламләвенә каршы баш селкеп кенә җавап биргәч, таныш түгел кешеләрнең берсе сөйләвен дәвам итте. Бернәрсәдән хәбәрдар булмаган Левин янәшәсендә утырган директорның колагына иелеп:

– Консилиум нәрсә уңаеннан җыелды? – дип пышылдады.

– «Яшьләр бунты» вакытында бездән китеп, үзләре мөстәкыйль эшли башлаган яшь галимнәр төркеме нindидер ЧП китереп чыгарган, ди бугай. Монда бүген федераллар, прокуратура вәкилләре шуңа бәйле мәсьәләне тикшерәләр...

– Ә безнең нинди катнашыбыз бар ул яшьләрдә? Кайчандыр бездә эшләгән булсалар да, киткәннәренә шактый вакыт бит.

– Барыбер без очырган «асылкош»лар. Оясында ни күрсә, очканында шул, дигәндәй... Бәлки, әлеге хәлгә карата фән учреждениесе вәкилләренең фикерләрен ишетәселәре киләдер...

Директор сүзен әйтеп бетерә алмады, киңәшмәгә рәислек итүче адәм, дәрестә тыңламыйча утыручы укучыны тәртипкә чакырырга теләгәндәй, кулындагы ручка арты белән өстәлгә тукылдатып алды. Трибуна артында Сергей Попов иде.

– ...Әйе, без вакыт аша күчеш теориясенең дөреслеген тәҗрибә юлы белән исбатладык. Бу – фәндә бик әһәмиятле адым. Гомумән, бу теория зур алгарышларга тәрәзә ачачак. Фән өлкәсендә – кискен борылыш, революция. Энергия запасларына кытлык заманда, энергиянең әлегә кадәр үзләштерелмәгән төрләрен куллану, киләчәк заман фәненнән күпме кирәк

мәгълүмат алу мөмкинлеге. Беләсезме, бу фән-техника өлкәсендә алга сикереш булачак, – дип, матур сүзләр белән теленә салынды Сергей.

Ашыгасың, егеткәй! Хыялларың акылыңнан алдарак йөгерә түгелме?! Сикереш ясау өчен яхшылап этенеп китәргә кирәк. Зуррак сикереш ясау өчен йөгереп, тизләнеш алу зарур. Ә син?.. Борынгы грек галиме Архимед: «Миңа таяну ноктасы бирсәгез, дөньяның астын-өскә китерәм», – дигәнме? Син дә шуның шикелле. Киләчәк заманнар тәҗрибәсеннән файдаланмакчы, имеш! Яшь галимнең сүзләрен тыңлаганда, әнә шундый уйлар йөгереп узды Левинның башыннан.

– Сүз дә юк, сез әйткәннәрнең барысы да бик заманча яңгырый. Болары – фәнни ягы. Ә менә җәмгыятькә нинди йогынты ясар икән сезнең ачыш? Җәмгыять үсешенә ясалма тизләнеш кирәкме? Гомумән, вакыт машинасы уйлап табылуны кешелек дөньясы ничек кабул итәр? Теориядә барысы да ахырынача уйланганмы? Күчкән Сала авылы янында булган гадәттән тыш хәлләр моның гел киресен раслый. Вакыт аша күчеш теориясе буенча әле беренче тәҗрибәләр уздырыла, инде корбаннар да бар, – дип, сорауларның яртысын алдындагы кәгазьдән укып, калган яртысы белән күңелендәгесен чыгарып салды рәислек итүче.

– Вакыт теориясе соңгы ноктасына кадәр төгәл уйланылган. Ә менә җәмгыятькә йогынтысына килгәндә... Фәнгә нинди генә яңалык керсә дә, ул корбаннарсыз булмаган. Кеше уттан файдалана башлаган – ут та кеше сәламәтлеге өчен куркыныч. Янып үлүчеләр күп бит. Әле хәзер дә янгыннар чыгып тора. Электр уйлап тапканнар – кешеләрне ток суккан. Аңа карап, электрдан ваз кичкәннәрме? Юк! Хәзерге вакытта яшәешебезне электрдан башка күз алдына да китереп булмый. Атом көчен уйлап тапканнар – шунда ук кешеләрне меңәрләп кыручы атом бомбалары ясала башлаган. Боларга өстәп, тыныч шартларда файдаланылучы атом станцияләрендә фаҗигаләр булып тора. Гуманлылык күзлегеннән караганда, атом энергиясеннән файдалану күптән тыелырга тиеш тә бит. Тыеламы? Юк! Шулай булгач, әгәр вакыт машинасы уйлап табылу фән-техника алгарышына юл сала икән, кешелек дөньясындагы аз санлы корбаннарга гына беркем дә карап тормаячак.

Сергейның дәлилләре шактый нигезле идеме, әллә рәислек итүченең бу өлкәдә белеме шуның кадәр генә булдымы – ул башкача сораулар бирмәде, галимгә урынына барып утырырга кушты. Аннан соң янәшәсендә утырган институт хезмәткәре белән нәрсәдер сөйләшеп алды. Тегесе Левин ягына ымлап күрсәтеп, нидер әйтте. Үзенә сүз бирәчәкләрен аңлап алды Левин. Чыннан да, әлеге хәлгә карата фикерен белдерү өчен сүзне аңа бирделәр. Тик ул сөйли башлаганчы, рәис вакыт машинасы уйлап табылуга бәйле рәвештә Күчкән Сала авылында килеп туган гадәттән тыш хәлне кыскача гына сөйләп бирде.

– Вакыт машинасы уйлап табылу – фән өлкәсендә гаять зур вакыйга. Аның киләчәктә перспективасы барлыгына минем шигем юк. Яшь галимнең бу хакта китергән дәлилләре белән килешәм, – дип башлады сүзен Левин. – Ләкин Күчкән Сала авылы янында булган фаҗигаләр бу күренешнең бөтен нечкәлекләренә кадәр өйрәнелеп бетелмәве турында сөйли. Фәнни яңалыкның икътисади ягы гына түгел, куркынычсызлыгы да ныклап уйланып беткәч кенә, аны тәҗрибәдә кулланырга мөмкин. Ә бу очракта моның киресен күрәбез. Фәнни ачыш әле кешелеккә файда китермәгән, ә инде корбаннар бар...

– Александр Васильевич, сүзегезне бүлдергәнем өчен гафу итегез, фаҗигаләргә китергән төп сәбәпләрне нәрсәдә күрәсез, ягъни теориянең

ахырынача өйрәнелеп бетмәгән яклары турында сөйләп бирә аласызмы? – дип соравын кыстырды рәис.

– Беренчедән, бу эшне хәрбиләрнең һәм федералларның үз канатлары астына алуы да моңа йогынты ясамый калмагандыр, әлбәттә, – дип сөйләвен дәвам итте Левин. – Чөнки хәрбиләрне, иң беренче чиратта, мәсьәләнең җимергеч ягы, яки дошманнарны күпләп юк итү кызыксындыра. Шуңа күрә аларны теләсә нинди фәнни экспериментлардан читләштерергә кирәк. Мондый экспериментларны хөкүмәт үз күзәтчелегенә алырга тиеш. Бу очракта яшь галимнәрне гаепләп тә булмый. Әгәр аларның фәнни тикшеренү эшләрен хөкүмәт тиешенчә финанслаган булса, аларның хәрбиләр ярдәменә ихтыяҗлары булмас иде. Икенчедән, эксперимент барышы турында тирә-якта яшәүчеләр кисәтелмәгән.

– Эксперимент тайга уртасында алып барылды. Ул тирәләрдә дистәләрчә километр диаметрда сыңар адәмне дә очратырмын, димә. Шул кыргый хайваннар – аюлар, бүреләр булса гына инде. Александр Васильевич, әйдәгез, мәсьәләгә кагылышлы җитдирәк дәлилләр китерегез әле, – дип урыныннан гына кычкырды Сергей Попов.

Аның «аюлар, бүреләр булса гына инде», дигән сүзләреннән кайсыдыр хихылдап көлә башлаган иде, рәис янә ручкасы белән өстәлне төеп алды.

– Ә нигә, аюлар, бүреләр дә – тереклек ияләре. Әгәр, әйтик, бер сыңар тереклек иясе генә дә вакыт аралыгы аша үткәннәргә күчсә һәм андагы бер җәнлекне генә тотып ашаса да, ул фаунага төзәтеп булмаслык зыян салырга мөмкин. Хәтта үткәннәргә барып, бер күбәләкне генә үтергән очракта да, бөҗәкләрнең кайбер төрләре тулысынча югалуга дучар булырга мөмкин. Моннан тереклек дөньясына зур үзгәрешләр китереп чыгару куркынычы яный.

Сергей бу урында да җавапсыз калмады:

– Әгәр безнең заманнан үткәннәргә нинди дә булса тереклек күчкән икән, хәзерге көндә нинди дә булса глобаль һәлакәткә китерерлек йогынты ясамаган, дип уйлыйм мин. Бүреләр дә тук, сарыклар да исән, барысы да үз урынында, кем әйтмешли. Хайваннар дөньясына вакыт аралыгы аша күчкән тереклек ияләре түгел, хәзерге заманның елдан-ел аза барган браконьерлары ныграк зыян сала, – диде ул.

– Анысы шулай. Браконьерларны да авызлыкларга кирәк. Тик менә сезнең экспериментлар нәтиҗәсендә анда берәр җәнлек күчкән булса да, без бу көн күзлегеннән карап, аның табигатькә ни дәрәҗәдә үзгәреш китергәнен әйтә алмаячакбыз, – дип, моңа карата үз фикерен белдерде Александр Васильевич.

Сергей тагын нәрсәдер әйтә башлаган иде, Левинның тавышын күтәрә төшебрәк әйткән «өченчедән» дигән сүзе, аның тавышын күмеп китте һәм ул кул селтәп, эндәшми калырга булды.

– Өченчедән, – дип кабатлады Левин, – вакыт туннеле аша ике яклы күчеш булганлыктан, үткән заманнардан күчү механизмы бөтенләй өйрәнелмәгән. Сезнең экспериментларда бу хәл үз агымына куелган. Ягъни башка вакыт араларыннан килгән йогышлы куркыныч авырулар, агрессив кешеләр безнең заман кешеләренә куркыныч тудыра. Шундый очраклардан саклану механизмы юк. Бу исә төзәтеп булмаслык фаҗигаләргә китерергә мөмкин. Күчкән Саладагы вакыйгалар – моның ачык мисалы. Нәкъ менә сез ачкан вакыт туннеле аша, Бөек Ватан сугышы чорыннан без яши торган вакытка фашистлар күчкән, нәтиҗәдә тыныч халык белән баштанаяк коралланган хәрбиләр арасында бәрелешләр булган. Ярый Күчкән Сала халкы тиз арада

хәлгә төшенеп, оешкан төстә, узган заманның чакырылмаган кунакларын җиңә алганнар. Тик аянычы шул: бу җиңү тыныч халык арасында дистәдән артык корбан бәрабәренә ирешелгән, – дип тәмамлады сүзен Левин.

* * *

Күчкән Сала авылында булган вакыйгалардан соң, авылның миналар шартлаудан һәм янгыннан исән калган йорт хуҗалары үз өйләренә кайтып яши башладылар. Вакытлыча гына Южный бистәсендә яшәп торучыларга бөтен уңайлыклары булган йортлардан фатир бирербез, гел шунда гына яшәрсез, дисәләр дә, Күчкән Сала кешеләренең ата-бабалары нигез салган, үзләре күп еллар гомер кичергән авылны ташлыйсылары килмәде. Бигрәк тә өлкәннәр Южный бистәсендә күченергә теләмәделәр. Әгәр йортлар салышуда ярдәм итсәгез, калган гомеребезне туган авылда яшәр идек, диделәр. «Фашистларга каршы геройларча көрәшеп, үз авылларын саклап калган, алай гына түгел, илбасарларның юлын кисеп, Южный бистәсен һөҗүмнән саклаганнары өчен, күчкәнсалалыларның торак проблемасын хөкүмәт югарылыгында хәл итү максатыннан, сугыш ветераннары гаиләләренең торак шартларын яхшырту дәүләт программасына кертелеп, йортсыз калганнарга Күчкән Салада йорт төзү турында карар кабул ителде. Ә йортлары әзер булганчы, һәр гаиләгә Южныйда барактан кечерәк кенә бүлмә бирделәр.

Зөфәр белән Харрас та шул категориягә эләкте. Чөнки икесенең дә йортлары янган, каралты-куралары җимерелгән. Хәер, бу «игълан ителмәгән сугыш» Харрасны озак вакытка авылдан аерып, хастаханә караватына да бәйләде. Өстәвенә ярасы бик җитди. Аңа хастаханәдә озак дәваланырга туры киләчәк әле, диделәр. Зөфәр аның янына көн саен килә. Озак вакыт ял алмыйча эшләгән Зөфәргә, ниһаять, мондый мөмкинлек тәтеде. Тик ул эшсез ятарга өйрәнмәгән. Җанын кая куярга белмәгән чаклары байтак. Кайвакыт бер йөреп кайтыйм әле, дип, өеннән чыгып китә дә Харрас янына хастаханәгә барып утыра. Тегесе дә, көне буе урын өстендә ятып, аралашуга сусаган. Үзара әңгәмә башлыйлар да, җыен юк-бар турындагы гәпләре бик тиз арада Күчкән Сала авылында булып узган вакыйгаларга әйләнеп кайта. Әлеге гайре табигый хәлләргә һәркем үзенең белеменә, акыл югарылыгына карап бәя бирә. Бәхәсләшеп алган чаклары да булгалый.

Менә бүген дә кабат шул темага күчкәннәр иде. Зөфәр кесәсеннән пөхтәләп кәгазьгә төрелгән кечерәк төргәк тартып чыгарды да Харрас алдындагы юрган өстенә куеп, ача башлады.

– Нәрсә ул? – дип сорады Харрас.

– Моны миңа үләр алдыннан Андрей биргән иде, дөресрәге, гимнастёрка астарына фотолар белән әти-әниемнең адресы тегелгән, сугыш беткәч, шуны аларга тапшырып, ничек һәлак булуым турында җиткерерсез, дигән иде. Бу – аның соңгы әманәте, Харрас абый. Соңгы вакыттагы мәшәкатьләр белән мин ул хакта онытканмын. Кичә ничектер искә төште дә, сиңа да күрсәтергә булдым.

Зөфәр төргәкне саклык белән генә сүтте. Аннан ике фото һәм бер кечкенә генә хат килеп чыкты. Адресында Ом өлкәсендәге бер бистә күрсәтелгән. «Советская урамы, 12 нче йорт», – дип, кәгазьдәге язуны укыды Зөфәр. Аннан соң фотоларның берсен алды. Бераз карап торгач, аның артын әйләндерде. Язуы бар икән. «Дорогому мужу и папе от любимой жены и маленькой Галочки», диелгән анда. Зөфәр фотоны Харраска сузды. Үзенең күзләре яшьләнде. Икенче фотодан ике хәрби карап тора. Зөфәр аларның берсен – уң ягындагысын

шунда ук таныды. Бу – Андрей иде. Икенчесе – старшина погоннарыннан, полкташыдыр, күрәсең. Фото артына берни дә язылмаган иде.

– Монысы Андрейның сугышчан дусты булса кирәк, – дип, бу фотоны да Харраска сузды Зөфәр.

Аны кулына алып карауга Харрасның йөзе кинәт үзгәрде. Ул күзлеген бер күтәрде, бер төшерде. Күзләрендә гаҗәпләнү чаткылары барлыкка килде.

– Бу бит... Бу фото безнең өйдә, стенада эленгән рамда саклана... Әти аны әнигә фронттан җибәргән иде...

Харрас дулкынланудан урыныннан торырга талпынды. Ләкин җайсызрак кыймылдады булса кирәк, аягы авыртудан ыңгырашты. Күзләрен йомып, кабат башын мендәргә куйды. Ул шул хәлендә шактый ятты. Тагын бер-ике мәртәбә ыңгырашты. Зөфәр аңа комачауламады. Бары тик баш астындагы мендәрен рәтләштергәләде.

Берникадәр яткач, аягының сызлавы басылды булса кирәк, Харрас күзләрен ачты:

– Бу фотоны әти фронттан җибәргән иде, – дип дәвам итте ул башлаган сүзен, башын Зөфәр ягына борып. – Ул анда командиры Андрей Ильич белән төшкән... Әйе, әйе, капитан Андрей Захаров... Бу исем миңа бала чактан таныш. Әтием сугыштан исән-сау кайтты. Ул безгә 1942 елда канкойгыч сугышларның берсендә чолганышта калулары, соңыннан төнлә белән һөҗүмгә күтәрелеп, чолганыштан чыгулары турында сөйләгән иде. Ул шунда капитан Захаровны югалта. Исән калучылар арасында командирлары булмый инде. Чолганыштан чыккан полкташларыннан сораштырып караса да, аның турында беркем дә белми. Төнлә бит... Бәлки һәлак булгандыр, йә әсирлеккә эләккәндер?.. Сугыш тәмамланганнан соң да әти аны эзләтеп карады. Кайларга гына язмады. Оборона министрлыгының Подольскидагы хәрби архивыннан «Хәбәрсез югалган» дигән рәсми җавап килгәч, кабат эзләтмәде... Әй, сугышта аның кебек хәбәрсез югалганнар миллионлап бит.

Зөфәр ни өчендер үзалдына елмаеп куйды:

– Димәк, Харрас абый, син тайгада әтиеңнең командиры белән фашистларга каршы бергә сугышып йөргәнсең?

Әллә әлеге сүзләрнең мәгънәсе аңына бик авыр барып ирешкәнгә, әллә тагын аягы борчып алды, Харрас бөтен гәүдәсе белән куырылып, калтыранып куйды.

– Шулай килеп чыга инде, – диде ул, озак кына көттереп.

– Өстәвенә, бер генә көнгә булса да, син аның командиры да идең.

Харрас нәрсәдер исенә төшерергә җыенгандай кашларын җыерды.

– Сугыш тынып торган арада, Андрей: «Син миңа бер кешене хәтерләтәсең. Без аның белән дуслар идек. Ул да татар иде», – дигән иде. Фамилиясен дә әйтте кебек. Тик ишетмичә калдым. Шулчак янәшәгә генә граната төшеп шартлады. Ботыма да шуның ярчыгы тиде менә.

Харрас тагын тынып калды. Озак кына эндәшмәде.

– Әгәр янәшәмдә кем икәнен белгән булсам, үземнең җанымнан да ныграк саклар идем, – диде ул, үкенүен сиздереп.

– Хәзер моның әһәмияте бармы соң инде?!

– Бәлки юктыр. Тик әтиемнең рухы каршында үземне гаепле сизәм. Ул гомере буе эзләде, таба алмады. Ә мин таптым... һәм югалттым. Үкенечле ничектер...

Харрас күзләрен йомып, ыңгырашып куйды.

– Әй-й-йе, – дип сузды Зөфәр, тик алга таба әңгәмәне дәвам итеп, Харрасны борчыйсы килмәде.

Ә бераздан Харрас, күзләрен ачып, тамагын кыргалады.

– Мин бу хәлемдә тиз генә аякка баса алмам әле. Зөфәр, сиңа бер үтенечем бар. Син шушы адрес буенча барып, менә монда күрсәтелгән йортны эзләп таба алмассыңмы? Үзләре исән дә түгелдер инде. Балалары, оныклары бардыр, бәлки. Һич югы, якын-тирәдәге берәр мәктәп музеена тапшырып кайт... Фашист илбасарларына каршы көрәштә геройларча һәлак булган капитан Захаровның... этиемнең дусты Андрейның соңгы әманәте бит. Ә әманәтне үтәргә кирәк...

Харрас фотоларны Зөфәргә сузды.

* * *

Зур булмаган Заречное бистәсендәге үзе эзләгән йортны табу кыен булмады Зөфәргә. Ул капка келәсен күтәреп ачуга, ишегалдындагы каралты-кура тирәсеннән һау-һаулап, бер эт өреп чыкты. Зөфәр эт күрмәгән кеше түгел. Шулай да шүрләп, капканы үзенә тартты һәм азрак ачык калдырылган ярыктан ишегалдын күзәтә башлады. Эт якынга килеп, борынын ярыкка ук тыгып иснәде дә ырылдап куйды. Берәр метр арырак китеп, җиргә утырды. Тагын берничә мәртәбә һау-һаулап өреп алды. Акыллы эт, хуҗаларына тавыш бирде дә үзе тыныч кына көтеп утыра, дип уйлады Зөфәр.

Чыннан да, бер-ике минут уздымы икән, йорт ишеге ягында хәрәкәт сизелде. «Чарли, а ну домой!» – дигән хатын-кыз тавышы ишетелде. Эт күндәм генә оясына таба юл алды. Алай да ярты юлда туктап, борылып, бер мәртәбә өреп куйды. Бу аның: «Кара аны, явыз ниятең була икән, мин ерак китмим. Хәзер йөгереп килеп эләктереп алырмын», – диюе иде булса кирәк.

Капканы 50-60 яшьләрдәге тулырак гәүдәле бер хатын ачты да сораулы карашы белән Зөфәргә төбәлде. Менә шул чакта Зөфәр сүзне нидән башларга белмичә, аптырап калды. Бу күрешү мизгелләрен күңеленнән күп тапкырлар кичергән булса да, башлап нинди сүз әйтергә кирәклеге уйланылмаган. Шуңадыр, ни әйтергә белмичә төртелеп калды. «Здравствуйте!» Ул дулкынлануын сиздермәскә тырышты. Хатын да, «Здрасьте, здрасьте», диде, башын бераз ия төшеп. Ә үзе Зөфәрне баштанаяк күзәтеп тикшерүен дәвам итте.

Андрей биргән фотодагы теге бәләкәй кызчыклы хатын белән моның арасында шактый охшашлык тапты Зөфәр. Шуңа күрә ул:

– Сез... сез Татьяна буласызмы?.. Татьяна Захарова? – диде дә кабалана-кабалана кулындагы пакетын ачып, анда актарына башлады.

– Юк, мин Татьяна түгел. Мин – Ольга Тимофеева, – дип, әлеге сорауга гаҗәпләнеп калды хатын.

Зөфәр шунда гына вакыт белән булган хәлләрне онытып җибәрүен аңлады. Андрейның хатыны Татьянага Бөек Ватан сугышы чорында чама белән 25-30 яшьләр тирәсе булса да, ул хәзер исән түгел бит инде. Аннан соң тагын шунысы да бар: Андрей хатынын һәм кызын бомба астында үлде, диде бугай. Шулай да Зөфәр пакетында актарынуын дәвам итте. Бераздан аннан фото алып, Ольгага сузды.

– Сез бу кешеләрне белмисезме?

Хатын фотога текәлде. Ә бераздан аның йөзе май кояшыдай балкыды:

– Әлбәттә, беләм! Болар минем әбием һәм әнием... Бик күптәнге карточка. Татьяна Захарова – әбием инде ул. Бу фото сезгә каян килде?

Зөфәр «Э-э-э...» дип нәрсәдер әйтә башлаган иде, хатын кунакны өйгә

чакырмыйча, һаман капка төбендә тотуын аңышып алды да: «Нишләп монда басып торабыз соң әле, әйдәгез, керик», – дип, йортка таба атлады. Зөфәр күндәм генә аның артыннан иярде. Барган уңайга:

– Димәк, сез Татьяна Захарованың оныгы буласыз инде? – дип, янә бер мәртәбә ачыклык кертте ул.

– Әйе! Татьяна Захарованың кызы Галина Андреевна – минем әнием. Ул хәзер дә исән әле.

– Ә ул кайда?

– Өйдә. Менә хәзер янына керәбез. Дөрес, бик өлкән яшьтә инде ул. Йөзне куа. Шулай булса да, хәтере ачык. Кайвакыт миңа караганда күбрәк тә белә әле.

Ольга кычкырып көлде.

Өйгә кергәч, хатын кунакка урын тәкъдим итте. Үзе каршысына утырды. Ул әбисе белән әнисе сурәтләнгән әлеге иске фотоны тотып килүченең юкка гына йөрмәгәнен, ниндидер көтелмәгән хәбәр әйтергә җыенганын сизенгән иде инде.

– Сез үзегез кем буласыз соң?

– Мин – Зөфәр. Хәер, минем исем сезгә таныш түгел. Сезнең якларга ерактан килдем. Мин бабагыз Андрей турында. Андрей Захаров сезнең бабагыз бит ул, шулаймы?

– Әйе, бабам. Тик мин аны белмим. Ул мин туганчы әллә кайчан сугышта һәлак булган.

Сүз сөрешенең үзе теләгән юнәлешне алуы Зөфәрне рухландырып җибәрде. Ул дулкынлануын яшермичә, үзе дә сизмәстән ашыга-кабалана сөйли башлады:

– Әйе, әйе, һәлак булган... Ә беләсезме, ул минем кулларымда үлде... Соңгы аманәте итеп...

Гаҗәпләнүдән Ольганың күзләре зур булып ачылды. Ул нидер әйтергә теләп, авызын бер ачты, бер йомды. Хәтта торып китәргә теләгәндәй, урыныннан кузгалып куйды. Аның карашыннан бик нык аптырау, шул ук вакытта җәлләү чалымнарын шәйләргә була иде. Яңа гына ишеткән сүзләрдән ул Зөфәрне җиңеләйгән кеше дип уйлады булса кирәк. Аны өйгә чакырып кертүенә бераз үкенде дә кебек.

– Сез... сез нәрсә сөйлисез?.. Ничек инде мин туганчы үлгән бабам сезнең кулларда җан бирсен?! Сез миңа караганда да шактый яшь күренәсез әле?

Зөфәр ашыгып, ялгыш сүзләр әйтеп ычкындыруын шунда гына аңлады. Вакыт хикмәтләрен тагын онытып җибәрде ләбаса. Тик соң иде инде. Авыздан очып чыккан сүзне кире алып булмый. Ләкин бөтенесе дә бетте дигән сүз түгел. Хәзер ничек тә бу уңайсыз хәлдән чыгу җаен карарга кирәк.

– Зинһар, гафу итегез! Мин – татар милләтеннән. Чит сүзләр белән сөйләгәндә, фикеремне дөрес тә аңлатып бирә алмыйм кайвакыт. Буталам. Бабагыз минем кулларда түгел, ә бабамның кулларында үлгән. Алар сугышта бергә булганнар, – диде ул.

Бу уйдырмасы бик уңышлы чыкты булса кирәк, Ольганың кыяфәте гадәти халәткә керде. Ул тагын матур итеп елмайды:

– Шулай дисәгез генә инде. Юкса, бөтенләй куркыттыгыз, – дип, урыныннан торды да: – Әйдәгез, мин сезне әнием белән таныштырам, – дип, күрше бүлмәгә алып кереп китте...

Караватта ап-ак чәчләре мендәргә таралган карчык ята. Йөзе тирән буразналар белән җыерчыкланган. Тәрәзә челтәре аша төшкән тонык яктылык ул сырларны тагын да тирәнәйтеп күрсәтә. Юрган өстенә чыгарып салган

ябык кулларында кан тамырлары бүлтәеп күренә. Карчык үзалдына нидер сөйләнәме – вакыт-вакыт иреннәре кыймылдап куя, ләкин тавышы ишетелми. Бәлки шундый гадәт кенәдер?

– Әни, менә бу кеше бабай турында нәрсәдер сөйләргә тели. Аның бабасы белән алар сугышта бергә булганнар, – дип таныштырды да әнисен торгызып, мендәренә терәп утыртты. – Ерак юлдан килеп ачыккансыз, мин хәзер табын әзерлим. Ә сез монда серләшә торыгыз, – дип, кухня ягына чыгып китте.

Зөфәр фотоларны карчыкка сузды. Галина әби аларны сакланып кына тотып, озаклап карап торды. Кыяфәтендә елмаю галәмәте чагылып киткәндәй булды хәтта.

– Әтием Андрей Захаров турында нәрсәләр беләсез, сөйләгез, – диде ул, башын күтәреп.

– Алай бик күп нәрсә белмим... Әтиегез минем бабамның кулында үлгән. Соңгы сүзе, менә бу фотоларны адрес буенча әти-әнисенә тапшыруын һәм ничек үлгәнен сөйләп бирүен үтенгән. Ләкин бабам сугыштан алган яраларыннан мантый алмыйча, урын өстендә озак ятып үлә. Сугышчан дустының әманәтен үтәргә мөмкинлеге булмаган аның.

Карчык яңадан фотоларга күз төшерде. Әтисенең фотосын калтыранган ябык кулы белән сыйпаштыргандай итте.

– Әтиемне мин бик аз хәтерлим. Офицер булганын беләм. Хәрби формадан йөри иде... Сугыш башланган көн. Мәхшәр. Әти безнең белән ашыгып кына саубуллашты да заставага чыгып йөгерде. Без аны шуннан соң бүтән күрмәдек. Сугыш беткәч, эзләтеп караган идек, хәбәрсез югалган, диделәр...

– Әтиегез бабама, хатыным белән кызым бомба астында калып һәлак булдылар, дигән. Сез ничек исән калдыгыз соң?

Карчык уйга бирелде. Үткәндәге хатирәләрне барлый, күрәсең.

– Сугышның беренче көннәрендәге ул мәхшәрне уйласам, минем әле бүген дә тәнем эсселе-суыклы була. Анда бик күпләр югалды. Ә без могҗиза белән генә исән калдык. Берничә офицер хатыны җыелышып сөйләшкәннәр дә гаилә белән эвакуацияләнергә карар кылганнар. Әйберләрдән бернәрсә дә алмыйча, балаларын гына җитәкләп чыгып киткәннәр. Әни дә шулар белән тәвәккәлләгән. Чыннан да, без яшәгән йортка бомба эләгеп җимерелгәнен соңыннан ишетеп белдек. Анда калган гаиләләрдән барысы да һәлак булган. Әтием шул хакта ишетеп, әни белән мине бомба астында калган, дип уйлаган, күрәсең.

Галина әби тагын үз уйларына бирелде. Ул вакытларны искә төшерү аңа җиңел түгел, әлбәттә. Хәтта күзеннән бер бөртек яшь чыгып, җыерчыклы бите буйлап тәгәрәде дә юрган өстенә тамды.

– Аннан соң әтидән бер хат алдык әле. Дөресрәге, ул хатны әти-әнисенә – минем әби белән бабайга язган иде. Каты сугышка керәбез. Әгәр андый-мондый хәл булса, бәхил булыгыз, дигән иде ул анда. Соңыннан белдек, шул канкойгыч сугышта алар часте чолганышта калган. Әтиемнең шуннан соңгы язмышы билгесез...

– Ул чолганыштан Андрей Захаров исән-имин чыккан һәм партизаннар отрядына кушылган. Чөнки Совет армиясенең төп көчләре чигенеп, фронт сызыгы еракка күчкән булган инде. Чолганыштан чыгучыларның шактые тайгадагы партизаннар отрядына кушылган ул вакытта. Әтиегез анда партизаннар отряды комиссары булган. Минем бабам белән бергә партизанлык иткәннәр. Бабам Харрас Камалов отрядның командиры булган. Бер канкойгыч

сугыш барышында әтиегезгә пуля тиеп, бик нык яраланган. Соңгы сулышын алыр алдыннан, ул минем бабама әманәт итеп, менә шушы фотоларны тапшыруын үтенгән, – дип, үзенең шактый гына ышандырырлык хикәят уйлап табуына куанып, сүзен йомгаклады Зөфәр.

Авыл башлыгы Харрас Камаловны да үзе дә сизмәстән «бабам» дип атарга туры килде аңа. Нишләсен? «Әтиегез моннан ун көн элек кенә минем кулларымда җан бирде!» – дип әйтә алмый бит инде. Юкса бу карчык, үзеннән көлә, дип уйлаячак. Эх, белсә иде ул Зөфәрнең күңелендә нинди уйлар өермәсе барлыгын?!

* * *

Көннәрдән бер көнне Зөфәрне тагын Южный бистәсе хакимияте бинасына чакырттылар. Башкаладан Күчкән Сала вакыйгасын тикшерү буенча оештырылган комиссия вәкиле килгән икән. Имеш, кайбер нәрсәләрне тәгаенләргә кирәк. Башыннан алып ахырына кадәр әлеге вакыйгаларның үзәгендә кайнаган Зөфәрдән сорашмыйча, кемнән сорашсыннар.

Инде бер мәртәбә тикшерү иләге аша узган Зөфәр әлеге чакыруга бик теләп бармады, әлбәттә. Ул төпченеп сораштырулардан гарык булган иде инде. Комиссия үз эшен төгәлләп китеп баргач, өстеннән авыр йөк төшкәндәй җиңеләеп калды, бүтән үзен борчып йөрмәсләр, дип уйлаган иде. Ә менә сорыйсы нәрсәләре калган икән әле...

Ул тиешле вакытка килеп, үзенең чакыру кәгазендә күрсәтелгән кабинет ишеген шакып кергәндә, түрдәге өстәл артында утыручы пеләш башлы адәм, компьютер төймәләренә тиз-тиз баскалап, нидер язып утыра иде. Башын күтәреп, Зөфәрне бер кат баштанаяк карап чыкты. Гадәттә, югарыдан килгән кешеләр «провинциал»ларга түбәнсетеп караучан. Ләкин бу кешедә андый нәрсә сизелмәде. Ул хәтта урыныннан торып, бик дустанә генә елмаеп, керүчегә кулын сузды. Үзе белән таныштырды. Тикшерү комиссиясе эксперты Новиков Михаил Степанович дигән кеше икән.

– Димәк, сез Зиннуров Зөфәр? Шулаймы, ялгышмадыммы? – дип сөйләнә-сөйләнә аңа урын тәкъдим итте.

– Әйе!

Зөфәр үзе эш кешесе булгач, вакыт уздырып, кирәкмәс сораулар белән эч пошырып йөрүчеләрне җене сөйми. Шуңа күрә Новиков дигән бу кешенең беренче сорауларына бераз ачуы да килде. Әгәр үзләре нәкъ шушы вакытка, шушы бүлмәгә чакыртканнар икән, Зөфәр булмыйча кем булсын соң?

– Фашистларны тайгада беренче булып очратучы кеше сез буласыз инде, шулаймы?

– Шулай, шулай, – дип җөпләде аның сүзләрен Зөфәр.

– Кулыгызга корал тотып, көрәшергә дә туры килде инде?

– Бүтәнчә мөмкин түгел иде.

– Сезне бик төз ата, диләр?

– Безнең Күчкән Салада барысы да төз ата. Без – буыннан-буынга килгән аучылар.

– Аңлашыла! Алай да, шәхсән үзегез күпме фашистны дөмектердегез соң?

Бу кеше әллә аны кеше үтерүдә гаепләргә җыенамы, дигән уй йөгереп узды Зөфәрнең башыннан. Тик ул бу тискәре уйларын куарга тырышты.

– Санамадым. Ул чакта санап торырга вакыт булмады.

Аның шикләрен сизеп, сорау алучы тынычландырырга ашыкты:

– Борчылмагыз, мин сезне гаепләргә җыенмыйм. Әгәр сез аларга көчле каршылык күрсәтмәгән булсагыз, авылдашларыгыз арасында корбаннар тагын да күбрәк булыр иде. Кылган гамәлләрегез бары тик мактауга гына лаек.

Аннан соң Михаил Степанович төп темага күчте. Ул беренче мәртәбә фашистларга әсирлеккә төшкәч, немец офицерының үзенә нинди сораулар бирүен, партизан Андрейның аннан нәрсәләр соравын, ничек качып китүләрен – барысын да җентекләп сораштыра башлады. Күрәсең, шулай энәсеннән җебенә кадәр сораштыру бу тикшерүчеләрнең канына сеңгән инде, дип уйлады Зөфәр.

«Берничә соравым бар иде», дип тотынган эксперт каршында, аз да түгел, күп тә түгел, ике сәгатьләп утырырга туры килде Зөфәргә. Новиков һәр сорауга җавапны диктофонга яздырып барды. Соңыннан әлеге сораштыруның компьютерда язылган кыскача эчтәлеген принтердан чыгарып, Зөфәргә кул куйдыртты. Шуннан соң экспертның эше тәмамланды шикелле. Ул кәгазьләрен бер читкә җыеп куйды да эшеннән канәгать калуына куанып булса кирәк, учынучка чәпелдәтеп сугып алды, рәхәтләнеп киерелде. Урындыгына җайлабрак утырды.

– Ә беләсезме, архивларда казына торгач, бик кызыклы мәгълүматлар таптык без.

Новиковның сөйләү тоны, рәсмилектән бигрәк, үзенең ахире белән тормышкөнкүреш турында гәп сатучы авыл мужикларыныкына охшап калды. Зөфәр, «мин каян белим инде» дигәндәй, иңнәрен сикертте.

– Сез яшәгән урыннарда Бөек Ватан сугышы чорында, чыннан да, партизаннар хәрәкәте киң җәелгән булган. Алар фашистларга көн күрсәтмәгәннәр. Тайга, урман. Агачлар арасыннан кинәт кенә килеп чыгып, зур-зур отрядларны тармар итеп торганнар. Соңыннан үзләре кабат урманга кереп качканнар. Бу хәлгә нишләргә белмәгән немец командованиесе, партизаннарны эзәрлекләп юк итәргә зур гына карательләр отряды җибәргән.

– Карательләр җибәрелү турында ничек шулай ышандырып әйтә аласыз? Бу хакта төгәл документлар бармы?

Әле генә эксперт сорауларына җавап биреп утырган Зөфәр хәзер үзе сорау бирүче ролենә күчте. Ләкин әңгәмәдәше моңа бер дә кыенсынмады. Ул, киресенчә, үзендә булган мәгълүматны кемгә дә булса «бушатасы» килү теләге белән яна иде булса кирәк.

– Әйе, андый документ бар. Бу урманнарда аерым хәрәкәт итүче күпсанлы партизан отрядларын берләштерү өчен фашистлар тылына махсус җибәрелгән полковник Мартынов 1942 елның июлендә Мәскәүгә җибәргән досьесында, зур гына карательләр отрядының партизаннарны эзәрлекләве, шуңа күрә отрядларның урыннарын урман эченәрәк алмаштыруы турында әйткән. Ә берәр атнадан Мәскәүдән җибәрелгән «Ничек анда, карательләр һаман тынгылык бирмиме?» дигән сорауга, шул ук Мартыновтан: «Соңгы вакытта алар күренми. Эзне югалтыпмы, куркыпмы, тайгадан кире чыгып киткәннәр бугай. Без кабат үз позицияләребезгә кайтабыз», – дигән җавап килгән.

– Сез шушы сүзләргә нигезләнеп, карательләр ул чакта очраклы гына вакыт аралыгына эләгеп, безнең заманга күчкән, дип уйлыйсызмы?

– Әйе, шулай уйларга берникадәр нигез бар. Моны, нәкъ шулайдыр дип, ышандырып булмаган кебек, юк, алай булмаган, дип кире кагу да мөмкин түгел инде хәзер.

Новиков сөйләгәннәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде Зөфәр.

Күңеленең бер почмагында «Ничек инде ул?» дигән сорау туса, аңа каршы: «Ә Күчкән Салада нәрсәләр булды? Каяндыр килеп чыккан фашистлар чын сугыш оештырдылар бит», – дигән уйлар кайнады башында.

– Ә ул архивларда Андрей Захаров турында берәр мәгълүмат тапмадыгызмы?

– Нәкъ шул Андрей Захаровтыр дип әйтә алмасак та, шундагы партизаннар отрядында сугышкан берничә кешенең язып калдырган истәлекләрендә, отрядларның берсендә, чыннан да, капитан Андрей Захаров дигән кешенең комиссар булуы телгә алынган. Ләкин аның алдагы язмышы билгесез. Кайда һәм кайчан һәлак булганын дәлилләүче рәсми документлар да, истәлекләр дә беркайда да юк. Оборона министрлыгының Подольскидагы үзәк архивыннан сораштырган идек. Безне кызыксындырган Андрей Захаров анда хәбәрсез югалучылар исемлегендә икән.

Шушы да булдымы кызыклы мәгълүмат?! Зөфәр әллә соң, чыннан да, вакыт аша күчүне дәлилләгән берәр рәсми документ тапканнармы, дип уйлаган иде.

Новиков аның уйларын сизгәндәй, әңгәмәне бөтенләй икенче якка борды:

– Ә иң кызыклысы, беләсезме, нәрсә? Без Германиянең Россиядәге илчелегенә, ул вакыттагы Вермахт армиясендә шушы вакыйгага кагылышлы документлар сакланмыймы икән дип, сорау юллаган идек. Озак та көттермичә, җавап килде. Чыннан да, 1942 елның җәй башында, сезнең төбәктәге урманнар эчендә тупланып, фашистлар белән көрәшүче партизаннарга каршы баштанаяк коралланган бер рота эсэсчыларны җибәргән булганнар. Рота белән командалык итүче офицерның исеме – гауптштурмфюрер Уильям Фредерик Мартин. Әйе, әйе, «Ерак привал»да урнашкан урманчы йортында сездән сорау алган эсэс офицеры исеменә туры килә. Мондый нәрсә очраклылык кына түгел, минемчә...

Күрче, болар чыннан да тик ятмаганнар икән, дип уйлап куйды Зөфәр. Хәтта яңа гына әйтелгән шушы сүзләре генә дә вакыт аша күчүне тулысы белән раслый түгелме?

– Тагын бер документ бар. Анда әлеге отрядның бик серле рәвештә хәбәрсез югалуы бәян ителгән. Уйлап карагыз, рота кадәр рота югала! Ул чакта фашистлар армиясе командованиесе бу вакыйгадан бернинди мистика да эзләп тормаган, әлбәттә, барысын да партизаннарга сылтап, шуның белән онытканнар.

Новиков урыныннан торып, ишекле-түрле йөренде. Аның кыяфәтеннән һәм һәр хәрәкәтеннән әле иң мөһим нәрсәне әйтеп бетермәгәнлеге сизелеп тора иде.

– Бу урында тагын бер нәрсәне искәртү урынлы, – дип дәвам итте сүзен эксперт. – Алар әлеге вакыйгага кагылышлы рәсми булмаган башка мәгълүмат тапканнар. Карательләр тайгага китеп, берәр атна үткәч, шул тирәләрдәге тайга кырыенда буталып-адашып йөрүче бер кешене тоткарлыйлар немец солдатлары. Немец киемендәге ул солдаттан сораштыра торгач, ул каратель итеп җибәрелгән әлеге ротаныкы булып чыга. Әлбәттә, аны дезертирлыкта гаепләп, гестапога тапшыралар. Ә сорау алу вакытында ул гаҗәп хәлләр турында сөйли. Тайга эченә шактый кергәч, солдат кече йомышына кысталып, туктап кала. Башкалар арырак китә. «Эшен» төгәлләгәч, отряд артыннан куып җитәргә тели. Каршысында нindидер куе ак томан күреп ала. Солдат анда керергә курка. Томан тиз тарала. Ләкин ул, ары сугылып, бире сугылып күпме генә йөрмәсен, ротаны таба алмый. Берәр атна адашып йөргәч, тайга читенә килеп чыга. Гестапода аның сөйләгәннәренә ышанмыйлар, әлбәттә. Антифашистлар тотыла торган концлагерьларның берсенә җибәрәләр. Алга таба аның язмышы билгесез, – дип тәмамлады сүзен Новиков.

Федераллар вакыйгага «үтә яшерен» келәймәсе чәпәп, кешеләргә серне чишмәү турында куллар куйдырып, мәгълүматны халык арасына чыгармаска никадәр генә тырышмасыннар, телгә кергән хәбәр таралмыйча калмый икән ул. Аккан су юлын табар, диләр бит, белгәне белеп, белмәгәне белмичә, бу хәлләрнең асылын аңлатырга тырышты. Күчкән Сала авылы янында булган гаҗәп хәлләргә карата Зөфәргә дә күп төрле имеш-мимешләр ишетелде. Ә хәлнең чын дөресе ничек, рәсми органнарда әлеге хәлне ничек аңлаталар? Бу хакта төгәл мәгълүмат ишетергә туры килмәде. Бу Новиков дигән адәмнән шул хакта белешеп карарга була бит. Һәм Зөфәр мөмкинлекне кулдан ычкындырмады. Бөтен кешене гаҗәпкә калдырган мондый гайре табигый хәлләрнең ни сәбәпле килеп чыгуы турында экспертка сорау бирде. Тегесе бераз икеләнеп торды да, булгач-булгач булсын инде дигән кебек, хәлләргә кыскача гына аныклык кертте. Күрше урман хуҗалыгында, «Граф Елисеев» агач эшкәртү оешмасында, яшерен фәнни-тикшеренү полигоны булган. Анда «Вакыт машинасы» белән сынаулар үткәрелгән. Галимнәрнең исәпләүләрендә төгәлсезлекләр килеп чыгу сәбәпле, «Вакыт машинасы» хасил иткән вакыт туннеле аша үткән заманнардан, ягъни Бөек Ватан сугышы чорыннан безнең заманнарга фашист солдатлары күчүе турында бәян итте.

– Хәзер ул галимнәрне нишләтәләр инде?

– Аларны кулга алганнар, хәзерге вакытта күзәтү астында. Тиздән суд булачак. Күп кешенең үлеменә китергән гамәлләре өчен, аларга күп елларга ирекләреннән мәхрүм ителү яный. Яшь галимнәр икән әле үзләре...

– Кызганыч, – дип куйды Зөфәр галимнәрнең хәлләренә кергәндәй. – Мондый хәлләр булмаса, тагын күпме ачышлар ясаган булырлар иде.

– Сез нәрсә, җәза срогын үтәгәндә, алар кулларына көрәк-чүкеч тотып, физик эш белән шөгыльләнәчәкләр, дип уйлыйсызмы әллә? Һич кенә дә юк. Алар анда да шул ук фәнни эшләрен дәвам итәчәкләр, минемчә. «Граф Елисеев»тагы җиһазларны сүтеп, машиналарга төяп алып киттеләр. Аны каядыр берәр хәрби базага илтеп, кабат җыячаклар. Вакыт машинасының мөмкинлекләрен киңрәк өйрәнү дәвам итәчәк. Һәм бу эш шул ук яшь галим-голамәләр җилкәсенә төшәчәк. Шулай булгач, алар язмышы өчен борчылырга кирәк түгел, – дип сүзен түгәрәкләде эксперт Новиков.

* * *

«Ерак привал»дагы вакыйгалардан соң өч ай узды. Шушы кыска гына вакыт эчендә Күчкән Сала авылы кешеләре тормышында зур үзгәрешләр булды. Янгыннардан зыян күреп, йортсыз-җирсез калган кешеләргә авылда өр-яңа йортлар җиткерелде. Вакытлыча читтә яшәргә мәҗбүр булган күчкәнсалалылар өчен бу куанычлы хәл булды, әлбәттә. Төз, юан чыршы-нараттан буралган өйләрдә сагыз исе аңкып тора, киң итеп эшләнгән тәрәзәләреннән кояш нурлары бик мулдан керә. Һәр җирдә сафлык, иркенлек...

Кешегә яшәү шартлары тудырсаң, ул кайда да үзен бәхетле тоя. Шундый өйләр җиткереп кергән берничә гаиләгә, шәһәргә чыгып киткән балалары да кайтырга җыена икән, дип ишеттерделәр авылда. Бик мөмкин. Кайдадыр чит җирләрдә, кеше почмакларында зар-интизар булып йөргәнче, туган җирендә, әти-әнисе белән бергә-бергә дөнья көтү күңелле дә, отышлы да булачак. Киләчәктә Күчкән Салага яшьләрне җәлеп итәргә өмет бирә торган тагын бер сәбәп бар: авыл белән Южный бистәсе арсындагы 50 чакрымлы юлга асфальт

җәймәкчеләр икән. Заманча асфальт юлдан җиңел машинада «Олы җир»гә нибары ярты сәгатьтә барып җитәргә мөмкин булачак. Ә урман тракторы белән бер якка гына өч-дүрт сәгать барыла иде.

Урман тракторы дигәннән, Рафатның «ТТ-4» тракторын реставрацияләп, тарихи экспонат итеп, пьедесталга куярга җыеналар. Беренчедән, ул заманында урман хуҗалыгын үстерүдә керткән өлешен күрсәтеп торса, икенчедән, күчкәнсалалылар өчен тагын бер ягы: юлсыз чакта авыл кешеләрен «Олы җир» белән тоташтырып торучы бердәнбер транспорт чарасы булып торды. Бу легендар техниканы хөрмәтле урынга куюның тагын бер сәбәбе бар икән әле: күчкәнсалалыларга ул фашистлар белән көрәшкән көнне, ирексездән шәһит киткәннәрне искә төшереп торачак.

Бу хәлләрдән соң, урман хуҗалыгына хөкүмәт дәрәҗәсендә игътибар артыр кебек. Узган айда Южныйда гына түгел, гомумән, тирә-яктагы урман хуҗалыкларында да төрле дәрәҗәдәге тикшерүләр күп килде. Южный белән янәшәдәге урман хуҗалыгы җитәкчесе Геннадий Сазонов, ниһаять, лаеклы ялга киткән. Аның карамагындагы урманда урнашкан «Граф Елисеев» предприятиесендәге фәнни лаборатория җиһазларын хәрби машиналарга төяп, каядыр озатканнар. Алардан бушап калган биналарга, Сазонов урынына килгән яшь җитәкче, заманча агач эшкәртү станоклары кайтартырга планлаштыра икән. Ул урында да предприятие ачып, эшчәнлекләрен киңәйтмәкчеләр. Ә бу өстәмә эш урыннары дигән сүз. Димәк, яшьләр эшсез йөрмәячәк.

Южный посёлогы белән Күчкән Сала авылы арасына да зур чыгымнар тотып, юкка гына асфальт юл салмыйлардыр. Халык арасында Күчкән Салада элекке кебек үк агач эшкәртү предприятиесе төзергә ниятлиләр икән, дигән сүз йөри. Җил исми, яфрак селкенми – булырга мөмкин. Ул чакта, авылның киңәеп китүенә дә өмет бар. Эшне планлы алып барганда, агач эшкәртү предприятиесе, гомумән, урман хуҗалыгы табышлы тармак бит ул. Әлегә агачның бәясе төшкәне юк. Урмансыз төбәкләрдә, чит илләрдә агач материаллары бик кыйммәтле чимал, аларга ихтыяҗ зур...

Сугышта һәлак булган күчкәнсалалыларны зират түрендә барысын бер тирәгә тезеп җирләделәр. Халык теленә ул үзеннән-үзе «Батырлар аллеясы» дигән исем белән керде. Южный бистәсендәге урман җитәкчелеге Күчкән Сала авылы янында фашистларны җиңүнең бер еллыгына бу урынга һәйкәл ачарга дигән карар кабул итте. Хәзер күчкәнсалалылар Җиңү көнен елга ике тапкыр билгеләп үтәргә җыеналар. Бу хакта Харрас Камалов әйткән. Ә ул үзе һаман Южный бистәсе хастаханәсендә ята. Култык таягы белән йөрергә маташа, диләр. Ләкин табиблар әлегә иртәрәк, сөякләре ныгысын дип, тоткарлап киләләр икән.

Авыл башлыгы вазифаларын вакытлыча Зөфәр башкара. Харрас, бүтән эшләмәм, урынымда сине калдырырмын, дисә дә, ул риза түгел. «Минем эшем – урман. Аңа беркайчан да хыянәт итә алмыйм», – ди...

Менә иртәгә фашистлар белән булган бәрелештән соң беренче мәртәбә, «Ерак привал»га барырга җыена Зөфәр. Авылдашларының кабат анда барырга курыкмыйсыңмы соң, дигән соравына елмая гына. Хәзер инде Гражданнар сугышы чорындагы акгвардиячеләр, йә Наполеон җитәкчелегендәге француз гаскәре килеп чыкса да, курыкмаячакмын, ди ул. Теге хәлләрдән соң, «Граф Елисеев» предприятиесенә дә кереп, карап чыгарга исәбе бар. Күрше урман хуҗалыгында нәрсәләр майтарып яталар икән?

«Ерак привал»га чыгып китәр алдыннан, фашистлар кулыннан һәлак


булганнарның каберләре янына – «Батырлар аллеясы»на барып килермен, дип адарынган иде. Авыл читендәге ачыклыктан бер кочак чәчәк җыеп, зиратка таба атлады ул.

Каберләргә вакытлыча язып куелган исемнәрне тагын бер мәртәбә күздән кичерде: Вафин Зиннур, Зыятдинов Сөнгать, Зарипов Шакир, фельдшер Сидорова Светлана, Талипов Камил... Исемнәрен кычкырып укып, һәрберсенә чәчәкләр куеп, каберләр рәтеннән узды Зөфәр. Тракторы белән Южныйга барганда атып үтерелгән Рафатны һәм авыл урамында атылган Габделхак картны да монда җирләделәр. Барысы 16 кеше.

Аркадашы Камил кабере янында озаграк торды Зөфәр. Күзләренә яшь килде. Зур үкенеч шул: ярдәм килеп җитәргә, фашистларны пыран-заран китерергә нибары биш-ун минутлап калганда һәлак булды Камил. Әгәр, сугыш ахырына кадәр тайга эченә тылга җибәрелгәннәр арасында калса, ул һәлак булу түгел, сугышның үзен дә күрмәс иде. Юк, үз өстендә җаваплылык тоеп, мылтыклар белән коралланган дүрт хатынны да ияртеп, засадада торучы отрядка ярдәмгә ашыккан. Фашистларның соңгы һөҗүмен кайтаруда аларның ярдәме бик мөһим иде. Кем белә, алар вакытында килеп җитмәсә, көне буе ярсый-ярсый һөҗүмгә ташланган фашистлар бу «биеклек»не алган да булырлар иде. «Барысы өчен дә рәхмәт сиңа, Камил дус. Авыр туфрагың җиңел булсын!» – дигән сүзләрне Зөфәр аркадашы белән янәшә генә торып сөйләшкәндәй кычкырып әйтте.

Камил үлгәч, аның эте Шарикны үзенә алды Зөфәр. Акыллы эт! Хуҗасын югалту кайгысын бик авыр кичерде. Берәр атна буе Камилнең кабереннән китмичә, зиратта яткан. Ябыгып беткән. Хәзер әкренләп Зөфәргә ияләнеп килә инде. Бүген зиратка килгәндә, Шарикны үзе белән алмады. Тирән йөрәк яраларын искә төшереп борчыйсы килмәде. Эт булса да, ул да җан иясе бит. Өстәвенә, иртәгә ерак юлга кузгалырга җыеналар...

Әнә шуларны уйлап, зираттан чыгу ягына атлады Зөфәр. Көн кояшлы, шундый матур! Мондый һәр мизгелнең рәхәтен тоеп кына яшәргә дә бит!.. Тик кайчак тормышта чатаклыклар килеп чыга да, күңел түгәрәклеге кителә башлый. Дөрес, вакыт үтү белән андый хәлләр онытыла һәм тоныклана. Вакыт барысын да дәвалый. Әйе, барысы да вакытка бәйле. Чөнки вакытның үткәне һәм киләчәге бар. Теләсә нинди вакыйганың сәбәбе үткәндә булса, аны хәл итү – бүген һәм киләчәк эше. Бу – даими процесс. Әнә шул эчпошыргыч даимилекне үзгәртеп, кайчак вакыт өермәләре уйнап ала, үткәннәрдә инде әллә кайчан хәл ителгән тарихи вакыйгаларның кечкенә генә бер чите киләчәккә дә кагылып узарга мөмкин... Шундый чакларда үз җаена гына барган тормыш чәлпәрәмә килә икән. Вакыт галәмәтләре! Нәкъ менә шундый галәмәтләр Күчкән Сала халкының да тыныч кына, үз җае белән аккан тормышын кинәт кенә астын-өскә китереп алды.



Ләис
Зөлкарнәй

# НУГАЙ ЙОРТЫ

САДАКТАГЫ УН КЫЙССА

## Бачман хан[1]

*Хан ханәше Йәникә*
*Тезгенгә килеп асылды:*
*– Чыга күрмә далага,*
*Кар-каралы башыңны*
*Кагып алыр Идегәй,*
*Җунҗыгалы[2] башыңны*
*Егып алыр Идегәй,*
*Чыга күрмә далага!*
«Идегәй» дастаны

1

Килеп кергәнме ят өйгә?! –
Империя тарихының
Алтын Урда битен нигә
Кара морза[3]
Ачып япкан.

Кысылышкан ил сулышы,
Кыпчакларның ил сагышы[4], –
Кымырҗып та ачылмаган:
Чапчагында[5]
Шәп чагыдай
Кымыз башы ачып яткан!

Куш каекта килүчеләр, –
«Матушка»сын имүчеләр[6]
Елъязмасын[7] да
ачмаган:
Әле һаман ур-суларда
Күрәннәргә үрт салсалар,
Җан түреннән ургып чыга! –

Ут чорналган чаптарларда,
Әрвах әйдәп, ыргып чаба
Тезен чүкмәс ыру ханы – Бачман хан!

2

Таш кирмәнле Болгар җирен
Батый аты таптаганда,
Диңгезгә җитеп,
Кан аккан... –
Шом сулаган суга багып,
Шома сусар саман сугып,
Актүбәсен[8] салдырткан хан
Күп учаклы кыпчакларын
Чүл-далага тараткан:

---

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ (1962) *– шагыйрь; «Балачак күге», «Кар өстендә алмалар», «Мәңгелектән исә җил...» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

«Кашкыр бүре[9] балалары
Саклап ятмас калаларны!
Таш каладан таш та калмас, –
Асты-өскә килгере!
Таш каладан таш та калмас,
Башкаладан баш та калмас!.. –
Даласында үлмәс бүре!»

Көтмәгәндә ташланырбыз
Көтү-көтү чирүләргә,
Төрлебез төрле яктан...
Бачман хан ул! –
Бар ыруын,
Яу кырында җыйналырга,
Айдалага тараткан!

«Сау калырга! –
Азауланып,
азлап-азлап,
бугазларга!»
Ыру белән җыен ясап,
Инде дога кылынган:
Иртә таңда,
Бачман ханның кылычыдай
Агып чыкты Актүбәсу[10]
Кара көмеш
Идел
кыныннан...

**3**

Көне җитсә, поскын корып[11],
Төне җитсә, посып торып,
Кашкыр азмы кыйраткан?! –
Табышының тез башына...
Тиз башына җитә бүре! –
Өзеп калмый
өзәңгеле
сыйрактан...

...Өч ел үткән, очып үткән,
Ут уйнатып. Утлар йотып...
Идел иңләп,
Йөзеп бара йөзләп кораб.
Ярдан чиру бара,
Иләп!
Идел-йортны...

Коты ботка төшсен
Дала бүресенең,
Дөрселдәсен
«Дөрс-дөрс!» каугa[12]:
Мәңгү хан[13] ул!
Ауга чыкты,
Мәңгелек хан чыкты ауга[14]!

«Утчагарлы[15] унбашларым, –
Капу[16] йодрык,
Урай[17] учларым, –
Арысланнар аулый бүген
Камыш асты сычканнарын:
Сыганакны[18] алу
Җиңелрәк идеме?!
Кирмәннәрнең
таш суын
сыгучыларым...»

– Бүз җәбәдә[19] мәлҗеп барма,
Бүчек углан[20]!
Камышларга үрт салдыр да
Чөй син лачын:
Канатлары
Көеп очсын саз кошлары! –
Авазлары яман зарлы,
Шом салмасын...

Баш очымда әйләнгәләп,
Кыйку салып
йөрмәсеннәр:
Күл иясе казгош булса,
Мин күпләрнең иясе лә!

**4**

...Кошлар дәррәү күтәрелә! –
Каршы ярда күрәннәргә
Җилләр үрт салып[21] үтә әллә.
Әллә ярдан су китәме,
Кичүдәге эзгә тулып,
Үрсәләнә-үрсәләнә...

Урман тапса, поскын корып,
Утрау тапса, посып торып,
Кашкыр озак кыйраткан:
Табышының җиз башына,
Тиз башына җитә азау[22], –
Өзеп капса,
өзәңгеле
сыйрактан!

Соң арада җанга якын
Атауларның учар талы[23]:
Як-ягына карангалап,
Күләгәдә яра ялап,
Ята ыру...
Ята ханы... –
Бүген таңда Хомай[24] төште:
Хозурына Ходай дәште
Ягыры[25] яман...
Бачманны...

Гомеркәйләр әллә ничә! –
Кичүләрне кичә-кичә,

Кичә генә кузгалгандай...
Кузалакның[26]
Һич тә кипмәс, –
Кечерәймәс күчәрләре!
Җан сихәте күләгәңне,
Дегет итеп, ярага яп...
Актүбәнең
кара көмеш
учар талы!

Гомеркәйләр әллә ничә! –
Кичүләрне кичә-кичә,
Кичә генә кузгалгандай...
Кузалакның җирне сөрмәс, –
Өзелү белмәс кучәрләре!
Яфраклар
туфрак булып
коеладыр...

Кошлар дәррәү күтәрелә!
Үрсәләнә-үрсәләнә,
Күкләренә...
Күчүләре... –
Тәңкә итеп, күләгәсен...
Күз кабагын элсә-элсен
Актүбәнең
кара көмеш
учар талы...

**5**

Кошлар дәррәү күтәрелә! –
Каршы ярда күрәннәргә
Җилләр үрт салып үтә, әнә.
Ярдан тагын су китәме,
Мәңгү ханга юл ачтым дип,
Үрсәләнә-үрсәләнә...

Кичүгә каерырга! –
Быргысын яңгыратмады;
Кырку «ур-ра!»сын
уралдырып,
Ук яңгыры яудыртмады, –
Кай ара соң?!
Кай арада?! –
Каравылны турап салган:
Көпчәкләргә аркаланган
Кыпчакларны урап алган
Мәңгү ханның яугырлары!

– Тылсым, имеш,
Тәңренең теләге бу! –
Мәңгү ханның күкләрдәге терәге бу,
Ярдан су тибәреп!
Атауга
юл ачкан...

Угры[27] халкың тугры халкым булыр!.. –
«Чү!» дисәм дә тезеңә чүк,
Атаным[28] бул,
кол Бачман!

«Чү!» дисәм дә тезеңә чүк!
Коллыгыңны атландырып,
Тураебрак басуга,
Идел-Җаек асабасы[29]
Иле кунган Баскынчакта[30]
Калмагае...
баскынга!

Үлеп яткан
Алып Бачман
Ачуыннан!..
Калгып баскан:

– Бер кавем дә тураялмас,
Бер кавымга мунчак кисә:
Кылыч капылт кисмәгәнне,
Акыртынлап,
Мунчак кисә...

Тезләндерә!
Тирмәләрдән
чыккан җайга...
Бурлат тай менеп,
Аҗау кигән Таң гына:

Чабучы булсаң,
Баш – менә!
Түгүче булсаң,
кан – менә!

– Тамыр җибәргән тирәктәй
Тормасын ла, –
Чабып аудар, Бүчек!
Угры Бачманны.

...Дәррәү кошлар,
Кыйкулашып, күтәрелә! –
Әллә инде
Чабылганын онтып тора.
Әллә шулай
Казгошлармы[31] тотып тора:
Аягүрә җан ашырды...
Аягүрә!
Актүбәнең
нургыбалы[32]
учар талы.

---

[1] Бачман – Кыпчакларның пәһлеван ханы, затлы татар нәселләренең шәҗәрә башы (1200 –1239), баскыннар белән тигезсез көрәштә «партизан сугышы»на нигез салучы каһарман.

[2] Жунҗыга – аҗау, Алтын Урда ханнарының таҗы.

[3] Кара морза – Н.М.Карамзин (1766 – 1826) тарихчы, шагыйрь, чыгышы белән кырым татары.

[4] Кыпчакларның ил сагышы – кыпчак бабаларыбыз, V гасырда Кияү каласын төзеп, көньяктан Азак диңгезе белән чикләнгән, төньяктан Мәскәү елгасына кадәр җәелгән Дәште Кыпчак дәүләтен булдырган.

[5] Чапчак – кисмәк.

[6] «Матушка»сын имүчеләр – Идел елгасы буендагы авыл-калаларны, талап-яндырып, көн күрүче елга юлбасарлары – ушкуйниклар.

[7] Елъязма – Бачманны фарсы тарихчысы Җөбәйни дә, кытай тарихчылары да искә алган, ә ут күршедәге рус елъязмачылары күрми калдырган.

[8]Актүбә – Актүбәсу буендагы кала,Сарайчык төзелгәнче, Нугай-кыпчакларның башкаласы.

[9] Кашкыр бүре – дала бүресе.

[10] Актүбәсу – Идел тамагының сул тармагын борынгылар шулай атаган.

[11] Поскын кору – качып торып, көтмәгәндә һөҗүм итү.

[12] Кауга – афәт-каза килгәндә генә кагыла торган зур барабан.

[13] Мәңгү хан – Маңгул империясенең дүртенче бөек каһаны (1208 – 1259), Болгар, Дәште Кыпчак җирләрен яуларга Батый хан белән бергә Мәңгү хан да юнәлә.

[14] «Мәңгелек хан чыкты ауга!» – Дәште Кыпчак җиңел генә җиңелми, инде буйсынды дигәндә дә, Бачман кебек баһадирлар баш күтәргәләп тора. 1239 елда Мәңгү хан, Иделнең ике ярын да иңләп, Бачман яугырларын ауларга чыга.

[15] Утчагар – туп.

[16] Капу – шәһәр капкасы.

[17] Урай – кирмәннәрне уратып алучы тирән ур-чокыр.

[18] Сыганак – көнчыгыш кыпчакларның Сырдәрья елгасы буенда урнашкан башкаласы.

[19] Бүз җәбә – ак ябага тай.

[20] Бүчек углан – Мәңгү ханның ир туганы.

[21] Үрт салу – былтыргы үлән-камышларга ут үрләтү.

[22] Азау – явыз бүре.

[23] Учар тал – мул күләгәле бөдрә тал.

[24] Һомай – яхшы хәбәр китерүче кош, бәхет кошы.

[25] Ягыр – аякка бастырмаслык яра.

[26] Кузалак – аскы үрәчәсе генә булган арба.

[27] Угры – Мәңгү ханның сарай тарихчысы Бачманны угры дип атый.

[28] Атан – печкән дөя.

[29] Асаба – җирле халык, төп халык.

[30] Баскынчак – Актүбәсуның сул ягында тозлы күл. Аның урынында борынгы дәрьядан калган тоз тавы Ак Түбә торган.

[31] Казгошлар – казлар гаиләсенә караучы су кошлары.

[32] Нургыба – ханнарның көбә туны.

## Баскынчак

***Борадәрем Фәиз Зөлкарнәй рухына – «Салават»***

*Туктамыштан җик күреп,*
*Шаһ Тимергә барсаң да,*
*Ул да сиңа тураймас!*
*Йортыңны талап, кан эчеп,*
*Токымыңны кол итеп,*
*Йортың йорттан күчереп,*
*Илеңне җирдән аерып,*
*Үз кулың белән кол итеп,*
*Мең хәйләгә юл итәр...*

«Идегәй» дастаны

### 1

Ходай җамы – Баскынчакның
Тозлак[1] яры өркәч-өркәч –
Кәрван күптән төянгәндер,
Баш төрткәндер дөяләре.

Кәрван күптән төянгәндер! –
Бөек Ефәк Юлын урап,
Тоз җамына тагын карап,
– Баш төртик бер! – диярләрме?

Тау сыртындагы Баскынчак –
Кәрван сыртында, басымчак:
Юашланып
басылачак! –
Кыя тозы вагара ул,
Бара-бара агара ул,
Тарала ул!
Кыпчак сыман[2]... –
Кузгалачак,
Кузгалачак
кәрваннарның
дөяләре.

Җиде диңгез арасында, –
Кояшның җиз табасында
Дәште Кыпчак[3] куырылган!

Болытларга дулкын орган,
Тоз кыясы булып корган
Тартар дәрьясы[4]
Тынып тормас, –

Корыса да оныттырмас:
Дулкыннарын куар кылган!
Дулкыннарын куар кылган!

Күпме кавем, кәрван-кәрван,
Ил-йорт белән кубарылган, –
Җәһәннәмнең төпләреннән
Дәрья тозы куптарылган,
Тартарны[5] кичәр
Татарны
төгәл итеп...
бар кылырга!

**2**

Япан дала,
Тәңреңә ялварсаң да,
Син балаңа булдың
Һаман яу кыры:
Буыннардан буын чаптырды,
Буыннардан кан чаптырды, –
Аягына иләт чак торды...
Яу китергән елларга
Ләгънәт яугыры!

Япан тугай сайла, нугай!
Тормасыннар, тарсынып:
Төмән-төмән татар сыйсын,
Сындырырга Мамай[6] сыртын!
Укталган
яулардан
кылганда
шау калган.
Шашынган диңгезләр,
Офыкны тезгенләр! –
Камчы-өзәңгеләр
каешланган
кылган
шавыннан.

Яулар узган Калка суга,
Кояш төшеп, калкан суга![7]
Калка суда –
Төмән шәфәкъ... –
Кан-кардәшләр калка судан,
Калка судан ун мең яугыр!
Монда яуның узасы юк... –
Баш очында
Тордык, Мамай,
соң сулышны
озаксынып.
Иләтең диңгезен
Юксына шау кылган:
Кырымлы иләттән,
Кылганны инәлткән,
Корымлы шау калган... –

Офтанган
диңгезләр
сулышын
тигезләр –
Тургайларга оя үрә!
Кылган шавыннан.

**3**

Яулар узган Кондырчада[8]
Камыш өзсәң, кандыр чыга –
Урда тоткан кардәшләрем
Камыш булган Кондырчада.
Ярда камыш – кырык төмән...
Монда яуның
У-за-сы – юк!
Баш очында
Торам, кандаш,
соң сулышны
озаксынып.

Коны качкан Кондырчада
Аксак Тимер[9] орган чукмар,
Алты гасыр очкан шәпкә,
Чаллы юлын яр-чык-лар!

Юл фаҗигасе генә, ди?!
Имештер,
Юл һәлакәте... –
Халыкларга орган чукмар
Зөлкарнәйне[10]!
Һәлак итте.

Татарларны татар кырган
Кондырчада,
Бурсыклыда,
Ярга дулкын бәргән саен
Бәгырьләр дә сулкылдар:
Дәш, давылбаз[11],
Дәш давылны, –
Бәгырьләрдә сулкылда! –
Үрсәләнгән дулкыннарның
Күбекләнгән ак сыртында –
Борадәрем!
Үлән ерган бүредәй,
Бәкләр бәге Идегәй[12]
Чирүләрне ерган алдан!
Ул баш тарткан алападан[13] –
Кабатлаган кылыч-калкан:
Алапа – дан!
Алапа – дан!
Елкылдаган кылыч-калкан:
Алапа – дан!
Алапа – дан!
Орыш тынмас Бурсыклыда[14]!

Яу кырларын сайла, татар!
Тормасын җаннар,
Тарсынып:
Туксан төмән нугай сыйсын,
Сындырырга
Урда сыртын!

Кондырчада.
Бурсыклыда.
Үлек сулы Терек суда[15], –
Үлек тулы
Терек суда
Кан-кардәшләр озак сынды.
Аянычлы тарихыбыз –
Кан туганның каны белән
Баш очында торуыбыз,
Соң сулышны
Озаксынып:
Дөньялыктан
Ансат кына
узасы юк,
узасы юк!

Бер төш күрдем:
Яулардан соң,
Шәм күтәреп, кичен йөрдем. –
Ак олаулар,
Бер-бер артлы
кереп бара
баешларга!

Ил җәсәден җыеп алып,
Янәшәләп, атлый халык:
Туктамышны[16]
Озатулары
Соңгы туй
Олаулары –
ак дугалы
аргышларда.

Һай, тугайда тояк уба! –
Коргаксыган.
Төн савымын
Нугай Ана кырга сауган:
Яңгыр тулсын
Болытларның турсыгына.
Татарларның каннарыннан
Кантар гына Арал тозы –
Арган татар
Атларына! –
кара тутлы
аран тозы.

Алтын Урда шәһит киткән
Иминлеккә! –
Ут йотучы
Йолдызларның үзгәреше.

Күк биянең савымчысы!
Күзгә тамды сөт тамчысы.
Азак тозы –
азаккысы
күз яшенең.

Сум алтын ул,
Эресә дә
Зәркәнченең учагында,
Юкка чыкмый – артып тора:
Кыпчак кызы кочагында... –
Югалдың син,
Алтын Урда!
Кияү кала[17] капкасында,
Һаман әле сине көтеп,
Иярләнгән атың тора!
Кемдер юшан[18]
Бәйләгәндер
кирәүкә[19]
канҗагасына[20].

**4**

Япан дала,
Тәңрегә син ялварганга,
Яу юлларын өзгән язга
Рәхмәт яугыры!
Колынчактай,
Бу сулаган савырыңны
Ялый, алмачуарлатып,
Тамга сала,
Чобарлатып,
борак бия[21] –
яз яңгыры.
Оча шоңкар!
Болыт кочар канатына
Кайнар һава калгышларын ягып кына,
Күкләренә
ятыш күңел –
ялгыз шоңкар!
Китә әнә киңлекләрдән киңлекләргә,
Җил иркенә
ятыш күңел –
Йолдыз кашка.
Баш бирмичә китә әнә,
Кинәнергә!
Һәй, Иректә, –
Идегәйдәй
җилкенергә:
Уята ул, камышларны кыштырдатып,
Аман калган
дала халкын –
йомраннарын.

Йолдызларга бирә:
– Йортта йоклагыз, – дип,
Әрләннәрнең
әрәм яткан
ояларын.

Япан далам,
Китте кая, китте кая
Иләтеңә
Ил-йорт булырга хыялларың?! –
Ялгыз калган
Оя инде хәзер син дә.
Япан далам, –
Япан йортым, япан оя...
йөзләп санлы –
меңләп санлы – миллионлы –
Идегәйле – милли аңлы
Нугай балаң
китте кая,
китте кая?!
Япан далам,
Тәңреңә ялварсаң да,
Балаңа син булдың һаман –
Яу кыры.
Буыннардан буын чаптырды, –
Яралардан сөт чаптырды.
Ярдәмгә телсез чакырды, –
Иләт тезенә чак торды:
Шыпырт орыш елларын
Ләгънәт оргыры!

Кытайлардан керсә кыргын,
Урманнардан керде муры:
Ил курпысы баш калкытса, –
Урды.
Урды.
Умырып урды!
Бу далада кыргый холык, –
Сарайчыкта[22]
Үрчи халык,
Саранчадай үрчи халык!
«Барчабызны йотмас кабып,
Ара-тирә торсак кырып,
Токымнарын
корыттырып!»

Шыпырт килеп керә кыргын,
Керә кырын-кырын гына,
Үләт-кыргын[23] кырды гына,
Дала халкын урды гына, –
Барып җитеп,
Кырымына,
Урдаларын орды гына!
Торды дала дошманнары
Тамакларын
бик канәгать
кырып кына...

Вабаларның яманнары –
Бабалардан калганнары:
Кеш туннары итеп бүләк,
Бәк-түрәне кирәмәтләп,
Иләтемә үткән үләт
Сирәкли әле бүген дә,
Берәмтекләп,
Йөзәр меңләп!

Турагачлы туграсына[24]
Тугры калган туган йортым, –
Ничә җигеп туарсаң да,
Мичәү[25] калган Нугай Йортым[26],
Дөньялыктан
Тыныч кына –
Тынчып кына...
Узасым юк:
Баш очында рухың тора –
Ау лачыны шаңрау ора!
Соң сулышны
Озаксынып.

**5**

Дәш, давылбаз!
Дәш давылны, –
Дәште Кыпчак[27], сулкылда!
Үрсәләнгән кылганнарның
Күбекләнгән ак сыртында –
Борадәрем!
Үкенечләр
яуга җилә! –
Дала иңләп, ярдәм килә:
Селтәргә дип,
Барысын да!

Япан дала,
Чапраксыз савырында –
Камчы эзе!
Кичке таңдай сызылгандыр.
Күз яшенең кәрваннары
Тәңре төшкән офыкларга,
Идел булып
Сузылгандыр...
Ханбикәсез ил боеккан... –
Бөйрәккә
Тоз утыргандыр...
Йөрәккә –
Кан!

Кара булып, оешканы –
Кан туганың,

Каршы басып,
Җаныңны кыешканы,
Каныңны коешканы!

Казан халкы озак сынды... –
Баш очында, Касыйм ханы[28],
Әле дә син торасыңмы?!
Соң сулышны озаксынып...
Бу мәхшәрнең татар өчен
Узганы юк,
Узасы юк!

Кырым сынды.
Азак сынды.
Кан-кардәшләр озак сынды! –
Кабатлана тарихыбыз:
Кан туганның каны белән
Баш очында торабызмы?! –
Соң сулышын
Озаксынып.

Татарларны татар кырган
Казансуда,
Бурсыклыда,
Ярга дулкын бәргән саен,
Бәгырьләр дә сулкылдар:
Чү, давылбай[29],
Чү, давылкай, –
Бәгырьләрдә сулкылда... –
Ял күперткән дулкыннарның
Күбекләнгән ак сыртында,
Борадәрем,
Тын ал инде:
Алапа
алтыннан инде!
Уйга талып, тын ал инде:
Даннар җуйдык.
Каннар җуйдык.
Калды халык, уйдык-уйдык...
Орыш тынмас Казансуда,
Орыш тынмас Бурсыклыда,
Тынлык та –
Алапага... –
Алтыннан инде!

**6**

Таулар баскан таш астында,
Кысылса да, сулап ята:
Әрвахларның зар-моңыдыр –
Әргәнченең гармуныдыр –
«Шахта көен» сулкылдата:

«Ил-көнсезләр!
Ялгыз очкан кар булырсыз!
Каралудан –
Каргалудан ышык эзләп,
Җаекларда җаен тапкан,
Бае арткан саен арткан:
Кырык күчә, –
Күч аерткан
Каргалыга[30]
Омтылырсыз...
Япан дала
Күптән инде язлар көтә, –
Җиргә сеңеп,
Онытылырсыз...»

Алкышлары дөмбәсләгән! –
Такташ йөргән Донбассларда[31]
Шахта саен гармун ята.
Күрегеннән күмер бөркеп,
Җиз теләндә тоз эретеп,
«Шахта көен» сулкылдата:

«Солан чыккан солончакта
Садак-садак кылган чыккан –
Яз уйнаклый коланчактай...
Һай! Рәхмәт яугыры!
Бу сулаган савырыңны
Яңа туган итеп ялый,
Яннарыңнан тотам калмый
Борак бия –
Яз яңгыры!»

Баскынчакта, тоз астында,
Гармуннар ул, сулап ята:
Ходай дәшеп пышылдаган,
Тоз ялаган Буга таудан[32]
Язгы сулар төшкән саен,
«Шахта көен» сулкылдата:

«Күчмә булып яратылып, –
Урда-урда кылган булып,
Арба-атсыз да, дала тулып
Арба-атлыга
Омтылырбыз!»

**7**

Колан чапкан солончакта
Ияр салдыр! –
Атың ятсын.
Нугай Ана, төягендә
Төк калганчы, ат аунатсын!
Яу алдыннан тулгау әйтеп,
Нугай Ана ат аунатa:
«Төягендә[33] төге калса,
Таш яуса да,
Атлар кайта;
Алыбын ул ни хәлдә дә
Иярендә алып кайта...»

Кайчак дәшми
Йолдызларның үзгәреше...
Кырлы курай[34] тоз татымас,
Курлы нугай тоз татыр:
Инде ничә гасыр,
Инде ничә гасыр
Кур[35] сүндерми Нугай Ана, –
Алыплары атта кайтыр...
Сөенен[36] дә алып кайтыр...
Атлар кайтты,
кайта,
кайтыр!
Казанга ул
Кереп уза, һәр көз саен...
Кирмән тауда, әнә,
Әби чуаклары:
Томаннарның бәбәй итәк өрфиясен
Сөйрәп төшә
Ханбикәнең
Тим Чуары.

**8**

Нугай юллары тикән –
Нугай камчысы.
Чугы очында кипкән
Таңнар тамчысы.
Җәйде канат,
яңгыр явы,
күкләр иңләп!
Там-тамнарын ормый никтән?!
Там-тамчысы...

Олы юлда кубарылды ком бураны, –
Баскынчакны,
Төпләренә төшеп!
Актарды.
Өерелгән тоз бураны
Тузаннарын –
Төмән-төмән күтәрелгән
Үз татарын
Барлады да...
Узып китте!
Туктамышның
бүз Тарланы[37].

Тәңре ялгыш
Каугасына[38] кагылгандыр:
Тол-ятимнәр
Тозы кискән солончактан[39]
Офтандырган офыкларның өсләренә,
Әрвахларга
күпер булып,
солан[40] чыккан.

Офтандырган офыкларга
Кылган куган дәрья сыман
Калебең Салават күндергән. –

Онытылган ил-йортыңа
Дога кылган дәрья сыман
Калебең Салават күндергән. –

Догалылар тозын каплар:
– Баскынчакның кыя тозын,
Кемнәр кыеп,
Кемнәр ваклар, –
Тоз кантарлы зынҗыр салып,
Оҗмахка
күчте
әрвахлар! –
Куш салават күпереннән.

---

[1] Тозлак – тоз катламы каплаган җир, тозлавык.

[2] «Тарала ул, кыпчак сыман» – IVгасырда Алтай даласыннан китәргә мәҗбүр булган кыпчаклар бар дөньяга таралган, төрле дәверләрдә, төрле исемнәрдә тарих битләрендә калыккан: Дәһшәтле Дәште Кыпчак дәүләте хуҗалары, Бөек Могол империясе яугырлары, Мисыр мәмлүкләре, Наполеон гвардиясе җайдаклары.

[3] Дәште Кыпчак – Алтайдан Дунай ярларына кадәр җәелгән кыпчак даласы.

[4] Тартар дәрьясы – кыпчак даласы урынында борынгы дәрья булган.

[5] Тартар – җәһәннәм. Сәяхәтчеләр кыпчак даласын шулай атаган.

[6] Мамай – Алтын Урданың төмән башы (1335 – 1380).Чыңгыз нәселеннән булмаса да, хан урынына утырырга хыялланып, Нугай Йортына күп казалар китерә.

[7] «Калка суга төшеп, кояш төшеп калкан суга...» – 1380 елда Мамай морза Калка елгасы тугаенда Алтын Урда ханы Туктамыш тарафыннан җиңелә.

[8] Кондырча сугышы – Мәскәү олысына яу белән барган Аксак Тимергә Кондырча елгасы буенда Туктамыш хан каршы төшә.1391 елның 18 июнендә татарлар бәрелешкән бу зур орышта 150 меңләп яугыр һәлак була.

[9] Аксак Тимер – җиһангир (1336-1404).

[10] Зөлкарнәй – күренекле шагыйрь, мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй (1951 – 1997). 17 июльдә, М7 трассасының 74 чакрымында юл фаҗигасенә юлыгып, яшь гомере өзелә. Ул сигез ел буе җитәкләгән «Идел» журналы милли офыкларны барлаучы матбугат булып өлгерде.

[11] Давылбаз – лачынны чакыручы ау барабаны.

[12] Идегәй – Нугай Йортының төмән башы, бәкләр бәге (1352 – 1419).

[13] Алапа – гаскәрнең хезмәт хакы.

[14] «Орыш тынмас Бурсыклыда!» –1399 елда Бурсыклы елгасы буенда Идегәй белән Туктамыш хан гаскәрләре чәкәләшә. Алтын Урданы тәмам таркаткан, үз ирегенә чыккан олысларын яклаучысыз калдырган Бурсыклы сугышы да аяусыз:100 меңләп татар яугыры һәлак була.

[15] «Үлек сулы Терек суда...» – 1395 елның 15 апрелендә Терек елгасы буенда Туктамыш хан белән Аксак Тимер бәрелешкән аяусыз орышта миллионга якын төрки яугыр үзара сугыша, 300 меңе үлә.

[16] Туктамыш – иленең бердәмлеге өчен җанын фида кылган Алтын Урда ханы.

[17] Кияү кала – V гасырда кыпчаклар нигез салган Киев шәһәре.

[18] Юшан – бал исе аңкыган дала әреме.

[19] Кирәүкә – тимер бөҗралардан бәйләнгән яу туны.

[20] Канҗага – ияр артына бәйләнгән күн юл капчыгы.

[21] Борак – канатлы ат, толпар.

[22] Сарайчык – Нугай Йорты мәркәзе.

[23] Кыргын – холера.

[24] Турагачлы тугра – бөркетле герб.

[25] Мичәү – атны янга җигү; мичәү калу – читтә калу, тибәрелү.

[26] Нугай Йорты – үз исемен нугай атамасында мәңгеләштереп калдырган Җүчи хан оныгы Нугай бәкнең һәлакәтеннән соң (1300), Алтын Урда дәүләте үз эчендә күбрәк «Нугай йорты» дип, ә анда яшәүче күчмә төркиләр – Алтын Урда татарлары «нугайлар» дип йөртелә башлый.

[27] Дәште кыпчак – борынгы кыпчак бабаларыбыз V гасырда Азак диңгезе буенда төзегән дәүләт, башкаласы – Кияү кала.

[28] Касыйм ханы – Казан ханлыгын бетерүгә күп көч куйган Шаһали хан.

[29] Давылбай – ау лачынын чакыра торган бакыр быргы.

[30] Каргалы – Сәед бистәсе.

[31] Такташ – бөек татар шагыйре Һади Такташ Донбасста меңәрләгән татар шахтёрлары белән очрашуларын теркәп калдырган.

[32] Буга тау – Баскынчак күле янында Богдо тавы.

[33] Төяк – ватан.

[34] Кырлы курай – тозлавык үсемлеге.

[35] Кур – ут саклар өчен көлгә күмелгән утлы күмер.

[36] Сөен – Казан ханбикәсе Сөен Бикә (1519 – 1557).

[37] Бүз Тарлан – Туктамыш ханның ак айгыры.

[38] Кауга – афәт-каза килгәндә кагыла торган барабан.

[39] Солончак – тозлавык.

[40] Солан – салават күпере.

## Ат җибәрдем табырга[1]

*Таугa оялар шоңкармын,*
*Тау аркылы юртармын!*
*Торлаксыз[2] үскән коланмын[3],*
*Мизгелсез юшап уртлармын[4],*
*Яралыштан асаумын[5] –*
*Бугалак[6] салсаң туктармын!*
«Идегәй» дастаны

Ат ялыдай елкылдаган кылганнарны
Нугай тауның[7] сукмаклары уңай салган.
Көбәсенә[8] дирбиясен –
Колмак элгән
Ялгыз имән төшеп килә Нугай таудан, –
Нугайлардан[9] бугай ул да,
Нугайлардан!

Елкылдаган
Кылганнардай,
Елкыларны...
Салган уңай!
Нугай тауның сукмаклары –
Ыклардан соң
Тупырдаган
Чулманнарга табыр куган[10]
Нугайларның сукмакларын
Тукмаклады, тукмаклады, –
Аксак Тимер[11] халыкларны
Тукмагандай тукмаклады! –
Кыеп-кыеп, очкын коеп,
Даг дагасы тукмаклады! –
Уелган таш –
Нугай тауның сукмаклары...

Татар башын татар орган чукмар ярды!
Җуелган баш тирмәседер Чучаклары...
Куштирәкнең төрбәседер Чөкәләсе[12] –
Тигезләнгән курганнары...
Татар башын татар орган чукмар ярды!–
Бармы хәзер,
Искә алучылар бармы?!

Хәтәр булган
Нугайларның сукмаклары!
Алдан барган иравыллар[13] хәбәр сала –
Тау башыннан хәбәр сала учаклары:
«Сак булыгыз!
Поскын тора яу чаптары!»

Татар башын татар орган чукмар ярды!
Дөнья куган нугайларның сукмакларын
Туктамыштай тукмаклады!
Кыяларын кыя-кыя,
Кыйгач тояк тукмаклады:

Ташъязма ул –
Нугай тауның сукмаклары...
Атлар таный
Тояк уйган тамгаларны:
Тәкрарлый
Нугайларның сукмаклары:
Атын җуйган
Алысларга юл сабалмас!
Җәяүле хан Туктамыштай
«Юыктан[14] да юл табалмас...» –
Аҗау башны[15] татар орган чукмар ярды!–
Бармы хәзер,
Сабак алучылар бармы?!

Җәяүлеләр иңли алмас ил-көнен дә!
Ат җуйганнар,
Баса-баса көн эзенә,
Ничек узсын?!
Таң кузгала Хан күленнән[16], –
Шәфәкъ туарыла
Азак диңгезендә[17]!..

Таныйлармы?!
Еллар уйган тамгаларны...
Елъязма ул –
Нугайларның сукмаклары:
Юлы юкның дөньялыкта юк базары...
Юлың булса,
Чыкмый тормас юлбасары! –
Юлъязма ул –
Нугай тауның сукмаклары...
Җәяүлек башына төшкән[18] Идегәйнең
Такыр башын татар орган чукмар ярды:
Бармы хәзер,
Гыйбрәт алучылар бармы?!

Ил танымас
Иләт салган тамгаларны...
Ильязма ул –
Нугайларның сукмаклары:
«Ат җибәрдем,
Ат җибәрдем табырга.
Маңгай ялын үреп куйдым, –
Танырга...»
Ил танымас
Иләт салган тамгаларны!
Ат җуйганнар,
Баса-баса көн эзенә,
Ничек узсын?!
Ат сугарган Бай күленнән
Бурлат[19] йөздергән Азак диңгезенә[20]...

Хәтәр булган нугайларның сукмаклары!
Хәбәр салган Каравыл тау учаклары:
«Сак булыгыз!
Поскын тора килер көнең!..» –
Ханбикәне әманәткә бирешкәннең
Чалма башын татар орган чукмар ярды... –
Бармы хәзер,
Гыйбрәт алучылар бармы?!

Язмышкаен алдан белеп торган сыман,
Салган гавам,
Җанын ярып, салган җырга:
«Ат җибәрдем,
ат җибәрдем
табырга.
Маңгай ялын
Үреп куйдым – танырга...» –

Ат ялыдай елкылдаган кылганнарны
Нугай тауның сукмаклары уңай салган!.. –
Көбәсенә ат йөгәне –
Колмак элгән
Ялгыз имән төшеп килә Нугай таудан.
Нугайлардан бугай ул да,
Атын җуйган!
Нугайлардан...

---

[1]«Ат җибәрдем табырга» – халык җыры.
[2] Торлаксыз – аранга ябылмаган.
[3] Колан – кыргый дала аты.
[4] «Мизгелсез юшап уртлармын» – елның дүрт фасылында да көтүдә йөргән тибен аты.
[5]Асау – кулга ияләштерелмәгән кырагай.
[6] Бугалак – бер очы элмәкле аркан.
[7] Нугай тау – Ык елгасының уң ярындагы тау.
[8] Көбә – тимер боҗралардан бәйләнгән борынгы яу киеме.
[9] Нугайлар – Алтын Урда татарлары.
[10] «Чулманнарга табыр куган» – Нугай Йорты ат-елкы үрчетеп, көн күргән.Чулман буйларында да ат базарлары булган.Мәсәлән, бүгенге көндә дә Минзәлә базарын «Ат базары» дип йөртәләр.
[11] Аксак Тимер – XIV йөз ахырында Болгар олысындагы Нугай Йортын талап, бик күп халкын әсирлеккә куып алып киткән җиһангир.
[12] Чучак,Чөкәле... – Ык елгасының уң ярындагы курганнар (Башкортстан, Бакалы районы Яңа Саскүл һәм Куштирәк авыллары).
[13] Иравыл – авангард.
[14] Юык – якын.
[15] Аҗау баш – таҗ кигән хан.
[16] Хан күле – Ерак Көнчыгыштагы күл.
[17] Азак диңгез – Азов диңгезе.
[18] Җәяүлек башына төшкән – дан-дәрәҗә җуйган.
[19] Бурлат – кызыл җирлектә ак йоны булган ат.

## Угыз сөте

*Ил китәр дә ни калыр?*
*Ил китәрдә йорт калыр;*
*Йорт китәр дә ни калыр?*
*Йорт китәрдә сөт калыр...*
«Идегәй» дастаны

Тула баса август таңы.
Сөен туган ак утауны[1]
Түрдә кора тугайларым... –
Сөенече кырга сыймый тургайларның.
Кубарыла!
Тамырларда ат табырлый, –
Иярләгән атын барлый!
Татар атын – затын тоткан нугайларым...

Атларның җам танавыннан,
Артылышып, тулган тыннан
Ак киездәй томан тора!
Ышыктан
аккан Ыкта...

Ил-йортымның Ык йорты бу,
Ил-йортымның ак йорты!
Ак чатырның киезләрен
Ык сулары агартты;
Көмеш белән чигә-чигә,
Чык сулары агартты:
Ил-йортымның Ык йорты бу,
Ил-йортымның ак йорты!

Ык тугае – елбыр үлән.
Сусын басмый яңгыр белән:
Кояш җыеп алганчы ук,
Чык чемләргә елгыр үлән.
Җәй килмәсә яңгыр белән,
Чык җимләргә елгыр үлән! –
Каулаксыз айдаладан
Кайтыр нугай елкы белән.

...Тезләрен учлап,
Бөрешеп,
Йоклаганда куравычлар[2],
Кояш чыга Сөендектән[3]... –
Ак тирмәдән Сөен[4] чыгар!
«Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан[5]»
Сөен Бикәч хозурынмы сагынганга,
Томан белән төнбоеклар арасында
Су коенган нугай кызы
Сагымлана...

Яр буена, таллар булып, еллар баса, –
Ни була ул шәүлегәнгә еламаса?!

Нугай тауга җитә дә Ык,
Тармакланып,
Ил сыярлык атау ясый – тугайлана:
Тугарылып, ага вакыт тугайларда!
Сәйран сорый!
Хәйран сорый!
Буыннарда типкән канда
Канча гасыр табыр куган Нугай Ана.

Төнбоеклар йокламаган:
Томар сурәт отып алган –
Ак чәчәккә йотып алган...
Киләчәктә –
кирәк чакта күтәрелеп,
Чык суыннан түм-түм тулып,
Түңкәрелеп,
Таң Сулышы – саф сурәтне,
Иплән-иплән түгә биреп,
Им – томанда сагымларга:
Томсалаган ил-иләтне,
Асыллатып, им-томларга...

Сагынудан суга багып,
Соңармаек, Нугай Ана,
Иртәнге
Савымнарга.
Нугай юлы томаннары әле һаман
Сөен Бикәч төсе –
Ак ефәк шәл белән!
«...Ат ялына чык эчәргә төшкән кошкай, –
Сөенемнең күз яшьләрен чемләгәнгә,
Тын да алмый! –
Туктый алмый...
Сулкылдаган шәүлегән.» –
Нугай юлы тугайлары әле дә бит
Үтәмешнең юл биләве –
Сөен Бикә шәленнән:

«Һәй,Тим Чуар, Тим Чуар!
Тимгел-тимгел тир чыгар,
Купмас җирдән
Җир кубар! –
Мәскәүгә тотып бирергә,
Безне морзалар куар.

Тимгел-тимгел Тим Чуар,
Тирдән тимгел Тим Чуар!

Кирмән
тавы
томаннары
Безгә һәйкәлләр куяр...»

Сөен Бикәчен юк искә алучы да... –
Сава җанны, сава җанны Нугай Ана:
Юк искә алучы да!
Юк искәрүче дә... –
«Кырыкмышлар савылмаса,
Бер көндә кырагайлана!»
Дала сорый!
Сәхрә сорый! –
Буыннарда типкән канда
Канча еллар, тындырмыйча,
Елкы куган Нугай Ана.

**2**

Нугай юлы тугайлары әле дә бит
Иңсәсеннән төшмәс ... – Сөен шәленнән!
Кайгың булса калдыр,
Көмеш йөгерттерсен,
Нугаемның зар-моң зәркәнчесе! –
Ай шәүләсеннән
көмеш эрләр
шәүлегән.
Нугай-йорттай кавем саен яракланып,
Ил сыярлык атау ясап, тармакланып,
саеккан Ык,
саеккан Ык!
Нык саеккан!
Ханзадәне алып киткән каек сыман
Котсыз утрау калкып чыккан уртасына –
Әй, «цыкылдый» анда!
Сотник саескан:

«Дәвран сөргән нугайларның
Даласы да, каласы да
Бикләрендә нык торачак,
Гәрәйләрнең токымнарын
Казаннарда корыттырсак!
Нык торачак тыштан биктә...
Да! Ханзадә...
Аз булачак...
Әманәткә – Ханбикә!
Әманәткә – Ханбикә!»

Шәһвәтле Шаһалигә[6] аркаланып,
Шәүкәтле Күкдалага арка борып,
саеккан Ил,
саеккан Ил!
Бик саеккан! –
Кыелдырып, дала җанын суга алмас,
Коендырып, дала җанын суга салмас, –
Нугай Йорты өсләрендә
Өерелә!
Иеромонах пумаласы... – саескан.

Карадуган, Карауҗалар
Ханбикәдән юллый хәбәр:
«Коткар, әтәй, коткарсана, –
Гәрәемне, аерып сөттән,
Мәскәү куша тәресенә!»

Тынгы бирми Йосыф бигә[7]
Көн дә килгән бер үк хәбәр:
«Нугайларны сатты Казан!
Соңга калмыйк...
Мәскәүгә бар!»

«Хазардан азган[8] Казан, ди?! –
Кан-кардәш тә артык күрде
Кеш туннарны, көмешләрне...» –
Яуга дигәч,
Атны борды!
Сабый кочкан ханбикәгә
Кул изәгән халык сыман
Яр буена
Еллар баса...

**3**

Ил киткәндә йорт киткән, –
Өметеңне кырт кискән! –

Телеңне дә «кырт» иткән... –
Белмәс идек, белмәс идек,
Һаман да әле качып кына,
Шәүлегәндәй еламасак.

Ак төтенне күккә чөеп учагыннан,
Каравыллар
Ак көн юллый Чучак таудан.
Чыртанында, әнә, кояш чырт-чырт яна...
Куравычлар казан аса, Нугай Ана!

Хуш исеннән...
Җил җаена
Ауган үлән, –
Даланыкы сыман... – Нугай тауда үлән:
Сөт ташымый, –
Хуш ис ташый!
Учакларда төтәгәндә,
Юшан[9] катыш каудан үлән[10]!

Чыртанында ялгыз каен чатырдаган
Кара төтен хәбәр салган Чатыр таудан[11]:
«Казан ауган!
Казан ауган!!
Казан ауган!!!»
«Нукай җанын әманәткә оста алган,

Лыкыр[12] җирен – тояк ялын[13] аска салган»
Шаһгалинең токымнары купай-ла-на!
Сөен Бикә әле дә рәнҗидер... –
Җаным кайный, –
Әрем ягып, сөт кайната Нугай Ана.
Ирек сорап, капкач бәрә! –
Сөт кайнаса.
Нугай сыман ташып чыга! –
Сөт кайнаса.
Нугай сыман төшеп тына...
Сөт кайнаса.

Казан халкын
Ташлап киткән гаскәр сыман,
Яр буена башын игән таллар баса... –
Ни була ул шәүлегәнгә еламаса?!

Әйләнергә «татарларның каймагы»на,
Кайткан сыман Касыймнарның
Шәп чагына!
Һомай каулап,
Ватан хакын кайгырталар... –
Ходай биргән изге сөтне аерталар!
Коя-коя
ачы катык
чапчагына.

Казанда сөт әрнүләрдәй сагымлана, –
Әрем ягып,
Җан кайната Нугай Ана...

**4**

Ил киткәндә сөт тә киткән,
Хәтерләрне сөртә киткән:

Хан-дәүләтең искә төшмәс,
Төшсә дә, инде килешмәс!
Җан тулышмас, сөт төшкәндәй, –
Җанга ятып елый яңгыр теләнчесе[13]! –
Инәкәйдән
тибәртелгән
Үтәмешгәрәй.
Әй, бу Казандагы
Алама
Холыкны! –
Ава-түнә аягына чак калыкты,
Кемгә таянганын шундук онытты:
Сөен Бикәч белән Үтәмеш оныкны
Эткә сөяк ыргыткандай ыргытты... –
Инде искә алучылар да юкмы?!
Инде искә алучылар да юкмы?!.

Сөененнән көенечле хәбәр килеп,
Тугайлардан
Тургайларны куган мәллә?
Алтын яңгыр теләнчесе,
Китмәскә дип,
Нугай Ана бәгыренә кунган мәллә?
Яңгыр теләнчесе –
Тугай шәүлегәне –
Нугай Ана хәсрәтеннән шәүлә генә...
Сулкылда-са!..
Нугай таудай рәнҗеш ташый
Тал яфрагы кадәр генә шәүлегәндә!
Нугай юлы томаннары әле һаман
Сөен Бикә төсе –
Ак ефәк шәл белән!
Ат ялына чык эчәргә төшкән кошкай –
Томшыгына күз яше элгән шәүлегәндер,
Күз яше белән сулкылдый ул шәүлегән.

Алтын сыктау –
Бәгырьләрдә.
Көмеш кенәз[14] белән бергә
Сыктауга да соклан икән,
Сыктауга да сөен икән...

Казаннарның төрбәсендә,
Касыймнарның төрмәсендә
Ярославна сыман ярмый!
Җан ярасыдай – зарый...
Зари елый Сөен Бикә:

«Нугай затым,
Хан-дәүләтем... һаман юкмы?! –
Чура булу[15]... Чура булу... Уңай укмы?!
Нугай затым,
Хан-дәүләтем... һаман юкмы?! –
Чүрәләнү[16]... Чүрәләнү... Уңганлыкмы?!
Нугай затым...
Сүзе тат-лым...»

Телсез торып калган
Үксез торыннарның –
Әчегән сөттәй
Куксып-куксып торганнарның
Сәйран сорап савылмаган җанкайларын,
Яңгыр сыман җайлап кына сава-сава,
Коткарырга! –
Нигә җиңне сызганмыйсың, Нугай Ана?
Әллә инде кызганмыйсың, Нугай Ана?..
Сабырлыкның
савытлары
сарыксынга,
Чыкмый инде,
Чыкмый төнге савымнарга... –
Илдән генә сөргән идек,
Йөрәкләрдән
Китеп баргансың ла, Нугай Ана! –
Сөт аклыгы суала да[17],
Җан ташлана...

Сабый кочкан ханбикәгә
кул изәгән халык сыман,
Яр буена әле һаман,
Елбыр үлән –
Еллар баса...
Шыбырдыймы шомлы сулар:
«Илне төптән чабачаклар!
Суалса-суалмаса
Ходай биргән сөте:
Урыс кышы узган саен,
Иләтләрне иңләп чапкан,
Кызыл җәйләр килеп җитә,
Килеп җитте печән өсте!»

**5**

Ил киткәндә, сөт тә киткән, –
Үрелгәнне сүтә киткән!

Искә төшмәс иде бер дә,
Болыннарның бәгырендә, –
Имекәйгә ияләшкән Үтәмешгәрәй
Алтын яңгыр теләнчесе белән бергә, –
Сурыгудан сулык-сулык еламаса...

Сараналар саркым суза сыңар касә,
Тузганаклар сутын суза, йомрылап.
Уралган да Нугай юлда томаннарга,
Яңа чорның
ямчылары
томырыла:
«Казаннарда-а! Кассапларда-а!
Газапларда колын сала:
Газапларда! – Ил өмете.
Иткә китә кысыр гасыр...
Буаз буат,
Бугаз ертып, иткә китте! –
Эткә китте
колынчактай!
Ил өмете...»

Тора табын...
Шәфәкъларга бөялгәндер... –
Колыннарын дәшеп алган бияләрдер:
«Китмәс идек,
Ил-сөткәйләр суалмаса.»
Таллар баса чабылмаган тугайларны,
Күләгәсе бәкәл кискән күрән баса.
Куксыган сут – җыелмаган җиләкләрдә!
Тукранбаш та угыз сөтен
Суза алмый, касә-касә.

Аптөш канат очкаеңда, әй, тургаем,
Ак болытның яңа гына савылганын:
Колынчагы ими текәп тора алмый, –
Кигәвеннәр, оры салып, сырып талый
Биеп торган бияләрнең саурыннарын.

Сөен үскән утыз башлы ак утауны,
Томан туглап, корып куя тугайларым, –
Сөенече кырга сыймый тургайларның!
Кубарылып,
буыннардан
буыннарга,
Тамырларда – ат табырлый!
Иярләгән атын барлый!
Нугайларым...

«Ата-бабаң агач атта атынганмы,
Йөрәгеңдә
Иярләнгән атың бармы?» –

Тын кысылса, сорый шулай Нугай Юлы:
Үр артында –
Китүче...
Кайтучылары...
Ат исе аңкыган!..
Бурлат тикәннәргә
Кигәвеннәр ил-күч белән килгән мәллә?! –
Кигәвен биләүли!..
Нугай камчылары[18].

Бияләре колынласа,
Килеп баса Нугай Ана,
Угыз сөте имезергә[19], –
Тугыз өмет имезергә:
«Колынчактай урдам шулай
Ыргып басты аягына, –
Тугаена! –
Тугры ирен дымын –

Тугра[20] ирен дымын!
Туган җиргә тигезергә...»

Имегүдән[21], җанга төртсә ил-колынчак,
Сөенеч Сөткәен!
Сирпемәс
кем җаны? –
Әллә инде юкмы искә алучы да?
Юкмы искәрүче дә?!.

Кичер, юлкай,
Җәяү життек кичләреңә...
Ат догасын откан ком-таш эчләреңдә
Кырык дага
Кырыс дога кылачак, кымшанып:
«Торып бассын
Ил-колынчак! –
Аягында
Гел калачак!» –
Алтын дагалы чәчкә атты
Палас җәйгән комташы...

Алтын яңгыр зәркәнчесе
Алтынламый, –
Яңгыр тупырдавын тыңлый Нугай Юлы!
Алтын яңгыр теләнчесе
Тын да алмый:
Таныш тояк тавышы бар, –
Сагаюлы:

Бурлат чәчкәләрен сырган кигәвенне
Тиз генә җибәрмәс нугай камчылары... –
Кайтып бара!
Чыланса да ашыкмаган,
Туктап-туктап,
колынчагын
ышыклаган
Ханбикәнең ак канатлы Тим Чуары...

[1] Ак утау – Нугай бәкләренең күп гөмбәзле зур тирмәсе.

[2] Куравыч – бикәчнең сакчы-хезмәтче кызлары.

[3] «Кояш чыга Сөендектән!» – Яңа Сөендек авылы риваяте Сөен Бикә ханбикәнең беренче көннәре хакында сөйли: «Таудан тауга күченеп, тирмәләр кордыртып килүче ханның хатыны көмәнле булган, безнең җәйләүгә җиткәч кенә бәбәйләгән. И, сөенгән инде безнең халык! Хан кызына Сөен дип исем кушканнар, соңыннан безнең җәйләүгә Сөендек дип исем биргәннәр. Менә шулай, хан заманыннан килә ул безнең авылның исеме!» 1924 елда туган Тәзкирә Гарәф кызы Сөнәгатовадан 1994 елда язып алынды. (Башкортстан, Бакалы районы, Яңа Сөендек авылы.)

[4] Сөен – Нугай бәге Йосыф кызы, Идегәй морза торыны; Казан ханы Сафа Гәрәй хатыны – Сөен Бикә, Казанның иминлеге бәрабәренә ханзадә Үтәмешгәрәй белән бергә урыс патшасына әманәткә җибәрелеп, тоткынлыкта һәлак булган ханбикә (1519 – 1557).

[5] «Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан...» – Нәвоидан, Дәрдемәнд тәкълиде.

[6] Шаһали – Касыйм белән Казан ханы (1505 – 1567). «Казанда үзеннән башка хан булмавы турындагы теләгенә иреште». Риза казый Шаһали хакында шулай язып калдырган.

[7] Йосыф би – Нугай урдасының сул канатын җитәкләгән хәрби түрә, туган-тумачалары белән Җаек,Чулман һәм Ык тугайларында җәйләүдә йөргән.

[8] «Хазардан азган Казан» – Рус тарихчысы Лев Гумилев «Каһанатлары таралгач, хәзәрләрнең бер өлеше Иске Казанга килеп урнашкан булуы ихтимал,» дип фаразлаган.

[9] Юшан – даланың хуш исле бүз әреме.

[10] Каудан үлән – узган елдан калган кура-үлән, «дала утыны.»/16Чыртан – Ак чатырдагы хан учагы.

[11] Чатыр тау – Азнакайдагы тау.

[12] «Нукай, лыкыр» – Нугай, Казан татарларын көнбатыш шивәсе вәкилләре шулай атый.

[13] Тояк ялы – җиңелгән дәүләттән җиңүче файдасына түләтелә торган салым.

[14] Көмеш кенәз – кенәз Серебрянный,Казанның бар алтыны белән бергә, иң зур хәзинә – ханбикә китапханәсен дә төяттереп, Үтәмешгәрәй белән Сөен Бикәне әманәт итеп, Мәскәүгә алып китүче түрә.

[15] Чура – әсир, кол.

[16] Чүрәләнү – илсез калу.

[17] Суалу – утлар үлән калмагач, сөтнең аз төшүе.

[18] Нугай камчысы – шайтан таягы.

[19] Угыз сөте имезү – Колынлагач, бозаулагач, мал-туарның саргылт-көрән төстәге сөте. Шул сөтне имезсәң,тайгак тояклы колын-бозаулар бер көн эчендә чабып йөри башлый.

[20] Тугра – хан исеме язылган мөһер.

[21] Имегү – колын халкында ачыгу, сусау.

## Үтәмешгәрәй[1]

*Кыйгач камыш колаклы,*
*Тустагандай тояклы,*
*Чапкан чакта җил җитмәс*
*Табаны ялпак Тарлан бүз*
*Ат бирәдер ханияң,*
*Менсәнә, Идегәй, менсәнә!*
«Идегәй» дастаны

Терек сулы Терекләрдә,
Тибеннәрдә җил киссә дә,
Ил өркетеп,
Силләр төшә,
Төпкелләргә
Сил ишелә!
Асау атлар[2] оча аска!
Асау атлар оча аска-у!
Ишетелә...

Инешенә
Ишелеп үскән бөтнек исе...

Кыйсса-кыйсса
Тынсыз тояк тавышлары,
Олысларда көлгә басып,
Пышылдаган бөтенесен:
«Мәскәүнең дә йөрәгендә
Иярләгән ат ятты... –
Нугай Йорты табырында
Асау үскән ат ятты... –
Тышаулатмас,
Укталса да,
Нукта[3] салмас

Чорсыз Ордынкасы[4],
Әрсез хәзәр Арбаты[5]...»

**2**

Арба-атын туарганнар
Ябагалы куллар белән
Чатыр корып, элгән дага –
Биш гасыр... Һич!
Йокы алмый:
Чак-чак какса Алмачуар,
Тим Чуар да сак-сак кага!
Шәмнәр тамган җәймәсен төн,
Шуып төшсә, өскә яба.
Иртә дә кич
Өзелми һич –
Көй сулкылдый өске очта:
*«...Во поле берёзонька стояла...»*[6]

Күз йомсак та,
Йоммасак та,
Дала көе тора сакта
Кабатла, Арбат!
Юанычка:
Дала җиле каен кочкан,
Дала җиле каен кочкан! –
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

Арбатына җигелгән җан
Төн җитүгә туарыла:
Сиздермәстән сихерләргә,
Тән яктысы!
Сирпелә дә,
Шәм яктысын урап ала.
Күз йомсак та,
Йоммасак та,
Борынгы көй тора сакта:
Чак-чак какса Алмачуар,
Тим Чуар да сак-сак кага!
Арбат кызы өнсез ятты... –
Түшәмгә!
шәм!
сөрем!
атты!
Арбат кызы күреп калган
Бүлмәсендә җилгән атны...

«Милый...» – диmи Арбат кызы,
Ак беләге урап ала:
Дала җилен каен кочкан!
Дала җилен!
Каен кочкан... –
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

Күз йомсак та,
Йоммасак та,
Кан ырымы тора сакта:
Чак-чак какса Алмачуар,
Тим Чуар да сак-сак кага.
Йөрәк шулай хәбәр сала
Гомер зая узмасынга...
Мин елмаям куанычтан!
Иделдә ат алыштырган[7]
Җитмеш алты морза сыман
Кайтып барам Арбатымнан.
Александр – Үтәмештәй
Кайтып барам Ордынкама... –
Дала җилен каен кочкан,
Дала җилен каен кочкан!
Чукындырып,
Җиде ятны
Ятыштырган! –
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

**3**

Хан-солтаным[8], Казан-йортта
Тарлан Бүзең азлап юртса,
Ханбикәнең Тим Чуары
Җилдерергә тотынгандыр! –
Оныткандыр инде Казан,
Хан капкасын оныткандыр...

Алтын яшьләр койган саен
Кирмәндәге җәсәдеңә,
Кыенлаша ханбикәңә –
Казанда ул берьялгызы
Кайгы аша карый илгә,
Казанда ул берьялгызы! –
Баш очындагы
Каен гына –
Морзалар бии өстәлдә:
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

Ил якларлык морза беткән[9].
Яклау көтмә Кол сәеттән[10]:
Өстә этләр өргән саен,
Калҗа-сөяк ташларгамы?!
Ханбикәдән
Башларгамы?! –
Ыргыттылар бурзай эткә!
Үтәмешне ташларгамы?! –
Ыргыттылар,
селтәп-селтәп!
Баш очында бетмәс каен,
Казанда ул,
Кайгы беткән...
Марҗалар бии өстәлдә:
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

Мәскәүдә ул
Ак әманәт –

Кәтүк хәтле Үтәмешкә
Күкрәк сөте тамган ана.
Касыймда ул –
«Канәт... канәт!»
Шаһалинең «канәт»еннән
Авыз-борын бетте канап... –
Касыймда ул,
Күкрәк сыен,
Нарасыен җуйган ана,
Җанның соңгы суты тамган
Чабылган
Каен гына... –
Өстәлә кичке азанга:
*«...Во поле берёзонька стояла...»*

**4**

Укталып, менә Укадан!
Тим Чуардай ак томан.

Уянды да тоякларның
Мөнәҗәтле Сак-Согына,
Урдаларның хан мәчете,
Кара яшел намазлыгын,
Селтәп җәйде!
Касыймына...

Касыйм ханы төрбәсендә[11],
Исемсез таш гүр өстендә:
Исем сорап тормый үлем... –
Үзенеке итеп ала!
Үзенекен китеп ала!
Сөен Бикәгә
Бу төрбә
Мәңге төрмә булыр иде! –
Өстәлә ялгыз Ясинга:
*«...Во поле берёзонька стояла…»*

Юырттырып,
Юл көенә кылган дога
Кырчан ташлы ак төрбәне
Узды,
Аксап...

Уктала томан Укадан! –
Кара яшел намазлыкта
Тим Чуар дагасы –
Тим Чуар догасы:
Сак-Сок!
Сак-Сок!

Искәрүчеләр дә – юк!
Искә алучылар да – юк!

Япан кырда...
Ялгыз каен...
Баш очында тора басып.
Мең биш йөз дә илле җиде[12]... –
Казан хәтта белмәс инде!
Ясин чыкса,
Чыгар Касыйм...

Ә Казанның эте-бете
Белмәс гафу үтенүне. –
Соң булса да, ханбикәдән
Гафу үтендеме,
Шаһали хан!
Синең Ясин.

**5**

Җамаяк – тустаганнары
Тулы тояк тавышлары
Моңсу җыру түгел дәдер –
Күңеленә түгелгәндер!
Түгелгәндер
Бөтенесе:
Төшләреңә чыклар төшсә,
Галиҗәнап, гаҗәпләнмә,
Мәмрәтеп
Сеңгән, әнә,
мендәреңә
бөтнек исе!

Олысларга җилә җайдак,
Алыслардан килә җайдак.
Гаҗәпләнмә,
Галиҗәнап,
Төшләреңә керсә җайдак,
Сагымнарга урангалап:
«Нугай затым,
Кайда минем Хан-дәүләтем?!» –
Җуйган илен
эзли җайдак
Урда буйлап!

«Үтәмешкә хан читеге,
Җәүһәр чемләп, чиккән идем.
Таманлатып, алыймчы дип,
Сөеп-кагып, калыймчы дип,
Томаннарда чыккан идем, –
Тим Чуарым адаштымы?! –
Аймылыштык, Тулган аем,
Хан читеге чиккән идем!»

Туган илен эзли җайдак:
«Хан-дәүләтем минем кайда?!
Хан-дәүләтем минем кайда-ау?!»
Казаннан ул,
Кайтты ярсып! –
Нугай йорты камчысыдыр,
Кисә тояк тавышларын:
Сак-Сок!
Сак-Сок!

«Үтәмештән хәбәр дә – юк!
Соңгы ханнан
Хәбәр дә – юк!

Ил-йорт эзләп кайткан идем –
Ак Сарайдан[13] хәрабә юк.
Сарайчыктан
Хәбәр дә юк!

Ил-йорт эзләп кайткан идем, –
Дүңгәләген тәгәрәтеп,
Абайламый калды Идел.

Ил-йорт эзләп кайткан идем, –
Таныгандай ак җайдагын
Баш чайкады Җаек талы,
Саз кошлары баш чайкады...»

Урамнарда Тим Чуар ул,
Буат[14] саен
Бер туар ул –
Дөнья кума, дим, туарыл!

– Гаҗәпләнмә, Галиҗәнап!
Хан угылын
Тапмыйм һаман,
Ургыл җанга урын тапмам!
Хан угылын
Тапмый торып,
Ургыл җанга урын тапмам! –
...Ике мең дә илле ике...
Иллесе дә
Илсезе дә,
Икәүләшеп иңри инде
Йөрәкләрне,
дөрселдәтеп,
тупырдаудан!

**6**

Терек сулы[15] Нугай йорты!
Тибеннәрдә[16] җил киссә дә,
Ил өркетеп,
Силләр төшә[17],
Төпкелләргә сил ишелә! –

Асау атлар оча аска-у!
Асау атлар оча аска-у! –

Алгысытып,
Ишетелә:

Инешенә
Ишелеп үскән
Терек сулы бөтнек исе.
Гаҗәпләнмә,
Галиҗәнап!
Төшләреңне җил бөтерсә,

Мендәреңнең
Мәрмәрендә!
Иңкүләнсә тояк эзе,
Тозын койган
Тояк эзе.

Соңгы төрмәң –
Шомлы төрбәң –
Зур ачылган
Шомның күзе.

Атын җуйган арбатлылар
Синнән соң да ишекләргә
Эчке яктан элә дага:
Кичке якта! Кичке якта! –
Эчке якта... эчке якта...
Тагын кага!
Тагын кага!

Йөгән тыйган чаптар сыман,
Йөгән тойган чаптар сыман
Йөрәк кага,
Талгын кага. –

Бала җуйган Сөен Бикә
Үтәмешне эзләп килә!
Дала җуйган арбатлыга,
Дала җуйган арбатлыга.

Төнгә таба,төнгә таба
Тына дага, йөрәк тына... –
Бала җуйган ханбикәнең
Тим Чуары,
Канатына
Утыра да, җайлап кына,
Эзләшергә җайдак чыга:
Терек сулы!
Терексудан –
Урдалардан урап кайта!

Терек суын уртлап кайта
Дала җуйган Арбатына,
Дала җуйган Арбатына.

Юлаучы күп бу юлларда.
Юллаучы юк!
Елаучы күп бу елларда.
Еглаучы юк!

Син төшеңдә!
Эзләшергә җөрьәт иттең.
Алып чапса,
Йөгәне юк Тим Чуарның:
Ташлы еллар
Йолкып калыр йөрәк итен[18]!

Бу Мәскәүдә
Адашмады Сөен Бикә –
Әманәттә ай яктысы,
Ай яктысы әманәттә!
Әманәтнең үтәлеше –
Үтәмешен!
Казанга ул...
Ап-кайтачак!
Ап-ак атта!

Тарлан бүз ат бирә ханияң, –
Менсәнә!
Нугай Йорты[19] сөенеч көтәр
Мең сәнә...

Хан йокысын саклап тора соры собор[20].
Хан йокысын саклап торыр соры собор. –

Илтеп сал бар,
Илтеп сал бар, –
Чәчәк түгел!
Терек сулы
бөтнек исен.

Кыйссаларда җилә җайдак!
Гаҗәпләнмә,
Галиҗәнап, –
Саркыт таммас җамаяктан[21]
Тансык тояк
Тавышлары
түгеләчәк
бөтенесе!

---

[1] Үтәмешгәрәй – Казан ханы (1546 – 1566).1551 елда әнисе Сөен Бикә ханбикә белән Мәскәүгә әманәткә – әсирлеккә озатыла.

[2] Асау ат – кыргый ат көтүендә нукта киеп үскән әрсез татар аты.

[3] Нукта – далага куганда, елкыга кигертелүче авызлыксыз, гомерлек йөгән.

[4] Ордынка – Мәскәү урамы, Мәскәү кенәзлеге Алтын Урданың бер олысы булган елларда татарлар салган урам.

[5] Арбат – Мәскәү урамы. Хәзәр каһанаты таркалгач, угыз-кыпчак яраннары белән, яһүд динендәге аксөякләр килеп төпләнгән күчә-урам.

[6] «...Во поле берёзонька стояла...» – Нугай татарларыннан азган казаклар аша күчеп, урыс халык җырына әйләнгән борынгы дала көе.

[7] «Иделдә ат алыштырган» – Иделнең уң ярына, Мәскәү ягына качу белән чукынган Казан морзасы. Морзаларның сатылу колачына исең китәр, алар иман, ватан алыштырып кына калмыйлар, дошман сафына басып, Казан халкын кылычтан да үткәрәләр.

[8] Хан-солтаным – Казан каласын егерме ике ел дәвамында Мәскәү һөҗүменнән саклаучы Сафа Гәрәй хан (1510 – 1549),Үтәмеш Гәрәйнең этисе, Сөен Бикә ханбикәнең яраткан ире.

[9] «Ил якларлык морза беткән» – Үтәмеш Гәрәй хан булгач, Казаннан Мәскәү хезмәтенә күчү өчен ун меңләп кеше качып китә.

[10] Кол сәет – Үтәмеш белән ханбикәне Мәскәүгә әманәт итеп бирүне, Зөя каласына барып, оештырып йөрүче Колшәриф.

[11] Касыйм төрбәсе – XV гасыр башында Касыйм ханлыгы башкаласын төзегәндә калкулыкта Хан мәчете белән бергә хан төрбәсе дә салына.

[12] «Мең биш йөз дә илле җиде...» – Сөен Бикәнең Касыйм зинданында, кыйналу, ач торулардан йончып, һәлак булган елы. Шаһали хан белән аның туганнары җирләнгән Касыйм төрбәсендә бер читтәрәк исемсез таш тора. Ул таш астында Сөен Бикә кабере дип фаразлыйлар.

[13] Ак Сарай – Алтын Урда башкаласы. Кырым татарлары җир белән тигезләгән кала. /

[14] Буат – гасыр.

[15] Терек су – Төньяк Кавказдагы елга,нугайларның ватаны.

[16] Тибен – Атлар, кар астыннан тибеп алып, үлән утлаган кышкы көтүлек.

[17] Сил – кар эрү сәбәпле таулардан ишелгән боз-ташлы ташкын.

[18] Йөрәк ите – тояк тузып, атның чиләнгән табаны.

[19] Нугай Йорты – төркиләшкән монголларга угыз-кыпчаклар кушылып барлыкка килгән кавемгә исемен биреп калдырган Нугай хан һәлак булгач (1300 ел), нугайлар Алтын Урданы Нугай Йорты дип атый башлый.

[20] Соры собор – ватаны, иманы, диненнән яздырылган Үтәмеш – Александр озак яшәми, 20 яше тулар-тулмас, 1566 елның 11июнендә вафат була.Ул Кремльнең Архангел соборы төрбәсендә күмелә.

[21] «Саркыт таммас җамаяк» – шәрык шигърияте образы: узган гомер.

*(Ахыры киләсе санда).*



Равилә
Шәйдуллина-Мурат

# ҮКСЕЗЛӘР

ПОВЕСТЬ

– Кызым, уян әле, саташасың, ахры. Бисмилланы әйтеп әйләнеп ят!

Айзадә, уянып китеп, күзләрен ачты. Каршында әбисе басып тора иде.

– Төш күрәсең, ахры, кызым, җылыйсыңмы шунда, – дип, әбисе Айзадәнең башыннан сыйпады, өшкергәндәй итте.

Кыз, авырлык белән генә уянып җитеп, кичәге хәлләрне исенә төшерде:

...Кичә әнисен җирләгәнгә бер ел тулды. Туган-тумачаларны, күрше-күләнне чакырып, Коръән укыттылар. Андый көнне бала-чагага да эш җитәрлек була. Арыган иде Айзадә. Әмма барыннан да бигрәк аның җанын сагыш – әнисен өзелеп сагыну хисе телгәләде. Бигрәкләр дә әйбәт, җылы, ягымлы иде шул әнисе. Ашка килгән әбиләр дә ничек яратып, хөрмәт итеп искә алдылар үзен.

Әбисе уятканда, Айзадә, чыннан да, төш күрә иде.

Җәй көне, имеш. Кыз бер кош артыннан йөгерә. Ул кош шундый матур. Андый матурлык әкиятләрдә генә була торгандыр. Айзадәнең андый гүзәллекне моңарчы бер дә күргәне юк иде әле. Айзадә, инде тотам, дигәндә генә, кошчык буй җитмәс биеклеккә күтәрелә. Менә ул тасма кебек сузылган тимер юлга борыла. Ә ул юлдан ажгырып поезд килә. Кошчык, аны-моны аңышмыйча, бар дөньяны дуылдатып, зур тизлек белән якынлашып килгән поезд каршына оча. Айзадә дә туктый алмый, ул инде поездның җилен дә тоя. «Кошчыгым бәрелеп харап була инде», – дип уйлый кыз. Шулчак каяндыр әнисе килеп чыга. Ул, кулындагы аклы яулыгын күтәреп, поезд каршына баса. Поезд шып туктый. «Кара, ажгырып килгән поезд шулай тиз туктый ала микәнни?» – дип уйлый Айзадә, үзе, кошчык турында да онытып, ашкынып, кулларын җәеп, әнисе каршына йөгерә. Кыз аны өзелеп сагына бит, әнисеннән башка бик авыр Айзадәгә. Ул килеп сарылам дигәндә генә, әнисе һавада эри дә, юкка чыга. Ә Айзадә белән җилпенеп уйнаган матур кош, поезд түбәсен очып әйләнә дә әнисе тавышы белән: «Хуш, балам, сабыр бул!» – дип, урманга таба очып китә. Кыз тыела алмыйча үксеп елап җибәрә...

Уянып киткәндә, мендәре юеш иде кызның. «Әнием башка беркайчан да кайтмаячак» дигән уй менә инде ничәнче кабат Айзадәнең бөтен җанын, йөрәген, гәүдәсен сызландырып ярып үтте. Кыз инде өнендә дә елый иде. Яшьләре яңакларын чылатып акты да акты.

Айзадәнең әнисенә сөйләр сүзләре бик күп. Ул быел, көз җиткәч, мәктәпкә барачак: инде укырга, язарга да өйрәнде. Әтисе бик әйбәт Айзадәнең. Ул аңа яңа мәктәп

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ (1949) – *язучы; «Ялантауга ай кунган», «Сихәтләнү», «Алмагач дәресе» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

формасы, матур рәсемнәр белән бизәлгән портфель, күп итеп китап-дәфтәрләр алып кайтырмын, диде. Айзадә зур кыз инде хәзер. Әтисенә ашарга пешерергә булыша, алай тизрәк тә, күңеллерәк тә бит. Әтисенә ярдәм итә-итә, кайбер ризыкларны үзе дә пешерергә өйрәнде. Эх, әнисе күрсә, бик куаныр иде. Тик... үзләренә Гөлназ исемле апаның килеп йөрүен, әтисе белән йокы бүлмәсенә кереп, шунда төн кунуын гына әнисенә әйтмәс ул. Шул хакта уйлый-уйлый, Айзадә тагын йоклап китте.

Кыз кабат күзләрен ачканда, өй эче кояш нурларына күмелгән иде. Айзадәнең колагына әбисе белән әтисенең сөйләшүе ишетелә. Күрәсең, әбисе китәргә әзерләнәдер. Әтисе аны тагын бераз торырга кыстый.

«Әзрәк бездә яшә инде» дигән сүзенә әбисе җайлап кына җавап кайтара:

– Юк, кияү, кала алмыйм, бабаң ялгыз бит. Аңа мал-туар каравы бик авыр. Айзадәне алып китим, бездә яшәп укыр, каникулда синең яныңа да кайтып торыр, безгә бәбкә дә саклашыр...

– Сорама, әби! Динәмне югалттым. Аңардан башка яшәвемә дә бер ел үтте. Җирдә гәүдәм генә йөри... Кызымнан да аерыла алмыйм. Бердәнбер якын кешем ул хәзер. Мәктәбегез дә бик ерак... – Бу сүзләрне әйткәндә, әтисенең тавышы калтырабрак чыкты.

Айзадә, тиз генә торып, урын-җирен җыеп куйды, йокы күлмәген мендәр астына кыстырды. Әнисе шулай өйрәтте аны: «Нәни кошчыгым минем, – дип сөяр иде ул Айзадәне. – Урын-җиреңне йокыдан торуга пөхтәләп җыеп куя торган бул, ачык ишектән кем килеп кермәс... Бу кыз уңмаган икән, димәсеннәр...»

Әтисе белән әбисе өстәл янына утырганнар иде инде. Табынга кичә Коръән ашыннан калган тәмле ризыклар куелган.

– Кызым, әйдә юын да, бергәләп чәйләп алабыз, – диде әбисе.

Алар артык сүз сөйләшми генә чәй эчтеләр. Аннары әтисе әбисен машина белән вокзалга илтә китте. Кызга әбисе – аны ихластан яратып сөя торган, йомшак куллы якын кешесе белән аерылышу авыр булды, җанын кабат кадерле кешесеннән аерылу хисе өтеп алды. Боегып калган Айзадә тәрәзә каршына килеп утырды да уйга чумды, күргән төшен кабат исенә төшерде.

Ә ул төш бик татлы, бик ләззәтле иде. Төштәге әнисе аңа бер дә үзгәрмәгән сыман тоелды. Һаман да шул яратып кия торган аклы күлмәгеннән иде ул. Поездны туктатканда күтәргән яулыгы да – әтисе бүләге. «Әнием, ник мине көтеп тормадың, ник китеп югалдың?» – дип сөйләште ул аның белән күңеленнән. Шулчак тәрәзә шакыган тавыш ишетелде. Шык! Шык! Төшендә әнисе тавышы белән сөйләшкән кошчык түгелме соң бу?! Айзадә, канатлы дустын куркытмас өчен сак кына тәрәзә янына килде. Ә кошчык шомырт кебек кара күзләре белән кызга карап торды да пырхылдап очып китте. Айзадәнең өне белән төше буталды. Кыз бу халәтеннән чыга алмый аптырады...

Бер атнадан аларга тагын Гөлназ апа килде. Ул Айзадәнең бүлмәсенә керде дә стена-идәннәрне үлчи башлады.

– Монда ике катлы карават куярбыз. Өч кыз шушы бүлмәдә яшәрләр, бергә-бергә күңелле булыр, әйеме? – диде Гөлназ апасы Айзадәнең әтисенә, үзе кызны башыннан сыйпагандай итте. Аннары алар икесе бергә каядыр чыгып киттеләр.

Кызга ничектер авыр булып калды. Нинди өч кыз? Кемнәр алар? Нигә аның бүлмәсендә яшәргә җыеналар? Ник Гөлназ апа Айзадәнең курчакларын җыеп алып, өстәлгә атты? Кыз бу сорауларга җавап таба алмыйча аптырап бетте, күңелен бимазалаган авырлыктан арына алмады.

Кичкә таба өйгә озын-озын такталар, тимерләр ташыдылар. Айзадәнең рәсем ясый торган өстәлен ишек катына этәрделәр.

Әтисе икесе генә калган арада уңайсызланып кына сүз башлады:

– Менә шулай, кызым. Хәзер курчакларың монда булыр инде... – Ул Айзадәнең уенчыкларын иплəп кенә өстәл өстенә тезде. Ә кыз бер сүз дә әйтмичә, өйдәге тамашага шаккатып карап торды. «Гөлназ апа безгә бөтенләйгә күчеп килә микән әллә?» – дип борчылып уйланды ул.

Бераздан нindидер ят абыйлар килеп, Айзадә бүлмәсенә такта-тимерләрдән бик

тә зур ике катлы караватясап куйдылар. Кызның мондый сәндерәне киноларда гына күргәне бар иде.

Бүлмә эче котсызланып, ямьсезләнеп калды. Карават ясаучыларның берсе: «Девочка, теперь на небе будешь спать», – дип, кызның котын алды.

Кичен әтисе Айзадәне каршына утыртты да иплəп кенә сүз башлады:

– Кызым, беләсең, әниең инде мәңгелеккә безне ташлап китте, – диде ул. – Без синең белән ятим калдык. Тик болай озак яшәп булмый. Әбиең белән дә сөйләштек. Ул сиңа яңа әни алып кайтырга киңәш итә. Мин Гөлназ апаңа өйләнергә булдым. Ул сине бик ярата, ике кызы белән безгә күченеп киләчәк. Кызым, син аңа «әни» дип дәшәрсең, яме? Башта ук шулай димәсәң, соңыннан өйрәнүе авыр булыр...

– Әти, миңа яңа әни кирәкми, минем үземнеке бар. Миңа авыр түгел, бергә яшәдек бит әле. Инде ашарга да пешерәм, идән дә юам, өйне дә җыештырам. Әтием, өйләнмә! – Кыз ачыргаланып елап җибәрде. – Кирәкми миңа яңа әни, кирәкми!

– Йә, җитте, балавыз сыкма! Сиңа Гөлназ апаңның кызлары белән күңеллерәк тә булыр әле! Бу инде хәл ителгән! – дип, әтисе Айзадәне читкә этәреп торып басты да үз бүлмәсенә кереп китте. Кыз аның ишекле-түрле йөрүен, көрсенүен ишетеп торды.

Авыр иде Айзадәгә. Ул үз бүлмәсенә керде дә яраткан уенчыгын – песиен кочаклап, караватына барып ятты. Ике катлы сәндерә – карават аңа бу юлы авызын ачкан зур җанвар булып тоелды. Кызның әнисен дә шул җанвар йоткандыр әле.

Иртән Айзадә, ниндидер әйберләр дөбердәгән, савыт-саба шалтыраган, кычкырып сөйләшкән тавышларга уянып китте. Тик куркып, берара күзләрен ачмыйча ятты. Менә кемдер аның ишеген ачты. «Тут какая-то девочка спит», – дип русча сөйләшкән тавышка кыз торып утырды. Каршында ике кыз басып тора иде. Аларның берсе Айзадәдән шактый зур, икенчесе аның чамасы гына булыр. Аннары бүлмәгә әтисе белән Гөлназ апа да керде.

– Бу кызлар хәзер синең туганнарың була инде, – диде әтисе. – Әйдәгез, ашап алыгыз да әйберләрегезне урнаштырырсыз.

Кызларның зурысы – Ралинә, кечкенәсе Алинә исемле икән. Әтисе чәй эчкәндә дә, соңыннан да Айзадәгә күтәрелеп карамады. Урыныннан кузгалганда гына уңайсызланыбрак: «Менә шулай», – дип куйды.

Кызлар Айзадә бүлмәсенә кереп китте, нәрсәләрнедер төшереп җибәреп, тартмаларның ачылып ябылганы ишетелде. Айзадә ишек янына килеп, аларга карап тора башлады. Менә Ралинә Айзадәнең йомшак песиен сәндерәгә атты. Бер-бер артлы мендәр, матрас идәнгә очты. Инде чират дивардагы шәмаилгә җитте. Аны әнисе элгән иде. «Кызым, бу дога сине шайтаннардан саклар, өстеңдә рәхмәт фәрештәләре канатларын җәеп торыр, йоклаганда, матур төшләр күрерсең», – дигән иде. Ралинә: «Что за ерунда!» – дип, шәмаилне дә алып атты. Аннары: «Эту тётку тоже уберём! – дип, әнисенең фоторәсеменә үрелде. Шулчак Айзадә мәче елгырлыгы белән сикереп, караватына менде дә, әнисенең фоторәсемен алып, күкрәгенә кысты.

– Тимә! Это не тётка, это моя мама! – дип елап җибәрде.

Ралинә аңа кимсетүле караш ташлады:

– Не реви! Ты же будешь спать там – на верху! Приклей свою маму на потолок, всю ночь на неё смотреть будешь! – дип, Айзадәне этеп җибәрде. Шәмаил урынына ярымшәрә кыз кунаклады. – А здесь будет спать моя сестрёнка! Я как скажу, так и будет. Теперь я здесь хозяйка.

Айзадәнең коты очты. Ничек менәрмен, ничек йокларммын мин анда, дип уйлады куркынган кыз. Ул, гомумән, биеклектән курка иде. Кыз әтисенең тизрәк кайтуын теләде, ул бу гаделсезлеккә, Айзадәне караватыннан куугa юл куймас, дип уйлады. Тик әтисе күренмәде, ә Гөлназ апа кереп, әнисенең фоторәсемен шкаф эченә тыгып куйды.

– Айзадә, кешенең әнисе икәү булмый, хәзер синең әниең – мин. Бу «әниең» шкафта торсын, – диде ул. – Икенче катта тынычрак, син шунда йокларсың. Уенчыкларыңны да шунда менгереп куй! Бүлмәгә өч карават куеп булмый бит – урын тар!

– Гөлназ апа, мин биектә йоклый алмыйм, куркам, үз урынымда гына калыйм инде, – дип инәлеп сорады Айзадә.

Шулчак аларның сүзенә Ралинә кушылды:

– Монда мин – хуҗа, дип әйттем бит инде! – диде ул, Айзадәгә усал караш ташлап.

Өйнең асты-өскә килде. Җиһазларны күчерделәр, кием-салымнарын урнаштырдылар. Әмма әтисе кайтыр чак җиткәндә, барысы да тәртипкә китерелгән, идәннәр юылган, өйгә тәмле аш исе таралган иде.

Өстәл янына төшке ашка җыелдылар. Гөлназ апа әнисе урынына утырды. Айзадәнең күнеккән утыргычын Ралинә сайлады, аның янына Алинә урнашты, өстәл читендәге тар урын Айзадәгә калды.

– Зуррак өстәл аласы булыр, күбәйдек, – диде әтисе, Айзадәгә карап.

Кыз урыныннан торып китеп барды, аның ашыйсы да, эчәсе дә килми иде. Аннан: «Син нигә ашамыйсың?» – дип сораучы да булмады лабаса. Әтисе бигрәк тиз үзгәрде, үзен гел гаепле санап сөйләшә, Айзадәне дә күрмәмешкә салыша. Кызчыкның күзләреннән туктаусыз яшь акты.

Әтисе тагын каядыр чыгып китте. Кыз йөрәге ярылырдай булып куркып, кичне көтте. Ралинә белән Алинә әниләре янында сырпаланып йөрде. Тулай торак бүлмәсеннән күченеп килгән кызларга өч бүлмәле фатир җәннәт булып тоелды, күрәсең.

Айзадә турында барысы да онытты, ахры. Кыз үзе дә, тәрәзәгә карап утыра торгач, әрнүле уйларыннан беркадәр вакытка онытылып китте, әнисе исән чактагы күңелле көннәрне исенә төшерде. Әмма аңа барыбер бик авыр иде. Шулвакыт кызның уйларын бүлеп, тәрәзәгә тагын теге кошчык килде. Ул чем-кара нәни матур күзләре белән бер Айзадәгә, бер өй эченә карый. Кыз тагын әнисенең тавышын ишеткәндәй булды: «Сабыр бул, балам, сабыр бул! Барысы да үтәр». Кызның җанын кимереп торган газаплы уйлар кимеп киткәндәй тоелды. «Әллә әнием кош булып минем яныма кайта микән?» – дип уйлады ул. Аннары күңеленнән генә әнисе белән сөйләшә башлады: «Әнкәем, кадерлем, ник син мине ташлап киттең? Мин хәзер төн җитүдән дә куркам. Теге караватка менеп йоклыйсы да бар бит әле. Әнием, коткар мине бу бәладән», – дип, күзләрен кошка төбәп ялварырга тотынды.

Ә кошчык чырык-чырык итеп чыркылдады да очып китте. Кызга шунда тагын бер кабат: «Сабыр, сабыр!» дигән сүзләр ишетелгәндәй булды.

«Кошчыкның икенче килүенә ярма салып куярга кирәк. Мин аңа әниемә генә әйтәсе сүзләремне сөйләрмен», – дип уйлады Айзадә. Ул кухнядан ярма алып чыгарга булды. Урындык куйды да, шкафны ачып, тары ярмасы салынган банкага үрелде. Пыяла савытны кулына алуы булды, аның артыннан ук кухняга кергән Ралинә:

– Зачем туда лезешь? – дип кычкырып җибәрде һәм урындыкка китереп типте.

Аяк очларына баскан килеш банканы күтәргән Айзадә урындык өстеннән очып төште. Банка ватылды, пыяла ватыклары кызның тәненә, кул-аякларына кадалды, яралардан кан ага башлады.

– Нишләдең, зараза?! – Бусы Гөлназ апа тавышы иде. – Нәрсә калган иде анда сиңа? Идәннәрне әле генә юып чыгарган идем бит, имгәк! – дип, Айзадәне тартып торгызды ул. Аннары кызның канап беткән кул-аякларын күреп, үзе дә куркуга калды. – Әтисенә нәрсә әйтермен инде?

Кызның яраларын юып бәйләделәр. Ул «Башым авырта», – дип, үз караватына барып ауды. Ләкин Ралинә килеп, аны тартып торгызды:

– Иди, на своё место ложись!

Айзадәнең башы әйләнде, күңеле болганды, күз аллары караңгыланды. Кинәт теге кошчык пәйда булды да кызны үзе артыннан ияртеп алып китте. Караватыннан аерылган Айзадә биеккә очты да очты. Ә анда аны әнисе көтеп тора икән. «Сабыр, балам, сабыр! Барысы да үтәр!» – диде әнисе, кызын күкрәгенә кысып.

Айзадә бер атнадан гына аңына килде. Күзләрен ачса, бар дөнья ап-ак, яп-якты. Ул башта үзенең кайда икәнлеген аңлый алмады. Теге биек сәндерәдә ятмавын аңлап сөенде. Тик кайда соң ул? Бу нинди бүлмә? Монда барысы да үзгә. Әнисе тагын кая китте? Алар әле генә бергәләп болында йөрделәр бит! Ул җирләр шундый матур иде: ямь-яшел чирәм белән капланган болында гаҗәеп матур чәчәкләр үсә, каурыйлары аллы-гөлле булып елкылдап торган кошлар сайрый. Айзадәгә анда шулкадәр рәхәт булды! Әнисе аның битләреннән сыйпады, башыннан, аркасыннан сөйде, күзләреннән үпте.

– Әй балам, әй сабыем, ничек кенә булышыйм сиңа? – дип елады әнисе.

– Әнием, елама! Миңа синең белән шундый җиңел, шундый рәхәт, бер генә кайгым да калмады. Син мине калдырып кына китмә, – дип өзгәләнде Айзадә.

Әнисе аны тау итәгеннән бәреп чыккан чишмә янына алып төште, яраланган аяк-кулларын юды, кан саркып торган урыннарын бәйләде.

– Кызым, бу – изге чишмә, аның суы шифалы, эчсәң, җаныңдагы әрнүләрне дә баса, – диде әнисе.

Айзадә йотлыгып-йотлыгып чишмә суын эчте.

– Әнием, бигрәк рәхәт! Шулкадәр матур монда! Минем әле мондый гүзәл болынны күргәнем, мондый тәмле суны эчкәнем юк иде. Бергәләп барган Кара диңгез дә, Ялантау чишмәсенең тирә-ягы да болай матур түгел иде.

Әнисе чишмә буендагы эскәмиягә килеп утырды да Айзадәне янына чакырды.

– Кызым, сиңа кайтырга кирәк, – дип башлады ул сүзен. – Әгәр бик авыр булса, Сәйдә әбиеңнәргә кайт, алар янында яшәрсең. Ул сине үз канаты астына сыендырыр, ятимлегеңне сиздермәс, сиңа монда килергә иртә әле, балам!

– Әнием, минем монда, синең яныңда каласым килә. Өйдә Гөлназ апа, Ралинә бар, алар миңа биек сәндерәдә йокларга кушалар. Әнием, калыйм инде яныңда, калыйм инде!

Әнисе кинәт кенә урыныннан торды да Айзадәне йомшак кына этеп җибәрде:

– Хуш, кошчыгым! Мин синең яныңа көн дә кайтып йөрермен! Сабыр бул, кызым, сабыр бул!

* * *

Шулвакыт ишек ачылып китте дә, аннан әтисе белән Гөлназ апа килеп керде.

– Уяндыңмы, кызым?! Бик куркыттың бит, – дип, әтисе идәнгә килеп тезләнде дә Айзадәнең күзләреннән үпте. Әтисенең күзләре яшьле, тавышы калтырап чыга иде.

– Мансур, кызыбыз аңына килде бит! Нинди зур сөенеч! – диде Гөлназ апа, әтисенең башыннан сыйпый-сыйпый. – Айзадәне тиздән өйгә дә алып кайтырбыз.

Айзадәнең: «Мин өйгә кайтмыйм, әбиемнәргә китәм», – дип әйтәсе килде, тик тавышы чыкмады.

Шулчак бүлмәгә шәфкать туташы килеп керде.

– Балага тынычлык кирәк, – дип, ул әтисе белән Гөлназ апаны озатып җибәрде. Аннары кызчыкны сөеп алды да: – Хәзер мин сиңа авырттырмыйча гына укол ясармын. Син, Айзадә, йокларга тырыш, сиңа йокы хәзер бик файдалы, – дип, кызның күлмәген сак кына күтәреп, укол ясады.

Айзадә энәнең чеметтерүен дә тоймады. Аның тизрәк йоклыйсы, тагын әнисе белән очрашасы килә иде. Ул кабат тирән йокыга талды.

* * *

Айзадәне хастаханәдә бер айлап дәваладылар. Әтисе белән Гөлназ апа аның янына гел килеп йөрде. Кызның әтисе белән икәүдән-икәү генә каласы, иркенләп сөйләшеп утырасы килә иде. Әмма ул гел Гөлназ апа белән иде. Бәлки, Гөлназ апасының аны Айзадә янына үзен генә җибәрәсе килмәгәндер.

Бер килүендә әтисе кызына йомшак кына итеп болай диде:

– Айзадә, кызым, моннан соң кирәкмәгән җиргә менеп йөрмә инде. Имгәнерсең. Ярмаларны гел шуннан ала торган идең ләбаса. Аягың таеп киткәндер инде...

– Айзадә бигрәк шук кыз икән, – дип, Гөлназ апа да әтисенең сүзен куәтләп куйды. – Син аңа әйбәтләбрәк әйт инде, Мансур. Ул безне бер дә тыңламый бит.

– Кызымның моңарчы бер дә тәртипсезләнеп йөргәне юк иде бит. Бик гаҗәп! Син, Гөлназ, Айзадәгә үзең дә йошаграк бул инде.

Айзадәне хастаханәдән алып кайтканда, май бәйрәме җиткән иде инде: бар дөнья кояш нурларына төренгән, өй янындагы ямь-яшел бөреләр белән капланган тирәктә кошлар чыркылдаша, ишегалдындагы түтәлләр чистартылып, аңа яңа үсентеләр утыртылган, газоннарда ямь-яшел үлән борын төрткән.

Өйгә керүгә, Айзадә каршына Ралинә килеп басты.

– О, сестрёнка вернулась! – дип, кызны кочаклагандай итте ул. Ә әтисе белән Гөлназ

апа кухняга узгач, үзе: – Попробуй, әтиеңә әйт кенә, убью! – дип, Айзадәгә йодрык күрсәтте дә бүлмәсенә кереп китте.

Аш бүлмәсенә әтисе зур өстәл алып кайтып куйган.

Җәйге көннәрдә барысы бергә, Казан янындагы бакчаларында яшәрбез, дип сөйләштеләр. Айзадә әтисе белән икесе генә калган арада:

– Әти, минем әбиләргә кайтасым килә, шунда гына яшәп торыйм,– диде.

Әтисе:

– Юк, кызым, әлегә монда бул, сиңа яңа әниеңә ияләнергә кирәк, – дип кырт кисте.

– Миңа әнием үзе дә шунда яшәргә кушты, – диде кыз.

– Кайчан?!

– Авырып хастаханәдә ятканда. Без аның белән бергә йөрдек. Ул мине шундый яратты, яраларымны бәйләде. Аннары: «Бар, кызым, кайт, Сәйдә әбиең янында яшә», – диде. Әти, авылга кайтыйм инде, әбигә дә булышырмын. Ул үзе дә чакырган иде, Мишә буенда бәбкә сакларсың, дигән иде.

– Кызым, син әзрәк ялгышасың, әниең белән дә төшеңдә генә сөйләшкәнсең. Әбиеңнәргә китсәң, яңа туганнарыңнан бөтенләй читләшеп бетәчәксең. Ә минем сезне бергә яшәтәсем килә. Тик әниең сине: «Тәртипсез», – ди. Син аны тыңла инде, кызым. Ул сине начарлыкка өйрәтмәс.

Айзадә Ралинәнең үзен ничек кыерсытуы турында сөйлисе килде. Шул арада Гөлназ апа килеп керде.

– Әтисе, без җыенып беттек, әйдәгез, кузгалыйк, – диде.

«Жигули»га бакчага алып барасы кием-салымны, азык-төлекне төяделәр дә юлга кузгалдылар.

Әтисе янындагы утыргычта барган Гөлназ апа беркавем тынлыктан соң сүз башлады:

– Мансур, хәзер мондый машинада җыен хәерче йөри. Безгә башкаларныкы кебек чит ил машинасы сатып алырга кирәк.

– Гөлназ, акча юк бит әле. Аллаһы боерса, алга таба барысы да булыр! Әзрәк сабыр итик!

– Кредитка алырга да була. Кеше шулай эшли. Бу эшеңнән китәргә кирәктер сиңа. 28 меңгә инженер булып күпме йөрергә мөмкин?!

– Мин башка эш белмим бит, Гөлназ, – диде әтисе.

– Әнә, минем бер танышым дальнякта йөри. Акчаны көрәп ала. Күчәрсең. Хәзер гаиләң дә ишәйде инде.

Әтисе дәшмәде.

Ә Айзадә бу машинаны алгач, бергәләп ничек сөенешкәннәрен исенә төшерде. Әнисе беренче тапкыр «Жигули»га утырып каядыр барырга чыккач, юл буе әтисен мактаган иде: «Мансур җаным, синнән дә булдыклырак кеше юктыр. Шөкер, Аллаһы Тәгалә мине сиңа пар иткән, шуның белән бәхетемне биргән. Фатирыбыз да булды, инде бакчага йөрү дә җиңелләште, көз җиткәч, җиләк-җимеш кайнатмаларын, бар яшелчәне арба белән алып кайта идек...»

* * *

«Гөлназ апа мине дә, машинаны да яратмый», – дип уйлады Айзадә. Яңа хатыны алдында җебеп торган әтисенә дә ачуы килде кызның.

Бакчага килеп җиттеләр. Айзадә нигәдер үз йортларына ятсынып карады.

Әнә мунча кырыенда Актүш оясы. Актүшне нәни чагында әнисе табып алып кайткан иде. «Бу эт баласы автобус тукталышы янында туңып, калтыранып ята. Күрәсең, кемдер китереп ташлагандыр. Көне дә яңгырлы. Бик кызгандым үзен. Ачтыр инде ул. Мансур, син аңа мунча кырыенда оя ясап куй. Күрше-тирәнең дә калган ашлары булыр әле, без югында кертерләр, ашатырлар. Кышын бакча каравылчысы янында яшәр», – дигән иде әнисе. Бу Айзадәнең иң бәхетле көннәренең берсе булгандыр.

– Әти, әти, көчеккә оя яса инде, мин аны үзем карармын. Без аңа матур исем дә кушыйк, – дип инәлгән иде ул.

– Исеме Актүш булсын, түшендә ак табы да бар икән, – дип, кызының сүзен җөпләде әнисе. – Мин кечкенә чакта безнең дә Актүш исемле этебез бар иде.

Шулай итеп Актүш Айзадәләрдә яшәп калды. Кыз белән көчек бик дуслашты, ярыша-ярыша үсте. Эт кыз артыннан бер дә калмыйча ияреп йөрде. Акыллы көчек булып чыкты ул: кеше кишәрлегенә кермәде, кирәк-кирәкмәскә өрмәде. «Нәселле эт баласыдыр ул», – дигән иде әтисе.

Машина килеп туктау белән, эт Хәят апалар бакчасыннан атылып чыкты да арт аякларына басып, Айзадәне кочаклаган кебек итте, аннары битләрен, кулларын ялый башлады.

– Актүш, Актүш, – диде кыз, этне кочаклап. Аның нигәдер елыйсы килде. Эт аңа шулкадәр якын иде, ул Айзадәне әнисе кебек бик нык яратадыр кебек тоелды.

Шулвакыт күрше капкадан Хәят апасы да килеп чыкты.

– Балакаем, килдегезме? – дип, ул Айзадәне кочып алды. – Шундый үскәнсең, тәмам әниеңә охшап матурлангансың. Актүшең сине күптән көтә инде, бакчагыздан китми.

– Хәят апа, Актүш тә матурланып, тазарып киткән...

– Кызым, ул сиңа тиздән бәби көчекләр алып кайтыр, тик аларны кая гына куярсың инде...

Ул арада Актүш, бакчаларында йөргән ят кешеләрне күреп, буыла-буыла өреп, Ралинәгә ташланды. Гөлназ апа Ралинәнең ачыргаланып кычкыруыннан сискәнеп китте дә кызын эттән аралап, уртага керде. Шулчак Актүш хатынның кулын тешләп канатты. Менә өйгә кереп китәргә өлгергән әтисе дә атылып чыкты. Ул йорт стенасына сөяп куелган иске көрәкне алды да бар көче белән Актүшкә китереп орды. Эт ачы чинап, арткы тәпиен өстери-өстери, читкә тайпылды. Актүш аксый-аксый Хәят апалар өе турысына сузылып ятты да ярасын ялый башлады. Аның чем-кара йоны кызгылт-көрән төскә керде. Айзадә йөгереп барып, нәни куллары белән Актүшнең ярасын эзләп тапты, аны учы белән каплады. Әмма кан, кызның бармаклары арасыннан саркылып чыгып, җиргә тамды да тамды. Кызның да, этнең дә күзеннән яшь ага иде. Айзадәнең кул-аяклары, битләре, күлмәкләре дә кып-кызыл канга буялды.

Көтмәгәндә килеп туган бу аяныч хәлгә Хәят апа да аптырап калды:

– Мансур, харап иттегез бит этне. Аның әни булырга әзерләнгән чагы, тиздән көчекләре туарга тиеш иде бит. Гөнаһысын кая куярсың, Мансур?! – дип, ул Айзадәгә бер зур тастымал чыгарып бирде, үзе күзләренә яшь тулып, өенә кереп китте.

Айзадә тастымал белән этнең ярасын басты. Кан агуы кимегәндәй булды.

– Алып китеп аттырам мин бу мөртәтне, – диде шунда алар янына килеп баскан Мансур. – Эзе дә булмасын! Гөлназ апаң да: «Эт котырган булырга тиеш», – ди. Хәзер инде аңа укол ясатырга кирәк.

– Ул үзе котырган! – диде Актүшне кызганудан нишләргә белмәгән Айзадә. – Кызы да, үзе дә котырган. Мин аларны күралмыйм! Кайтар мине дә, Актүшне дә әбиләремә. Минем монда яшисем килми, яңа кызларың белән бергәләп яшәгез шунда!

Бу сүзләр шулкадәр әрнү, рәнҗү белән әйтелделәр ки, Мансур үзе дә бермәлгә югалып калгандай булды. Аның эт канына буялып беткән, битләреннән туктаусыз яшь агып торган кызын кызганудан йөрәге кысылып куйды, Айзадәсен кочагына алып юатасы, тынычландырасы килде. Әмма:

– Җитте, булды, шыңшыма этең белән бергә, – дигән сүздән ары юату сүзен әйтә алмады.

Аннары әтисе белән Гөлназ апа, укол ясатырга дип, хастаханәгә киттеләр. Ралинә аларның күздән югалганын гына көтеп торды да ишегалдына очып чыкты.

– Я убью твою собаку! Я ей живот распорю! И оттуда вытащу щенят. И тебя убью! Чтобы ты сдохла! – дип, Айзадәгә китереп типте.

Кызның авыртудан сыны катты. Эт ырылдап, Ралинәгә ташланды. Ләкин шулчак үзе дә авыртуга түзә алмыйча, шыңшып җиргә ауды. Айзадә эте янына сузылып ятты да Актүшне кочагына алды:

– Елама, Актүшем, сабыр бул! Миңа әни гел шулай әйтә иде. Яраң төзәлсен дә, без синең белән авылга кайтып китәрбез. Анда минем әбием белән бабаем бар. Ә хәзергә сабыр ит. Беркемнән дә курыкма! Үзеңә дә, бәбиләреңә дә тидермәм! Мин синең яклаучың булырмын, – диде Айзадә, этне юатып. Ике ятим бер-берсенә сыенып озак ятты, Айзадә шулай йоклап киткәнен дә сизми калды. Эт җылысына изрәп йокыга талган кыз төш күрде.

...Ялантау чишмәсе буенда Актүш белән бергәләп каз бәбкәләре саклыйлар, имеш. Болын аллы-гөлле чәчәкләрдән чуп-чуар булган: тукранбашлар да, зәңгәр кыңгыраулар да, лилияләр дә, тагын ул белмәгән әллә нинди матурлары бар. Шул чәчәкләргә күбәләкләр, энә караклары, бал кортлары килеп куна. Актүш аксый-аксый булса да, яланда көчекләре белән уйнап йөри. Кояш җылы нурлары белән Айзадәнең битләреннән, чәчләреннән сыйпагандай итә. Кызга шушы сәгадәтле гүзәллек эчендә шулкадәр рәхәт. Ул әбисе пешергән тары боткасы белән бәбкәләрне сыйлый. Бәбкәләр дә шулкадәр сөйкемле, йомшаклар. Шунда төш өзелде...

– И-и-и балам, нигә салкын җирдә йоклап ятасың? Әле җир җылынмаган. Гомерлек чир алуың бар. Әллә кайчан чыгып карыйсым калган да бит... Әйдә әле, мунча өлгергән иде. И үксезем, и ятимем минем, – дип, Хәят апа кызчыкны үзләренә алып кереп китте. – Хәзер бергәләп мунча керербез. Бер генә чынаяк кайнар чәй эчеп ал да...

Гомер буе табиб булып эшләгән Хәят апа мунчада Айзадәнең тәнендәге күгелҗем яра эзләрен шундук күреп алды.

– Кызым, кем кыйнады сине? – дип җай гына сорап, баланы куенына алды. Үзе дә ятимлектә үскән табибә ханым Айзадәнең хәлен аңлый иде:

– Аһ кансызлар, аһ оятсызлар! Кайтсыннар гына, күрсәтермен мин аларга! Ятим баланы рәнҗеткәннәр бит...

Кыз Хәят апаның әтисен ачулануын бер дә теләми иде.

– Юк, Хәят апа, егылдым гына мин. Әтинең бер гаебе дә юк, – диде ул, бердәнбер якын кешесен яклап. – Бүген мин сездә генә куныйм әле, Хәят апа! Ярыймы?

– Ярый, Айзадә. Кунарсың.

Күрше апасы Айзадәнең канга буялып беткән күлмәген юды да колгага элеп куйды.

– Без юынганчы кибә ул, – диде.

Мунчадан чыккач, Хәят апа Айзадәгә бөтнекле-мәтрүшкәле чәй эчерде дә йокларга яткырды.

– Йокла, кызым, иртә кичтән хәерлерәк, – дип, үзе тәрәзә каршына килеп утырды.

Айзадә Хәят апаның битеннән җыерчыклы куллары белән күз яшьләрен сөртеп-сөртеп алуына карап ятты-ятты да йоклап китте.

Кызның әтисе белән Гөлназ апа караңгы төшкәч кенә кайтты. Мансур бераздан Хәят апага Айзадәне алып чыгарга керде.

– Уятма, Мансур! Аның болай да җаны яралы. Миндә генә кунсын. Булдыргансыз болай булгач,  – дип, күршесен коры гына озата чыкты.

* * *

Актүшнең ярасы әкренләп төзәлде. Айзадә дә, күбрәк Хәят апасы янында чуалып йөри-йөри, үз хәленә ияләшә төште. Әтисе икенче эшкә керде. Хәзер аны кыз атналар буе күрми. Алагаем зур машина белән ерактан – чит илләрдән товар алып кайта ул. Гөлназ апаның кәефе бик шәп.

– Мансур акчаны көрәп ала, – дип, күрше-күләнгә мактанып та алгалады. Ул Айзадәне «күрми» дә, аңа игътибар да итми. Күрше-тирәләр дә кызның яңа әнисен нигәдер өнәп бетермәде. Хәят апасы кереп:

– Гөлназ, балага тырнак белән дә чиртәсе булма! Әгәр шушы ятимне рәнҗеткәнеңне сизсәк, ни эшләтергә белербез, хокук органнарына ук хәбәр итәрбез, – дип, ныклап әйтеп чыкты.

Гөлназ апа күршеләренә кереп-чыгып йөри торган сукмак янындагы ишекне дә такта белән кадаклатып куйды. Ә әнисе исән чагында алар күрше-тирә белән күңелле итеп аралашып яшиләр иде. Шул вакытларны исенә төшерде Айзадә. Их, күңелле чаклар иде ул! Тәмле ризык пешерсәләр, бер-берсен чәйгә дәшәрләр яисә «Авыз итегез әле» дип, өйләренә кертерләр иде. Җәйне, сөйләшеп-гәпләшеп, киңәшләшеп, тату бер гаилә булып уздыра торганнар иде.

* * *

Беркөнне Айзадә йокысыннан ниндидер ят тавышка уянып китте. Актүшнең оясын Хәят апаларының сарае янына күчергәннәр иде. Шуннан чыелдаган авазлар ишетелә. Кызчык йокы күлмәгеннән генә, артсыз башмаклар киеп, сарай янына йөгерде. Иртәнге

салкынча һава аны чиркандырып җибәрде. Мул итеп чык төшкән үлән яфраклары кояш нурлары яктысында төрле төсләргә кереп җемелди. Әйтерсең, кемдер җиргә асылташлар сибеп чыккан. Шушы матурлыкка хәйран калган кыз Актүшкә күз ташлады һәм шатлыгыннан кулларын чәбәкләп куйды. Эт сузылып яткан да яңа туган көчекләрен имезә. Эт балаларының икесе үзе кебек кап-кара, берсе ап-ак.

– Нинди матурлар! – диде кыз, шатланып. – Ә синең исемең Аппак булыр, – диде ул, ак көчеккә карап. Актүш балаларын ялый, ә үзе: «Күрәсеңме?» – дигәндәй, Айзадәгә карап-карап ала.

– Актүшкәем, рәхмәт сиңа! Булдыргансың! Мин сиңа балаларыңны үстерергә ярдәм итәрмен, – дип, кыз этнең башыннан сыйпады. – Әйдә, син көчекләреңне ашат, җылыт. Мин дә туңдым, бераз өйгә кереп ятып торам, – дип, бакча өенә таба йөгерде.

* * *

Йокысыннан уянуга, кызчык тагын көчекләр янына ашыкты һәм гаҗәпләнүдән баскан урынында катып калды: Аппак юк! Актүш үзенең ике баласын тәпиләре белән кочкан да күзләрен йомып ята.

– Актүш, Аппакны кая куйдың?

Кыз этне башыннан сыйпап уятты. Ул исә, берни булмагандай, чем-кара күзләре белән Айзадәгә карады да «Ник миңа тиясең?» дигән кыяфәт белән ваемсызланып ята бирде. Кыз уйга калды. Көчеккә кем тигән? Кем эше булыр бу? Айзадә шунда Ралинәнең сүзләрен хәтерләде. «Мин аның балаларын да үтерәм», – дигән иде бит ул. Йөрәгендә – таш, күзләрендә яшь иде Айзадәнең. Хәят апасы янына йөгерде.

– Аппакны үтергәннәр! – дип кычкырды Айзадә, елый-елый.

– Нинди Аппак? Кем үтергән? – дип аптырап калды Хәят апа. Ул әле Актүшнең көчекләр алып кайтуы турында белми иде.

Кыз аңа хәлне аңлатып бирде. Алар икәүләшеп эт янына чыктылар. Әмма Хәят апа көчекләргә әллә ни сөенмәде.

– Бу җан ияләрен кая гына куеп бетерербез инде? – диде ул уфтанып.

– Монда ап-ак төстәгесе дә бар иде. Аңа мин «Аппак» дип исем куштым. Шунысы юк.

– Күзеңә күренгәндер, балам! Шул арада кая китсен ул? Ралинә дә тимәгәндер. Иртүк монда кереп йөрмәгәндер. Алар йокыдан да уникедә генә тора бит. Аннары... Эттән алып кара син баласын! Ул аны беркемгә дә бирми бит. Ак көчекне төшеңдә генә күргәнсеңдер... Әйдә, эткә ашарга бирик. Ачыккандыр, – дип, Хәят апасы Актүшкә кичтән калган ашны салып бирде. Зур гына кисәк ит тә өстәде. – Комачауламыйк инде, иркенләп сыйлансын! – дип, кызны өенә алып кереп китте.

Айзадә уйга калды. Аппак бар иде ләбаса. Төшендә түгел, өнендә күрде ул аны.

* * *

Кызчык иртәнге чәен эчте дә күрше кишәрлекләр тирәсеннән Аппакны эзләргә чыгып китте. Аның ап-ак йонлы җансыз гәүдәсен козгыннар чукыйдыр кебек тоелды. Айзадә үзе белгән барлык ташландык кишәрлекләрне, елга тирәләрен әйләнде. Тик Аппак күренмәде. Кыз сусап, әлсерәп кайтып кергәндә, әтисе машинасы янында кайнаша иде.

– Әтием кайткан! Мин сине бик сагындым!– дип, кыз аны кочаклап алды. – Кайчан кайттың? Бу юлы бигрәк озак йөрдең, син киткәнгә ун көн узды.

– Мин төнлә кайттым. Син нигә Хәят апаңда кунып йөрисең? Кешедән яхшы түгел. Үз өебез бар бит...

– Әти, Актүш өч көчек алып кайтты. Икесе үзе кебек кап-кара, берсе ап-ак. Агы төнлә югалды. Әтием, әйдә икәү эзлик әле.

– Эт эзләп кенә йөрисем калды инде. Ул гарип этеңне күптән аттырырга кирәк. Артын сөйрәп йөрмәсен.

– Син аны үзең гарипләдең бит. Ул андый түгел иде. Аппакны да синең кызың үтергән...

– Телләшеп тор әле... Йә сугып җибәрермен... – диде әтисе, усалланып.

Кыз йөгереп, Хәят апасының бакчасына кереп китте, эт оясы янына килде. Көчекләр, юантык тәпиләренә басып, алпан-тилпән килеп йөрмәкче була. Әниләре борыны белән төрткәләп, аларны үзеннән ерак җибәрмәскә тырыша.

«Ак эт, чыннан да, булмаган, ахры, югыйсә Актүш үзен алай тыныч тотмас иде», – дип уйлады Айзадә. Төш күргәндер инде.

Айзадә белән Хәят апа көн саен кич җиткәч, елга тирәләрендә, урман яннарында йөреп кайта торган булды. «Сәламәтлеккә бик файдалы», – ди күрше апасы. Ул еш кына үзенең ятимлектә үткән бала чагын искә төшерә. Аның бер көйгә, салмак кына тавыш белән сөйләгәнен ярата Айзадә. Җәй көнендә алар бер-берсенә шулкадәр якынайдылар, сер сөйләрдәй дуска әверелделәр.

Ә беркөнне Айзадә Сәйдә әбисенә хат язды.

Дәфтәр битен «ДӘҮ ӘНИ! Яратам, кил, кил, кил, кил! Айзадә» дигән сүзләр белән чуарлады. Аннары хатны конвертка салды да тышына «Татарстан, Алансу, Сәйдә әбигә» дип язып куйды һәм Казанга кайтучы таныш апасына биреп җибәрде. Тик кыз Татарстанда Алансу дигән авылларның берничә икәнен белми иде шул.

Беркөнне Хәят апасы белән борылыштагы чүп-чар өеме яныннан үткәндә, кыз иртәнге таныш тавышны ишеткәндәй булды. Айзадә туктап калды. Нәзек кенә шыңшу тагын кабатланды. Эңгер-меңгер вакыт булса да, чыбык-чабык, пластик шешәләр арасында нәрсәдер кыймылдаган кебек тоелды. Кыз якынрак килеп караса, анда Аппак авызын кыймылдатып, ашарга имчәк эзләп ята.

– Хәят апа, мин Аппакны таптым! – дип, кичке һаваны ярып кычкырды Айзадә. – Ник монда ятасың син, Аппак? Ничек килдең? – дип, көчек белән өзгәләнеп сөйләште, аны куенына кысып сөйде, яратты. Ак аю баласын хәтерләткән нәни көчек тә, җылы тапканына сөенеп булса кирәк, кызга сыенды. Бу хәлне күзәтеп торган Хәят апа да аптырап калды. «Кара әле, бу бала белеп сөйләшкән икән. Ак көчекне дә төшендә күрмәгән. Тик нишләп монда ята соң бу эт баласы?» – дип уйланды ул.

Алар Аппакны алып кайтып, әнисе янына салдылар. Әмма Актүш, көчекне күргәч, ырылдап куйды, аңа аркасы белән борылып ятты, имәргә дип үрелгән баласын аяклары белән читкә этәрде. Көчек әнисенә сыенырга теләп килә, ә тегесе үзенә якын да җибәрми. Әйтерсең ул аның баласы түгел.

– Кара син аны, үз баласын кабул итә алмый. Кызым, ул аны имезмәс инде. Әйдә, өйгә алып керик тә авызына кашыклап сөт салыйк. Ачтан үлмәсен, – дип, Хәят апа Аппакны өйгә алып керде, Айзадә дә аннан калмады. Хәят апа көчекнең авызын ачтырып торды, Айзадә аңа кашыклап сөт салды. Эт баласы башта тончыккан кебек итенсә дә, соңрак төшенде булса кирәк: сөтне тәмләп эчә башлады. Тамагы туйган көчек кызның куенында изрәп йоклап та китте.

Айзадәнең Актүшкә ачуы килде. Ничек була инде бу: ике кара көчекне ярата, ә агын чүплеккә илтеп аткан...

– Хәят апа, ник алай кылана ул Актүш? – дип сорады кыз, аптырап. – Шунда Аппак үлгән булса...

– Аңламассың хәзер кешеләрне дә, этләрне дә... – диде Хәят апасы, авыр сулап. – Дөньясы буталды. Әмма хайваннарда бала аралау – бик сирәк күренеш. Иртәгә кибеттән имезлек алып кайтырбыз. Карап торып, җан иясен ачтан үтереп булмас.

Әтисе Айзадәне эзләп кермәде. Ике үксез, бер-берсенең җан җылысына сыенып, тирән йокыга талды.

Аппак Айзадәдән бер адым да калмады. Алар агылый белән тагылый кебек гел бергә йөрделәр, күрше апасында бергә йокладылар. Хәят апа, баланың йөрәк ярасы бераз төзәлмәсме, дип, сүз әйтмәде. Аппакны, зур тазга бастырып, шампунь белән юып торды, өйгә кергәндә дә, тәпиләрен чистартырга дип, ишек төбенә савыт белән су, чүпрәк куйды. Айзадә, көчекнең тәпиләрен башта юа, аннары коры чүпрәк белән сөртә торган булды.

Айзадә бәхетле иде. Актүш кенә Аппакны янына китермәде. Аны күрү белән ырылдап, көчекне читкә куды. Әйтерсең лә ул аңардан тумаган, аны кемдер Актүш янына китереп аткан. Тора-бара ул ике баласы белән бөтенләй юкка чыкты. Бакчалар янында кыргый этләр йөри башлаган, көн саен шуларны аталар, дип сөйләүләре хак булдымы, Актүшнең тавышы да ишетелмәде, үзе дә күренмәде. Хәят апасы: «Аңа баласының рәнҗеше төште, – диде. – Халык телендә шундый сүз бар: имештер, ана баласын имезмәсә, аңа сөт рәнҗеше төшә икән. Күрәсең, хактыр».

Айзадә этне кызганса да, баласын кыерсытканга, аңа ачуы да килә иде.

– Бәлки, ул исәндер әле, Хәят апа. Аппак монда булгач, башка җиргә күчеп киткәндер яисә аны берәрсе үзенә алгандыр. Акыллы эт иде бит ул, – дип, уйлары белән бүлеште.

* * *

Август ае килеп җитте. Иртә өлгерә торган әнис алмалары инде кызарып алланды, көннән-көн тәмләнә барды. Антоновка дигәне генә тешне камаштыра. Бакча тирәсендә үсә торган каен, тупыл кебек агачларда сирәк кенә сары яфраклар күренгәли башлады.

Сул як күрше кызы Камилә дә Айзадә белән бер яшьтә иде. Алар еш кына икесе бергә уйныйлар. Камиләне мәктәпкә барырга биштәр, форма, китап-дәфтәр алырга дип, Казанга алып кайтып киттеләр. Айзадәнең дә җете кызыл яки яшел төстәге бизәкле биштәр, матур кызыл куртка, тышына малайлар, кызлар төшерелгән дәреслекләр күз алдына килде. Ул төннәрен шулар турында хыялланып ята торган булды, әтисе аны да Казанга алып кайтыр дип көтте. Хәят апасы Айзадәнең күңеле күтәрелә башлавына сөенде. «Мәктәпкә баргач, балалар белән аралашып, тагын да ачыла төшәр, иншалла, – дип уйлады ул. – Бигрәкләр сөйкемле бала инде, бәхете генә була күрсен!» Тик үзенең генә бу арада кәефе юк: еш кына кан басымы күтәрелә, башы авырта. Инде үз өйләренә атнага бер генә, Хәят апасы кушканга гына кереп чыга торган бала, миңа ул-бу була калса, нәрсә эшләр, дип тә кайгыра иде.

Мансур көне-төне эштә. Ул хәзер бөтенләй үзгәрде, Гөлназ сүзеннән чыкмый. Ә хатынга бары тик акча гына кирәк. Бакчаларын билчән, алабута, ромашка, сарут, тузганак басты. Орлыклары җитешеп, күрше кишәрлекләргә дә сибелде. Колакларына унар, борынына икешәр божра тагып, чәчен шәмәхә төскә буятып йөрүче Ралинәләре көне-төне тимер тавышлы музыка акырта, ул мәхшәр Мансур өйдә чакта гына тынып тора. Гөлназ үзе дә, Ралинәсе дә Айзадә һәм Хәят апа белән шундый дорфа сөйләшәләр, башка күршеләрне дә санламыйлар.

«Ана дөньядан үтсә, ата урыска әверелә», – диюләре дөрестер, күрәсең. Мансур белән сөйләшәсе булыр, кызны әбисенә кайтарсын. Болай барса, бала харап булачак. Аннары әтисенең исенә төшерергә кирәк әле, беренче сентябрь җитә», – дип уйлап куйды Хәят. Тик сөйләшергә өлгерә алмады...

Айзадә әтисе кайткан көнне үзләренә чыгып китте. Кыз аны өзелеп сагынган, өстәвенә тиздән беренче сентябрь җитәчәген исенә төшерергә кирәк иде. Казанга кайтып киемнәр алырга вакыт җитте. «Югыйсә иң матурларын алып бетерерләр», – дип уйлады Айзадә. Ул өйгә килеп кергәндә, барысы бергә җыелып, әтисе алып кайткан акчаны санап утыралар иде. Кызга әтисеннән башка күтәрелеп караучы да, игътибар итүче дә булмады.

– Нихәл, кызым? – дип, әтисе аны кочагына алды.

Айзадәгә шулкадәр рәхәт булып китте. Аңа әтисенең әллә кайчаннан шулай якын, җылы итеп дәшкәне, иркәләгәне юк иде.

– Әти, әнә никадәр акча алып кайткансың! Миңа мәктәпкә барырга әйберләр алырга кирәк. Әйдә, иртәгә Казанга кайтып киләбез, – диде кыз, әтисенең күзләренә карап.

– Әйе, кызым, бик кирәк, – диде әтисе. – Кибетләргә әниеңне дә алып чыгарбыз.

Айзадәнең «әниең» дигән сүзне бик әйттерәсе килми иде, үз әнисе үпкәләр кебек тоелды аңа. Шулай да кыз дәшмәде.

Гөлназ апа ипләп кенә акчаларны сумкасына салып куйды да әтисе белән Айзадә янына килде.

– Мансур җаным, – дип дәште ул йомшак кына итеп, кыска итәк астыннан күренеп торган шәрә ботларын аңа терәп үк куеп. – Кредитка алган акчаны түләргә кирәк булуын үзең дә беләсең. Миллион ярымлык нинди матур машинада йөрисең. Ралинәдән калган күпме кием-салым, букча, китаплар ята. Алар барысы да – акча. Айзадәгә шуларны юып, үтүкләп кидерермен. Акча санаганны ярата, юкка сарыф итеп бетермик.

– Беренче сыйныфка барганда, яңадан киенсен, дигәнием. Бала күңеле сынмасын инде, Гөлназ.

– Мондый тәртипсез баланың булуыннан булмавы артык. Тәрбия күрмәгән инде. Хатының да бигрәк пешмәгән булган. Аба-а-у!

Әтисе дәшмәде. Айзадәнең күзләренә яшь тулды, ул елап, Хәят апасына йөгерде.

– Хәят апа, Хәят апа! Алар, алар... – дип, үксүеннән сүзен әйтә алмыйча торды күрше апасына сарылган кыз. Аппак исә куе йоннары белән аларның аякларын сыпыра, арлы-бирле йөри иде.

– Ни булды, балам, кем тиде? – диде Хәят апа, борчылып.

– Гөлназ апа, портфель дә, киемнәр дә алмыйбыз, Ралинәдән калган искеләрне юып бирәм, ди. Минем аның киемнәрен киясем килми, мәктәпкә үземә алган яңа формадан барасым килә.

– И бала! Борчылма... Берни дә эшләп булмый. Менә пенсиям килсә, үзем алып бирермен. Кушып җибәрергә әзрәк маям да бар иде. Кызым, син елама әле, яме. Бу арада кәефем китебрәк тора.

Хәят апа, Айзадә белән Аппак чыгып киткәч, Мансур белән сөйләшергә ниятләп, алар йортына таба атлады.

Ул кергәндә, күршеләре чәйләп утыра иде. Мансур торып басып, Хәят апага өстәл яныннан урын тәкъдим итте. Гөлназ күтәрелеп тә карамады.

– Мансур, әгәр мөмкин булса, чыгып кер әле, – дип сүз башлады күрше апа. – Үзең белән генә сөйләшәсе сүзем бар иде. Авырып торам, Казанга илтеп кайтмассыңмы икән дигән идем. Булнискә бармыйча узмас, ахры. Быел, никтер, тынгысызрак булды, җәем дә көйсезрәк узды.

– Ярар, Хәят апа, алып барып кайтырмын, – диде Мансур. – Хәзер чәемне генә эчеп бетерим дә.

– Машина су салып кына йөрми бит ул, хәзер бензин кыйммәт, – дип сүзгә кушылды Гөлназ.

– Курыкма, бензин хакын артыгы белән түләрмен, моңарчы кеше хакына кергәнем булмады, хәләл көчем белән гомер иттем, – диде Хәят апа һәм, Мансурга рәхмәт әйтеп, бакчасына таба атлады.

* * *

Хәят апасы, Айзадәне дә машинага утыртты. Исәбе банктан пенсия акчасын алу һәм кызны киендерү иде. Ул берочтан, юлда барганда, Гөлназ белән Ралинәнең Айзадәне ничек кыерсытуларын сөйләргә, Мансурны бу хатынның нечкә күңелле кызга әни була алмавына төшендерергә дә ниятләде. Тик сүзен башлап өлгермәде, ир аны кырт кына туктатты:

– Хәят апа, син инде безнең тормышка кысылма. Үзең бала таба алмагач, Гөлназдан көнләшәсең. Айзадәне дә безгә каршы котыртып, тормышыбызның ямен җибәрдең. Минем хатыным – дөнья бәһасе кеше! Синең кысыр булуыңда безнең гаебебез юк! Айзадә дә сезгә башка кереп йөрмәс! Югыйсә кызны бөтенләй бозып бетердең...

Тормышта күпне күргән Хәят апа кинәт әйтелгән бу кадәр нахак сүзләргә шаккатып калды, алардан качарга теләгәндәй, ике кулы белән башын кочып утырды; күз аллары караңгыланды. Авыр сүзләр гомер кояшы баюга таба баручы хатынның йөрәгенә пычактай кадалды. Кеше шул дәрәҗәдә мәрхәмәтсез һәм мәгънәсез була ала икән, дип уйлады ул. Мансур мондый түгел иде ләбаса. Иң рәнҗеткәне «кысыр хатын» дигән сүз иде. Ире дә гомере буе шулай дип теңкәсенә тиде. Әгәр ятимлектә кадерсезләнеп үсмәгән, салкын тидермәгән булса, бала тапмас идемени ул?! Хәят апа агарынып килде дә, бөтен тәне йомшап, Айзадә өстенә авып төште. – Әти, әти, нишләттең Хәят апаны?! – дип кычкырып җибәрде кыз. – Хәят апам, ач күзеңне! Үлмә! Мин хәзер синсез нишләрмен?!

Мансур тиз генә машинасын хастаханәгә таба борды. Тик соң иде инде. Инфаркт, диделәр...

* * *

Айзадә әтисе белән бакчага өч көннән соң гына кайтты. Хәят апасының бакча өе тәрәзәләренә аркылы-торкылы такталар кадакланган иде. Болай да кечкенә генә йорт тагын да мескенләнеп калган кебек тоелды. Хәят апасы утырткан кашкарыйлар, чәчәк атса да, моңсуланып, сулып утыра, бәрхет чәчәкнең нәзберек таҗлары да көз киләсен сизепме, башларын игән.

Аппак Айзадәне ике аягына басып кочып алды. Битләрен, кулларын ялап, сагынуын белдерде.

Айзадә әтисе белән өч көн бер авыз сүз сөйләшмәде. Казанда вакытта әтисе: «Әйдә, кибеткә кереп, киемнәр алыйк», – дип, сәүдә йорты ишек төбендә машинасын туктаткан иде, кыз нәни куллары белән автомобиль тотынгычына чытырдатып ябышты. Әтисе аны берничек тә куптарып ала алмады. Айзадә инде еламый иде. Бакча өйләренә дә керәсе итмәде, Аппагы белән урманга таба киттеләр.

Мансурның гомер булмаганча, көне буе башы авыртты. Бакчага кайтып җиткән мәлдә авырту шулкадәр көчәйде ки, чигәләренең, баш чүмеченең кысуына түзәр әмәле калмады. Ирнең машинадан чыгып, бер-ике адым атлавы булды, ул чалгы белән чапкан үлән кебек җиргә ауды.

Машина тавышы ишетеп чыккан Гөлназ Мансурны, күршеләре белән бергәләп күтәреп, өйгә алып керде. Аның сул аягы һәм кулы салынып төшкән, теле дә аңлап булмаслык дәрәҗәдә көрмәкләнгән иде.

Айзадә белән Аппак икәүләп эт оясына кереп берегеп ятты. Август аеның төннәре салкын иде. Ике үксез бер-берсен җылытырга тырышты. Аннан-моннан гына такталар каккалап ясалган оя тишекләреннән җил өрә, инде ничә көннәр юньләп ашамаган, эчмәгән Айзадә салкыннан бөрешеп килде, бөтен тәне авыртып калтыранды. Кызның хәлен сизгән Аппак аның әле бер, әле икенче ягына чыгып, җылытырга тырыша, битләрен ялый, аяклары белән коча иде.

* * *

Халисә, почтага килгән хатларны барлаганда, сәер бер хатка тап булды. Зәңгәр кыңгыраулар рәсеме ясалган конверт тышына басма хәрефләр белән «Татарстан, Алансу, Сәйдә әбигә» дип язылган.

Авылларында ике Сәйдә бар: берсенә кырык биш яшьләр булыр, ә икенчесе сиксәнгә җитеп килә.

Кемгә булыр икән бу хат? Балалар кулы белән язылган, фамилиясе дә юк.

Халисә хатлар салынган сумкасын иңбашына элде дә велосипедына утырып чыгып китте.

Сәйдә карчык үзенең Казан каласында беркеме дә юклыгын, инде оныкларының Чаллыда урнашуын, бу хатның аңа кагылышлы түгел икәнлеген аңлатты.

– Җук, олан, миңа түгел, Мөхәммәтҗан Сәйдәсенәдер. Аның балалары Казанда яши, – дип, Халисәне борып җибәрде.

Мөхәммәтҗан Сәйдәсенең өе балалар тавышыннан гөр килеп тора иде. Улының да, кызының да балалары җәйге ялга авылга кайтканнар, качышлы уйнап яталар.

– Бар, дәү әниеңне чакырып чык әле, наным, – дип, ягымлы тавыш белән дәште Халисә. Өстенә кыска зәңгәр күлмәк, аягына үкчәләре тапталып беткән сандал кигән зәңгәр күзле кыз йөгереп өйгә кереп китте. Аңа ияреп чыккан Сәйдә Халисәне елмаеп каршы алды.

– Нинди яхшы хәбәрләр алып килдең, илдә-көндәниләр бар, Халисә? Әйдә, кер, – дип, өйгә чакырды ул хат ташучыны.

– Җук, Сәйдә апа, кереп тормыйм. Менә бер хат килгән иде, «Сәйдә әбигә» дип язылган, фамилиясе җук, сиңа түгел микән?

Хатын кара эштән ярылып беткән кулына зәңгәр чәчәкле конвертны алып, әйләндереп-әйләндереп карады.

– Кемгә генә булыр икән бу хат? Минем оныклар барысы да авылда. Аптыраган. Авылда башка Сәйдәләр җук, ачып карасак кына инде. Шунда аңышып булса гына.

– И Сәйдә апа, хатларны ачып карарга ярамый бит. Белмим инде, нишлик икән?

– Болай ничек табасың аны – фамилиясе-ние җук. Үзеңә кара инде, Халисә.

Алар сак кына конвертны ачтылар. Анда тигез басма хәрефләр белән

«ДӘҮ ӘНИ! Яратам, кил, кил, кил, кил! Айзадә» дип, дәфтәр битен тутырып язылган иде.

Халисә белән Сәйдә аптырап калдылар: нинди хат булды бу? Бу балага ни булган? Нинди бәлагә юлыккан ул? Хатын да әллә ничек үзәге өзелеп язган сыман.

– Кара әле, Халисә, бу хат безнең авылга язылмагандыр. Татарстанда Алансу дигән авыл бер генә түгелдер, белеш әле.

Алансулар күп булып чыкты. Әле Йосыф Алансуы да бар икән... Халисә почтасын тиз генә таратып бетерде дә почта йортына кайтты. Хатны яңа конвертка салып, икенче Алансуга юллады. Кырыена почта келәе белән, әгәр бу авылда Сәйдә әби табылмаса, өченче Алансуга җибәрүләрен үтенеп, кәгазь ябыштырды. Үзе дә ике бала анасы Халисәнең бу балага бик тә ярдәм итәсе килә иде.

Икенче Алансуда да табылмады Сәйдә әби. Почтада эшләүче хатын хатны өченче Алансуга юллады. Конверт тышына «Әгәр Сәйдә әби табылмаса, Йосыф Алансуына җибәреп карагыз» дип, нәкъ Халисә шикелле келәйләп язу ябыштырды. Хат шулай хуҗасын эзләп йөри-йөри калынайды...

Хат ташучы килеп кергәндә, Сәйдә карчык тавыкларга җим ясап тора иде. Хатны кулына алды да аптырап калды. Катлы-катлы кәгазь ябыштырылган хатка карап торды да агарып китте. Оныгының «кил, кил»ләрдән торган һәм дәфтәр битен тутырып язган хатын күргәч, йөрәген нindidер хәвеф ярып узды.

– И Ходаем, ниләр булды икән сиңа, балакаем? – дип, аягындагы галушын лыштырдатып карты янына, төз лапас астына кереп китте. – Галихан, чык әле, чык тизрәк, нидер булган. Әйтәм аны хатлары, хәбәрләре юк. Айзадәгә нидер булган! Ай Аллам, тагын ниләр күрәсе бар икән?!

Карт, хатыны кулыннан хатны алып, озак итеп дәфтәр битен тутырып язылган «кил, кил»ләргә карап торды. Аның маңгае, имән кайрысына охшап калган җыерчыклы йөзе тагын да каралып китте. Яңакларындагы җыерчыклар тирәнәеп, авыз кырыена буразна булып кушылдылар. Аннан соң ул лапас кырыена куелган имән бүкәнгә барып утырды.

Озак кына сүзсез торганнан соң:

– Карчык, бар, Сәлимәгә кереп әйт, мал-туарны карап торсын. Җыен, Казанга чыгып китәбез. Дөнья хәлен белеп булмый, иртәгәне көтеп тормыйк, – дип, өйгә кереп китте.

Күршеләре Сәлимәне ризалаштыргач, Сәйдә карчык тиз арада, кабалана-кабалана, юлга әзерләнә башлады.

– Кичке автобуска өлгерергә кирәк, – дип ашыгып, Урыстау буйлап, җәяүләп Күкчәгә таба киттеләр.

* * *

Айзадәләр ишеген озак шакыдылар – звоноклары эшләми иде, күрәсең, ачучы булмады. Шуннан Галихан курка-курка гына уң як күршеләренең звонок төймәсенә басты.

– Кто там? – дип сорадылар эчтән.

– Иты я, Галихан, – диде карт. – Суседи дума нит, Мансур, Айзада!

Теге яктан ишек йозагын ачкан тавыш ишетелде. Ишек ачылып, тулы гына матур хатын чыкты.

– Исәнмесез, – дип исәнләште хатын. – Сезгә Мансур кирәкме? Алар җәй буе бакчаларында яшәделәр. Монда яшь хатынының балалары күренгәләде. Ә Айзадәне күрмәдем. Яшь хатын больницада Мансурны саклый, аңа инсульт булган. Калганын мин белмим, – диде ул.

Галихан күрше хатынның татар булуына сөенде. Әмма аның әйткән сүзләре йөрәген телеп узды.

Нидер булган! Кая барырга, кайдан эзләргә? Җитмәсә, үзенең урысчасы да ипилектозлык кына. Төнне кайда үткәрергә?

Күрше хатын аптырап калган картларны өенә чакырды:

– Әйдәгез, керегез. Берәрсе кайтып күренер әле. Юлдан килгәнсез, арыгансыздыр. Сез Динәнең әти-әнисеедер инде? Динә минем дустым иде. Мәрхүмкәем бик итагатьле, әйбәт кеше иде, баласын, ирен ташлап китеп барды бит, җаныкаем. Урыны җәннәттә булсын инде.

Картлар кыюсыз гына түргә уздылар. Брезенттан тегелгән чүәкләрен салып, урындык читенә утырдылар да йортка бәрәкәт теләп дога кылдылар.

Өйдә авыр тынлык урнашты. Сәйдә карчык сумка төбеннән оныгы язган хатны чыгарып, хуҗа хатынга сузды.

Хатын хатны кулына алды да берни аңламыйча, картларга карады.

– Менә, оныгым язган, – диде карчык. Әле укымый да бит, быел мәктәпкә керергә тиеш иде. Иртәгә беренче сентябрь. Кайда икән соң бу бала? – Сәйдә карчык елап җибәрде.

Хуҗа хатын хәзер күршеләре белән аралашмавын, Мансурның, Динә үлгәч, яшь хатын белән тора башлагач, бик үзгәреп китүен сөйләп алды. Кухняга чыгып, чәен куеп җибәрде.

«Күршеләре бик ипле икән» дигән уй килде картларның башына.

Утырып чәй эчтеләр. Азрак күңелләре ачыла төште. Хуҗа хатын үзен Асия дип таныштырды. Автовокзалда билет сата икән.

– Бүген сез Айзадәне таба алмассыз инде. Иртә белән Васильеводагы бакчаларына барырсыз. Яшь хатынның балалары беләләрдер. Тик иртәгә беренче сентябрь, алар мәктәпкә бара торганнардыр, – дип куйды. – Айзадәнең дә беренче класска керәсе елы бит. Кайда икән соң бу бала, гаҗәп хәл?

Караңгы төште.

Күрше фатирда ишек ачылып ябылган тавыш ишетелгән сыман булгач, Галихан чүәкләрен киеп чыкты да звонок төймәсенә басты.

– Кто там?

– Мин идем бу – Айзадәнең бабасы Галихан, ач әле, кызым.

– Какой Галихан? Мамы дома нет, не открою.

– Ач инде, кызым, деревнядан килгән идек, кунарга да урыныбыз юк. Ач инде, пужалысты. Айзадә кирәк иде. Незнай где искать.

– Нет, не открою. Уезжай обратно.

Ишек төбендә тынлык урнашты. Картның тамак төбенә әллә ниткән төер тыгылды. Ул аптырап, хәле китеп, баскычка барып утырды. Куллары калтырый, йөрәге дөп-дөп тибә иде аның.

Йа Хода! Бөтенләй чит кеше өенә кертеп чәйләр эчерде, хәлләренә керде. Ә үз кызының һәм оныгының йортына керә алмый. Югыйсә ишек артыннан кечкенә бала түгел, ә үсмер кыз тавышы килә бит! Бу Казаннарында үзләре генә торсыннар! Үз авылларында бөтен кеше туганнар кебек. Ишекнең ачкычы да гомер буе төз лапаста кадакта эленеп торды.

Карт урыныннан кузгала алмыйча озак утырды. Тәмам аягының егәре беткән иде. Аны Асия эзләп чыкты.

– Нигә монда утырасың, Галихан абзый? Нигә өйгә кермисең? Утырган урының да ару түгел бит. Әйдә, әйдә, тор, таш баскычта утырма. Сәйдә әби дә борчыла. Чәем дә кайнап чыкты.

– Ишекне ачмыйлар, наным. Бер кыз бала авылыма кире кайтып китәргә куша. Кайда гына төн катарга инде? Кая барырга дип аптырап утырам, олан. Ничек авылга кайтыйм, ди, мин, оныгымны тапмыйча? Нәрсәдер булган бу йортта! Күңелем сизә: Айзадәгә нәрсәдер булган. Әтисе бүлнистә, дисең, ә оныгым кайда? Иртәгә беренче сентябрь бит, аның мәктәпкә барыр елы. И рәхмәтле бер Аллам, ярдәмеңнән ташлама! И Раббым, шул ятим газиземне усал мотагай кулларына тап итмә! Юлларына рәхмәт фәрештәләрен чыгар!

Картның күзләреннән яшь ага, куллары дер-дер калтырый иде.

Асия күршеләренең звонок төймәсенә басты. Фатирдан дөбер-дөбер килгән музыка, хахылдап көлгән тавышлар ишетелә. Ишетмиләрме, әллә ишетеп ачмыйлармы? Асия, ачуланып, ишеккә тибә башлады. Музыканы туктаттылар. Ишекнең теге ягыннан ир-ат тавышы ишетелде:

– Старик, ещё раз подойдёшь к дверям, размажу по стенке, к своей бабке не доедешь! Убью!

– Откройте! Бабушка с дедушкой Айзады приехали, им ночевать негде, – диде Асия.

– Пусть ночуют в подъезде, не зима, – монысы үсмер кыз тавышы иде.

Асия ишек яныннан китеп, Галихан янына килде. Хәле китеп, стенага сөялде.

– Кертмиләр, – диде ул, кыска гына итеп. – Кертмиләр, – дип кабатлады. – Аллаһы Тәгалә бирде дә соң күршеләрне! Берәр гөнаһым булгандыр инде. Төне буе музыка акырталар, атна буе инде юньләп йоклаганым юк. Яшел чәчле кызларына әйтеп

караган идем, «ты себе бируши купи, помогает» дип мыскыл итте. Әйтмәм дигән идем инде, әйтмичә дә булмый. Әйдә, тор, Галихан абзый, өйгә керик. Борчылмагыз, үземдә кунарсыз. Фатирым кечкенә, бер генә бүлмәле малометражка булса да, күңелем киң, сыярбыз әле, Аллаһы боерса. Үзем кухняда булса да йокларммын, – дип, бабайга торырга булышты.

Галихан карт йөрәгенә дулкын-дулкын булып җылы тулганын, җанының җылына баруын тоеп, урыныннан кузгалды. Фатир ишеген ача башлаган Асияне туктатты да:

– Олан, син монда булган хәлләрне минем карчыгыма сөйли күрмә! Йөрәк өянәге бар аның. Алла сакласын. Яме, наным, – диде.

– Ярар, бабай, сөйләмәм.

Өйгә керделәр. Карт ишек катындагы сумкасын һәм ятьмә букчасын күтәреп, Сәйдә әби белән кухняга юнәлде.

– Менә, Асия, аз гына авыл күчтәнәче бар иде, авыз итәрсең, – дип, Галихан бабай бер литрлы банка белән балны, каклаган каз, йомарламы белән май, һәрберсен берәмләп мул гына китап битенә төргән күкәйләрне өстәлгә куйды. – Моны бирердәй кеше җук бугай монда. Әз булса да, күп итеп ал инде, олан. Алланың рәхмәте яусын сиңа, без картларны сөендергән өчен. Бәхетең арткыры.

Асия аһ итте:

– Юк, бабай, моның хәтле күчтәнәч ала алмыйм мин. Бу бит минем ярты айлык хезмәт хакым бәясенә тора! Кирәкми, оныгыңны тапкач тапшырырсың, – дип каршы төште.

Картлар кызып китте:

– Җук, олан, чын күңелдән бирәбез, ал гына. Шундый мәрхәмәтле хатын икәнсең. Оныгымны тапкач булыр әле, кибеттән сатып алган әйбер түгел. Алла саулыгыңны бирсен, Ходай тигезлектән аермасын!

– Ирем юк шул минем, бабай. Икенче хатынга чыгып китте. Әйбәт иде үзе. Ник алай иткәндер, белмим...

Картлар дәшмәде. Йортта авыр тынлык урнашты. «Авырткан җиренә тидем, ахры», – дип кайгырды карт.

Асия сүзен дәвам итте:

– Ялгызлык яман икән ул: иртән берүзең, кич берүзең дигәндәй. Ичмасам, бала табарга да өлгерә алмый калдым. Шундый да тупырдатып бала үстерәсем килгән иде! Кияүгә чыгарга кыстаучылар бар-барын, тик күңел тартмаганга чыгасы килми. Кеше гаиләсен дә җимерәсе килми. Кеше рәнҗетеп килгән бәхеттән яхшы нәрсә табып булмас. Ярый әле, әтиләрдән калган шушы почмак булды. Безнең фатирга баласы белән яшь хатын килде. Әйдә, рәхәтен күрсеннәр, тавышланмыйча гына чыгып киттем, – Асия кул аркасы белән күз яшьләрен сөртеп алды да суыткычтан аш алып җылытты, йомшак күмәч кисте.

– Үз күчтәнәчегездән үзегез авыз итегез, гомерегез озын булыр, – дип, балын, маен куйды. Инде каклаган казны да бүләм дигәндә, карт кырт кисте:

– Кит, булмаганны, тик торганда каз хәтле казны башлап утырма, кирәге чыгар әле. Йә берәр кунагың килер, каклаган каз – затлы ризык ул, табын күрке.

Өстәл тирәли утырыштылар. Чәйнек, кайнап чыгуын хәбәр итеп, сызгыра башлады. Асия чәй пешерде. Картларның тамаклары кипкән иде.

Асиягә дә шундый рәхәт булып китте: сагынган икән хатын әти-әниле, шау-шулы гаилә тормышын. Кара әле, бу картларның күңелләре нинди йомшак! Динә ахирәте менә ни өчен йомшак күңелле, юмарт булган икән. Әти-әнисеннән, нәселдән килгән итагатьлелек булган лабаса Динәдә. Ник шундый яхшы кешеләрнең гомерләрен кыска яраткан Ходай, белмәссең.

Тик иртәгә карт белән карчык ничек табарлар оныкларын? Кайгыларыннан сыгылып төшкәннәр, еларга гына торалар. Шәһәрне белмиләр, урысчалары да чамалы гына. Картларны йокларга салгач, ишек төбендәге кара телефоннан хезмәттәше Гөлсемгә шалтыратып хәлне аңлатып биргәч, тегесе сменасын алмаштырып торырга риза булды. Асиянең бу кешеләргә булышасы, ахирәтенең кызын – Айзадәне табасы килә, бу карт белән карчык, аның инде күптән вафат булган әти-әниләрен хәтерләтеп, күңеленә кереп урнашкан сыман булдылар.

* * *

Айзадә туңып уянып китте. Август киче шактый салкын, Аппак бер ягын җылытса, икенче яктан суык җил өрә. Кыз калтырана-калтырана, эт оясыннан чыкты да Хәят апасы белән үзләре генә белгән таш астыннан ачкычны табып алды. Ай яктысы шундый якты, караңгы күктә фонарь кебек янып тора. Йолдызлар җемелди. Алар шулкадәр күп, ләкин кызның аларны күрерлек хәле юк. Ул ачкычны йозакка туры китерә алмый азапланды. Аппак шыңшый-шыңшый, Айзадәнең аяк астында бөтерелде. Бакчада күп йортлар бушап калган – кайбер тәрәзәләрдә генә ут яна. Айзадә караңгыдан бик курка иде. Агачлар арасыннан әллә нинди куркыныч җанварлар, албастылар, җеннәр килеп чыгар, агачларның озын ботаклары, салкын җилдә чайкалып, менә-менә кызны тотып алырлар кебек. Әнә, өй кыегында нәрсәдер кыштырдый һәм чиный башлады. Кыз, кычкырып елап, стенага сыенды, күзләрен йомды. Кыштырдау туктагач, курка-курка гына күзләрен ачты. Ай яктысында өй кыегындагы оядан чыгып торган ике аерылы койрык очын күреп тынычланып китте. Үзенең карлыгачларын уяткан икән Айзадә! Кызның куркуы кимегәндәй булды һәм ул яңадан ачкычны йозакка кертергә тотынды. Ниһаять, ачкычны йозакка кертеп борып җибәргән иде, йозак ачылып китте.

Кыз сөенеченнән кычкырып җибәрде:

– Аппагым, булды, ачылды! Әйдә өйгә керәбез.

Аяк астында буталанган ач эт кыздан да алданрак өйгә атылып кереп, кухня өстәле тирәсендә бөтерелә, ашарга сорап сырпалана башлады. Өй эче кап-караңгы. Тәрәзәләргә такталар кадакланган. Ай яктысы, такта ярыкларыннан үтеп, сызык-сызык булып идәнгә төшкән. Бу тонык кына яктылык кыз баланың йөрәгенә оялаган шомны таратып, җанын җылытып җибәргәндәй булды. Кыз тиз генә Хәят апасы шырпы куя торган урыннан шәм табып алды, шырпы сызып, шәмнең каралып торган җебенә кабызды. Өйгә моңсу гына булып сыек яктылык таралды. Шәм мае, эреп, кулын пешерә башлагач, Айзадә шәмне стаканга бастырып куйды. Хуҗа хатын шәмнәрне күп итеп алып куйган, чөнки бакчаларында ут беткән вакытлар еш була иде.

Айзадә үзенең җылы кофтасын, чалбарын табып киде, кофта өстеннән Хәят апасының тузып беткән иске мамык шәлен япты. Калтыравы кимеде, эченә җылы кергәндәй булды. Инде әллә кайчаннан ашамаганлыгы исенә төште. Күкрәк астында нидер сулык-сулык итә. Аппак та ашарга сорап, аяк астында бутала. Айзадә ашамлыклар тора торган шкафтан консервалар табып алды, пычак белән ачмакчы булды. Ләкин бик тырышса да, ача алмады. Ипи куя торган савыт ачык калган. Анда таш булып каткан ярты ипи һәм башланган ак күмәч ята. Чәйнектә су да бар икән. Банкага тутырылган кайнатма табып алды. Ипине суда җебетеп ашый башлады. Эт, кызганыч чыелдап, кызның өстенә сикерде. Айзадә каткан күмәчне Аппакка бирде. Эт кабалана-кабалана, күмәч кимерә. Кыз, салкын суга кайнатма салып, җебетә-җебетә ипи ашый.

Тамаклары туйгач, караватка менеп, бер-берсенә сыенып яттылар. Этнең җылысын тоеп, юрган астында ятуы бик рәхәт иде кызга. Шәм уты дерелди-дерелди яна, күңеленә тынычлык иңдерә иде.

Кинәт Айзадә иртәгә беренче сентябрь икәнен, үзенең мәктәпкә бара алмавын, күрше кызының инде мәктәпкә барасы, дип, әниләре белән кайтып китүен исенә төшерде. Күзләренә тагын мөлдерәп яшь тулды, мендәрне чылатты.

– И әни җаным, никләргә генә мине ташлап киттең соң син! Мин сине өзелеп сагынам, әнием! Син киткәч, мине беркем дә «бәгырькәем, балакаем» дип, күкрәгенә кысып сөйми. Әти дә әллә нindigә әйләнде. Гел кычкырып кына тора. «Син яңа әниеңне тыңла», – ди. Мин бит, әни, бернинди начарлык эшләмим, шулай да гел ачуланалар. Әти Хәят апага да кычкырды. Шуннан Хәят апа минем өстемә ауды да үлеп китте. Ә ул мине ярата иде бит, әни! Җәй буе бергә яшәдек. Хәят апа миңа мәктәп формасы да алып бирмәкче иде, ләкин ул да синең янга китеп барды. Яраткан кешеләрем ник мине ташлап китәләр икән?! Әни, мин Сәйдә әбигә хат язган идем, килсә, аның белән Алансуга кайтып китәр идем. Ләкин ул да килми. Мин нишлим инде, әнием? Төннәр суык, монда кыш көне катып үләрмен инде. Коткар мине, әнием җаным, коткар!.. – Айзадә елый-елый йокыга талды...

Кыз Аппакның кымшануына уянып китте. Таң аткан, такта ярыкларыннан кергән яктылык өй эчен дә кояш нурларына күмгән иде. Ул нурлар өстәлдәге шакмаклы эскәтер өстенә, буялмаган идән такталарына тасма кебек сузылып төшкәннәр. Хәят апасының стенада эленеп торган карточкасы да яктырган, күз тирәләрендәге җыерчыклар гына ничектер моңсуланып тора.

«Кайгырма, Айзадә, үсәрсең, барысы да яхшы булыр. Мәктәптә үзеңә дуслар табарсың. Тик син тырышып укы! Синең яхшы укуыңны әниең дә ерактан күреп торыр. Ул да синең тәртипле, тырыш кыз булып үсүеңә шатланыр. Аллаһы Тәгалә тырыш кешегә генә бәхет ишекләрен ачып торырмын, дигән...»

Исән чакта күп тапкырлар кабатлаган бу сүзләрен Хәят апасы рәсемнән хәзер дә әйтә кебек.

– И-и Хәят апа! – дип авыр сулады кыз һәм, юрган астыннан чыгып, аяклары белән идәннән йомшак башмакларын эзләп тапты. Ап-ак җәймәдә Аппакның тәпиләреннән төшкән көрән тапларны күреп алды:

– Хәят апа булса, бирә иде кирәкне, – дип уйлап куйды.

Иртәнге салкынча һава чиркандырып җибәрде. Идәнгә басуга, кипкән идән такталары үзенә бер көйгә шыгырдадылар: әллә ыңгыраштылар, әллә елаштылар – кызчык аңламады. Кемдер аның колагына:

«Беренче сентябрь, беренче сентябрь, ә син өйдә, ә син өйдә!» дип пышылдый кебек. Яз башыннан ук өстенә көрән күлмәк киеп, ак алъяпкыч ябып, чәченә ак күбәләктәй бант бәйләп, яңа портфеленә китап-дәфтәрләрен салып, әтисенең көчле кулларына тотынып, мәктәпкә баруын ничек өзелеп көткән иде кыз! Ә бүген ул эте белән ялгызы бакчада. Айзадәнең күзләренә тагын яшь тулды. Эх, әнисе булса! Әнисе булсамы?! Гөлназ апа да, Ралинә дә булмаслар иде! Алинәсе булса да ярый, анысы әле Айзадә еласа, янына килеп чәчләреннән сыйпагандай итә. «Не плачь, пожалуйста, не плачь», – дип юата. Әнисе исән булса, Хәят апа да үлмәс иде, Айзадә дә бүген таң белән торып, күптәннән көткән уку көнен эт оясында каршыламас иде.

Кыз елап, көзге каршына килеп басты. Көзгедән аңа бодай саламы төсле аксыл чәчләре тузгыган, бите буйлап туктаусыз күз яшьләре агып торган нәни кызчык карап тора иде. Ул ни кылырга, нәрсә эшләргә белмичә, гаҗизләнүдән аптырап, комод янындагы артсыз урындыкка барып утырды. Үтереп ашыйсы килүдән, эче авырттырып сулкылдый, аяк арасында Аппак сырпалана. Әллә аның да ашарга сорап елавымы икән?

– И Аппагым, – диде кыз, – каян алыйм мин сиңа ашарга? Үзем дә ач бит, ипиебез дә бетте.

Айзадә шкафларны актарып карады һәм аннан дөге ярмасы, бераз макарон табып алды. Макаронны авызына кабып чәйнәп караган иде, ул таш кебек каты булып чыкты. Беразын Аппак алдына да салды. Тегесе койрыгын болгап, шатыр-шотыр макарон кимерә, үзе, әллә рәхмәт белдереп, әллә алдындагы макароннарны алмасыннар дип, кара күзләрен ялт-йолт уйната. Ап-ак йоннары көрәнсу төскә кергән – нәкъ аю баласы инде.

Айзадә кинәт тәрәзә шакылдаган тавышка башын күтәрсә – исе китте. Тәрәзә янына бер кош килгән. Теге кош бит бу: әнисен сагынганда, тәрәзәгә килеп куна торган, төшендәге кош! Әнә ул нәни кара күзләре белән Айзадәгә карап тора. Томшыгы белән каурыйларын тарап куйды. Шундый да матур, шундый да якын иде Айзадәнең йөрәгенә бу кош! Кояш нурларында яшькелт-зәңгәр каурыйлары төрле төсләргә кереп ялтырыйлар. Үзе нәни генә. Тәрәзәне шакый да күрәләрме икән, дигәндәй карап куя, аннан тагын шакый башлый.

Тукта, әллә әнисе кошка әйләнеп, кызын коткарырга кайтканмы? Шулайдыр! Ничек Казаннан ук килеп эзләп тапсын ул аны? Гади кош түгел, әнисе бу! Сәйдә әбисе әйткән иде бит: «Кызым, әниең йә күбәләккә әйләнеп, йә кош булып, сине күрергә кайтачак. Син, кызым, тәртипле бул. Әниеңне борчыма! Ул сине гомерең буена саклап, күзәтеп торыр», – дигән иде.

Менә бит иң авыр вакытта кызын эзләп тапкан әнисе!

– Нәни кошчыгым, бәгырькәем! – диде кыз, үзәге өзелеп. – Китмә, әни, китмә! Мин сиңа хәзер ярма салам, ашарсың. Миңа, син булгач, бик рәхәт, әнием, калчы,

зинһар. – Ул аякларына Хәят апасының кызыл эчле галушларын киеп, тәрәзәне ачты. Дөгене тәрәзәнең чыгыбрак торган, зәңгәргә буялып, инде төсе уңа башлаган тактасына салуы булды, кош куркып очып китте. Айзадә ишекне ачып чыгып, «Тукта, китмә!» дип кычкырып, кош артыннан йөгерде. Кош күршеләрнең карт алмагачына барып кунды. Кыз алмагач төбенә барып тезләнде. Күзләре тулы яшь, ә үзе бертуктаусыз:

– Әни, китмә, китмә, – дип тәкрарлый. Аның пышылдап диярлек әйткән сүзләре, әйләнеп, үзенә кайта сыман. – Китмә, әнием, китмә!

Ләкин кош тыңламады, пырылдап очып китте дә күздән югалды.

Айзадә акрын гына урыныннан торды. Үтереп ашыйсы килә. Җиргә, үләннәр өстенә алмалар коелган. Тирә-якка алма исе таралган. Кыз бер кызыл алманы алып, аны башта нәни куллары белән сөртте, аннан соң күлмәк итәгенә ышкыды. Алмага тешләрен батыруы булды, кызарып пешкән алмадан шунда ук татлы суты агып чыкты. Кыз ләззәтләнеп, күзләрен йомды. Айзадә үзенең артыннан килеп, еламсырап торган этенә дә алма бирде.

– Аша, Аппак, аша, бик тәмле.

Эт алманы иснәп тә карамады.

– Җүләр син, Аппак. Каткан макаронны ашадың, ә нинди тәмле алманы ашамыйсың! Җүләр түлке син.

Рәхәтләнде кыз алма ашап. Тамагы туйды.

Хәят апасының бакчасында быел ике төп алмагачы корыды.

– Хәерлегә булсын, – дигән иде Хәят апасы. – Көзгә яңаларын утыртырбыз, Аллаһы боерса.

Өлгерә алмады.

Айзадә күлмәк кесәсенә дә ике алма салды, кирәге чыгар әле.

Хәят апасының өенә әйләнеп кайтканда, инде көн җылынган, ялтырап торган чык тамчылары кипкән иде. Кыз бил турысына бәйләп куйган шәлен салып атты. Инде чалбарның да, җылы кофтаның да кирәге калмады кебек. Мунча кырыендагы су җыя торган мичкәдән, учы белән су алып, битен юасы итте. Әмма буе җитмәде. Ул Хәят апаның бакчада утырып эшли торган артсыз урындыгын алып килеп, шунда менеп басты. Мичкәгә зәңгәр күк белән кояш үзе төшеп чумган диярсең. Бер-ике сары яфрак та йөзә. Кызның кулы белән суга тиюе булды, кояш һәм болытлар да, зәңгәр күк тә әллә ничә кисәккә бүленеп юкка чыкты. Су салкын иде. Айзадә битенә нәни куллары белән су сипте. Бик рәхәт булып китте. Ләгән алып аякларын юды, әнисенеке шикелле чигә турысында бөдрәләнеп торган чәчләрен дә толымга үреп куйды. Пычранып беткән күлмәген салып, чиста ал күлмәген киде. Көзгегә карап алды. «Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк», – дияр иде Хәят апасы. Көзгедән җыйнаксыз, таушалып беткән күлмәкле кыз урынына зур зәңгәр күзле, керфекләре кашларына тия башлап, бөгелеп, күзләрен каймалаган, чөелеп торган кечкенә борынлы, уймак авызлы кыз карап тора. Тик күзләре генә сагышка төренгән.

– Уймак авызым, почык борыным, – дип сөяр иде аны әнисе. – Нәни кошчыгым минем! Күзләр генә тия күрмәсен. Сөбханалла, Аллаһы Тәгалә сиңа матурлыкны мул итеп биргән.

Тукта, теге кош алмагач ботагына тиккә генә кунмаган лабаса! Ул бит Айзадә алмагач янына килсен, алма ашасын өчен алып киткән кызны!

– Әнием, җаным! Ул кош – син бит! Мин беләм: син тагын килерсең. Тары ярмасы табасы иде, дөгене яратмадың, ахрысы.

* * *

Ун көн буе ятты Мансур хастаханәдә. Бер аягы һәм бер кулы тыңламый. Сөйләшүен аңлап булмый. Үрәмән хәтле ирнең хатынына нәрсәдер әйтәсе килә, әйтә генә алмый. Авызыннан «за-за» дигән әллә ниткән авазлар гына чыга, тик аңлашылмый. Авызына кашыклап шулпа сала Гөлназ. Анысы да, ирен кырыеннан агып чыгып, сакал-мыек баскан ияге буйлап муенына агып төшә.

– За-за-за... – Күкрәгенең әллә кайсы җиреннән актарылып чыга бу авазлар. Бер күзе ябык, ачык күзеннән туктаусыз яшь ага.

Гөлназ, зәгыйфь ирне карап туйды. Ачу китереп, өстенә сынарлык итеп крахмалланган, зәңгәрләнеп торган халат кигән шәфкать туташы:

– Апа, ирегезнең сакалларын нигә кырмыйсыз, бомж кебек ята, – дип әйтеп тора.

«Ун көн буена ир астын җыеп карасын әле. Миңа имгәк булып ята бит ул. Үзем дә җүләр – әллә кайчан пропискага кереп куймадым! Тагын машина кредиты түләргә кирәк. Бу имгәк белән нишләрмен? Машинаны банк алса, җәяүгә каласы. Ә фатир? Тагын тулай торакка кайтыргамы?» дигән уйлар борчыды Гөлназны.

Ю-у-ук! Ул анда мәңге кайтмаячак. Моңарчы бөтен эшен җиренә җиткереп куя торган иде бит. Беренче ирен «акча эшли белмисең» дип ташлап китте. Инде булды дигәндә генә, монысы тагын...

– Аза-за-за, – дип сузды ире, хатынны уйларыннан бүлдереп.

– Җитте инде, – диде хатын, – туйдырдың «за-за»ларың белән. – Ә үзе борчулы уйларына чумды.

Әллә кызының исемен әйтмәкче була инде?! Кара, истән дә чыккан ул кыз, кайда йөри икән соң? Теге убырлы врач хатын да катты, әйбәт булды әле. Һаман бөтен җиргә кысылып, үзәккә үтә иде. Җәй буе Айзадәне карады инде, анысы яхшы булды. Тукта, ул кыз беренче класска мәктәпкә барасы иде бит!

Кызлар да үзләре генә яшиләр. Ралинәсенә дәрт кергән инде, берәрсе белән ярамаган нәрсә кылып ятмасын тагын. Анысы югалып кала торганнардан түгел. Алинәсе генә атасына охшаган, җебегән нәрсә.

– Әни, ник Айзадә бездә тормый ул? – дип, үзәгенә үтте. Үзенә берәр нәрсә алсаң, Айзадәгә дә ник алмыйсыз, дип аптырата. Юк, монысыннан була торган түгел, Айзадәгә ярты җанын бүлеп бирер иде.

Беркөнне Гөлназны бөтенләй аптыраушта калдырды:

– Әни, әгәр син үлсәң, мин дә Айзадә кебек эт белән күршеләрдә торырмынмы? – ди.

– Ни өчен мин үләргә тиеш, ә? Нәрсә юрап утырасың? Ай тулган төндә теләкләр кабул булучан, юньсез нәрсә!

– Айзадәнең дә әнисе яшь булган. Ул үлгән бит.

– Җиттеме сиңа, юкмы! – дип акырып салды хатын. – Туктамасаң, бар, Айзадә янына эт оясына чыгып ят! Икегезгә күңеллерәк тә булыр.

Кыз акрын гына кузгалып торып китте. Ишек шыгырдаганы ишетелде. Акрын гына тәрәзә почмагыннан караса, кыз айга төбәлгән дә нәрсәдер пышылдый. Ай яктысы су кебек. Алинәнең яңагы буйлап аккан күз яшьләре кызның битендә зөбәрҗәт тамчылары кебек җемелдиләр.

Озак вакыт үтте, кыз кермәде. Айга карап, нидер сөйли дә сөйли. Гөлназ өстенә җылы кофта элеп, болдырга чыкты.

– Ник монда берүзең басып торасың?

– Әни, мин айга үземнең теләкләремне сөйләдем.

– Нәмәрсәләр турында сөйләдең инде син тулган айга?

– Мине әтием янына кайтар, әтием белән яшисем килә, дидем. Минем үз әтием – бик әйбәт кеше, мине сагына торгандыр, дидем. Айзадәгә әнисен кайтар. Әтисе Айзадәне дә яратсын. Минем әниемне үтермә, минем Айзадә кебек эт оясында яшисем килми, дидем.

Гөлназ кызын җилтерәтеп өйгә кертеп җибәрде.

– Бар, бүген үк атаң янына кайтып кит! Ике бозау яшәрсез шунда, ыштансызлар! Үз кадерегезне үзегез белмәгән нәрсәләр! Йә Хода, ничекләр генә гомер итәр бу бала?! Анасына бер грамм да охшамаган бит!

Гөлназ өйгә кергәндә, кызы елый-елый йоклап киткән иде, ара-тирә сулкылдап ала. Әйе, аттан ала да туа, кола да туа шул.

– Азә-зә, – дип өзгәләнде ир.

Гөлназ уйларыннан айнып китте. Ул арада күрше койкада ятучы ирнең хатыны иренең йомышын йомышлатты да Гөлназ янына килде.

– Син аңарга кәгазь белән каләм бир. Аның нидер әйтәсе килә. – Үзе шунда ук, китап өстенә дәфтәр бите куеп, ирнең кулына тоттырды. Мансур ярты биткә җитәрлек хәрефләр белән «Айзадә кайда?» дип, көч-хәл белән язды да аңын җуйды.

* * *

Галихан белән Сәйдә карчык иртән йокыдан уянганда, Асия кухня ягында нәрсәдер пешереп йөри иде. Йортка бәрәкәт иңдереп, коймак исе таралган. Хуҗабикәнең йөргәне дә сизелми, кунакларны уятырга теләми булса кирәк.

– Кызымның күршесе бигрәк тә мәрхәмәтле кеше икән, бәхете арткыры, – дип уйлап куйды карт.

Торып, акрын гына исәнләштеләр, тәһарәт алдылар.

Сәйдә карчык кыяр-кыймас кына Асия янына килде.

– Кызым, намаз укып алсак ачуланмассыңмы? Бераз ару тастымалың да булмасмы, дигән идек. Кичәге намазларыбыз да казага калды.

– И Сәйдә түти, укыгыз, өйгә дә дога керер. Минә үзем дә дога укырга өйрәнәм, мәчеткә абыстайга йөрим. Берегезгә намазлыгым да бар, берегезгә ару сөлге бирәм, – дип, тиз генә намаз укырга урын әзерләде Асия. Шкаф кырыендагы чөйдән һәрбер ташына «Аллаһ» дип язылган тәсбих алып, намазлык кырыена куйды.

Карт белән карчык аллы-артлы намазга бастылар. Галихан карт кулларын колак артына куеп азан әйтте. Тавышы моңлы иде Галиханның. Күкрәгенең төбеннән ургылып чыккан, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, рухын онытмаска өндәгән тавыш.

Кухня тәрәзәсеннән картларның намаз укыганын карап торды Асия. Ничек матур, тигез итеп картайганнар! Ул да шулай яшәп, тигез итеп картаеп, икәүләп намазлар укырбыз дип хыялланган иде бит, булмады... Еллар үткән саен, бу хыялы буй җитмәс якты йолдыз сыман ерагая бара аның.

«Хәерлегә булсын, – диде хатын тыныч кына. – Тик минә ялгызлык кына үзәгемә үтә. Ходай ялгызлыкны дошманыма да бирмәсен! Ичмасам, балам да юк бит. Үземә бер юаныч булыр иде...»

Картлар намазларын укып бетереп чыкканда, өстәл әзерләнгән, күпереп пешкән коймаклар, өстәл өстендә нәни кояшлар кебек ята, өрек, кара җимеш юып куелган. Күчтәнәчләрне дә тезеп куярга онытмаган Асия. Картларның күңеле күтәрелеп китте. Бар бит Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәтле бәндәләре, рәхмәт яугыры!

Картлар озак итеп дога кылдылар да акрын гына киенеп чыгып китәргә җыендылар.

– Туктагыз, – диде Асия. – Ничек тапмакчы буласыз Айзадәне? Адресын белмисез, урысчагыз да чамалы. Үзем озата барам. Мин сменамны алыштырдым. Ул тиз генә чәчәкле күлмәген, аның өстеннән күлмәге төсендәге кофтасын, аякларына үкчәсез туфлиен киде; кечкенә генә сумкасын кулына алды.

– Минем аларның Васильеводагы бакчаларына барганым бар иде. Әллә кая түгелдер Айзадә, күршеләре Хәят апада булырга тиеш. Бер тапкыр гына барганым бар, таба алсак ярый инде.

Сәйдә белән Галиханның башлары күккә тигәндәй булды.

– Рәхмәт төшкере, бәхетең арткыры!

Карт шомарып тузып беткән кара күн янчыгыннан акча чыгарып бирәсе итте.

– Кит, булмаганны! Сездән акча аламмы соң, Динә дустымның эти-әнисеннән! Рәнҗетмәгез мине, – дип, Асия картның кулын йомшак кына этеп җибәрде.

* * *

Аппак ашарга сорап шыңшыды да шыңшыды. Айзадә ризык куярдай барлык шкафларны карап бетерде, ләкин ашарга яраклы бернәрсә дә таба алмады. Шкаф төбендә чәчелеп калган ике токмачны эт кыз кулыннан өзәрлек итеп тартып алды, шатырдатып ашап та бетерде.

Консерваларны кулында тотып әйләндергәләп карады кыз, тик ачу чарасын таба алмады. Киштәдә зур пычак бар иде. Хәят апа аның төбен зәңгәр изолента белән чолгап куйган. Пычак очын банкага терәп, өстенә сугып карады Айзадә, банка ачылмады. Уч төпләре кызарып чыкты. Аннан соң, тукмак алып, шуның белән суккан иде, банка шуып китте дә аяк астында бөтерелгән Аппакның башына килеп төште. Эт шыңшып, иске суыткыч артына кереп посты. Бераздан тагын килеп, кызның аягына сырпалана башлады. Аптырады Айзадә. Күз алдына күрше Хәсән абыйның утын ярганы килде.

– Балта белән бәреп карыйк, ачылмасмы, – дип уйлады кыз.

Чолан почмагына сөяп куелган иске балта да табылды. Ул банканы бүкәнгә куеп, бар булган көченә балта белән китереп сукты. Банка яньчелде, Айзадә аңа тагын һәм тагын сукты. Ниһаять, банка кырыеннан майлы шулпа агып чыкты. Айзадә авызын тишеккә куеп шулпа суырды. Тәмле иде итле шулпа! Кызның авызына мул булып төкерек җыелды. Тагын бер китереп сугуы булды – банканың өстендәге түгәрәк калай кубып чыкты. Аппак тиз арада банкага ябышты. Үзе кабаланып ит консервасын ялый, үзе ялт-йолт кызга карап ала. Айзадә атылып киткән түгәрәк калайны җирдән күтәреп алды да тәмләп яланды. Кесәсендәге алмаларны алып ашап куйгач, тамагы туеп киткәндәй булды. Өстенә «Сайра» дип язылган банканы да ача алды кыз. Анысыннан бер кисәк балык алып калырга өлгерде, чөнки Аппак анысын да ялмап бетерде.

Эзләнә торгач, кыз шкаф эченнән полиэтилен капчыктан тары ярмасы да табып алды. И сөенде кыз, шундый сөенде. Хәзер ул ярманы теге матур кошка салып куяр, һәм ул көн дә килә башлар. Ә ярма шактый әле монда. Килсен генә, килә генә күрсен! Айзадәгә ул кошның килүе үзенә күрә бер тынычлык бирә, күңеленә чиксез рәхәтлек сала иде.

Әнә, карлыгачлар йортның кыегына тезелеп утырганнар да, башларын боргалап, Айзадәне күзәтәләр. Кояш кыздыра. Кыз, эчәсе килеп, чәйнектән су агызасы итте. Тик тышына мәк чәчәге төшкән, капкачының бер кырые кителгән чәйнек буш булып чыкты. Урамга чыгып, яңгыр суы җыелган чиләктән су эчте кыз, эте дә үрелгән иде, таш өстендә торган чиләк янтаеп түгелеп китте. Эткә шул су да җитте. Аннары Айзадә өйгә кереп, караватка барып ятты. Өй эче салкынча, рәхәт. Арыган иде кыз, керфекләренә йокы эленде һәм бик рәхәт булып бөтен тәненә таралды... Айзадә татлы йокыга талды.

Күпме йоклагандыр, уянганда, кояш инде сүрелә төшкән, бакчадагы агачларның күләгәләре озынайган иде.

Ә тәрәзә төбендә теге матур кош кыяфәтендәге «әнисе» тары ярмасы чүпли.

– Килгән, килгән! – диде кыз, куанып. Үзе, кошны куркытмас өчен юрган астыннан шуып кына чыкты да тәрәзә каршына килде.

– Килдеңме, әнием? Тик китмә, яме. Тиздән төн җитә, ә мин төннән, караңгыдан бик куркам. Син булсаң, миңа рәхәт, – диде кыз. – Әтием мине эзләп килер, өйгә алып кайтыр. Аннан соң Аппак белән икебезне Сәйдә әбиләремә кайтарып куяр. Син дә кайтырсың, кошчыгым-әнием! – дип, үзалдына сөйләнде Айзадә. Ул бу кошның әнисе булуына чын-чынлап ышанган, аның юкка чыгуын күз алдына да китерә алмый иде.

Кош тары ярмаларын чүпләп бетерде дә мунча почмагына кунды. Томшыгы белән озак итеп каурыйларын тарады. Аннары, эшем бетте дигәндәй, томшыгын каурый арасына тыгып тынып калды. Айзадә эте белән барып, карт алмагач төбеннән алмалар җыеп алып килде. Кош әле һаман урынында иде. Аннары кыз колонкадан су алып кайтырга булды. Чәчәкле чәйнек белән, үләннәре саргая башлаган сукмак буйлап суга китте. Әмма кире борылып килеп, өй ишеген йозакка бикләп куясы итте. Кем белә, карак-мазар килеп чыкмасын.

Чәйнеккә көмештәй су тулгач, кайтырга чыкты Айзадә. Аяк астында Аппак та бөтерелә. Кыз җилкапканы ачып җибәрүгә, теге кошчык куркып очып китте. Айзадә чәйнеген ташлап, аның артыннан йөгерде. Аппак шыңшып, аңа иярде. Кошчык бераз оча да агач ботагына кунып ял итә. Кыз килеп җитәм дигәндә генә, тагын очып китә. Шулай юлга кадәр бардылар да, кошчык урманга таба очып китте һәм бер ноктага әйләнеп юкка чыкты. Айзадә елап җибәрде.

– Тагын китте, мине ташлап китте, – дип өзгәләнде ул.

* * *

Асия картлар белән Айзадәләр бакчасына килеп җиткәндә, инде төш җиткән, көннең кызуы сүрелә башлаган иде. Асия теге юлы Динәләр бакчасына машина белән килгән иде. Юл буе төрле хәлләр турында сөйләшеп, көлешә-көлешә килеп, нинди юлдан барганнары да хәтерендә калмаган. Шулай да эзләп таптылар алар бакчаны.

Асия Хәят апаның бакчасына керде. Тәрәзәләргә аркылы такталар кадакланган. Үләннәр арасында иске чәйнек аунап ята. Йортның ишегенә зур йозак эленгән. Кишәрлекне чүп-үлән, алабута, сарут басып киткән, ташландык бакча кебек.

Ул тәрәзәгә кадакланган такталарны каерып карады. Ләкин нык итеп кадакланганнар, бирешмәделәр. Кер элә торган бауда ике карлыгач утыра иде, алар куркып очып киттеләр дә өй почмагына барып кундылар.

Асия Хәят апаның бакчасыннан чыкканда, картлар арып-талып, аллеядагы бер бүкәндә утырып торалар иде. Галихан карт, кәләпүшен салып, тирләгән битен җилләтә. Ялтырап торган баш түбәсе тирләп чыккан. Үзе, гаҗизләнеп, Асиянең күзләренә карый.

– Юк, – диде Асия, – анда да юк. Тәрәзәләренә нигәдер такталар кадакланган. Милициягә хәбәр итәргә кирәк, шуннан башка булмас. Якын-тирәдә кеше дә күренми. Әйдәгез, бакча каравылчысыннан белешик әле, монда милиция бүлеге кайда икән?

Бакча каравылчысы аларга кая барырга кирәклеген өйрәтеп җибәрде.

* * *

Мансурны реанимациягә кертеп салдылар.

– Хәле авыр, исән калуы икеле, – диде табибә. Ул Мансурның кырынмаган, сакал-мыек баскан йөзен күреп, шәфкать туташын чакырды да, санитарлар авыруны кеше кыяфәтенә китерсеннәр, диде. Үзе авыр күз карашын Гөлназга ташлап:

– Андый-мондый хәл була калса, хатынына оят булыр, – дип өстәп куйды. – Ә сез кайтып китегез. Телефон номерыгызны реанимациядә эшләүче сестраларга калдырыгыз. Нәрсә булса да хәбәр итәрләр.

Тавышы бик коры иде табибәнең.

Гөлназ ашыгып, ишеккә юнәлде. Аның тизрәк бу бинадан чыгып китәсе, саф һава сулыйсы, кызларын кайтып кочасы, ниһаять, рәхәтләнеп үз урынына ятып йоклыйсы килә иде.

Туйды да соң бу «төрмәдән»! Инде нәрсә булса – шул.

Үзенең башында һаман бер уй: вакытында пропискага керә алмый калды – шунысы үкенеч. Әле теге имгәге кайтып керер, анысын әбиләренә озатырга кирәк булыр. Монда ике имгәк асрап булмас, фатир дип.

Шулай уйлана-уйлана, өйләренә кайтып керде Гөлназ.

Өйдә Алинә генә иде. Суыткычлары буш, ашарга юньле ризык юк. Мәет чыккан йорт кебек моңсу-ямансу.

– Әни! – дип килеп сарылды аңа Алинә. – Бөтенләйгә кайттыңмы? Мансур абый кайда? Айзадә кайда?

«Айзадә» исемен ишетүгә кабынып китте хатын:

– Каян белим мин аның кайда икәнен! Кайтыр, катмагандыр әле. Катса да, мин бәреп үтермәдем. Бәлки, әбиләренә озатканнардыр.

Алинә әнисенә аптырап карап торды.

– Чәй эчәсеңме?

– Юк, – диде хатын, – эчмим, туйдым, гарык булдым! Беркемне дә күрәсем килми. Бәхетең бер булмаса, булмый икән инде. Менә бу фатирдан да куып чыгарулары бар. Чыгарырлар да, бер акыллысы табылса. Хәер, авылдагы әби-бабасының башы җитмәс.

Кинәт ишектәге звонок төймәсенә озак итеп басып шалтыраттылар. Гөлназ, Ралинә кайткандыр дип, ишеккә килде. Ишек күзеннән караса, полиция киемендә ике ир кеше басып тора.

– Мансур Сабировлар квартирасымы? Сез кем буласыз? Хуҗа кайда?

Гөлназ бу кадәр сорауларга берьюлы җавап бирә алмыйча аптырап калды.

– Мансур Сабиров больницада. Мин, мин... – дип тотлыгып калды ул, – аның белән язылышмаган, яшәү урынына теркәлмәгән. Кем дип әйтергә инде?.. Мин – аның гражданский хатыны.

– Паспортыгызны бирегез!

Хатын каушавыннан паспортын таба алмый аптырады. Алинә китереп бирде, шкафта икән. Хастаханәдән кайткач, шунда куйган булган.

Кара чәчле, шадра йөзле полиция хезмәткәре паспортны бик җентекләп тикшерде дә кире кайтарып бирде.

– Сез Айзадә Сабирова исемле кызны беләсезме? Ул сезгә кем була? Соңгы тапкыр аны кайчан күрдегез? Нинди киемнән иде?

Гөлназның башына суктылармыни?! Аның башыннан яшен тизлегендә «Әллә үлгәнме? Үлгән булса, миңа сылтап, төрмәгә ябып куйсалар» дигән уйлар узып китте.

– Минем үги кызым ул. Соңгы тапкыр кайчан күргәнемне һәм өстендәге киемен хәтерләмим.

Полицейскийлар бер-берсенә карап куйды. Ничек инде ул җиде яшьлек баланың кайда йөргәнен хәтерләми?

Гөлназ аңлатып бирергә тырышты:

– Ул күбесенчә бездә түгел, эте белән күрше Хәят апада яшәде, – диде хатын.

– Нинди күрше, нинди эт?

– Ул үлде инде.

– Кем үлде?

– Хәят апа.

– Фамилиясе ничек?

– Белмим.

Хокук сакчылары Гөлназның паспортын сорап алдылар.

– Киенегез! Сез безнең белән полиция участогына барасыз.

– Нигә?

– Там разберутся.

– Не поеду, – диде хатын, – не я убивала, не я, – дип бәргәләнде.

– Она что мертва? Где труп? – диде икенче хокук сакчысы.

Гөлназны алып чыга алмыйча азапландылар. Ниһаять, икәүләшеп, хатынның ике кулыннан тотып, ишеккә юнәлделәр. Алинә елап, әнисенә ташланды.

– Ишегеңне бикләп кал, – диде татар полицейские, Алинәне читкә этәреп. – Белмәгән кешегә ачма.

* * *

Айзадә акрын гына урыныннан кузгалды. Кояш моңсуланып баюга таба бара. Инде көз сулышы кагылган агачлар кичке шәфәкъ утларында кызгылт-сары төскә кереп яналар, акрын гына искән җилдә чайкалалар. Сукмакларда төрле төстәге яфраклар. Әнә, йомшак койрыклы тиен каен агачы кәүсәсенә үрмәли һәм ботакка басып, Айзадәне күзәтә.

Айзадә беренче тапкыр тиенне зоопаркта күрде. Әнисе тиеннәр турында күп сөйләде аңа. Алар бик тырышлар һәм уңганнар икән. Кышка чикләвек әзерлиләр һәм аны агач куышына яшереп куялар. Чөнки җирне кар каплагач, азык табу читенләшә аларга.

Айзадәнең кыш көне салкын бакчада калачагы күз алдына килде, җир өстен каплап алган калын кар катламы, ахырда инде карт алмагач астындагы алмалар да калын кар астында калыр. Күзләренә яшь тулды. Ул кыш суыгын сизгәндәй, эченә салкын йөгергәнен, суыкның җилкәсеннән һәм күкрәгеннән аякларына таба шуышуын сизде.

«Әни! – диде кыз, – мин монда, кыш көне туңып үләрмен инде. Мине дә күмеп куярлар. Җир астында салкын һәм караңгыдыр. Әтием дә һаман килми дә килми». Кайчандыр Сәйдә әбисе сөйләгән «Үги кыз» әкияте Айзадәнең исенә төште. Ул кызны да урманга илтеп адаштырганнар, һәм ул да Айзадә кебек кая барырга белмичә тилмереп йөргән. Ләкин аны коткарганнар бит. Айзадәне дә әтисе килеп коткарыр әле.

Көн җылы булса да, кыз калтыранып куйды.

Аппак акрын гына аның янәшәсеннән атлап бара. Юл кырыенда берәр нәрсә кыштырдаса, һау-һаулап, үләннәр арасына кереп югала да тагын килеп чыга. Үзе кызның аяк арасында чуала, бөтерелә.

Кош артыннан йөгергәндә, Айзадәнең бер артсыз башмагы төшеп калды, икенчесен үзе ташлап калдырды. Тузанлы юлда нәни тәпи эзләре кала. Бала аяк эзләре белән янәшә, бер күренеп, бер югалып, дөньядагы иң якын дүрт аяклы дустының эзләре дә ияреп бара.

Көн кичкә авышты, салкынайтты. Тизрәк кайтып җитәсе, Хәят апасының идәннәре җырлап торган йортына кереп, җылы киемнәрен киеп, иске шәлгә төренеп, юрган астына чумып ятасы килде кызның. Чөнки әллә нинди зәһәр салкын эченә кереп урнашты да чыкмый да чыкмый. Йөгерергә дә хәле юк.

Ниһаять, кайтып җиттеләр. Аппак ашарга сорап шыңшый башлады. Ә Айзадәнең күңелендә бер генә уй: баш-башлары ак шарлы караватка ятып, юрган астына кереп җылынырга! Ашыйсы килүе дә сүрелде, әмма эчәсе бик килә иде. Ул яңгыр суы җыелып торган мичкә янына килде. Теге юлы үзе алып килгән артсыз урындыкка менеп басты. Аннары мичкәдә йөзеп йөргән сары яфракларны куллары белән этеп җибәрде дә йотлыга-йотлыга, сасый башлаган суны эчте. Эчеп туйгач, аяк астында әвәрәләнгән эткә дә игътибар итмичә, өй ишегенә таба юнәлде. Кулын кесәсенә тыкса, ачкыч юк... Нәни бармаклары, кесә төбендәге тишектән чыгып, кызның аңкы-миңке килеп карангалап торган күз алдында эреп юкка чыктылар. Кыз ару-талудан алпан-тилпән атлап, эт оясына юнәлде. Ояга шуышып керде дә эт йоны түшәлгән һәм эт исе аңкып торган иске паласка ятып, күзләрен йомды.

Аппак шыңшып, оя тирәсендә йөреп караса да, кыз чыкмады. Әллә файда югын аңлап, әллә үзе дә көне буе чабып арган иде, кысыла-кысыла оясына кереп, Айзадәгә сыенып ятты. Ике ятим, ике кыерсытылган, кимсетелгән җан иясе, бер-берсенә иптәш һәм терәк булып, аннан-моннан гына каккалап куелган эт оясында сыенышып яттылар.

* * *

Полиция бүлегендә озак тоттылар Гөлназны.

– Кызны кая куйдыгыз, ничек үтердегез? – дип сорау алды тикшерүче.

– Мин үтермәдем, җәй буена мин аны юньләп күрмәдем дә.

– Алайса үлгәнен каян беләсез? Үзегез, мин үтермәдем, дип әйттегез бит.

– Мин күрше хатыны – карт колдун турында әйттем.

– Җәй көне кыз кайда торды?

– Соң, эте белән күршеләрдә яшәделәр, дип әйттем бит инде.

– Үз кызларыгыз кайда торды?

– Бәй, үзем белән, минем кызлар бит инде алар.

– Ә Айзадә сезнең кыз түгелмени?

– Юк, ул – иремнең кызы.

– Ничек инде сез яңа гына җиде яшен тутырган баланы җәй буе күрмәдегез?

– Күрше хатынында яшәде, дип әйттем бит инде.

– Сез аны үлде, дидегез, үз сүзегезгә үзегез каршы киләсез түгелме?

Тәмам башын әйләндерделәр Гөлназның. Баштагы чаялыгы һәм елгырлыгы каядыр китеп югалды.

– Ә кыз күршеләрдә яшәгәндә, ирең кайда иде?

– Ул зур машинада дальнякка йөри иде. Атна-ун көн буе рейста, җәй буе юньләп өйдә торганы булмады.

– Ә бала? Күрше хатын үлгәч, аны кем карады?

– Ул соңыннан гына үлде, ирем кайткач кына.

– Хәзергә ирегез сорау алырлык хәлдә түгел. Хәлне ачыклаганчы, сезгә монда калырга туры килер.

– Ничек монда, төрмәдәме? Сез үз акылыгыздамы?– дип кычкырып, утырган җиреннән сикереп торды Гөлназ, аннары елап җибәрде.

– Утырыгыз! Бәлки, акылыгызга килеп, дөресен сөйләп бирерсез? Безгә бу чуалган йомгакны сүтәргә, баланы табарга кирәк. Ә әлегә...

Гөлназны сорау алу бүлмәсеннән алып китеп, читлеккә ябып куйдылар.

Кычкырып елады хатын. Больница төрмә түгел, чын төрмә шушы була икән. Бер гөнаһсыз ирен ай буе, ялганлап, төрмәдә тотуы исенә төште. Әллә шуның рәнҗеше төште инде?

* * *

Асия арып-талып соң гына өенә кайтып җитте. Тиз генә капкалап алдылар. Картлар ахшам намазына утыруга, күршеләренең ишегенә шалтыратты Асия. Ишек аркылы кыз бала тавышы ишетелде:

– Кто там?

– Кызым, ач әле, бу – күрше апаң Асия. Айзадәнең әбисе белән бабасы килделәр. Әниең өйдәме?

Кыз ишек «күзе»ннән карап, күрше хатынны танып алды да ишекне ачты, һәм:

– Маму полицейские забрали, а Айзадә пропала, – дип елап җибәрде.

– Син Айзадәне кайчан күрдең соң? Җәй буе бакчада бергә тордыгыз түгелме?

– Нет, она жила у соседки. Вместе с ней ещё собака Аппак была. Хаят апа умерла, – диде кыз һәм тагын да катырак итеп елый башлады. – Айзаду жалко, она умерла, наверное, они с собакой в будке жили.

Айсылу бу ябык кыз баланы кочагына алды. Кызчык оясыннан егылып төшкән нәни кош баласы кебек калтырый иде. Асия үзенең дә күзенә яшь тулганын сизде.

– Мин әтием янына барыйм, – диде кыз.

– Ул больницада бит.

– Юк, мин үз әтием янына...

– Әниең бар ич.

– Әнием дә әйбәт, тик минем үз әтием янында яшисем килә.

– Ә кайда яши соң ул?

– Общежитиедә.

– Бара беләсеңме?

– Әйе.

– Әйдә алайса, мин сине озатып куям.

Кыз ишекне бикләде дә, өстенә җиңел генә кофта киеп, Асия артыннан иярде...

Алар 6 нчы трамвайга утырып, Алинәнең әтисен эзләп киттеләр. Трамвай шактый озак барды. Асия дә, кыз да сөйләшмичә утырдылар. Соңгы тукталышка җиткәч, кыз җанланып китеп:

– Менә монда, – диде.

Тулай торак ишеген ачып керүгә, борынга пешкән кәбестә, балык һәм тагын әллә нәрсә исләре килеп бәрелде. Ишектән чыккан җыйнак кына гәүдәле, ак йөзле ир кызны шунда ук кочаклап алды:

– Кызым, кызым, кайттыңмы? Бик сагындым сине, сагындым, – дип тезеп китте ул.

Ә кызы әтисенең кочагында эреп, аңа сеңеп беткәндәй булды.

– Әтием минем!

Тулай торакның ишегеннән чыкканда, Асиянең күзләре яшь белән тулган иде. Ата-ана белән бала арасында башка берни белән дә чагыштырып булмый торган бәйләнеш – мәхәббәт бар. Ә Асиягә аны татырга язмаган, Ходай аннан бу бәхетне кызганган.

«Йә Раббым, ни гөнаһларым өчен мине ялгыз яшәргә хөкем иттең? – дип уйлады ул. – Нарасый Алинәне әтисеннән аергансың, аның нинди гөнаһысы бар? Әтисе кызыннан аерылган, начар кешегә дә охшамаган бит».

Аңламассың бу кешеләрне! Мансур белән Динә ничек пар килгәннәр иде! Айзадәне җитәкләп чыгып киткәндә, Асиянең алар артыннан көнләшеп карап калган чаклары да күп булды. Кызлары чыркылдап көлеп, йә әтисенең, йә әнисенең кулына ябышып, әллә ниләр сөйләнеп сикергәли. Әтисе, көчле куллары белән аны күтәреп алып, җилкәсенә утырта.

Аларның да тормышы чәлпәрәмә килде. Мансур аягына баса алырмы, Айзадә табылырмы? Кайгыларыннан башлары әйләнгән карт белән карчык нәрсә эшләрләр?..

Кичә генә автовокзалда билет сатып, үз көенә яшәп яткан Асиянең дә тормышы шул көннән бөтенләй икенче якка борылып китте. Күңелендә үзенә бер ятимне асрамага алып, үзен дә, назга сусаган баланы да бәхетле итү теләге уянды.

Асия кайтып кергәндә, картлар диванда аны көтеп утыралар иде. Алар өсләренә ишелеп төшкән кайгыдан әйтерсең кечерәеп калганнар. Карт белән карчык шунда ук сораулы күзләрен Асиягә текәделәр, ләкин Асия аларны тынычландырырлык сүз таба алмады.

* * *

Мансур аңына килмәде. Икенче кабат инсульттан соң ике атна буе аңсыз ятты да, Айзадәне дөм ятим калдырып, бакыйлыкка күчте. Табиблар, аның гәүдәсен моргка күчергәннән соң, кемгә хәбәр итәргә белмичә аптырадылар. Күптән түгел генә кырык яшен тутырган ир, кызын ташлап, тормыш дәрьясында берүзен калдырып, бу дөньядан китеп барды.

* * *

Гөлназны милиция бүлегеннән чыгармадылар. Ул елап та, үтенеп тә карады. Ләкин Айзаданең югалуы турындагы эшне алып баручы җирән чәчле капитан Гөлназдан көн саен сорау алды, аның моң-зарларына игътибар итмәде. Капитанның җиде яшьлек баланың җәй буе кайда йөргәнен, ашаганмы-юкмы икәнлеген дә белмәгән бу хатынга нәфрәте шулкадәр көчле иде ки, хәленнән килсә, ул аны өзгәләп атарга да әзер иде. Көн дә бер үк сораулар:

– Бала кайда? Аны ничек үтердегез? Ул кыз сезгә комачауладымы? Фатир кирәк булдымы? Әтисе нигә тәрбияләмәде? Нигә ул баланы Беренче сентябрьдә мәктәпкә алып бармадыгыз?

Көннәр узган саен, Гөлназ күбрәк буталды. Аның янына ике фахишә хатынны ябып куйдылар. Хокук сакчыларының хәтта ул җилбәзәкләргә дә мөнәсәбәтләре яхшырак иде. Гөлназның горурлыгы юып алган шикелле юкка чыкты. Ул мескен кыяфәткә керде. Бу хәлгә төшүенең сәбәбен аңлый алмый аптырады. Янып торган күзләре сүнде, күп ирләрне үзенә каратырлык йөзе сулды. Ләкин күңелендә Мансурга да, Айзадәгә дә бер генә мыскал да кызгану хисе уянмады. Аны башка уйлар борчыды: вакытында Мансур белән никахны рәсмиләштереп өлгерә алмады, ә бу аны фатирсыз калдырачак. Бары шундый уй гына йөрәген талады. Тагын тормыш итә белмәгән, бозауга тиң беренче ире янына кайтып утырыргамы? Ул Гөлназны гафу итәр, билгеле. Тик гаиләгә бер тиен дә алып кайтмаган, ыштан туздырып, гел китаплары белән мәш килгән ир аңа нәрсәгә кирәк? «Акчаны кая куйдың?» – дип сорамый, нәрсә пешерсәң, шуны ашый. Балаларны мәктәпкә һәм балалар бакчасына йөртә иде үзе. Тик «өйдә татарча сөйләшегез, марҗа түгел бит сез» дип аптырата иде. Нәрсәгә кирәктер инде кызларга татарча сөйләшү?

Гөлназга уч тутырып акча таба торган, гаилә дилбегәсен кулында нык тоткан, янып торган ир кирәк булды.

Мансур менә чын ир иде ичмасам. Гөлназның кайнар кочагында эреде дә бетте. Кызын да сирәк кенә исенә төшерә, ерак рейсларга йөри башлагач, атна-ун көне юлда үтә иде. Рейстан шулкадәр сагынып кайта иде, сүз белән әйтеп бетергесез! Ләкин бәхете бик кыска, эт кояшы кадәр генә булып чыкты Гөлназның.

Айзадә кайларда йөридер? Әбиләрендә булса, милиция белер иде. Ходаем, үлә генә күрмәсен, юкса гомер буе төрмәдә черетерләр.

Борчулы уйларына чумып, соры юрган ябынып йокларга ятты хатын. Йокыга куерып барганда, сары чәчле озын аяклы фахишә аның артына китереп типте:

– Бар, ишек янына барып ят, бу – минем урын! Здесь я главная!

Гөлназ дәшми-тынмый гына, ишек янындагы урынга күчеп ятты. Чарасызлыктан нәрсә эшләргә белмичә, үксеп елап җибәрде.

– Заткнись, чувиха, или своё получишь! – дип акырдылар уң яктагы ятактан.

* * *

Аппак Айзадәнең битен ялап, аны йөнтәс гәүдәсе белән төрткәләп уятмакчы итте. Ләкин кыз ыңгыраша, бер утта яна, бер салкыннан калтыранып ята иде. Вакыт-вакыт, саташып:

– Әнием, әнием, – дип пышылдап куя.

Бакча кишәрлеге яныннан кешеләр сөйләшкән тавышлар ишетелде: бакча каравылчысы кем беләндер су алырга бара икән. Аппак оясыннан атылып чыкты да, шыңшып, аларның аякларына килеп уралды. Аннан соң оясына таба йөгерде, яңадан килде, тагын борылып китте, гүя нидер әйтергә тели һәм кешеләрне үз артыннан барырга өнди иде кебек.

– Нигәдер өзгәләнә бу көчек, ташлап киткәннәрдер, мөгаен. Нинди юньсез бу кешеләр, этләрне, мәчеләрне ияләштерәләр дә көз җиткәч ташлап калдыралар. Аннан кыш буе нәрсә эшләргә белми аптырый бу җан ияләре, күбесе язга кадәр исән дә калмый. Әйдә минем белән, бигрәк тә ак аюга охшаган матур эт икәнсең, дип, бакча каравылчысы Идрис карт сызгырып куйды һәм Аппакны үзе белән барырга чакырды. Эт койрыгын болгап, картка иярде. Каравылчы йортына килеп җиткәч, Идрис, калган ашка ипи турап, эт алдына китереп куйды. Аппак ашыга-кабалана, ашны ашап бетерде

дә Идриснең күзенә карап, шыңшып өрә башлады. Аннан соң Хәят апалар йортына таба йөгерде. Артына борылып карап, Идриснең килмәгәнен күргәч, яңадан кире килде. Шулай берничә мәртәбә кабатлангач, Идрис аксый-аксый, эт артыннан иярде.

«Этләр акыллы була, моның миңа нәрсәдер күрсәтәсе килә, ахры», – дип уйлады карт. Аппак бер алга, бер артка чапты һәм шулай итеп Идрисне үзенең оясына кадәр алып килде. Аннары шомырттай кара күзләрен тутырып картка карады да кинәт тукталып калды.

Эт оясыннан тузанга баткан кеп-кечкенә ялан тәпи чыгып тора, вакыт-вакыт акрын гына ыңгырашкан тавыш та ишетелә.

– Әстәгъфирулла! – дип катып калды карт. – Бу ни бу? Бала ич бу! – Эт оясының эченә үрелеп караса: кыз бала ята. Идрис карт көч-хәл белән аңсыз баланы оядан чыгарды да күтәреп, үзенә алып китте. Эт аңа иярде.

Баланың тәне ут кебек яна, куллары салынып төшкән. Картның йөрәген тимер кыршау белән кысып алдылармыни?! Менә сиңа Маугли! Бу бала нигә монда? Сабый гына лабаса!

– Хәзер, кызым, хәзер ашыгыч ярдәм чакыртам, – диде карт.

Ул баланы юрганга төрде дә кызулап, ашыгыч ярдәм чакырырга чыгып китте. Аппак үксез дустының аяк астына сузылып ятты. Этнең күзләре дә, Айзадәне кызганудан сагышланып, утлы күмер булып көйриләр иде.

* * *

Айзадәне эзләргә милиция хезмәткәрләре өйрәтелгән эт белән чыктылар. Тирә-юньдәге урманнарны айкадылар, барлык бакчаларны тикшерделәр. Айзадәнең өйләреннән бер күлмәген алып, аны эткә иснәттеләр, ләкин эт эзне таба алмады. Тирә-юньдә «Айзадә! Айзадә!» дип кычкырган тавышлар яңгырап торды. Кыз табылмады. Көн кичкә авышып, караңгы төшәр алдыннан эт кызның төшеп калган башмагын табып алды. Артсыз сыңар башмак юл чатында, тузан эчендә аунап ята иде...

* * *

...Айзадә хастаханәдә аңына килде. Яп-якты бүлмә. Янында елый-елый шешенеп беткән Сәйдә әбисе утыра. Оныгының күзләрен ачканын күреп, ул кызчыкның битләреннән үбә башлады һәм:

– Балакаем, бәгырькәем, уяндың бит, уяндың! Әмма куркыттың да соң безне, – дип тәкрарлады.

Айзадә әбисенә карады: карчык кечерәеп, бөрешеп калган...

– Әбием, син китмә, – диде кыз, – мине калдырма. Әтием кайда? Аппак кайда? – Ул бутала-бутала сөйләнде дә тагын йоклап китте.

Табиблар, кызга салкын тигән, нервлары какшаган, нәрсәдер ашап агуланган, дип әйттеләр. Сәйдә әби Айзадәне сакларга калды. Асия апасы көн саен тәмле-тәмле ризыклар алып килде. Ә менә әтисенең үлеме турында кызга әлегә әйтмәскә булдылар. Кыз әтисен таптырды, Аппакны алып килүләрен сорап аптыратып бетерде.

– Асия апа, этне барып алып кил инде. Авылга бергә кайтып китәр идек. Миннән башка нишләр ул анда? Ул ач, алма да ашамады. Үләр ич минем Аппагым! Алып кайт инде, Асия апа!

Асия аптырап калды: бик нык үзгәләнә бу бала. Әбисе, бабасы ни әйтерләр? Айзадәне ай буе әбисе белән чиратлашып караганга, Асия кыз белән дуслашып та өлгергән иде. Динә ахирәтенең кызы аңа үз кызы кебек якын. Бу балага әнисе бирә алмаган бөтен назын, яратуын бирәсе килде аның. Кыздан аерылу көнен үзәге өзелердәй булып куркып-борчылып көтә иде ул.

– Ярар, Айзадә, мин иртәгә синең этеңне эзләп карармын. Әллә кая китмәгәндер. Ул Идрис агай янында булырга тиеш, бер дә кайгырма, – дип, кызчыкны кочагына алды. Бала Асиянең куенына сеңде. Апасы аның битеннән, чәчләреннән үпте.

– Бер дә кайгырма, – дип кабатлады тагын бер тапкыр Асия, – барысы да яхшы булыр.

Айзадәне хастаханәдән чыгарырга бер көн калгач, Асия Сәйдә әби белән сөйләшеп карарга булды.

– Сәйдә апа, – дип башлады ул сүзен, – ачуланмасаң, сиңа бер сүзем бар иде. Айзадә кышка миндә калса, ничек булыр икән? Сез инде олы кешеләр, мәктәбегез дә ерак, дисез. Мин аңа дустым Динә урынына әнисе кебек булырга тырышырмын. Җәйгә сезгә кайтып торыр иде. Галихан бабай белән сине мин әнием-әтием урынына күрәм бит.

Сәйдә карчык аптырап калды, чөнки бу сөйләшүгә ул әзер түгел иде. Дөрес, шактый вакыт инде аның башында үзәген өзеп бер уй әйләнә: без үлеп китсәк, бу бала дөньялыкта берүзе кала – ничек яшәр?

– Белмим шул, Асия, үзем дә сиңа нык ияләштем, Динәмне күргәндәй булдым. Ләкин Галихан бабаң белән сөйләшмичә, сиңа җавап бирә алмам, – дип, хатынга өметләнергә урын калдырды.

– Мин бүген кызның этен эзләп табармын. Аппагым, дип, бик өзгәләнә. Иртәгә авылыгызга алып кайтып китәр идегез.

Карчык дәшмәде. Карты ни әйтер? Ул гомер буе ире сүзеннән чыкмый яшәде. Хәзер дә эт ияртеп кайту турында Галихан нәрсә әйтер, дип борчылып куйды.

Айзадә хастаханәдән чыккан көнне үк Асия аңа кыз күптән көткән көрән төстәге йон күлмәк белән ак алъяпкыч, аллы-гөлле чәчәкләр төшерелгән портфель, китап-дәфтәрләр һәм тагын беренче класс өчен кирәк булган әллә ниләр сатып алды. Айзаданең шатлыгы чиксез иде. Тыны-көне бетеп, сөенде ул. Аннары:

– Бик рәхмәт сиңа, Асия апа, – дип, апасын кочаклап үпте.

Кыз сөенеченнән нәрсә эшләргә белмәсә, Асия соңлап килгән бәхетенә куана иде.

Тик... Әтисенең үлеме турында бу кызчыкка ничек әйтергә? Күңел яралары да яңа гына җөйләнә башлады бит аның. Шулай да Асиянең яңа тормышны ялганнан башлыйсы килмәде. Ул Айзадәгә әтисенең күккә, әнисе янына киткәнлеген, аннан кызын яклап-саклап торачагын әйтте. Бер ел эчендә үги әнисе Гөлназдан гына түгел, үз әтисеннән дә бер авыз җылы сүз ишетмәгән кызчык Асияне кочаклап елап җибәрде...

Иртәгесен Айзадә, әбисе һәм Асия апасының кулларына тотынып, октябрь башында беренче класска укырга китте.

Икенче көнне Сәйдә әби Аппакны алып, Алансуга кайтып төште. Борчылуы юкка булган икән. Галихан бабай этне күрү белән:

– Каян алдың бу аю баласын? – дип, төксе генә сораса да, Аппакның оныгы Айзадә эте булуын белгәч, оя ясарга дип, остаханәсенә юнәлде.

* * *

Асия күршеләрнең ишеген шакыды. Исәбе  кызның көзге киемнәрен алып, фатирның язмышын ачыклау иде. Ишекне Гөлназ ачты.

– Миңа Айзаданең киемнәре кирәк. Көз керде, тышта хәзер салкын.

– Сиңа нәрсәгә аның киемнәре?

– Айзадә миндә яшәр, бабасы һәм әбисе шулай хәл иттеләр.

– Мин аның, үги булсам да, әнисе, нигә синдә яшәргә тиеш әле ул? Фатиры кирәк булдымы? Шуңа күтләкләнәсеңме?!

– Минем фатирым бар. Айзадә үсеп җиткәч, үз фатирында яшәр. Ләкин фатирны хәзер Айзадә исеменә рәсмиләштерергә уйлыйм һәм бу эшкә иртәгәдән үк тотынам. Синең аркада Мансур үлеп китте, кызы шундый хәлдә калды. Син бит үз балаларыңның да кайда йөргәнен белмисең, – диде Асия кырыс кына. – Ятим бала хакын ашамаска өйрән. Югыйсә, тәмуг утында янарсың, – диде ул, чыгып киткәндә.

* * *

Айзадә белән Асия бер-берсенә бик якынайдылар. Асия Динәнең фотосурәтен кызның караваты янына элеп куйды.

– Кызым, Айзадә, әниең синең йокыңны саклап, исән-сау булуыңа сөенеп торсын, ә бу – әниең миңа бүләк иткән шәмаил, ул сине шайтаннардан саклар, – дип, анысын да фото янына беркетте.

Кыз бик сөенде һәм сорап куйды:

– Асия апа, каникуллар җитәргә күпме калды, әбиләрне, Аппакны бик сагындым.

– Күп калмады, Айзадә. Мин дә эштән бер атна ял алырмын, бергә кайтырбыз.

– Асия апа, Алинәне күптән күргәнем юк, кайда икән ул? Гөлназ апа белән Ралинә мине ачуланган вакытта, ул мине гел яклый иде.

– Мин аның кайда икәнен беләм, теләсәң алып барырмын, – диде хатын.

* * *

Алар килеп кергәндә, Алинә әтисе белән дәресләрен әзерләп утыра иде. Айзадәне күргәч, Алинә, сикереп торып, аны кочаклап алды һәм:

– Айзадә, сестрёнка, ты живая, как я рада! – дип, битеннән үпте.

Майкадан гына утырган Алинәнең әтисе тиз генә өстенә ак күлмәк киеп куйды да, уңайсызланып:

– Гафу итегез, теге юлы рәтләп рәхмәт тә әйтә алмый калдым. Күзгә күрендегез дә юкка чыктыгыз. Кызымның кайтуына шундый сөендем. Ялгызлык бик яман бит, – диде ул, елмаеп. Куе керфекләр белән каймаланган зур көрән күзләре тирәсендә кояш нурлары кебек җыерчыклар пәйда булды, алар ирнең йөзен гүя яктыртып җибәрде.

«Нинди сөйкемле кеше! – дип уйлады Асия. – Өендә бик чиста. Кечкенә генә бүлмә, үзенә күрә кош оясы кебек. Бөтен әйбер үз урынында».

Айзадә белән Алинә берсен-берсе уздырып, ни турындадыр сөйләшәләр, серләшәләр. Ә ир үзен Таһир дип таныштырды да Асиянең ай-ваена карамыйча, чәй куярга кухняга чыгып китте. Асия кабат бүлмәгә күз салды. Стенаның бер ягы идәннән түшәмгә кадәр китаплар белән тулган. Галим кеше, ахры, бик итагатьле. Өйдә хатын-кыз әйберләре күренми, ялгызак, күрәсең.

Таһир өстәлгә тәм-томнар куйды, йомшак күмәч кисте.

– Бераздан ашым да пешеп җитә. Ничек киләсе иттегез? Кызым Айзадә турында күп сөйләде, сагынып, кызганып сөйләде. Ятим калу – балалар өчен бик авыр хәл. Ятим баланың күңеле китек һәм бик сизгер була. Үзем дә ятим үстем мин, үги ана белән. Ул, ашаганда да, үз балаларына итен күбрәк сала иде. Аның балаларыннан калган иске, ямалган киемнәрне киеп үстем. Әти бу хәлләрне күрми, әллә күреп тә берни эшли алмый иде. Гел үртәлеп яшәлде инде. Тик шулай да гаиләдә яшәү балалар йортына караганда яхшырак. Алинәнең сөйләве буенча, күрше апасы үлгәч, эт оясында яшәгән икән Айзадә. Аллага шөкер, тапканнар. Гөлназ каты бәгырьле шул ул, акчаны бик ярата. Ләкин хатын-кызда аз гына йомшаклык булырга тиеш ләбаса! Хайваннарны да кызганасың.

Таһир кухнядан чәйнекне алып керде. Бөтнек салып чәй пешерде. Өйгә тәмле чәй, бөтнек исе таралды. Озаклап сөйләшеп утырдылар. Асиянең нигәдер бу кечкенә тулай торак бүлмәсеннән китәсе килми иде. Кичкә таба гына кызларны яңадан күрештерергә сүз куешып аерылыштылар. Әллә инде үзләренең дә кабат очрашасылары килде, анысы әлегә әйтелмәгән сер иде.

Озатырга чыкканда, Таһир, кыенсынып:

– Бүлмәбез бик кечкенә. Эштә язга өч бүлмәле фатир бирергә вәгъдә иттеләр. Алла боерса, вакыты җитсә, булыр, – дип куйды.

...Трамвай шалтыр-шолтыр килеп, Яңа бистә ягына үрмәләде. Янында сөенечтән балкып торган Айзадәсе, күңелендә – елмайганда көрән күзләре тирәсенә яктылык һәм нур җыела торган Таһир иде Асиянең.

«Йә Хода! Гөлназга бу ирнең кай җире ярамады икән?» дигән сәер уй бөтерелде ялгыз хатынның башында. Начарлык күрмичә, яхшылыкның кадерен белмибез шул!

Өйләренә кайтып җиткәндә, Айзадә арыган, күзләренә йокы эленгән иде. Юынып, йокы күлмәкләрен киеп алды да йокларга ятты ул. Фоторәсемнән әнисе аңа:

«Сабырлык кирәк, кызым, шул чакта барысы да яхшы булыр», – дип елмаеп әйтә сыман. Чыннан да, тиздән каникуллар башланыр, авылга кайтырлар, әбисе белән бабасын, сагынган Аппагын күрер... Шундый татлы уйлар белән Айзадә тирән йокыга талды.

* * *

Гөлназ Алинәне алып китү өчен ире янына килде. Әгәр Таһир кире үзенә чакырса, каршы килмәс. Чөнки соңгы вакытта тормышы гел артка тәгәри башлады. Ралинәсе бөтенләй бәйдән ычкынды: әнисенең әйткән сүзен тыңламый, гел каршы дәшә. Әллә нинди шикле егетләргә ияреп чыгып китә, кайчак хәтта кунарга да кайтмый. Орышып

та карады. Ләкин Ралинә: «Сама такая!» – дип кенә кычкыра. Күршеләрен дә өнәп бетерми. Бакчада Хәят үзәгенә үткән булса, монда Асия фатирны Айзадә исеменә хосусыйлаштырып йөри – тиздән өеннән дә куып чыгарачаклар. Машинаны банк алды. Кичә базарда Таһир белән бергә эшләүче хатын очрады. Ул Таһирның язга өч бүлмәле фатир алачагы турында сөйләп торды. Менә сиңа бозау! Теге вакытта балаларны алып, киемнәрен, барлык акчаларын җыеп чыгып киткәндә, иренең, күзләрен яшьләндереп, тәрәзәдән карап калганы әле дә исендә.

«Китмә, балаларны ятим итмә, Гөлназ! Чит кеше балаларга чын әти түгел, үги була ул аларга. Нинди генә яхшы кеше дисәң дә, барыбер үги әти була. Мин алардан башка нишләрмен? Фатирны да алырбыз», – дип ялынган иде Таһир. Ләкин Гөлназ тыңламады. Чыгып киткәненә әле бер ел да узмаган, хәзер менә үзе тулай торак бүлмәсенең ишеге каршында нәрсә эшләргә белмичә аптырап басып тора. Кыяр-кыймас кына ишек шакыды хатын.

– Ачык, керегез! – Бу – Таһир тавышы иде.

Гөлназ өйгә керде.

– Нихәл, Таһир, исән-имин генә яшисезме? Мин Алинәне алырга килдем, – диде ул.

– Исәнме, Гөлназ! Әйбәт кенә гомер итәбез. Алинә күрше кызы белән урамда. Тик сиңа кире кайтмас ул, – ирнең тавышы җанны өшетердәй салкын, ят иде.

– Ничек кайтмасын, кем әйтте сиңа бу сүзләрне? Синнән кем сорап тора әле аны?! – Хатын иренә элеккечә акырып җибәрде. Ләкин Таһирның кырыс тавышы аны тиз акылына китерде:

– Син монда кычкырышырга килдеңме? Ул вакытлар үтте инде, әле һаман да шуны аңламадыңмы?

Тукта, алай ярамый лабаса! Ул бит ире янына яңадан әйләнеп кайту нияте белән килде. Сүзне дөрес башламады бит.

– Таһир, – диде ул, тавышын йомшартып. – Гафу ит, зинһар. Минем сине рәнҗетәсем килмәгән иде. Кызымны бик сагынам. Ралинә дә йөгәннән ычкынып бара. Әйдә, яңадан кавышыйк, балалар хакына булса да! – Гөлназның күзендә яшь бөртеге җемелдәде. Ул Таһирны кочаклап алырга теләде. Тик ир аның үзенә үрелгән кулларын этеп җибәрде дә диванга барып утырды.

– Спектакль уйнама, Гөлназ! Без синең белән беркайчан да яңадан бергә була алмабыз. Кызлар кем белән яшәргә икәнен үзләре хәл итәр. Моның өчен аларның инде яшьләре җиткән!

Хатын сүзеннән беркайчан да чыкмый торган Таһирны алмаштырып куйганнармыни?! Гөлназ кулын җилкәсенә куюга сары майдай эреп китә торган ир кая киткән? Шул ир яраткан кешесен читкә этәрәме?! Шаккатты Гөлназ.

– Үзеңә себеркеләр таптыңмы? Хәзер мин кирәк түгелме? Балалар да артыкмы? – Гөлназ улап елый башлады.

– Тукта, хәзер үк тукта! Күршеләр ишетер. Син чыгып киткәч, колаклары тынып торган иде. Кире кайтыр бу, дип уйлап, йөрәкләре алыныр.

Алинә, кайтып, ишек янында тыңлап тора икән. Ул әтисенә килеп сарылды.

– Әйдә, кызым, өйгә кайтабыз, – диде Гөлназ.

Ләкин кызы ябык кулларын әтисенең муеныннан ычкындырмады:

– Мин әти белән калам!

...Гөлназ трамвай тукталышына кадәр елап барды. Барлык тормышы чәлпәрәмә килде хатынның! Бары да бетте! Һавадагы торнага ышанып, кулындагы чыпчыкны ычкындырды! Акрын гына яшәп ятарга иде шунда, кирәк чакта үз күңелеңне үзең күреп. Вәт җүләр. Бу Таһирны ничек булса да, фатир алганчы, үз ягына борырга кирәк. Моңа гына хәйләсе җитәр. Балалар аркылы эш итәргә кирәк булыр. Шулай дип өметләнде Гөлназ.

* * *

– Әти, син мине әнигә җибәрмәссеңме? Не отдавай меня, – дип елады Алинә.

Таһир кызын тынычландырды:

– Юк, кызым. Мин сине беркемгә дә бирмим! Икәү яшәрбез. Елама, кызым. Син хәзер Айзадә кебек матур итеп татарча сөйләшә башладың. Әби-бабаларыбызның

телен белү кирәк. Хәзер кичке ашны өлгертәм. Бар, саф һавада уйный тор. Бик ерак китмә, яме. Әзер булгач чакырырмын.

Асия Таһирның күңеленнән китмәде. Моңа кадәр ике генә тапкыр күргән хатын елга якын ялгыз яшәгән ирнең йөрәген яулап алды. Асиянең Айзадәгә һәм Алинәгә карата яхшы мөгамәләсе, эчкерсезлеге, елмайганда, бит очларында барлыкка килгән чокырчыклары әле дә күз алдында. Асиянең киткәндә, «Айзадә белән Алинәне еш очраштырып торырбыз» дигән сүзләре аның күңелендә татлы өметләр уятты. Әгәр Асия Таһирны аз гына булса да ошатса, кызлар да бергә-бергә үсәрләр иде.

Ә Ралинә белән нишләргә? Ул кыз кечкенәдән холыксыз булып үсте, олылар сүзен тыңламады. «Алай ярамый!» – дип әйтә башласаң, әнисе:

– Аннан үзең кебек хәреф корты, бозау ясыйсың киләме? – дип кенә кысыла иде. Хәзер менә үзе дә кызының юлдан язып барганына борчыла. Алла сакласын, бер юлдан язса, кире акылга утыртып булмас.

Асияне күргәннән соң, дөнья Таһир өчен икенче төсмер алды. Күз аллары яктырып, күңеле күтәрелеп китте. Бүген дә алар башта кызы белән бергәләп дәрес әзерләделәр, аннан соң ул докторлык диссертациясенә утырды.

Асия стена тулы китапларны күреп:

– Абау, Таһир, күп укыйсың икән, барысы да – гыйльми китаплар, – дип шаккатып карап торган иде.

– Минем эшем шул бит, Асия, – уку, язу, укыту. Башка эшне белмим дә, кирәксенмим дә. Чөнки үз эшемне яратам. Дөрес, акчасы артык баерлык түгел.

– Кара эшне кем дә булдыра, аның өчен зур белемгә ия булу кирәк түгел, – дигән иде Асия, соклануын яшермичә. – Кеше акча колы түгел, ә акча үзе синең колың булырга тиеш!

Таһир күрде: Асия белән Гөлназ арасында аерма җир белән күк арасындагы кебек. Өйләнгәнче, егет чагында ук ничек абайламады соң ул Гөлназның холкын? Чибәр иде, юмагай телле иде кыз. Баштарак «мой учёный» дип кенә дәшә иде. Таһирның башы әйләнде. Ятимлектә һәм гаделсезлектә, ягымлы сүзләр ишетмичә үртәлеп үскән егеткә шуннан да зуррак бәхет юк сыман тоелды. Ләкин гомер итә башлагач, Гөлназ бик үзгәрде. Ралинә тугач, Зөһрә дип исем кушыйк дип әйтеп караган иде, Гөлназ кискен каршы төште:

– Нинди Зөһрә, заманча исем кушабыз. Нәрсә беләсең соң син?! – диде ул.

Таһир карышып маташмады. Ралинәгә аваздаш булсын дип, икенче кызларына Алинә дип куштылар. Балаларның икесе ике төрле булып үсте. Ралинә әнисенә охшаган – чая, үткен, үзсүзле. Ә Алинә – әтисе кебек басынкы, оялчан һәм нечкә күңелле.

Гаиләдә акча беренче урынга чыкты. Көн саен чыккан тавыш, гауга ярату хисен үтерде. Гөлназның матурлыгы Таһирны җәлеп итми башлады, мәхәббәт юкка чыкты. Тышкы матурлык артында күпме мәкер, ялган яшеренеп яткан икән ләбаса! Күпме гомер заяга аккан! Ләкин, алай дисәң, ике кызы үсеп килә. Менә докторлык диссертациясе дә әзер диярлек. Фатиры да булырга тора – «Аллага шөкер» дияргә генә! Тик гаилә тормышы гына хәл ителмәгән.

* * *

Айзадә тәрәзәгә шык-шык иткән тавышка уянды. Караса, кошчыгы! Кыз, салам көлтәсе кебек чәчләрен тузгытып, тәрәзә янына килде. Кошчык очып китмәде. Айзаданең кичтән салып куйган тары ярмасын чүпли, үзе кызга карап-карап ала. Иртәнге кояш нурларында зәңгәрсу-яшькелт каурыйлары төрле төсләргә кереп ялтырый. Айзадә елмаеп, кошка дәште:

– Менә, әнием-кошчыгым, үзең күрәсең, барысы да яхшы!

* * *

Көзнең агачлары алтынсу-сары төскә кергән бер көнендә Галихан карт белән Сәйдә әбинең капка төбенә Таһир абыйларының машинасына төялеп: Асия, Айзадә һәм Алинә кайтып төштеләр. Күзгә күренеп үскән Аппак якын дусларына каршы атылды...

*Гаврил Андросов (1985) – якут шагыйре, публицист һәм тәрҗемәче. Саха (Якутия) Язучылар берлеге рәисе урынбасары, «Чолбон» («Чулпан») әдәби журналының баш мөхәррир урынбасары.*

*Ул М.К.Аммосов исемендәге Якутия дәүләт университетының якут филологиясе һәм мәдәнияте факультеты әдәби тәнкыйть бүлеген тәмамлый. Ике шигырь китабы һәм өч публицистик җыентык авторы. Шигырьләре «Россия халыкларының хәзерге заман әдәбияты. Поэзия» антологиясенә кертелгән, шулай ук рус, поляк, болгар, вьетнам, кыргыз, тува, нугай телләренә тәрҗемә ителгән.*

*2010 елдан Россия Язучылар берлеге әгъзасы.*



Гаврил
Андросов

# УЗУ КИРӘК УТНЫҢ ҮТКЕЛЕННӘН...

* * *

Синең язмыш: кылыч тотып, атта җилү –
Ышан, түз!
Чәчәк койган, сулган, көйгән аланнарны
Урап уз!
Батырларның мәңге үзгәрмәс язмышын
Сакла нык!
Утка һәм суга кер, табигать көчләрен
Җиңеп чык!..

Вакытның аяусыз җиленә бирешмә –
Бул юлда!
Йөрәккә үтәли кадалган укка да
Син чыда!
Тынычлыкка, тук тынлыкка өметләнмә –
Бар, атла!
Якты киләчәгеңне күз карасыдай
Гел сакла!

Ашыгып язмышны хәл иткән шобага –
Ташланган!
Рәхәт тормыш артта калган, сынау юлы
Башланган...

## Ялвару

Саран иреннәреңнең
Кайнар үбүе белән
Ирек даулаган,
Илләр яулаган,
Сугышка мөкиббән киткән
Батырны
Коралсызландыр,
Акылдан яздыр!

Ялтырап торган,
Ут янып торган
Хәрби киемнән
Арган тәнемне
Иреккә чыгар...
Ул күпме түзәр,
Күпмегә чыдар?!
Кочакла мине,
Шашып кочакла!
Эссе кайнарлык,
Хисле кайнарлык
Тәнне иркәләр
Әнә шул чакта!

Ат өстендәге йөгемне
Барлык кеше каршында
Кылыч белән кисеп төшер –
Уй таралсын башымда!
Хәйләкәр сафлыкны ал...
Ташла!
Батырлыкны ирлектә
Расла!..

Арыт син, арыт
Дәрт гарасаты,
Һавасы белән!
Дулкындай бәрел
Һәм күм татлы наз
Лавасы белән!

* * *

Йомшак кар яуды. Узган төндә... Кинәт...
«Чана кары яуды», – дип әйтер иде,
ала үгезен җигеп, ерак бабам,
күз карашын алыс офыкка төбәп...

Иске ас туным җилкәмә салып,
Саха – Сайсары[*] җирләре буйлап
мин атлап киләм, тиз атлап киләм,
Ихаталарның тынлыгын җыйнап.

Чылбыр тагылган, йозак эленгән
эт тормышына шом-шөбһә өстәп,
буш һәм бормалы урамнан барам...
Эт өрә... кемне алгандыр тешләп.

Әле бик иртә. Әле караңгы.
Кинәттән генә тамагым ачты:
бер утыруда зур гына кисәк
ит ашар идем... – Уйлар таралды...

* * *

Кулыңны бир, әй, син, чибәр,
Уйларың офыкка җибәр!
Җир һәм күкне тоташтырган
Гаҗәп кояш яши торган
Ерак тарафка юл алыйк,
Бер язмыш булып уяныйк!

[*] Саха – якут; Сайсары – төрки сүз, «сай» һәм «сары» сүзләреннән.

Юл җиңел түгел,
ләкин без
Аны бергәләп үтәрбез,
Явызлыкның ярсу көче,
Караңгылык белән үче
Артыбыздан йөгерсә дә,
Күперләрне себерсә дә...

Үз язмышларыбыздан без
Зәңгәр офыкка китәрбез.
Куучылардан качарга,
Җилдән дә җитез очарга
Булышыр чабыш атлары,
Аларның бар канатлары.

Сөекле ярым – аккошым!
Барлыгым, сулышым, һушым!
Җир һәм күкне тоташтырган
Гаҗәп кояш яши торган
Серле тарафка юл алыйк,
Бер язмыш булып уяныйк!

* * *

Бөек серле хәрәкәттән туган
Бик борынгы чорлар төпкеленнән –
Өлкән агайлардан әмер килде:
Узу кирәк утның үткеленнән.
«Сез ут белән уйнагыз!» – дип алар,
Васыятьләрен әйтеп калдырды.
Ут җылытты безне, ут яшәтте,
Саклап калды тирән тамырны.
Асылмалы биштәр калды безгә
Өлкән агайлардан.
Барлыгы:
Чыныккан чакма корычы,
Сихерләнгән чакма ташы,
Очкын кисәр чакма мамыгы!

Эшлексез һәм ялкау адәм заты
Җиңүченең авыр данын йөртә,
Сугыш чукмары һәм җилкуарлар
Ау мылтыгы белән иңгә төртә.
Болар нинди тормыш алып килер?..
Ә киләчәк ни дип җавап бирер?..

Үзсүзле холыклы, аяусыз
Мохтаҗлык табар ла үз җаен –
Акылга утыртыр, мөгаен,
Хак юлны күрсәтер, мөгаен...

*Якутчадан* **Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәләре*



*Айгөл Абдрахманова 1993 елда Татарстанның Кайбыч районы Борындык авылында туа. Урта мәктәптән соң, Казан (Идел буе) федераль университетының Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтында укый, «Филолог» белгечлеге буенча аспирантура тәмамлый. Укыганда ук, ул үсмерләр һәм яшьләр арасында кайнап яши, «Сәләт» Яшьләр үзәгендә педагог, «Ялкын» журналында бүлек мөхәррире булып эшли. Әдәби иҗат белән мәктәп чорыннан ук шөгыльләнә, вакытлы матбугатта аның проза әсәрләре басылып тора.*

Айгөл
Абдрахманова

# СИН – КАҺВӘ

ХИКӘЯ

Кичә каһвәдән баш тартырга карар кылынды. Әллә күпкә китте, әллә миңа ярамый торган яңа сорт эләкте шунда: йөрәк каккан тавыш чигәләрдә яңгырый, күңел болгана.

Күпкә дә киткәндер инде. Иртәне каһвәдән башлап, төшке аш урынына бер чынаяк каһвә тотып икәүдән-икәү урам әйләнүләр, төнне каһвә белән каршылау гадәткә кергән иде бит. Сүземдә нык торыр өчен, җәмәгатьчелек алдында (инстаграм сторисларын шулай атарга ярыйдыр бит?) «Каһвәсез торачакмын», – дип ант иттем. Бар да җитди!

1 нче көн:

Иртә. Артык иртә. Күзләремне көчкә ертып ачтым. Шырпы кыстырып куйсаң, күз кабакларының авырлыгыннан ул да шартлап сынар иде, билләһи. Уянмыйча гына кухняга чыктым. Мендәр кочаклап ятып, оеп беткән куллар шкафның өске киштәсендә торган каһвәгә үрелде. Каһәр!!!

Үзем эшкә барам. Ә үземнең бөтен уйларым синең турыда. Йокыдан айнымаган тәнгә дә, синсезлекне кабул итәргә теләмәгән җанга да каһвә кирәк. Әллә эшкә иртәрәк барып, кеше күрмәгәндә генә бер шакмак шикәр салынган кара каһвә эчәргә инде?! Әйе, шулай итәргә кирәк! Безнең очрашуны кеше күрмәсә, ант бозылган булмый. Төштән соң башлармын каһвәсезлекне. Йөгерә-атлый, редакциягә килеп кердем... Коллегалар – эштә!

...Көн дәвамында синең белән очрашырга җай эзләдем. Әллә начар эзләнелде, әллә җай табылмады, әллә намус комачаулады: кофейняга кереп, яраткан капучиноны эчү мөмкинлегеннән үзем баш тарттым. Кеше күрмәгән дә булыр иде югыйсә. Тик эчмәдем.

Сабырлыгым күпмегә җитәр?!

2 нче көн:

Сабыр төбе – сары алтын. Ә минеке – ярык тагарак.

...Онытылып беткән, ләкин шундый таныш урында синең белән очрашу билгеләдек. Безне беркем дә күрергә тиеш түгел иде.

– Каһвә эчик әле.

– Әйдә.

– Беркемгә дә әйтмибез бит?!

– Ант бозылмаган, дип уйласын барысы да.

– Килештек?

– Килештек.

Каһвәле һәм синле очрашудан балкып торганда, җылынырга һәм кайнар чәй эчәргә дип, шул ук кафега кергән танышымны күреп алдым. Елмая. Нишләргә җыенганлыгымны белә чөнки... Сүгеним әле?!.

Танышым каһвәсезлек анты турында белә бит. Тотылганлыгымны аңлаудан ни күләргә, ни көенергә белми таптанып тордым да кыю адымнар белән танышым утырган өстәлгә таба атладым. «Серне сатма, яме?»

...Әйе, мин антымны боздым. Икенче көнне үк, кешеләрдән качып синең белән төшке ашны уздырдык. Миңа оят түгел! Миңа рәхәт.

Каһвәсезлеккә иртәгә кире кайтырбыз. Мөгаен...

3 нче көн:

«Кайнар шоколад каһвәгә саналамы икән?» Баш мие бүген шундый сорау белән уятырга булды.

– Ми, йоклыйк әле, зинһар өчен. Нинди матур төш күрсәтә идең, карап бетерим инде.

– Төш качмый ул. Иртәгәсе сериягә кушып күрсәтермен. Монда җитдирәк мәсьәлә бар! Кайнар шоколад эчсәк, ант бозыламы?

– Шоколад яратмыйм. Миңа каһвә кирәк.

Котлыйм: көн тагын сине уйлап уза!

4 нче көн:

«Ломка»ның ни икәнлеген белгәнлектән, алдан ук чыгу юлларын эзли башладым. Иң җайлы ысул, әлбәттә, цикорийга күчү. Каһвә эчәсе килгән саен чәй яки су эчеп куярга мөмкин. Ярар, чыгу юллары юк түгел бугай. Сине уйлаудан гына котылып булмый. Аптыраганнан чәйгә чакыруны кабул иттем.

– Җиләкле кара чәйме, әллә яшелнеме?

– Берсен дә түгел.

– ...

– Үзең теләгәнне...

Эш, сәяхәт, эш, кабат сәяхәт турындагы сөйләшүләр. «Ә менә чит илдә бездәгедән яхшырак», «Менә Америкада хезмәт хакы безнеке кадәр ун, диләр. Үзем барып күрмәдем, конечно. Но, шәп, диләр, анда», «Индонезиядә кафеларда сорамасаң да, каһвә янына сухофрукты китерәләр», «Бездәге мокытлык юк шул чит илдә»...

Бер йотым ясарга дип, иреннәргә китерелгән чәй чынаягы илтифатсыз гына тәлинкәсенә утыртылды. Эчемдәге патриот, каны кайнауга түзә алмыйча, чынаякны читкә этеп җибәрде.

– Ни булды?

– Чәе кайнар. Пештем.

...Чынлыкта исә чәй түзеп булмаслык ачы һәм күптән суынган иде.

5 нче көн:

Әгәр парфюмер булсам, дөньядагы бөтен каһвә төрләренең исләрен мәңгеләштерер идем. Сары чәчле кешеләрнең чәчләреннән – латте, кара чәчлеләрдән – капучино исе, яшь кызларның муеннарыннан – ванильле раф, шагыйрьләрдән эспрессо исе килер иде. Үз дәрәҗәсен белә торган, эшенә һәм дөньяга гашыйк ирләр өчен махсус ис – ристретто. Кайнар канлы ирләр өчен – аз шикәрле, ачы шоколадлы төрек каһвәсе.

Иң якыннарыма, һичшиксез, чын каһвә исе салынган парфюм гына бүләк итәр идем. Иң якыннарымнан гел чын ис килер, алар чын булырлар иде. Ә калганнар, CHANELнең арзанлы подделкасы сыман, төрле тәмләткечләр кушып ясалган каһвә исе белән аңкырлар иде.

Парфюмер булсам, бөтен дөньяны каһвә исенә күмәр идем. Әлегә исә, иреннәргә кунган яшь кар бөртекләрен җылытып, синле каһвә тәмен искә төшерергә генә кала.

6 нчы көн:

Тиздән бер атна була икән бит инде. Сине күрмәгәнгә дә бүген 4 нче көн. Үзең дә «Күрешик», – димисең... Әй, тырный инде күңел ишеген мәче баласы, әй, тырный. Әллә йомышы бар, әллә иркәләнергә тели – аңламассың. Мин дә шул песи кебек, йөзеңә карап: «Синсез дә яши алам менә», – дип көләсе, шул ук вакытта куеныңа кереп сырпаланасы килә. Күрешәсе килә, канга каһвә дозасы җитми.

...Эштән соң дуслар белән күрешеп, кафега барырга, дөнья хәлләрен сөйләшергә, килми калган танышларның гайбәтен сатарга булдык. Мондый чараларга бармый калырга ярамый. Бертуктаусыз очкылык тотарга һәм икенче көнне үзең турында инстаграмда пост укырга теләмәсәң, барырга кирәк.

Бөтен кеше каһвә алган. Кемдер килгәч заказ бирде, кемдер үзе белән алып килгән. Ә мин нәрсә? Миңа официант үземнән дә зуррак бургер күтәреп килде. Ярар инде. Ичмасам, тамагым туяр.

7 нче көн:

Син дә мин йөргән урамнардан йөрисеңме икән? Сиңа да шул кояш яктыртамы? Күкрәк тутырып, Казан һавасын сулыйм дигәндә, синең дә үпкәләрең гади шәһәр исе белән туламы?

Островский һәм Татарстан киселешендәге кофейня яныннан узганда, ниләр кичерәсең? Узасыңмы, дип сорамыйм, һәр иртә юлың шуннан үтә бит. Үзеңне очратмасам да, син баскан ташларга басыйм, син күргән шәһәрне күрим дип, әллә ничә әйләнәм шул урамнарны. Кофейняга гына керергә ярамый.

Безнең урын бездән башка яши... Ә без?

10 нчы көн:

Синле каһвәне кемнәр эчә икән?

11 нче көн:

Каһвәсезлекнең сәер стадиясен кичерәм.

Синсез торып та булмый, антны да боза алмыйм. Читтән генә кешеләрнең каһвә эчкәнен карап торам. (Читтән генә сине күзәтәм.)

Ничә ай рәттән башкара торган бер йолам бар: һәр иртәдә тәрәзә пәрдәләре белән бер үк вакытта синең белән язышу тарихы «ачыла». Эленке-салынкы гына булып төшә торган нурлар төннең авыр шәүләсеннән коткара. Йокы патшалыгының гаскәрләре бер чынаяк кара каһвә һәм «Хәерле иртә!» сүзләреннән соң юкка чыга. Ләкин каһвәсезлек чоры башлангач, бу йоланы онытырга туры килде. Болай да «чыксам – чыгам, чыкмасам – юк» дип торган кояш бүген гадәттәгедән дә кәефсезрәк. Нурлары да безне яшәтер өчен түгел, көн җиткәнлекне белдерер өчен генә яктырта. Төн гаскәренә җиңелүдән куркып, авыр артиллерияне чыгарырга булдым.

Телефон клавиатурасы йөрәк белән бер тактка басылды: «Хәерле иртә»...

– Ми, ник кирәк иде безгә болай итү?

– Белмим, йөрәктән сора. Аннан заявка килде бит.

– Йөрә-ә-әк...

– Ник усалланасың? Соравыңа җавапны белмим. Просто шулай кирәк иде. Просто.

...Йөрәкнең бертуктаусыз йөренеп торган тавышы фатирны тутырды. Ә баш мие: «Мин арыдым. Эшлисе килми», – дип, кабат юрган астына кереп ятты.

Хәтта урамга чыгып баскач та тормады Ми. «Эшеңә кадәр юлны беләсең. Если что, иптәшкә Йөрәк бар. 1-2 сәгатьтән дәшәрсез, торырмын. Ләкин кара аны: теге тиленең бөтен әйткәнен тыңлап йөрмә», – диде дә борылып ятты.

Йөрәк исә бәйрәм итте. Бер-ике сәгатькә булса да, икәүдән-икәү калу бәхетеннән плейлисттагы иң күңелсез җырны тыңладык, кондукторның усал итеп каравыннан елап алдык; кибеткә кереп, бер кочак тәм-том алып чыктык. Ә эшкә килгәч, редакциядә кеше юклыктан файдаланып, каһвә ясадык. «Әрем исе» җырын

кабыздык, бер кулга – каһвә, икенчесенә – фундуклы круассан тотып, урыныма барып утырдым.

Каһвә салынган чынаякны ашыкмыйча гына борын төбенә китердем. Күкрәк тутырып, яңа гына кайнатылган каһвә иснәдем. Бер мизгелгә иң биек тауларга күтәрелдем һәм иң бөек хисләргә чумдым. Моңарчы кайда, нинди каһвә эчүемне, нинди хисләр кичерүемне – барысын да искә төшердем. Менә ул – Алтай таулары арасында ясалган «3 в 1» һәм Катунь елгасы исе, менә ул – Мәскәүнең иң кыйбатлы кофейнясында эчелгән латте һәм пафос, менә ул – Тюнектепе тауларында эчкән каһвә һәм ихласлык исе. Менә ул – Казанның иң шәп кофейнясында эчелгән капучино һәм бәхет исе. Рәхәт.

Бу истәлекләр күпмегә сузылгандыр – белмим. Дөньяга кайтканда, каһвәм суына башлаган иде. Тизрәк эчәргә кирәк. Юкса Ми уяныргя, коллегалар килеп җитәргә мөмкин.

Чынаяк иреннәргә якынлашкан саен, «каһвә эчәсе килми икән» дигән уй ачыграк яңгырады. Ми уянганмы, дисәм, юк, йоклый әле. Ашказаны кабул итми икән каһвәне.

Менә сиңа кирәк булса...

Кәефе тәмам кырылган йөрәк, тәрәзә ачып, салкын һава сулады да «Телефоныңны тикшер әле. СМС килмәгәнме?» – дип, ялварулы караш ташлады...

Кеше күргәнче, чынаякны бушатып, юып килергә кирәк.

16 нчы көн:

Телефон чыңлаган тавышка уяндым. Будильникка кадәр вакыт бар бит әле, дип, күзләремне ертып ачам. Тик телефон экранында будильник түгел, ә СМС билгесе ялтырап тора. «Иртәңне дөрес башла. Бер стакан су эчәргә онытма».

Ачы таңнан киңәш таратучы бу акыллы башка ачулы булсам да, уятканы өчен эчтән генә рәхмәт укыдым. Кичтән будильник куярга онытылган. СМС килмәсә, эшкә соңара идем.

Рәхмәт, Яхшы кеше!

Ми белән Йөрәкне уятып тормый гына эшкә йөгердем. Соңгы көннәрдә бу гадәткә әйләнде инде. Ми төшке аш вакыты җитәрәк кенә уяна, ә йөрәк, гомумән, «больничный» алды.

12.20

Ми:

– Әй, кеше, анда сиңа иртән СМС килгән иде. Җавап бирергә кирәк булыр. Әдәп кагыйдәләре турында онытма!

– Әйе шул.

«Иртәнге киңәшегез өчен рәхмәт. Тик Сез ялгыш номерга җибәргәнсез бугай. Адресат мин булмаганмындыр инде».

«Әгәр СМС Сезгә килгән икән, димәк, адресат – Сез. Кем булуыгыз мөһим түгел. Иң мөһиме: иртәгезне дөрес башлагыз. Су эчәргә онытмагыз».

«Рәхмәт. Айгөл булам».

«Бик шатмын. Ильяс».

21нче көн.

«Иртәңне судан башла. Һәм онытма: бүген төшке аш вакытында күрешәбез.»

Тәрәзә пәрдәләрен ачканчы, Ильяс белән язышу тарихы ачыла. Матур бер гадәт.

Иртәм бераз үзгәрсә дә, калганы шул килеш калды. Йокыдан уяну әле дә зур авырлык белән бирелә. Күзләрне «ертып», юыну бүлмәсенә узам. Салкын су белән юынып, Мине уятырга тырышам. Кухняга чыгып, каһвә кайнатам. Үземә түгел: кабат укырга соңга калучы, каударлана-каударлана киенеп йөрүче сеңлем өчен. Ә үзем, салмак кына ява торган кар бөртекләренә карый-карый, бер стакан җылымса су эчәм. Тәмле икән...

# АЙГӨЛ АБДРАХМАНОВА. «СИН – КАҺВӘ»

Татар әдәбиятына килә торган яшьләрнең бер сыйфаты күңелемә аеруча ятышлы: ул да булса – яңалыктан курыкмау, әдәбиятта беренче сүзне традицион булмаган мәйданчыкта әйтеп карый алудыр. Прозада булсын, шигърияттә булсын, күп кенә яшьләр классик әдәбиятта сыналган, традициягә әйләнгән сукмакта исем яңгырату ягына басмыйча, татар әдәбияты өчен яңа булган сукмак салырга керешәләр! Нәкъ шушы сыйфат, минем фикеремчә, татар әдәбиятын, анда XX-XXI гасырлар чигендә башланган яңа дулкынны – олы яңарышка китерә ала.

Менә Айгөл Абдрахманованың «Син – каһвә» хикәясен укыганда да, шушы тәэсир күңелдә ныгыганнан-ныгыды. Аның шартлы-метафорик кимәлдә язылуы яшь каләм сынаучының әдәбиятны яхшы белүе, үз-үзенә ышанычы турында да сөйли дип кабул иттем.

Башта шушы «сукмак» – шартлы-метафорик юнәлеш турында берничә сүз әйтү кирәк булыр. Шартлылык – тормышка язучы карашын, мөнәсәбәтен белдерү чарасы булган бу юнәлеш, әйтик, 1980 елларда рус әдәбиятында идеологик цензурага мөнәсәбәт кебек активлашып, зур үзгәрешләргә китерде. Мисалга аеруча билгеле берничә әсәрне искә төшерергә мөмкин: Ф.Искәндәрнең «Куяннар һәм буар еланнар», В.Орловның «Альтист Данилов», В.Пелевинның «Бөҗәкләр тормышы» һ.б.

Хәзерге татар прозасында бу юнәлештә язылган әсәрләр юк түгел, язылуга – алар үзләренә игътибарны җәлеп итеп, милли әдәби хәзинәбездә үзенчәлекле урын алдылар. Бу очракта Ф.Бәйрәмованың «Су кызы», М.Кәбировның «Канатлы кеше», «Мин яратам сине», «Дүртенче үлчәм» кебек әсәрләр хәтергә килә. Татар әдәбиятында шартлы-метафорик прозаның фәлсәфи төренә өстенлек бирелә, А.Абдрахманова хикәясе дә шушы кимәлдә иҗат ителгән.

Әдәбият фәне шартлы-метафорик прозада шартлылык тудыруның берничә юлын аерып күрсәтә: әкияти, мифологик һәм фантастик шартлылык. А.Абдрахманова хикәясендә нигез итеп әкияти шартлылык алынган: үзәккә куелган каһвә образы заман сурәтен тудыра торган эчтәлек белән тутырылган.

Текстка якынрак килик. Шартлы-метафорик проза характерларның психологик үзенчәлекләренә игътибар итми (бу урында Ф.Бәйрәмованың телгә алынган повестенда башка мөмкинлек табылганын искәртмичә ярамас). А.Абдрахманова хикәясендә дә шулай. Ул беренче заттан хикәяләнә, «мин»нең яшь кыз булуы, редакциядә эшләве, аннан кечерәк яшьтәге студент сеңлесе барлык – төп мәгълүмат шулар белән чикләнә дә.

Сюжет хәрәкәте каһвәгә (һәм егеткә) нисбәтле барлыкка килә. Кыз алардан баш тартырга карар кыла, шуннан соңгы вакыйгалар әлеге карарны тормышка ашыру юлы булып күзаллана. Бу юл 21 көнгә сузыла. Беренче көннәр һәрберсе тасвирлап барыла. 11нче көн – каһвәсез яшәү белән ризалашу көне, аннан соң инде 16нчы һәм 21нче көннәр бу тарихны тәмамлап куя һәм яңа тарихка җеп суза.

Шартлы-метафорик каһвә образы – кеше ярата, аннан башка яши алмыйм дип уйлый торган теләсә нинди әйбер, хәтта кеше – ярату объекты булып аңлашыла ала. «Мин» тормышыннан каһвә һәм «син» китә – аның урынына җылы су һәм Ильяс дәгъва итә.

Шул рәвешле, асылда хикәя кеше тормышы, психологиясе, аның үз-үзен тотышының универсаль моделе хакында сөйли. Кешеләрнең нииндидер кыйммәтләргә, башка кешеләргә бик тиз иялəшеп китүе, алардан башка яши алмас хәлгә җиттем дип күзаллавы, әмма моның ялгыш икәнлеге тасвирлана. Моның сәбәбен хикәя авторы кешеләрнең – йөрәкне тыңлап, хис белән яшәвендә дип күрсәтә. Бу яктан, хикәядәге 11нче көн, бары тик йөрәк белән генә яшәп алуны тасвирлау гаять матур язылган.

Әкияти шартлылык вакыйгаларның гадилеген-гадәтилеген таләп итә. Бу үз чиратында шартлы-метафорик ситуациянең нигезендә чынбарлык ятканлыкны ассызыклый. Бу яктан, хикәя авторының осталыгын билгеләргә кирәк. «Мин»нең

каһвәгә бәйле эчке көрәше ышандырырлык һәм танылырлык итеп сурәтләнгән. Менә берничә мисал: «Иртә. Артык иртә. Күзләремне көчкә ертып ачтым. Ширпы кыстырып куйсаң, күз кабакларының авырлыгыннан ул да шартлап сынар иде, билләһи. Уянмыйча гына кухняга чыктым. Мендәр кочаклап ятып, оеп беткән куллар шкафның өске киштәсендә торган каһвәгә үрелде. Каһәр!!!»; «Безнең очрашуны кеше күрмәсә, ант бозылган булмый. Төштән соң башлармын каһвәсезлекне»; «Каһвәле һәм синле очрашудан балкып торганда, җылынырга һәм кайнар чәй эчәргә дип, шул ук кафега кергән танышымны күреп алдым. Елмая. Нишләргә җыенганлыгымны белә чөнки... Сүгеним әле?!.» «Кайнар шоколад каһвәгә саналамы икән?» «Баш мие бүген шундый сорау белән уятырга булды»; «Каһвә салынган чынаякны ашыкмыйча гына борын төбенә китердем. Күкрәк тутырып, яңа гына кайнатылган каһвә иснәдем. Бер мизгелгә иң биек тауларга күтәрелдем һәм иң бөек хисләргә чумдым. Моңарчы кайда, нинди каһвә эчүемне, нинди хисләр кичерүемне – барысын да искә төшердем. (...) Рәхәт» һ.б.

«Мин»нең һәр көнен сурәтләп-күзәтеп бару заман яшьләренең тормышын шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Аерым бер термин-төшенчәләр (инстаграм, плейлист һ.б.) дә шуңа юнәлтелгән.

Шартлы-метафорик проза билгеле бер чор тормышына иҗтимагый-көнкүреш яссылыгында гына түгел, бәлки сәяси яктан бәя бирү өчен дә зур мөмкинлекләргә ия. А.Абдрахманова хикәясендә моның орлыгы, башлангычы күренеп тора, урыны билгеләнгән: «Эш, сәяхәт, эш, кабат сәяхәт турындагы сөйләшүләр. «Ә менә чит илдә бездәгедән яхшырак», «Менә Америкада хезмәт хакы безнеке кадәр ун, диләр. Үзем барып күрмәдем, конечно. Но, шәп, диләр, анда», «Индонезиядә кафеларда, сорамасаң да, каһвә янына сухофрукты китерәләр», «Бездәге мокытлык юк шул чит илдә»... Әмма бу урын бәяләү киңлегенә чыкмаган. Бу урында, сәяси якка кагылмаган очракта, илдәшләребезнең психологик үзенчәлеген ассызыклап үтү мөмкин булыр иде.

Хикәядәге тагын бер уңышлы алымны билгеләп үтәсе килә – ул кабатлауның укылыш вариантын күрсәтү өчен файдаланылуы. Кабатлана торган җөмлә мондый: 11 нче көнне – «Ничә ай рәттән башкара торган бер йолам бар: һәр иртәдә тәрәзә пәрдәләре белән бер үк вакытта синең белән язышу тарихы «ачыла»». Һәм соңгы көнне: «Тәрәзә пәрдәләрен ачканчы, Ильяс белән язышу тарихы ачыла. Матур бер гадәт». Бу кабатлау каһвәнең – гыйшык, мәхәббәт булу вариантын калкуландыра, яратуның – төрлелеген, кешенең төрле кешеләргә карата ярату хисе кичерү мөмкинлеген төп фикер-идея итеп күрсәтә.

Шуның артыннан ук килгән соңгы абзац исә – кешедәге үзгәрүчәнлекне искәртә. Сеңел образы һәм «Мин»нең каһвәне сеңлесе өчен кайнатуы тормышның төрле этапларында кешегә кадерле булган кыйммәтләрнең алмашынуын да тагын бер кат ассызыклый: «Ә үзем салмак кына ява торган кар бөртекләрен карый-карый, бер стакан җылымса су эчәм. Тәмле икән... ».

Җитди мәсьәләләр турындагы текстның җиңел укылышын, заманча, «клиптагыча фикерләү»гә якынайтылуын күрсәтергә кирәк. А.Абдрахманованың җылы юморы (бу, бигрәк тә, ми һәм йөрәкне аеру өлешләрендә тәэсирле), ихлас хикәяләү рәвешен тудыруы – хуплауга лаек.

Гомумән, яшьләрнең яңалыкка тартылуы, яңача, үзләренчә язып карарга омтылуы – иң мөһиме. Чөнки татар әдәбиятына үзгәрешләр: тематик киңәю, дөньяга заманча караш кирәк. Төрек әдәбияты инде пост-постмодернизм әсәрләре тудыра – Бурхан Сенмезнең «Стамбул Стамбул»ын укыганда дөнья әдәбиятындагы әлеге яңа язу рәвешенең төрки телле әдәбиятлар өчен үз була алуы күренмимени?! Яки азәрбайҗан әдәбиятындагы постмодернизм үрнәкләре булган Камал Абдулланың «Тылсымчылар үзәне» («Долина кудесников») яки Эльчинның «Баш» («Голова») кебек романнары татар әдәбиятының да яңа сукмаклар ачу мөмкинлекләре булып тоела. Безнең яшьләребез дә эзләнсен, тәҗрибәләр ясасын, иҗатта үз сукмакларын салып карасын. Аларның эзләнүе – татар әдәбиятының киләчәге ул.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



*Әти-әнисе белән туган нигезендә. 2003 ел.*



*Муса Җәлилне һәм җәлилчеләрне искә алу мәрәсимендә. Сулдан уңга: Ркаил Зәйдулла, Роберт Миңнуллин, Фәрит Мөхәммәтшин, Ренат Харис, Разил Вәлиев, Салисә Гәрәева, Хатыйп Миңнегулов, Рафаэль Мостафин, Луара Шакирҗанова. 2005 ел.*



*Яңа Кырлайда. Сулдан уңга: Рәфкать Кәрами, Саимә Ибраһимова, Вагыйз Минһаҗев, Искәндәр Мәһдиев, Рөстәм Сүлти, Мөхәммәт Мәһдиев, Госман Хәбибуллин, Хәлил Ачыккүз (Төркия), Газинур Морат, Әбрар Кәримуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Гариф Ахунов, Илсөяр Иксанова, Наил Габдрахманов. 1993 ел.*



*Туфан Миңнуллин белән
Изге Болгар җыенында. 2008 ел.*



*Мөхәммәт Мәһдиев каберен зыярәт кылу. Уңнан сулга: Рөстәм Галиуллин,
Ркаил Зәйдулла, Сания Әхмәтҗанова, Газинур Морат. 2009 ел.*



*Марсель Галиев белән
Алтайда Николай Рерих
һәйкәле янында. 2019 ел.*

*Фотолар* **Газинур МОРАТ** *архивыннан алынды.*



Зиннур
Хөснияр

# ДОКТОР БАЙЧУРИН

хикәя

Минем кулда пычак.

Иртәгә мин тагын йөрәк тамырына операция ясарга тиеш. Бүтән андый катлаулы операциягә алынмам, дигән идем инде. Әнигә ясаганнан соң... Аңа да шактый еллар узган. Сукыр эчәккә дә күптән ясаган юк.

Аңарчы мин бүген атасы үтенече белән егерме өч яшьлек егетне теге дөньяга озатырга тиеш.

Кайчак шулай була бит ул: көтмәгәндә китереп суга тәкъдир.

Минем кулда тагын пычак.

Мин теге чакта үз кулларым белән әнинең йөрәк тамырына операция ясаган идем инде...

Пычакны элек «ланцет» дия торган идек, хәзер «скальпель» дип йөртәбез. Нинди генә исем белән атасаң да, барыбер пычак пычак инде, кисә, суя торган бик үткен тимер кисәге. Мин пешекче түгел, суган да әрчемим, бәрәңге дә турамыйм; мин табиб-хирург, адәм баласының авыру үтеп кергән әгъзасын кисәм, аннары тегәм, ябыштырам.

Мин газиз әниемнең күкрәк турысыннан шул пычак белән ярып, кан тамырын кисеп ямадым.

Шул чакта минем ниләр кичергәнне аңламаган кешенең бернинди гаебе юк, чөнки аны шәрехләп тә, тәфсилләп сөйләп тә булмый. Мин операция бүлмәсеннән чыкканда ук үлеп калган шикелле тоелдым. Коридорда акшарлаган мичтәй ап-ак кыяфәтле ике абыйны, өч энемне күргәч, аңымны югалтканмын... Болай да... һәрберсе берәрне тондырса да, аякта тора алмаган булыр идем... Аларның сугуын көтмичә дә һуштан язганмын... Кайгыдан булмаган бу, шатлыкны күтәрә алмаган әни биргән йөрәгем – шулай, диделәр соңыннан... Мин үлдем, юк булдым, беттем, югалдым. Күптән кирәк булган икән – минем яшәргә бернинди хакым юк. Мин кардиохирург түгел. Ләкин килеп терәлгәч кенә, каян табасың андый белгечне?!

Бәлки, шул ук хастаханә коридорында баласын, әнинең үлеп яраткан оныгы Айгөлне күтәреп торган олы кызымны күргәч югалтканмындыр аңымны... Әле ярый шул чакта һуштан язганмын, югыйсә, әнине ярган пычак белән үземнең кан тамырын сызып җибәрер хәлдә идем. Беләм бит: алай-болай була калса, эти мине пычак белән түгел, авыл агаеның көрәк кадәрле кулы белән бәреп очырачак. Сукса каты суга ул, теге чакта мине капка төбендә тәгәрәтә-тәгәрәтә сөзгән колхоз үгезен дә ничек бәреп аударды.

Ул вакытта колхоз үгезе үлмәде, исән калды. Тезләнгән җиреннән алгы аякларына

торып басты да аннары аңгырайган дәү башын як-якка айкап торды, соңыннан, сарык бәтие кебек мескен тавыш белән мөгрәп, көтү артыннан атлады. Безнең кара мунча бурасы чаклы аклы-каралы үгезнең күзләре дымлы иде. Елады микән ул шул чакта? Еласа, авыртудан түгел, гарьлектән елагандыр дәһшәтле һәм усал колхоз үгезе.

Меңләгән операция ясаган хирург буларак, минем бер кагыйдә бар, урысча әйтәм: «надеясь на лучшее, готовься к худшему»... Хәер, минеке түгел бу гыйбарә-кагыйдә, институтта чакта безгә анатомиядән лекция укыган яһүд профессоры Берманның яратып тәкрарлый торган сүзләре. Профессор бик акыллы кеше иде. Хәзер уйлыйм, шундый акыллы яһүд тә мәгънәсез сүзләрне кабатлар икән!.. Мин бит яхшы булсын дип эшлим, ахырда ул шулай булып чыга да. Аллага шөкер!

«Йа, Хода!» – дип пышылдыйм. Аннары операция өстәле өстендә яткан әнием янына килгәндә, «Алла исеңә төштеме, доктор Байчурин?» – дип мыскыллыйм үземне. Табиб буларак беләм: баш мие үтә дә катлаулы, аның икенче почмагында башка уй – «надейся на худшее, готовься на лучшее...» Карале, нишләп минем акыл урысча уйлый әле. Нәкъ чын табиблар кебек кылана башлаганмын... Чөнки татар табиблары хастаханәдә гел урысча сөйләшә. Модамы бу, әллә шулай тиешме? Оныгым Марат ишетсә, миннән көләчәк, чөнки мин аны теле ачылганда ук, «папа-мама» урынына «әти-әни, әби-бабай» дип әйтергә кирәк дип үстердем. Милләтче түгел мин. Мин – бары гап-гади бер татар малае. Өстемдә ак халатлы булсам да, кулда скальп-пычак булса да.

Зиһенем саф. Уйлар гына чуар. Коридорда әтине күргәч, алар да тәртипкә килде. Әнине авыр хәлдә хастаханәгә ат белән китереп җиткергән әтинең кыяфәте теге чактагы колхоз үгезенеке кебек: бетәшкән, кечерәеп калган, күзләре дымлы...

Аның бу кыяфәте мине тиз айнытты. Әле операция ясау түгел, әнине күрмәгән дә килеш, әнә, нинди уйлар уйлап өлгердем! Уйларның тезгене юк. Без яшь чакта әтинең авылда бер шәп йөгәне бар иде. Чын каештан эшләнгән. Хәтерлим: ул йөгәннән әле һаман да чи каеш һәм ат тире исе килә. Икесе бергә кушылгач, әти исе килә башлый иде...

Бер, ике, өч... Кеше үз теле белән «егерме өч» дип әйткәндә, нәкъ бер секунд вакыт уза, диләр. Өч мәртәбә шулай дип кабатларлык кына вакыт узса да, әллә ниләр уйлап бетердем. Анестезиологның эше беткәнне дә беләм үзем.

Бүген мин аларның икесен дә төшемдә күрдем. Үзебезнең авылдагы күл, имеш. Шул күлдә әни ак каз булып йөзә, әти дә каз кыяфәтендә. Менә бүрекле әнкә каз күл уртасына таба йөзеп китте һәм шулчак аның өстенә алагаем зур бөркет ташланды. Әткә каз бөркеттән дә җәһәтрәк булып чыкты, ул су өстеннән йөзеп түгел, очып диярлек әнкә каз янына барып җитте, ни арада бөркетнең башын чукып та алды. Каздан да зуррак булып күренгән бөркеткә охшаган кош су белән агып китте. Әнкә каз белән әткә каз, күңелле каңгылдашып, икесе бергә кушылды. Бераздан алар янына бер бәбкә каз йөзеп килде. Юк, җәмгысы җидәү икән. Тик җиденең берсе читтәрәк, оя янына йөзеп барырга бик теләсә дә, дулкын аны читкә этәрә.

Ул бәбкә каз әллә мин булдыммы икән?..

Бер, ике... егерме өч... Малаена егерме өч әле күптән түгел генә тулган. Үзе кебек озын буйлы, кара тутлы. Тик йөзе агарган инде, авыру кыяфәте кергән. Мин шулай дип уйладым да, егетнең күз бәбәкләрен ачтырып карадым, йөзен бармагым белән сыпырдым. Яшь әле, организмы да бетәшмәгән, йөрәге дә мунчалага әйләнеп бетмәгән. Моны аның яңакларыннан, ике як муеннан күреп була: бавыр таркала башламаган. Бавырга зыян килсә, гадәттә ике як муенда кызыл җирлектә дуңгыз колбасасындагы кебек ак таплар ялтырап тора. Каты эчкән ир-атның шулай була – муен ике якта ак майлы дуңгыз казылыгы кебек. Бу адәмгә бавырыннан начар хәбәр.

Хәер, егетне бик әйбәтләп хастаханәдәге белгечләр тикшерде.

Мин ясаган операцияләр инде берничә меңнән артты. Миңа чират торалар. Казанга күченеп киткәч тә, Чулманкалага еш кайтам. Болай гына да, аннары сирәк булса да, операцияләр дә ясап китәм. Монда һаман «хирург Байчуринны» онытмыйлар. Әнә, бер бабай «хирург Байчурин ясаса гына, пычак астына керәм!» – ди икән. Гаиләсе

гозерләнеп, Казанга ук килгән. Нишлим, бер ялымда чыгып киттем инде. Мине хөрмәт итәләр, зурлап «хирург Үтәшев» дип тә атыйлар, дидем. Хәзер шул хөрмәтне бер селтәнүдә үз кулларым белән юк итәсе була. Әгәр атасы гозере буенча малайны теге дөньяга озату карарына килсәм, мин үз-үземне кичермәячәкмен... Ә тегеләй мине кичермәячәкләр...

Ата кеше яңа гына үз губерналарында зур түрә булган. Күрәсең, андый кешенең малае наркоман булырга тиеш түгелдер... Язылмаган кануннар буенча да шулай бит. Наркоман атасын андый зур тәхеттә озак тотмаячаклар... Әле белеп өлгермәгәннәрдер, куймаган да булырлар иде. Бу илдә бигрәк тә шулай. Җитәкчегә хатын белән дә аерылышырга ярамый. Гашыйк булырга да. Шуңа күрә, гашыйк булып тинтерәтмәс өчен, тәхеткә утыруга аларга йөрәкләрен йонга төреп куярга туры килә. Шуның белән бергә миһербанлык, кече күңеллелек, олы җанлылык һәм кешелеклелек дигән сыйфатлар да калын йон эчендә кала. Сәвитләрдән калган мирас бу.

Минем алда бик авыр бурыч. Әни әйтә торган иде: «Улым, тормышта кыен хәлдә калсаң, миңа операция ясаган чакларыңны исеңә төшер... Сиңа бик авыр булды бит ул чакта! Мин беләм, улым! Алты абыеңны исеңә төшер шул чагында. Әтиеңне... Синең өчен дөньяда шуннан да авыр газап булмас, моннан да авыррак сораулар битәрләмәс сине. Шулай дип уйласаң, кыенлыкларны тиз җиңәрсең, алар моның белән чагыштырганда, барысы да вак-төяк кенә булып калыр», – ди торган иде.

Менә шуларны уйлап утырам хәзер. Әнинең киңәшен тотып... Шуңа күрә дә ошбу хикәятне сөйләр алдыннан мин әнинең йөрәгенә ясаган операция турында искә төшердем. Бу миңа берәр ак юл күрсәтер сыман иде: нишләргә? Үтәргәме бу түрә агайның гозерен, әллә гариза язып, эштән китеп барыргамы? Ул безнекеләрдән дә шалтыраттырды. Югыйсә, хастаханәгә андый авыруны кабул да итмәгән булыр идек. Махсус диспансер бар лабаса.

Хәер, бу бик зур сер, гомерлек сер булып калырга тиеш иде. Сөйләшү-килешү баштан ук шулайрак барды... Миңа карата куелган шартлар бихисап: малай якты дөньядан газап-сызлануларсыз гына китәргә тиеш. Әни кеше моның шулай икәнлеген белергә тиеш түгел. Чөнки бу гамәл ана хакына, аны исән калдыру өчен эшләнә. Әнисе исән калу өчен баласы вакытыннан алда китеп барырга тиеш!!! Кабахәтнең дә кабахәте син – язмыш. Имеш, аның әле тагын ике баласы бар, ул аларны аякка бастырырга тиеш... Усал, аяусыз тормыш дигәнең...

Әнинең киңәше дә әлегә ярдәм итә алмый. Кызык кешеләр инде сез – әниләр. Имеш, «бик авыр вакытларыңда операция өстәлендә мине җан бирде дип уйла»! Әни кырыс булган безнең.

Мин ясаган операцияләрнең барысы да уңышлы булды, күпме кеше исән-сау калды. Хәер, бу – рәхим-шәфкать түгелдер, мөгаен. Бу – эш, бу – минем һөнәр. Гиппократ анты биргән һөнәр ияләре бит без. Ләкин мин ул Гиппократны күреп белмим, мин әти белән әнине беләм, алар кешеләргә һәрчак ярдәмчел булдылар. Ул моң кебек, күңелдән, йөрәктән агылып чыга.

Аллага шөкер, минем киңәшерлек остазларым, өлкән дусларым күп булды үз гомеремдә. Наил Сәлаховичның бер сүзен гомер онытасым юк: «Менә син хирург буларак ничәмә-ничә гомерләрне коткарып калдың, ә сине берәр авырлык килсә, кем коткарыр соң? Шулай дип уйлап караганың бармы, Харис туган», – дип, алга фәлсәфи сорау куя. Наил Сәлахович минем кебек баш табиб булып кына түгел, дистә еллар министр урынбасары булып та эшләгән шәхес. Меңләгән кешеләр рәхмәтле аңа! Юкка гына, тиктомалдан гына бу хакта уйланмаган бит инде аксакал. Ләкин аның фәлсәфи теле тагын дәвам иттерә әлеге фикерне: хирург бары үзенә ышанырга тиеш. Син операция ясаганда, башка кеше белән киңәшергә вакытың да, җаең да булмаган кебек, андый чакта да һәрчак үз башың белән генә «киңәшләшә» аласың!

Бер, ике, өч... егерме бер, аннары егерме ике, егерме өч... Организм, юк, психика егерме бер көн эчендә урынына утыра. Егерме бер көн буена ихтыярыңны җыеп, тәмәке тартмасаң, әлеге бәладән сине баш мие үзе коткара – ташлыйсың. Никотиннан

котылу өчен башта өч көн кирәк... Өч һәм егерме бер... Адәм баласының организмы ул көннәрне үзе «исәпли». Бәлки, малайны наркотик тәэсиреннән егерме бер көн эчендә коткарып булыр? Мин җитәкләгән хастаханәдә психотерапия бүлеге бар. Шуңа күрә миңа килгәннәр. Махсус диспансерга салсалар, беленәчәк бит наркоман икәнлеге... Мин инде ничә еллар буена хирургтан психотерапевтка әйләнеп беткәнмен. Бер көнне үлем хәлендә бер атаклы актёрны алып килделәр. Затлы, олуг актёр! Халыкның яраткан, сөекле улы. Ошбу актёр халыкның бәгырендә. Бер тамчы су да йота алмый бахыр. Тамагыннан үтми. Үләргә әзерләнгән. Аны шундый кыяфәттә күреп, мин үзем дә «үләргә» җыендым бугай. Ничек булса да, коткарып калырга кирәк! Бүлек табиблары бар көчләрен куя аны аякка бастырырга. Ләкин тамагыннан су үтмәгәч соң инде?.. Ябыккан, бетәшкән. Мин дә бетәшә яздым. Ләкин табиб сырхауның авыруына караганда да көчлерәк булырга тиеш. Монысы да Наил Сәлахович сүзләре. Алтын сүзләр. Актёр янына йөгерәм. Утыз градус эссе август көне. Палатага җиткәнче тамак чытырдап кибә. Әллә агайның сусыны миңа күчте инде – үлеп эчәсе килә. Авыруның тумбочкасы өстендә ике шешә шифалы су тора. Янында утырган театр директоры алып килгән, ахры. Ул Алла бәндәсе көн-төн актёр янында. Ничек аякка бастырырга белми... Хәер, без барыбыз да күренекле актёрның гомере өзеләчәк, дигән уй белән килешкән идек инде. Шешәләр кояш нурларында ялтырап утырып тора. Авыру ул якка борылып та карый алмый. Шулчак мин хәйләгә керешәм, дөресрәге «психика» белән эш итәргә дигән карарга киләм: берни булмагандай шешәләрнең берсен тавышланып ачам да шыбырдатып, тустаганга агызам, икенче тустаганга да салам. Үзем юри тәмләп эчәргә керешәм, рәхәтлектән төрле тавыш-ымлыклар чыгарган булам, кыскасы, актёр янында «артистланам» да шундук икенче тустаганны аңа сузам: янәсе бик кызу, эссе бит, тамагыңны чылатып куймыйсыңмы? Актёрым берни булмагандай, авыруын да онытып, аны кулына ала һәм миңа карап үзе дә сизмичә голт итеп эчеп тә куя! Авыруның күзләре шар, директорыбыз шатлыгыннан тораташ булып каткан. Ул, тотлыга-тотлыга: «Харис! Карале! Эчтем бит!» – ди. Мин тустаганга тагын шифалы су агызам, анысын инде актёр абыем үзе «белеп» йота. И сөенүләр шул чакта. Директор әле мине, әле агайны кочаклый. Үзе елый-елый: «Абый, без сиңа кәфенлекләргә кадәр әзерләп куйган идек бит инде!» – ди. Мин көләм, кәфенлекне алдан хәстәрләп куйган кеше, гадәттә, озак яши, диләр. Әнә, туксан яшьлек әбиләрне кара син, тәгәрәшеп йөриләр. Аларның кәфенлекләре, үлемтеккә дигән күлмәкләре, садака акчалары сандык төбендә ята-ята күптән күгәреп беткән инде. Ходайның хикмәте диген...

Бер, ике, өч... егерме бер... Мин йозаклы палатаны ачып керәм. Малайның күзләре акайган, рәхәтлек дөньясында тирбәлә. Тагын доза эләктергән, тәгаен «капкан» бит бу дигән уй мине ток куыргандай итә. Кем алып кергән?! Кем биргән? Кем эше бу? Кизү табибны таптырам. Таң тишегеннән атасы килгән булган икән. Кабинетка кире әйләнеп кергәндә, Фәлән Фәләнович кабул итү бүлмәсендә үзе басып тора иде. Ул миңа авыз ачарга ирек бирмәде: «Улымның шулай газапланганына түзә алмыйм! Сүз әйтмә!» Мин дәшмим, бары эчтән ачы итеп сүгенәм. Баш табиб булып билгеләнгәч, «эчтән» генә сүгенергә өйрәндем. Аны берәү дә ишетми, белми, ә мин рәхәтләнеп күңелне бушатам. Ә менә операция ясаганда җырлавымны, йә берәр көй көйләвемне бар кеше дә белә, андый дан таралганын үземә дә ишеттерәләр. Операция алдыннан әүвәл пациенттан нинди көй яратканын сорыйм, йә туганнары аша белешәм дә шуны көйлим. Андый чакта пациент авыртуны да, вакыт узганын да сизми икән. Кайбер операцияләр гомуми наркозсыз гына ясала торган иде. Тавышың бар синең, диләр миңа. Әни кечкенә чакта җырчы булуымны теләгән, әти каршы килде, табиб буласың, диде. Ул чакта, кем булырга икән дип икеле-микеле уйлар белән йөргәндә, сукыр эчәгем шартлап, миңа район хастаханәсендә ашыгыч операция ясадылар. Соңыннан хирург: «Күлмәк белән тугансың икән, малай! Чак исән калдың!» – диде. Чыгып киткәндә, баш табиб та: «Хирургка рәхмәт әйт! Ул булмаса!..» – диде. Мин шул вакыйгадан соң табиблыкка укырга дигән ныклы карарга килдем. Яшь чакта язучы да буласым килә иде, кешеләргә әйтер сүзем күп минем. Тик менә күрәсез, гап-гади бер табиб,

хирург мин хәзер. Кешеләр син гади хирург түгел, синең кулың сихәтле, диләр диюен. Алла белә, бәлки, шулайдыр. Тик менә хирургтан психотерапевтка әйләнермен дип, башыма да китереп карамадым. Язмыш синнән сорап тормый икән. Хәерле булсын, әлегә чаклы барысы да яхшы бара кебек. Иде... Бу хәлгә чаклы. Егерме өч яшьлек егетне ничекләр итеп теге дөньяга озатырга тиеш инде мин?!

Баланың интеккәнен күреп, атасыннан бигрәк, анасы өзгәләнә икән, дидем. Әти кеше чарасызлыктан шундый карарга килгән. Әнисе белми, әлбәттә. Сызланмасын иде инде, бер җире дә авыртмасын үлгәндә, ди. Үзе белми дә калсын ничек китеп барганын дип гозерләнә.

– Ашыкмыйк, дәвалап карыйк! – дип, мин мең дә беренче мәртәбә үз сүземне кабатлыйм.

– Булмый! Булмаячак! – ди ата кеше катгый итеп. Баксаң, алар Германиягә дә барып караганнар икән. Зур акчалар түккән түрә абзый. Булмый, соң, дип кайтарганнар. Берничә мәртәбә Мәскәүгә дә барганнар, анда да кеше итәселәренә ышандырмаганнар. Вакытны туктатырга мөмкин түгел шул аны. Кирегә дә җибәреп булмый...

– Мин синнән монда гына түгел, теләсәң, ил күләмендә зур кеше ясыйм! – дип ялвара ата кеше. Хәер, хәзер үтенүнең әсәре дә юк тавышында. Боера ул. Боерык бирә.

Боерырлыгы да бар. Малай аркасында хатыны да юкка чыгачак, ике кызы белән утырып калачак абзыең. Аңлыйм мин аның хәлен. Ләкин ул аңламый: мин кешене үтерүче түгел, дәвалаучы, терелтүче ләбаса!

– Мин сине акчага күмәм! – ди ата кеше. – Ышанмасаң, авансны бүген үк китереп бирәм!

Акча... Димәк, мин хәзер акчага эшли торган киллер булып чыгам икән! Доктор Үтәшев түгел, Киллер Үтәшев! Үсә-ә-әәәм!

– «Доктор Байчурин» дип, мине бер язучы дустым атый. Шуннан ябышып калды инде бу. Хәзер оныгым Марат та яратып, үз итеп «Доктор Байчурин!» дип йөртә бабасын. Ләкин миңа аның сузып: «Ба-а-ааабай!» дип әйтүе күбрәк ошый. Монысы күңелне бигрәкләр дә рәхәт чеметеп ала инде.

Оныгыма киләсе атнада унөч тула икән инде. Киявем белән кызым, дөнья кубарып, малайның туган көнен уздырабыз, дип йөриләр. Булат үзе каршы. Скутер алып бирсәгез, шул туган көн булыр иде, ди. Әбисе «унөч саны никтер күңелемә ятып бетми, әйдәгез, Аллаһ ризалыгы һәм улыбызның саулыгы өчен Коръән ашы уткәрик», – ди. Шул рәвешле өч төрле фикер, нәкъ экияттәге кебек «аккош, кысла һәм чуртан» өчесе өч якка тарта. Минем дә фикерне беләселәре килә. Әлегә мин ныклы сүземне әйткәнем юк. Хатыным Хәмидә фикере барыбер өстен чыгачак. Ул намаздагы кеше, аның сүзенә каршы килергә берәү дә җөрьәт итмәячәк. Һәм… дөрес тә әйтә бугай. Яшүсмергә бу яшьтә Аллаһ фатихасы бик кирәк вакыт. Яшәсен минем Хәмидәм! Өч кызымның затлы анасы!

Тагын ун елдан яраткан оныгым Булатка егерме өч яшь туласы, Аллаһ боерса. Доктор кеше, нигәдер соңгы вакытта Аллаһны еш искә төшерә башладың әле, дип, миңа төрттереп тә алгалыйлар. «Төшерерсең, минем хәлдә калып карагыз әле сез», дип уйлыйм эчтән генә.

Наркоман егетнең әнисе килде. Ата кеше аның үзен генә ничек җибәргәндер, дип уйлап та бетермәдем, ул моны сизгәндәй, миңа: «Белми ул. Качып килдем!» – диде. Элек (баласы бәлагә тарганчы, мәсәлән) ул бик чибәр булгандыр. Кара тутлы, калын иренле, зур күзле матур ханым. Хәзер шактый бетәшкән, йөзе сулган, күзләре дымлы да, моңлы да. «Доктор, үләчәкме ул?» – дип, миңа шул күзләре белән тилмереп тә, өметләнеп тә карый. Нинди табиб газиз әнкәсенә «әйе» дип баш каксын инде. «Юк!» – дим ашыгып. Ашыгып әйтәм. Әйе, алдан әйтәм шул – кем белә?! Хәле авыр, исән калмас инде. «Юк!» – дип кабатлыйм мин тагын һәм бу юлы тавышым каяндыр күкрәктән чыга. Ул тавышны «ишетеп» үзем дә сискәнеп китәм. «Аның күзе төшеп йөргән кызы бар идеме?» – дип сорыйм башка ни әйтергә белмәгәннән. «Бар!» – ди ана кинәт кычкырып диярлек. – Зөһрә исемле!» Аның әлеге сүзләре баш миемне

отыры эшләтеп җибәрә, акыл чүлмәгенә төрле-төрле фикерләр коела, мин аларның иң саллысын гына сайлап алам да уйга чумам. Авызымны ачып сүз әйтмәкче булам. Ана мине шундук аңлап ала һәм: «Алып киләм! Монда чакырттырам мин аны!» – ди. Ашыгып чыгып китә.

Миңа чираттагы операциягә керергә вакыт. Ассистент кыз алдан ук авыруны «өйрәнеп» куйган, миңа аның нинди җыр яратканын пышылдый. «Җидегән чишмә» икән «Җидегән чишмә» булсын. Минем яраткан җырларымның берсе. Олы яшьләрдәге ир-ат ул, бик сызлана. Әле тагын үзенең шартларын да куярлык хәлдә икән: «Миңа наркоз ясамагыз! Барыбер үләм! Йоклаган килеш китеп барасым килми!» – ди.

«Наркоз ясамыйбыз, борчылма. Үлгәнеңне белеп ятарсың, яме, агай!» – дип шаяртам. Күрәсең, минем шаяртып әйткән сүзләр аны куркытып җибәрә. Ул: «Ничек ясамыйсыз!» – дип, киресен сөйли. «Соң... Үзең кушканча эшлибез!» – дим исем китмәгән кыяфәттә, ассистентка күз кысканны күрми теге. Мин аның ашказаны өстеннән кисеп җибәрәм. Чишмә кебек кайнар кан бәрә. Кулларым үз эшләрен белә, берни булмагандай акрын гына җырларга керешәм:

«Җидегән чишмәләрдә җиде улак, җиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый.
Шул чакларда бигрәк,
шул чакларда бигрәк ямансу.»

Бу җырны мин ул дөньяга чыкканчы ук белгәнмендер кебек. Әни дә, әти дә белгәндер. Җиде – безнең гаилә өчен кадерле сан. Без гаиләдә нәкъ җиде малай булгангадыр инде. Әни кыз бала көткән, ә без бер-бер артлы дөньяга малай кыяфәтендә килгәнбез. Әтине сөендереп, әнине көендереп. Хәер, малайлар гына булганга мин әнинең уфтанганын беркайчан да ишетмәдем.

«Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, йөзек салдым.
Җидегән йолдыз күреп калсын дип,
Җанкай Җанаш күрсен дә куансын
Вәгъдәләрем булып,
вәгъдәләрем булып калсын дип.»

Мин егетнең әнисенә вәгъдә бирдем. Нинди акыл белән әйткәнмендер ул сүзләрне?! Хәзер ни кылырга белмим. Ичмаса, хастаханә янына ук берәү кран китереп куйган. Атасына «Малаеңны теге дөньяга җибәрергә ярдәм итәрмен», – дип вәгъдә бирмәдем бирүен. Ә анасына вәгъдә итеп ташлаганмын. Ашыгычлык белән... каушаудандыр инде... Кран тырылдый да тырылдый. Хәер, искә төште: тышкы яктан кайбер урыннарда кирпечләр купкан, эшчеләр шуларны рәтли, тәртип ясый.

Теге бай абзый мин югында урынбасар белән сөйләшеп, бригада китерткән. Бушка эшләп бирәм, кирәк булса, бөтен больницаңны яңадан сүтеп җыя алам, ди. Ризалык биргәне өчен урынбасарны эт итеп сүктем, эшчеләрен дә бер куып җибәргән идем инде, тагын килеп басканнар. Машинадагы кран-күтәргеч, әнә, берсен өченче катка кадәр менгергән. Пәрдә аша аның шәүләсен күрәм. Нәкъ операция барган вакытта бит, җитмәсә! Хәер, эшне тәмамладым бит инде. Хастам: «Тәки наркозсыз гына ясадың бит, ә, доктор!» – ди. Ассистент кызга күз кысам, ә авыруга: «Әйе, болай гына, вак-төяк, местный гына!» – дим һәм савыгуын теләп, аны озатырга кушам. Операциясе уңышлы чыгып, хәле яхшы булса да, реанимациягә салырга диган карарымны әйтәм; күзәтү астында ятсын әле берәр тәүлек. Алып киткәндә, хәлсез тавыш белән җырларга маташа тагы үзе, миңа рәхмәт йөзеннәндер инде: «Җидегә-ә-әәән чишмәләрдә-ә-ә-әәә...» Җыр шунда өзелә, ә агайның гомере әле озын булачак...

Егетем үтереп «доза» сорый. Бирермен, дидем. Ә үземнең башта башка план өлгереп килә. Зөһрә атлы чибәркәй килеп җитүгә, минем планны тормышка ашырырга

керештек. Кыз бик ушлы иде, үзеннән ни таләп ителгәнен шундук аңлап алды. Аны теге кранның басмасына бастырдык та дүртенче катка күтәрдек. Ул бик матур итеп киенгән, елмаерга, көләргә куштык. Тәрәзәдә нәкъ канатлы фәрештә кебек сөйгән кызы пәйда булгач, егетем имәнем китте. Аптырап бер аңа карый, бер миңа. «Глюка түгел бу! – дим. – Сәлам, диген. Кул болга.»

Кул болгый, аңа каршы кыз матур итеп елмая. Ике бармагын иреннәренә куя да «үбешү» тәмен аңа таба очырып җибәрә. Монысы да шуны кабатлый. Егетемә җан керә башлады. Мин кранны алырга куштым. Шәфкать туташлары шул арада кереп, егеткә тынычландыра торган укол кадап өлгергәннәр иде. Ул йоклап китте.

Уянгач, беренче эш итеп тәрәзәгә бара, бусагага менмәкче була, Зөһрәсен эзли. Аннары, «теге хәлне «глюка» гына икән, дип уйлаптыр, бик күңелсезләнә, уйга чума, үз эченә йомыла. Вакыт безнең файдага эшли, мин бер мизгелне дә ычкындырырга тиеш түгел, һәрбер секунды кадерле. Егеткә «доза» сузам. «Йә чын Зөһрә белән күрештерәм, йә шушыны аласың. Сайла!» – дим. Ул минем кулымны читкә этәрә. Пышылдап кына: «Глюка» булдымы ул?» – ди.

Телефон шалтырый. Кабул итү бүлмәсеннән. Анда мине егетнең атасы белән анасы көтеп тора икән. Сәркатип кызга аларны бүлмәгә кертеп утыртырга кушам.

Кабинет ишеге бераз ачык калган. Анда ата белән ананың сөйләшкәнен ишетәм. Хатын: «Син генә гаепле! Байыйм, имеш. Байыйм да барысын да сатып алам! Иң зур түрә булам! Ул наркотикларыңны өйдә качырып саклап, үзәгемә үттең. Өйдә яшүсмер улың барын онытып! Син генә гаепле! Менә хәзер сатып ал инде! Малай сатып ал нәкъ шундый! Нәкъ минем улым кебекне! Белеп тор, кызлар белән ялгызың гына утырып калачаксың! Мин бу хәлгә түзеп тора алмыйм!» Ата кеше аны тынычландырмакчы була, ахрысы: «Бар да әйбәт булачак, акыллым! Түз инде, түз бераз!» Ләкин хатын тынычлана алмый: «Баланың шулай газапланганын күрә торып түзәргәме? Эшлә берәр нәрсә! Азаплана бит! Тилмерә, интегә бит йөрәк парәм! Син имансыз, син кеше түгел, син иблис! Ул наркоталарыңны, бандит дусларыңны полициягә барып әйтәм! Бүген үк! Белеп тор!»

Мин бүлмәгә кермим, лифт белән реанимация катына күтәреләм. «Җидегән...»не көйләп, операция ясаган хастамның хәле яхшыра. Шаярта да башлаган, җырың наркоз кебек тәэсир итте, ди.

Кабул итү бүлмәсенә кире әйләнеп килгәндә, бүлмәмдә һаман шул тавышлар. Тыңлап тору яхшы гамәл булмаса да, колакны томалап куеп булмый. «Нигә монда кадәр, Казанга хәтле алып килдең аны? Үзебездә синең сүзең яхшырак үтә бит?» – дип тинтерәтә хатын ирен. «Үзебездә бу турыда белдерергә ярамаганын чамаламыйсың что ли?! Мин сезнең өчен тырышам бит!» – ди аңа каршы ире. «Бик тырыштың инде! Булдырдың!» – монысы хатыны тавышы. «Ник килдең монда балаларны калдырып? Мин сиңа өйдә генә көтәргә куштым!» «Радик минем өчен бала түгел мәллә?»

Бер, ике, өч... Егерме өч. Егерме өч яшьтә синең өчен мең чакрым ара үтеп, хастаханәгә килүче сөйгән кызың булу яхшы инде ул, дип уйлый идем. Баксаң, ата кеше Зөһрәгә зур акчалар тәкъдим иткәнен ишеттем. Ничектер күңелсез булып китте. Мин һәрчак үземнең оныкларымны уйлыйм: дөнья гел акчага корылып бара. Әшнәлек, туган-тумача һәм акча. Намус, әхлак... мәхәббәт. Мине җәмгыятьтә мәхәббәтнең арткы планга күчүе ныграк борчый бугай. Мәхәббәт ул егет белән кызның кочаклашып үбешүе генә түгел, ул – бөек төшенчә. Әти-әнигә, балаларга, хатынга карата булган мәхәббәт. Ватан, Илгә карата булган мәхәббәт ни хәлдә? Белмим анысын, мин гап-гади табиб, мин сигез оныгымның яраткан бабасы... Мәхәббәт турында хәзер китапларда гына язалар бугай инде. Һәм бездән китеп барган Ватан турында да... Мәхәббәт, сөю... Кеше шуны шашынып укый. Чөнки һәркемнең тормышта булмаганны «татып» карыйсы килә торгандыр инде... Болай уйлап, мин ялгышамдыр, бәлки? Ялгышсам гына ярар иде, Ярабби! Ә менә бит әле! Аллаһка карата мәхәббәт!.. Анысын акчага да сатып алып булмый. Монысы кан тамырлары буйлап ага... Пенсия яше җиткәч, намазга утырган хатынымны күз алдына китерәм. Шуның аркасында аның йөзендә кыз чакта,

чибәр, матур вакытларында булган иман нуры сакланып калды... Яраттыра, һәркемне гашыйк итә торган нур... Ходай безне шул нурдан аермасын! Аны бернинди алтынга да алыштырып булмый!.. Җан тынычлыгын да алыштырып булмый...

Бер, ике, өч... җиде. Хастаханәдә ыгы-зыгы башланды. Мин тавыш килгән якка атылдым. «Бикле палатада яткан Радикка берәр хәл булгандыр, йә үлгәндер егетем?» – дигән уй баш миен яндырып алды. Үзебездәге бер түрәдән шалтырату булмаса, мин андый авыруны кабул итәргә тиеш идемме соң? Әүвәл аның наркоман икәнен әйтмәде бит атасы?! Юлламасы буенча безнең психотерапия пациенты иде ул. Мин каты итеп баш бармак белән кабыргага төрттем. Авырттырырлык итеп. Үзең турында уйлама, Үтәшев!

Үзем хакында да уйлыйсы булган икән шул: егетем тәрәзәдән сикергән! Шунысы табышмак: ул беркайда да юк! Тәрәзә турысындагы асфальтта кан җыелып тора. Ә Радик кайда?! Аның мәете, үле гәүдәсе кайда соң?!

Урамны, ишегалдындагы кедр агачлары паркын бер кат әйләнгәч, бүлек мөдире белән янә палатага керәбез. Тәрәзә тышкы яктан да бикле иде, кемдер ачкан, димәк. Мин, бусагага сузылып, аска карыйм: инде әле генә күргән кан таплары да юк – сукырайдым, ахры!.. Мине инсульт бәрде бугай, гәүдәне сизәм, ә аяк-кулларны юк. Үзем һаман бусага аша тышка үрмәлим икән. Нindидер дулкын мине дүртенче каттан урамга алып атты.

## Соңгы сүз алдыннан

Теге чакта тәрәзә астындагы асфальтта утын әрдәнәсе кебек итеп җылыткыч сүсләре өелгән иде. Ремонт ясаучы эшчеләрдән калган. Мин шул «әрдәнәгә» туры килдем. Кабырга да сынмады хәтта!

Хәзер баш табиб булып эшләмим инде. Элеккеге ментлар булмаган кебек, элекке табиблар да булмый. Әлеге һөнәрең гомергә. Табиб булып эшләвемне дәвам итәм. Йөрәктә дәрт, беләктә көч күп, дигәндәй, һәр яшьнең үз матурлыгы бар – мин нәкъ менә шундый матур яшьтә. Йөрәк унсигездә булгач, ни кыласың инде, дим Хәмидәгә дә. Мин дә унсигездә, ди хатыным. Аннары «унсигездәге» әбием намаз укырга әзерләнә башлый.

Ә мин һаман да «доктор Байчурин».

Оныгым: «Доктор Байчурин! Зур үскәч, минем дә табиб буласым килә», – ди. Мин, Үтәшев, аңа шундук җавап бирмим. Чөнки һаман башка дөньяда яшим генә түгел, «йөзәм» кебек әлегә. Күптән түгел генә Радик белән Зөһрә килеп киттеләр. Теге чакта хастаханәдән Радикны шушы кыз урлаган икән инде. Кран басмасына утырып менгән дә... Өйләнешергә җыеналар. Икесе дә бәхетле. Аларны күргәч, мин икеләтә бәхетле.

Оныгымның соравына каршы әчтән генә: «Бәхетле кеше булып яшисең килсә, булырсың, улым!» – дип җавап бирәм.

## Соңгы сүз

Аллага шөкер, Әнием... фани дөньядан үз үлеме белән китеп барды. Мин ясаган операция бик уңышлы булды. Әти дә вафат инде. Эчем пошкан саен мин аларның каберләренә барам. Шуның өчен махсус рәвештә догалар өйрәндем. Укыйм. Быел беренче мәртәбә бөтен шартын китереп ураза тоттым. Аллаһ кабул итсен!

Радиодан җыр ишетелә:

«Сез каласыз инде, без китәбез

Без китәбез ерак, без китәбез ерак илләргә.

Сез каласыз инде, без китәбез..».

Китсәк тә... безнең буынның миһербанлыгы, кешелеклелеге калсын иде яшьләргә, балаларыма, оныкларыма калсын иде дип уйлыйм.



Нурания
Гыйльметдинова

# ЙӨРӘКНЕҢ ДҮРТ КЫЛЫ

ХИКӘЯ

*Гомерләрен кеше сәламәтлеген саклауга багышлаган якташларым Вәлимөхәммәт Нурмөхәммәт улы Габдрахманов һәм Зәрә Гали кызы Габдрахманованың якты истәлегенә багышлыйм.*

Көтүләр куылып, эшкә йөрүчеләр иртәнге чәйләрен эчеп, кайсы кая таралышкач, җәйге авыл тагын бер тынлыкка чумып ала. Кичә караңгы төшкәнче уйнаган бала-чага әле чайрап, чоланнарда йоклап ята. Килен-улларын эшкә озаткан карт-коры да уйнак оланнар торганчы дип, бераз гына баш төртеп торган вакыт бу. Эш гөрелтесе авыл кырыендагы фермага, көтүлекләргә, болын-кырларга, техника паркларына күчкән чак. Ара-тирә генә йә арбалы ат, йә машина үтеп китә дә, артыннан әллә никадәр тузан болыты күтәрелә. Әнә зур тизлек белән олы урамга килеп кергән «ГАЗ» машинасы хастаханә тыкрыгына борылды. Кайчандыр буялып та, хәзер нинди төстә булуы да аңлашылмаган зур агач капканың өстенә «Үсәли участок больницасы» дип язып куелган. Баганаларга бәйләп куелган атлар ялкау гына печән чемченә. Кайбер арбаларда ат җигүчеләр йокымсырый. Машина капка каршына килеп туктады. Бу инде хастаханәгә җитди авыру алып килгәннәр дигән сүз. Ни дисәң дә, бөтен тирә-юнендә машиналарны бармак белән генә санарлык. Юк-бар сәбәп белән машина куып йөрмиләр.

Үсәли участок больницасының баш врачы Дружков Борис Константинович – рус кешесе. Менә биш ел чеп-чи татар авылында эшләү дәверендә ул – татарчага, ә больница эшчеләре урысчага өйрәнәләр.

Шуңа күрә Үсәли больницасында санитар апайлар элеккечә бүлнис дип, кәлидүр, әбрәкәй, кәкәй савыты дип түгел, Борис Константинович кебек культурный сөйләшергә тырышалар. Төнге сменасын көндезге санитаркага тапшыручы тезеп китә:

– Горшукларны дезинфекцияләргә раствор җитмәде, Мәсер килгәч (сестра хозяйка Мәсрүрәгә шулай дәшәләр), санпрепаратлар алып ясарсың, туалетка да куярсың, җәме. Хирургиядәге бальнуйларның куйкыларын заправит итеп бетердем, – һәм ул сумкасында буш шешәләр шалтыратып китеп барган җиреннән санитаркага борылып, тиз генә икенче вазифа да йөкли:

– Дружков операциядә, мине эптиккә даруларга җибәрәләр, каридурны юып бетерерсең. Машина көтә, малай, бегом чаптым.

Такта белән пөхтәләп тышланган бу бинаның зур тәрәзәләре, биек баскычлары, матур кәрнизле, күп морҗалы калай түбәсе элекке алпавыт утарын хәтерләтә. Баскычтан менгәч, ике якка ачыла торган зур ишек өстенә «Үсәли участок больницасының авыруларны кабул

итү бүлеге» дип язылган такта эленгән. Ишек һаман саен ачылып-ябылып тора, кешеләр керә-чыга. Көньякка таба бераз читтәрәк, киртә буйлый бер рәт булып каеннар тезелеп киткән. Шул каеннар күләгәсендә бер егет утыра. Баш табиб операциядә, тиз генә булмас, диделәр. Шушы ике-өч сәгать эчендә бөтен персоналны күз алдыннан үткәрде инде егетебез. Әле ишегалды буйлап йөреп алды, әле гаражга барып килде. Киртә кырыеннан башланып киткән болын, елганы да күзәтеп торды. Искиткеч матур урын.

Шулчак баскыч тирәсендә ниндидер тавышлар ишетелеп китте, җанлану булып алды. Егеткә кирәк баш табиб операциядән чыгып, баскыч кырыендагы эскәмиягә утырган икән. Шунда ук аның янына бер ир-ат килеп басты да табибны шапылдатып кочты, кулларын кысты. Алар нәрсәдер сөйләшеп алдылар һәм теге ир-ат родильный тәрәзәсенә таба йөгерде. Баскычтан менә башлаган баш табибны ашыгып килгән егетнең тавышы туктатты.

– Исәнмесез, Борис Константинович. Мин сезне көтә идем. Менә. – Егет, өлгереп калыйм дигәндәй, тиз генә кулындагы кәгазен баш табибка сузды. Ачык калган ишеккә бер карап алгач, Борис Константинович кәгазьне укый башлады. Арыган кыяфәте ачылып китте, хәтта йөзенә елмаю кунды һәм ул егетне ияртеп, каен күләгәсендәге эскәмиягә таба атлады.

– Как күнелсез башланган кюн, как күнелле дәвам итә. Значит, егет сез безгә эшкә киләсез. Якши, якши. «Габдрахманов Вали-мухамет Нур-муха-ме-тович. Студент Казанского мединститута, врач стоматолог», – дип укыды ул кәгазьдән.

– Интернатураны сездә узарга булдым. Мин Катмыш авылыннан, туган авылга якын бит, – дип, эшкә дигән сүзгә төзәтмә кертергә ашыкты егетебез.

– Дополнительно нинди курсларыгыз бар, Вали Нурмиевич?

Вәли кызарыбрак куйды, бөтен тирә-якта дәрәҗәле баш табиб Борис Константиновичның аны зурлап әтисе исеме белән дәшүе шаярту кебек тоелды. Тик баш табиб тамчы да шаяртмыйча, аңа коллега итеп карап, җавап көтә иде.

– Өч ел травматология курсларын өйрәндем, шуның буенча РКБ га дежуркаларга йөрдем, Борис Константинович. Тагын әле безнең курсны яңа рентген аппараты белән эшләргә дә өйрәттеләр, ул дипломга да язылды, – диде ул имтиханда җавап биргән кебек.

Баш табибның шатлыгы эченә сыймыйча, йөзенә чыкты.

– Сез просто находка безнең больница өчен. Но мин сезне хәзер үк эшкә чакыра алмыйм әле, Вали Нурмиевич.

Вәли тагын кызарды, тик каушавын, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, сорарга ашыкты:

– Нигә, Борис Константинович?

– Шуңа, Вали Нурмиевич, авыл кешеләре тешне лечить пустяк эш дип саныйлар. Алар тешне только удалить киләләр. Сез моны итак легко сможете, дип беләм. – Бу сүзләрне әйткәндә, ул егетнең озын буена, киң җилкәләренә күз ташлап алды. – Безнең больницада стоматология кабинеты юк. Безгә тешне лечить кирәк. А ведь сәламәтлек тештән, авыздан башлана. Слава Богу, моя мечта сбывается. Сез районда бераз практикуйте. Мин дә анда барганда, райздравка буду заходить. Теш кабинетын оборудуем и монда эшли башлыйсыз.

Баш табиб әйтәсе сүзләрен шулай татарчалы-русчалы ермачлап чыккач, егетебез җиңел сулап куйды. Берникадәр районда яшәп һәм эшләп алуга гына түзәргә була. Юкса ул, бу больницага эшкә алмыйлар, дип борчылган иде.

Кайту ягына атлый башлаган Вәлигә Борис Константиновичның:

– Гафу, ещё вопрос можно? Как у вас дела с гинекологией? – дигән соравы егетнең аяк атлауларына кадәр буташтырып җибәрде. Ул аптыраудан үзенең русчага күчкәнен дә сизми калды:

– В смысле?..

– А в самом прямом смысле, Вали Нурмиевич, в самом прямом... – Баш табиб бераз уйланып торгач, шушы участок больницасына караган авылларда елына

400 дән артык бала тууын, гинекология белән бәйле операцияләр дә күп ясалуын әйтте. Акушер хатынны батыр, молодец хатын, дип мактады. Тик бала тудыру гел әйбәт кенә узмый. Менә бүген дә өч сәгать буе операция ясарга туры килгән. – Эх, монда көтеп торганыгызны белмәдем, операцияне карарга алып керә идем. Уникаль очрак. Авыл җирендә гел кесарево сечение ясап тормыйсың. Казанда укыганда, бөек акушер-гинеколог Евгений Эдуардович Гаак өйрәтте мине мондый операциягә. Әтием дә Алабугада хирург бит минем – Константин Дружков. Ялларга кайтканда, ул ясаган операцияләрдә катнаша идем. Хәзер менә биш ел инде шул операцияләрне үзем ясыйм. Кул эшли-эшли остара. Онытмагыз, Вали Нурмиевич, хирург һәр нәрсәгә әзер булырга тиеш. Бу минем эш түгел, дип торсам, тагын бер ярты сәгатьтән әнисен дә, баланы да алып калып булмый иде инде. Районда гел тешне генә өйрәнеп ятмассыз, башка кабинетларга да кереп, врач широкого профиля булып, тәҗрибә алып кайтырсыз.  Авыл больницасының спецификасы да шунда: син бөтен төр авыруларга да беренче ярдәмне күрсәтергә тиешсең. Беренче ярдәм кайчакта катлаулы операциягә дә әверелә.

Очрашу шулай төгәлләнде. Вәли җиңел һәм җитез адымнар белән болын ягына таба китте. Атлы юлчыларга, сирәк булса да очраштыргалаган машиналарга өмет тотып, тузанлы юлдан атламаска булды. Дружков белән очрашуны, аның һәр сүзен кабат күңеленнән үткәреп, югары классларга Үсәлигә йөргән таныш болын юлыннан кайтасы килде егетнең...

Июль аенда район больницасында практика узган, август башында Үсәлидә эшли башлаган Вәлине Дружков кая гына йолкымады: операцияләрдә ассистентлык итүне мәҗбүри итеп куйды, теш кабинетын җиһазлаттырды, теш дәвалауны ныклы контрольдә тотты, алынырга тиешле тешләрнең снимокларын таләп итте. Ашыгыч ярдәм белән чыгып киткәндә, җай туры килгән саен Вәлине һәрвакыт үзе белән йөртте. Вәли Нурмиевич (хәзер инде аңа Үсәли больницасында гына түгел, бөтен тирә-як авылларда, районда да шулай дәшәләр) бу өйрәтүләрне эссе көндә йотлыгып су эчкәндәй тәненә, миенә һәм кулына сеңдерә барды. Кулына дигәннән, бер атнаны егетебез Катмышка кайткач, печән әзерләшеп кулларын чабартып, кытыршыландырып килгән иде. Иртәнге киңәшмәдә Борис Константинович егетнең кулларына игътибар итте. Алар тупасланган-тырналган иде.

– Вали Нурмиевич, хәзер үк прачкага барыгыз, берничә наволочка юыгыз, дежурный медсестрага барып, кулларыгызны йомшарту процедуралары башкарыгыз, бер сәгатьтән мин сезне ординаторскида көтәм, – дип боерды. Башкалар берни аңламый калсалар, Вәли бик яхшы аңлады сүзнең ни турында барганын. Кызарып чыгып киткән, прачкада кер юып кулын йомшартып кергән Вәлигә ординаторскида Дружков хирург куллары турында институт курсыннан бер лекция тыңлатты һәм соңыннан йомгаклап куйды:

– Врач куллары күрәк-сәнәк тотарга тиеш түгел! Врачның кул-бармакларындагы һәр нерв күзәнәге врач үзе үлгәнче аңа хезмәт итәргә тиеш.

Вәли өч айлап чамасы эшләгәч, алар икесе беренче җитди операцияне ясадылар. Хәтирә атлы ханымга ясалды бу операция. Борис Константинович аны Казанга да җибәреп карады. Андагы дуслары авыруның азынуын әйтеп кайтардылар. Димәк, соңга калырга ярамый. Бу авыруның хәтәр ягы да шунда шул: ул мәкерле. Башта авыртулар белән борчымый, әкрен генә үз эшен эшли. Беренче килүендә Хәтирәне Борис Константинович тикмәгә генә бәби табып үстерергә өндәмәгән иде. Сөт бизләрендәге тыгызланулар кайчагында хатын-кыз бәби табып имезә башлагач тарала, юкка чыга торган була. Бу, димәк, андый очрак түгел. Ә мәкерле шеш. Андый операцияләрне ул әтисе белән күп тапкырлар ясады. Бу юлы ул үзе генә ясар. Юк, Вәли Нурмиевич белән бергә...

Вәли Нурмиевич мондый авыруларга хирургларның бик алынырга теләмәүләрен, бу тар профильдәге белгеч эше булуын бик яхшы аңлый.

Яшь табибның сораулы карашына баш табиб:

– Нормально булачак, әлеге хатынның өч баласы бар, аларны үстереп бетерерлек гомер бирергә кирәк аңа, – диде.

Өч сәгатьтән артык барган операция уңышлы үтте. Уңышлы дип әйтү бу очракта табиблар күзлегеннән караганда гына... Хәтирәнең башка әни була алмавы, бәби имезә алмавы, инвалид булуы бәрабәренә аңа гомер бирелде. Кирәкме аңа бу гомер? «Кирәк! Кирәк! Кирәк! – диде хатын операция алдыннан сөйләшкәндә. – Ятып кына торсам да, ирем, балаларыма киңәшләр генә биреп торсам да, мин риза, минем үз әнием бик яшьли үлде. Гомеремне берничә елга гына озайтсагыз да, мин сезгә мең рәхмәтле...»

– Голубушка моя (Борис Константинович каты авыруларга, шулай эндәшә), без әйткәннәрне тыңласаң, сакланып яшәсәң, сүз берничә ел турында гына бармый. Картаюга да путёвка бирәбез әле без сиңа. – Соңгы җөмләсен әйткәч, ул кычкырып ук булмаса да, үзе әйтмешли, «от души» көлеп куйды.

Менә алар, ике табиб-хирург, катлаулы операциядән соң тыныч кына кабинетта утыралар, чәй эчәләр. Борис Константинович мондый чакларда башын артка ташлап, күзләрен йомып утырырга ярата. Чәй йоткалап ала. Сирәк-мирәк әйтеп куя:

– Безгә бу кабинетка кресло сорарга кирәк әле. Ординаторскида бөтен гәүдәне сузып ятып торсаң да ярый... Хирургларның да йөрәге бар ич. Мин үзем операция алдыннан йөрәгемне дүрт клапаннан дүрт кыл белән тарттырып куелгандай тоям. Гүяки, мин бөтен барлыгым белән операциядә катнашам, аерым автоном яшим, ә йөрәгем үзе аерым автомат режимга күчерелгән. Минем хәрәкәтләрем, уем, фикерләрем бары тик акылга гына буйсына. Операция вакытында күзем күргәннәрне, кулларым тойганны, башым фикерләгәнне мин йөрәккә информация итеп җибәрми торам. Операция тәгәлләнгәч, акрен генә ул кылларны йомшартырга кирәк. Киеренке калдырырга ярамый... Аңлашылдымы, Вали Нурмиевич?

– Аңлашылды, Борис Константинович, – ди Вәли. Ул да күзләрен йомган. Ләкин нәрсә аңлашылганын аңламый. Кара, чынлап болай бөтен тән ял итә икән...

– Аңламыйсыз әле сез аны, коллега. Әти сөйләгәндә, мин дә аңламый идем башта. Менә хәзер аңлыйм. Ничава, диләрме әле татарлар, аңларсыз. Тик, ради бога, ул кылларны алкоголь белән йомшартмагыз. Йөрәгегезне бетерәсез. Менә без хәзер сезнең белән шул кылларны йомшартып утырабыз. Бу бик мөһим. Операциядән соң, кабаланып, икенче эшкә керешмәгез. Без врач-хирургларга йөрәк ныклыгы бик кирәк.

* * *

Эче авыртып китерелгән авыруга төгәл генә диагноз куя алмадылар. Анализлардан берни дә аңлашылмый. Рентген сурәтен кат-кат караганнан соң, Вәли катгый карарга килде: кичектерергә ярамый! Авыру хатынның хәле күзгә күренеп начарая. Бу биш бала анасы иртәгә район үзәгенә алып баруны, йә баш хирург килгәнне көтеп җиткермәскә мөмкин.

Менә дүртенче сәгать инде операция бара. Барлык чаралар да алдан күрелгән: авылның «Бикми» дип йөртелгән электр станциясен туктатмаска кушылган, кирәкле группа кан әзерләнгән. Көн саен булмаса да, операцияләрне еш ясыйлар, тик Вәлинең эшләү дәверендә мондый очрак беренче: эчәгесе әйләнгән һәм эшкәртелгән ризык буылган. Баш табиб та, өлкән медсестра Фирая да, шәфкать туташлары да чиратлашып эчәкнең шушы өлешен чистарталар, хирургиядә гомер буе санитарка булып эшләгән Гайшә марганцовкалы суны гел алыштырып тора. Бар да юкка булмасмы? Юк бугай! Әнә, ниһаять, ул үзенең табигый төсенә керә башлады.

Авыруны палатага алып киткәч тә, Вәли озак кына кабинетында утырды. Тагын бер коткарылган кеше гомере. Ничә булды икән алар Вәли эшли башлаганнан бирле? Күп, бик күп инде. Авыру наркоздан чыгып, аның сорауларына җавап биргәч кенә, өенә кайтып китәргә, ә дежур чагы булса, ординатура бүлмәсенә керергә күнеккән ул. Гадәттә, караваты янына барып баскач, әле генә үлем белән көрәшеп яткан авыру, хәлсез куллары белән аның кулларына кагылырга тырыша. Үзенчә рәхмәтен җиткерүе. Менә бүген коткарылган апа да нәкъ шулай итте. Күзләрен ачмаган да килеш, Вәлинең

кулын табып, аны көчсез генә кысты. Күзләреннән ике бөртек яшь тәгәрәп төште, иреннәре кыймылдап куйды:

– Мин үлмимме инде?

– Операция уңышлы үтте, Бибинур апа, тормышка яңадан кайттың син, биш балаң янына! Борчылма, хәзер ял ит. Бар да әйбәт булыр.

– Рәхмәт, Вәли улым.

Ай, бу яшәүгә өмете уянган авыруның йөрәктән чыккан «рәхмәт» сүзе. Шул сүзне әйткәндә сытылып чыккан күз яшьләре!.. Кешегә үзен бәхетле итеп тоярга ярдәм иткәнеңә куану үзе зур бәхет бугай. Табибларның гомерләрен озайта торган хистер бу, әллә киресенчәме икән?..

Борис Константинович Казанга киткәннән соң, тәҗрибәле хирург Рафаил Нәбиевич белән эшләп алу да аңа шулай ук бик күп нәрсә бирде. Менә ярты еллап инде ул бөтен больницасында бердәнбер хирург та, стоматолог та, терапевт һәм гинеколог та. Борис Константинович дөрес әйткән: бала тудыру бүлеге иң җаваплы бүлек булып чыкты. Теләсә нинди һава торышында көндез дә, төнлә дә йөкле хатыннарны трактор арбасында, атта, чанада, машинада алып килә тордылар. Атна-ун көн больницада яткач, кояштай балкып, ап-акка төрелгән җан иясен күкрәкләренә кысып чыгып китә тордылар.

Казанга баргач, сирәк кенә булса да, Борис Константинович белән очрашалар алар. Вәли больницадагы хәлләрне сөйләп биргәч, ул, гадәттәгечә, рәхәтләнеп көлә дә аны үртәргә тотына:

– Ә мин сезнең кендек бабай булып китәсегезне күптән белдем инде. Баш табиб, хирург була торып, ничек инде дөньяга килергә ашыккан сабыйга булышмыйсың ди?! Син батыр һәм намуслы врач, мин гинеколог түгел, дип, читтә кала алмыйсың.

* * *

Актлар залына соңгарак калып килеп кергән Вәлине баш табиб практикантларга тәкъдим итәргә ашыкты:

– Кызлар, менә бер-икегез практика узарга барасы участок больницасының баш врачы – Вәли Нурмиевич. Таныш булыгыз, өйләнмәгән егет!

Шулвакыт кызлар арасыннан берсе «прых-х-х!» итеп көлеп җибәрде. Вәли үзе дә аңламастан, кисәк кенә борылып әлеге кызга карады. Озын чәчләре пөхтәләп җыеп куелган кызның карашын күрүгә, кызарып, башын аска иде.

Зал тынуга, сөйләүләр башланды. Вәли бөтен игътибарын туплап тыңларга тырышса да, барып чыкмады. Ул әледән-әле үзеннән алдарак утыручы теге кызны күзәтте. Аның колагындагы матур алкалары, шул алкага тиеп-тиеп китүче чәч бөдрәләре, дугаланып торган кашлары, керфекләренең канат кагынуы кул сузымында гына.Чыгышларны ул тыңлый алмады. Үз уйларыннан үзе оялып йөрүче үсмер түгел, утызга якынлашып килүче буйдак егет бит инде ул.

...Аның исеме Зәрә икән. Кечкенәдән аны: «Гали кызы бит син, үзеңнең Вәлиеңне кайчан табасың», – дип үртәгәннәр. Юкка гына көлмәгән бит ул теге көнне. Зәрәгә булган хисләре көнләп артты. Тизрәк аңлашасы иде. Юкса, йөрерсең кысыр гыйшык тотып, дип уйлады ул. Анысы алай ук авыр булып чыкмады. Район больницасына бер килгәндә, төш вакытындарак Вәли каушый-бутала сүз башлады:

– Зәрә, «Вятка» ресторанына төшке ашка барып килмибезме?

– Без кызлар белән монда гына ашаган идек инде, – диде Зәрә һәм шул минутта ук тормышында бик зур хата ясап маташуын аңлап алды. – Ә минем барыбер ашыйсым килә, бигрәк тә ресторанда.

Икесе дә көлеп җибәрделәр, икесенә дә бу минутта рәхәт, күңелле иде. Шушы көннән алар нindidер күзгә күренмәс җепләр белән бер-берсенә бәйләнеп куелган күк булдылар. Вәли Зәрәгә үзләренең эше турында туктаусыз сөйләде. Кыздан киңәшләр дә алды. Берничә тапкыр район больницасында ул Зәрәгә ассистентлык та итте. Кызның куллары ипле, үз эшенең җаен белә. Интернатура гына узучы димәссең!

Зәрәнең практикасы бетәргә торганда, Вәли тәвәккәлләп, аңа тәкъдим ясады. Анысы да үзенчә – Вәличә булды.

– Зәрә Гали кызы, сез үзегезнең Вәлиегезне эзлисез дип беләм. Ул мәхлук сезнең каршыгызда басып тора. Аны рәнҗетеп, тәкъдимен кире какмавыгызны үтенәм. Мәхәббәтенә ышанмасагыз, менә скальпель. Йөрәген ярып карагыз. Ул мескен, быел өйләнмәсәң, миңа инсульт була, дип тибә. Җәлләгез сез ул йөрәкне. Зинһар өчен!

Шундый җитди, кырыс баш табибның бу тамашасыннан бертуктаусыз чыркылдап көлгән Зәрә дә рольгә керде:

– Шундый егетнең күкрәгенә скальпель белән җәрәхәт ясыйлар, димени! Мин фонендоскоп белән тыңлап та аңа диагноз куя алам. Һәм дәваларга тырышачакмын. Рәхим итеп, йөрәгегезне тыңларга рөхсәт итегез! – Һәм кыз Вәлинең мәһабәт күкрәгенә колагын куйды. – Оhо! Монда хәлләр ба-а-ар. Йөрәгегезнең дүрт клапаны да берьюлы ачылган сезнең. Тибешен санавы кыен. Кичекмәстән, дәвалау курсын уза башларга кирәк, егеткәем...

– Мин риза, тик дәвалаучы сез булсагыз гына, – дип пышылдады егет кызның колагына.

Шул көнне үк Вәли Зәрәне Катмышка әти-әнисенә күрсәтергә алып кайтып китте.

* * *

Көннәр, айлар узды, Зәрәнең бәби табар вакыты җитеп килә. Декрет ялында булса да, ул әле алыштыргысыз операцияләргә, педиатр «обходларга» керә. Ә кечкә якта стационарда Вәли белән икәүдән-икәү генә кала.

Беркөнне Зәрәсе ирен аптыраштa калдырды.

– Мин курка башладым, Вәли.

– Нәрсәдән?

– Бәбиләүдән...

Нинди генә җавап булмасын, тик мондыйны көтми иде ул.

– Тыңла әле, Зәрә... – Вәли бераз уйланып торды. – Мин синең куркуыңа ышанам... Ул шулай булырга тиеш тә... Бәби табу ни икәнен мең хатын-кызның бер-икесе генә синең кебек үз күзләре белән күргәне бар... Син бит ничәмә-ничә катлаулы ситуацияне үзеңә күчереп уйлыйсың. Практикада булган һәр авыр очрак синең белән дә кабатланыр кебек тоела һәм шул сине куркыта башлаган. Әйдә, хәзер уйлыйк: куркырлык сәбәп бармы? Анализларың ничек?

– Әйбәт, – диде Зәрә әкрен генә.

– Үзеңне ничек хис итәсең?

– Әйбәт.

– Мондый очракта син пациентыңа нәрсә диясең инде?

– Барысы да әйбәт булыр, дим.

– Соң шулай булгач, бәгырь кисәгем, үзеңә дә шулай диген, үзеңне дә ышандыр.

Ниһаять, Зәрә көлеп җибәрде.

– Безнең больницада психотерапия кабинеты ачарга кирәк. Һәм аның кабул итүчесе сез булырсыз, Вәли Нурмиевич! Чөнки сез әле генә миңа үз-үземә ышанырга ярдәм иттегез.

Көлешкәч, икесенә дә җиңел булып китте.

* * *

Бәби алып китүчеләрне Зәрә тәрәзәдән карап озатырга ярата. Әнә ире ашыгып хатынын «Зил» кабинасына утырта. Бик сирәкләре генә әни кешене үбеп ала. Чәчәк дигән нәрсәләре юк та юк инде. Зәрә Галиевна, югыйсә, атна буе сөйли: чәчәкләр белән каршы алсыннар сезне, әйтегез, ди. Өйдә калган балаларыгыз булса, аларны да алып килсеннәр. Гаилә белән истәлеккә фотога төшегез. Без монда фотограф Хуҗи абыйны чакырта алабыз, ди.

«Кая ул! Килеп алгач рәхмәт инде!» – диешәләр хатыннар. Барысы да үзебездән башлана, хатыннар, без үзебезне яратсак, ирләребез дә безне яратыр. Кайткан көннән башлап, өйдә иң төп кешеләр бәбиегез белән үзегез булыгыз. Бер ай иң авыр күтәргәнегез балагыз булсын. Онытмагыз, бәбидән котылган хатынга кырык көн кабер авызы ачык торыр. Бу минем сүзләр түгел, борынгылар сүзе, ди Зәрә аларга.

Менә шуларның барысы турында да уйланып, ун көн инде ул үзенең бәбиләтү бүлегендә ята. Бәбиләгәннән соң, иртән уянып китсә – тумбочка өстендә чәчәкләр! Беренче уе: «Вәли!» булды. Ул алып килгән бу чәчәкләрне, һичшиксез! Аннары баласы турында сораша башлады. Гинеколог әнидән берни дә яшереп булмый иде шул... Бала әкрен имде, авырлык белән тернәкләнде. Шуңа күрә ун көнгә кадәр чыгарыгыз, дип үзе дә ялынмады.

Ниһаять, алар больницадан чыктылар.

...Кайсы төшләреннән генә бу тормышны кирегә борып куярга да үкенмәслек итеп яңадан шул урыннан дәресләргә икән соң? Зәрәнең баш миен гел бер сорау бораулады: авырлы чорында бар да әйбәт иде, үзем табибә булган килеш, нишләп болай кирегә китте... Ник безнең нарасыебыз – Энҗебез авыр туды? Шул сорауны үзенә кат-кат бирде, үзен гаепләде, Вәлиен аптыратып бетерде.

– Вәли, мин бу эшемдә алга таба эшли алырмын микән? Моннан ары ничек бәби таптырырмын? Ничек сабыйларны кулга алырмын?

– Тынычлан, Зәрә, кайчакта вакыт барысын да әкренләп үз урынына куя, яхшыга өметләник әле. Энҗе – ул безгә бүләк, һәм ул безгә – сынау да. Әйдә, әлеге сынауны чын кешеләр, чын табиблар булып үтәргә үзебездә көч табыйк.

Шулай килештеләр дә.

Ә иң үтемле сабакны әниләре бирде. Кайткан вакытларында Вәли белән Зәрәнең һаман сүрән йөрүләренә эче пошып, әниләре болай сүз башлады:

– Сез, балалар, артыгын кыланасыз. Сынмасны оста ясамас, үлмәсне Ходай ясамас, дигәнне онытмагыз әле. Бөтен чирне дә врачлар терелтә дә, бөтен туар баланы алар үстерә, дип беләсезме әллә? Ходай Тәгалә барын онытмагыз. Аның да шәфкате бик киң. Яраткан бәндәсенә чир бирермен, дигән. Сөйгән бәндәләрен зәгыйфь итеп, оҗмахлы итәрмен, дигән. Сөеп тә бирә, сынап та бирә ул бәндәсенә, – әниләре бу сүзләрне әйткәч, яшьләр бер-берсенә караштылар. – Ә син, килен, сырхавына күрә дәвасы нинди икәнен белергә тиеш инде, үзең хатын-кыз врачы. Икегез дә кырык ягына барасыз. Тупырдатып тагын бәбиләр алып кайт та бөтенебезне сөендер. Менә булырсың чын кендек әбисе!

Әниләренең шушы сүзләре, әйтерсең, алар күңелендәге авыр ташларны берәм-берәм алып ташлады. Ничә елга беренче тапкыр рәхәтләнеп елмаештылар.

* * *

...Бер-бер артлы ике малайлары тугач, өйләре күңелле мәшәкатькә күмелде. Тоташ декрет елларында Зәрә дә берничә ел өйдә хуҗабикә, бәхетле әни булып яшәде. Тик, гаиләләрендә барысының да ярату мөнбәренә әйләнгән Энҗеләрен Ходай алды шул... Бу сабый бер генә сүз әйтмәгән килеш тә, аларның барысына да халык акылының тирән хәзинәләреннән иң асыл ташларны калдырып китте: Зәрәне ул тормышны ничек бар, шулай яратырга өйрәтте. Зәрә үз һөнәренә чытырдап ябышты хәзер. Элек бала төшерергә дип килгәннәргә катгый булмаса, хәзер ул консультациягә килгән хатын-кызга яшәү мәгънәсе балаларда, дип сәгатьләр буе үгет-нәсихәт бирә. Вәлигә Энҗедән балаларны искиткеч ярату, аларга үзеңне кирәк итеп тою хисе һәм алга таба хезмәтләрендә кулланачак дәвалау тәҗрибәсе калды.

* * *

1979 ел. Яңа хастаханәдә иртәнге обход вакыты. Буяу исләре аңкып торган палаталар буйлап бер төркем табиб йөри. Төркемдә берничә яңа кеше бар. Ак халат кигән яңа райком һәм авыл партоешма секретарьлары да бирелә. Кунаклар арасында рус кешеләре

бардыр, күрәсең, Вәли Нурмиевич обходны русча ясый. Ниндидер тантана. Гадәттә обход вакытында баш табибка сораулар бирергә яраткан авырулар бүген авызларына су капкан. Сорашканда татарчага күчкән табибларына җавап бирәләр дә тизрәк кунакларның сөйләшүенә колак салалар. Казан хәтле Казаннан табиблар гел килеп тормый. Аның авыруы турында нәрсә әйтерләр икән, Казан «прафисырлары» бит. Авыл кешесе гомер буе шәһәрдәгеләрне зурга куеп яши инде ул. Ә менә Казанныкыларны шушы авыл больницасының баш табибы шаккатырды әле монда. Кайсы гына палатага килеп керсәләр дә, авыруның тарихын биш бармагы кебек белә, диагнозлар куелган, дәвалау дөрес билгеләнгән. Шуның өстенә күзәтүләр дә алып барылган, икеләнергә мөмкин очраклар бетерелгән. Ә бит обходка күп кеше килергә тиешлеге алдан билгеле түгел иде.

Бу делегациянең хастаханәгә нинди ният белән килүен күпме генә гоманласалар да, һич очына чыга алмадылар. Обход беткәч, барысы бергә җыелып, һәм бары тик Вәли Нурмиевичны гына чакырып, кабинетка кереп китүләре Зәрәне аптыраашта калдырды. Бүтән тикшерүчеләр больница эшчәнлегенә бөтен медхезмәткәрләр каршында бәя бирәләр иде.

Барысы да кич белән өйгә кайткач ачыкланды: Вәлине район больницасына баш табиб итеп кодалау турында сүз барган икән.

– Син нәрсә диден соң? – диде Зәрә бу хәбәргә шатланырга да, борчылырга да белмичә.

– Менә киңәш-табыш итәрбез, – диде ире, битараф кына. Аларның хезмәтенә, яңа хастаханәгә бик яхшы бәя куюларына Вәли бик куанды, әлбәттә. Тик шушы больницадан кубарылып, яңа җирдә, әле алга таба райздрав мәшәкатьләрен дә үз өстенә алып эшли башлауга ул сөенә алмады. Нәрсә бу, иптәш баш табиб, олыгая баруыңмы, сиңа бит әле кырык кына, иң булдыра торган чагың, диде ул үз-үзенә. Ләкин күңеле белән тоя: сәбәп башкада. Биш ел дәвамында яңа больница төзү мәшәкате белән янып-көеп йөрү аны шушы коллективка, үз эшенә нык беркеткән иде. Ул һәр яңа төзелеш уңышыннан килгән шатлыкны авыру кешенең савыгуыннан барлыкка килгән сөенеч кебек кабул итә иде. Без төзедек бит моны, без булдырдык, дип, башны горур тотып, заманча кабинет, палаталарга кереп, куанып йөрүләргә әле ияләнеп тә бетмәделәр бит.

* * *

...Боргаланып аккан Бөрсет суының сөзәк яр битендә учак яна. Яшел чирәмле үзәнлектә өч хатын-кыз табын хәстәрләү белән мәшгуль. Калкулык буйлап сузылган тигезлектә малайлар туп тибә. Аз да түгел, күп тә түгел, өч гаиләгә нәкъ җиде малай. Башка вакытларда этиләре дә кушылып, футбол командалары зурая иде. Бүген алар балык тоту белән озак мавыктылар, ни өстәл тирәсендәгеләргә, ни малайлар уенына кушылмыйлар. Балык капмаганга балыкчыларның бер дә исләре китмәде, рәхәтләнеп сөйләшеп утырдылар. Өч гаилә! Вәли, Хәсән, Миңнулла, аларның хатыннары Зәрә, Хаҗәр, Наилә. Ял иткәндә Вәлине хастаханәгә чакырдылар. Табиблар йөрәге ял белми.

Гаҗәеп август киче. Җылы. Июнь, июль эсселеге белән артык куандырмаган иде. Август, табигатьнең шул хатасын төзәтергә килгәндәй, и мәрхәмәтле, и җылы! Күктә йолдызлар яңгыры башланды. Әллә ничә йолдыз атылганын күрде Зәрә! Санын да югалтты инде. Йолдыз атылганда, теләкләр теләсәң, кабул була, диләр. Бертуктаусыз күңеленнән матур теләкләр теләде ул... Энҗебез безгә риза-бәхил булсын. Малайларыбыз исән-имин үссеннәр, бәхетле булсыннар. Шушы йортыбызда гына яшик. Үзебезнең больницабызда тагын озак еллар кешеләргә шифалы дәва биреп эшләргә насыйп ит, Раббым!..

Вәли дә аны ишетте.

Ул Зәрәнең теләкләрен алдан ук белеп торгандай:

– Амин!.. – дип куйды.

# МӘГАРӘ

Кама Тамагы районы, гомумән, тау ягы, без үскәндә, җәннәт бакчасыдай тоела иде. Алма, груша, чия, балан, карлыган, крыжовник, слива кебек агач-куакларга күмелеп утырган төбәккә кемнәр генә килеп сокланмаган да, кемнәр генә гашыйк булып китмәгән. Ул – меңнәрчә гектар җирләрдә үскән байлык белән Советлар Союзын, шул исәптән Совет армиясен дә алма-чия, слива, груша кайнатмалары, повидло-компотлар, конфетлар белән тәэмин итеп тордылар. Идел ярларына урнашкан җиләк-җимеш консервлау заводларында хәтта очсызлы гына шәраблар да җитештерелде. Аларны баржаларга төяп, илнең төрле төбәкләренә озата тордылар. Ләкин байлыкны җыеп та, эшкәртеп тә бетерерлек түгел иде. Шулай да юкка да чыгармыйлар иде. Чөнки терлек-туар бар. Җиләк-җимеш ашаган сыерның сөте дә, ите дә тәмле була. Шуңа күрәдер бирердә җитештерелгән азык-төлек турыдан-туры башкалабыз Казанга, хәтта Обком ашханәсенә озатыла торды. Туфан ага Миңнуллин биредәге таулар өстеннән сокланып, ике елга кушылып хасил булган иксез-чиксез суга карап торырга ярата иде. Чулман белән Идел кушылган җирдә каршы яктагы яр күренми. «Туфан абый, шулхәтле озак соклануудан күзләрегез армасын», – дисәләр, «Нинди ару, киресенчә, ял гына итә алар ошбу сихри матурлыктан!» – дия иде ул.

Кама Тамагының гүзәл табигатьтән гайре, үзен таныткан тагын бер табигый һәйкәле бар. Тенеш җирлегенә урнашкан гипс шахталары. Ул зур мәгарә күзгә ташланып тормый. Идел буйлап йөзгәндә, игътибар белән карап барсаң, Тенеш бистәсе янында ап-ак тауларны шәйләргә була. Көчле «КамАЗ»лар шахта-мәгарәгә кереп китәләр дә аксыл-соргылт таш төяп кире чыгалар. Биредә, әйтик, ачык һавада, руданы эшкәртү, төрле сортларга бүлгәләү башлана. Бертуктаусыз таш яру, ваклау, теткәләү процессы бара. Аны үткән гасырның 70нче елларында төзелгән, ЩКД -7 тегермәне башкара. Шулай ук күчереп йөртелә торган ваклау җайланмасы ПДСУ-200 дә «Атлар аланы үзәне» дип аталган мәйданчыкка урнаштырылган. Гипс ташын судно-танкерларга төяп, ерак җирләргә, хәтта Дания, Швеция, Финляндия кебек илләргә озаталар. Эш кайнап тора. Кама Тамагы гипс руднигының генераль директоры Зөфәр Гарәфиевнең фикеренчә: «Монда нинди генә көчле, заманча техника эшләмәсен, беренче урында – кеше! Элек тә, хәзер дә шулай. Шуңа күрә тикшерелгән, сыналган, сайлап алынган эшчеләр эшли биредә. Күпме гаилә династияләре үсеп чыкты. Алар – районыбызның гына түгел, республикабызның, илебезнең дә горурлыгы». Кемнәр соң алар, үз эшләрен атадан – улга, улдан оныкка тапшыра барган династия кешеләре?

Башта гипс рудникларының тарихына күз салып үтик әле. Тарихи тикшеренүләр шуны раслый: гипс ташы әле Бөек Болгар дәүләте яшәгәндә, VII-VIII гасырларда ук табылган. Төп эш кораллары булып кәйлә, лом, көрәк саналса, йөкне атлар тарта. Болгар, Казан кебек шәһәрләребездә таш пулатларны төзегәндә, әлеге чимал кулланылган. Гомерләр уза, чорына карап биредәге хезмәт тә бер көчәя, бер сүлпәнәя тора. Һәрбер заман үз таләпләрен куя. Үткән гасырның башында, Россиядә бу чималга сорау арткач, 1911 елда алебастр җитештерү заводы эшли башлый. Һәм шушы дата рудникның оешкан елы булып санала. «9 гыйнвар» исеме белән аталган төзелеш чималын җитештерү карамагында – Антоновка, Сөйки һәм Үзәк гипс чыгару рудниклары. Алебастр җитештерү заводы кечерәк фабрикалардан тора. Шушында ук яндырылган гипсны тартып алебастр ясау цехы, хәрәкәткә китерү станциясе, шулай ук складлар, ат абзарлары, эшчеләргә яшәү өчен бараклар. Ләкин техника, механизация булмау сәбәпле, гипс чыгару әллә ни зур күләмдә алып барылмый. Тик аннан-моннан салынган алебастр заводы 1930 елда ни-

гезе, стеналары ярылып-ишелеп, яраксызга чыга һәм үзенең яшәвен туктата. Бары тик 1931 елда гына житештерү үсеш кичерә.

Әйтеп киткәнемчә, төп эш коралы булып, башка шахталардагы кебек үк биредә дә кәйлә санала. Шахтёрлар шуның белән ташларны кубарып торалар, йөк төяүчеләр кул һәм көрәкләр белән вагонетка, ягъни тимер йөк арбаларына төяп, атлар белән руданы тышка, Идел ярына чыгаралар. Биредә эшләүчеләрнең сәламәт һәм физик яктан көчле булуы да таләп ителгән. Арбалар өчен рельслар салынуга карамастан, кешеләр һәм атлар төп егәр булып кала. Шунысын да искәртеп китәм: атлар белән гипс рудасын ташу хатын-кызлар җилкәсендә була. Дөм караңгыда йөрергә мәҗбүр булган малкайлар, кинәт яктылыкка чыккач, бик тиз сукырая торалар. Монда килгән ат якты кояш астына, урман-болыннарга, су буйларына кире әйләнеп кайталмый. Ни кызганыч!



*Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәймиев Кама Тамагындагы гипс руднигында Тәлгать Абдуллин (сулдан уңга), Рәфкать Кантюков һәм Зөфәр Гарәфиев белән.*

Ирләр таш ватса, хатыннары шуны ташыганнар. Бирегә эшкә якын-тирәдәге авыллардан килгәннәр. Кама Тамагы гипс руднигының йөз еллык тарихында коллективта бик күп нәсел династияләре әнә шулай туа торган. Бу инде, читкә бәхет эзләп китмичә, үз җиреңә тугры калу дигән сүз. Ә рудник өчен – тәҗрибәле, ышанычлы эшчеләр. Дистәләгән еллар буена бер-берсен алыштырып хезмәт итүче гаиләләр ошбу шахта тарихында бик күп. Туганлык җепләре бәйләгән гаиләләр бер-берсенә тап төшермәскә тырышып, таләпчәнлек күрсәтеп эшлиләр. Шаршалан – Чыршы Алан авылында 1914 елда туган Николай Агафонов 1932 елдан башлап 1986 елга хәтле слесарь, ПНБ-3 машинисты, аннары тимерче, токарь да булып эшли. Аның эшен улы Юрий дәвам итә, оныгы Сергей да читкә китми. Юрийның тормыш иптәше 1938 елны Кама Тамагы бистәсендә туган Тамара Константин кызы да педагогика училищесын тәмамлап, 1976 елда каенатасы, ире эшләгән рудникка өлкән инженер булып килә.

Шулай да биредә иң зур стажлы нәсел – Мөбарәкшиннар династиясе. Аларның гомуми хезмәт стажы 130 елга җыела! Баһрам Мөбарәкшин 1928 елны Кече Салтык авылында дөньяга килә. Ул 40 ел гомерен шушы мәгарәгә бирсә, тормыш иптәше Суфия ханым да төрле эшләрдә 22 ел тир түгә. Үзе ул Шәпкә авылыннан. Аларның уллары Альберт та 1975 елны район үзәгендәге урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, рудникка килә. 1976-1978 елларда хәрби хезмәттә була, аннан кайткач, тау цехында экскаватор белән идарә итә. Соңыннан смена остасы, 1992-2001 елларда баш инженер, ә инде 2006 елдан техник директор вазифасын башкара. «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә. Аның тормыш иптәше Румия дә, иренә терәк булып, башта тау эшчесе, аннары цех мастеры, лаборант, метролог



*Мөбарәкшиннар династиясе.*



*Бульдозерда эшләүче Рифат Хәйруллин.*

булып уртак эшкә үз өлешен кертә. Алма агачыннан ерак төшми дигәндәй, кече уллары Рөстәм дә Рудник урта мәктәбен тәмамлагач, Урал шәһәренең И.И.Ползунов исемендәге дәүләт колледжында белем ала. Тау эшләре буенча техник-технолог. Бүгенге көндә тау мастеры булып хезмәт куя, шул ук вакытта читтән торып Урал дәүләт университетында белем эсти. Шулай ук Кече Мәрәтхуҗа авылында туып үскән, өч буыны биредә таш чыгарган Гыйльметдин Баймөхәммәтовлар династиясенең дә (хатыны Фатыйма, уллары Ислам, оныклары Айрат) уртак хезмәт стажы – 114 ел.

Дорофеевларны Кама Тамагында белмәгән кеше юктыр. Иван Степан улы гражданнар сугышында аягын имгәтеп кайтса да, хатыны белән төрле эшләрне башкаралар. Өлкән уллары Пётрга ишле гаиләдә бик тиз кул астына кирәргә туры килә. Операция ясап, әтисенең тәненнән ядрә кыйпылчыкларын алгач, әнисенә терәк булып, эне-сеңелләрен аякка бастырыр өчен ул да шахтага яшьләй килә. 1943 елны 17 яшеннән үзе теләп сугышка китә. «Батырлык өчен» медале, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Сугыштан соң монда экскаваторчы, слесарь булып эшли. Хатыны Елизавета да янәшәсендә була. Уллары Александр – 1986 елдан бирле биредә мастер, хатыны Наталья – хисапчы.

Өч буыны биредә хезмәт куйган Камалетдиновларның да 84 елдан артык эш стажы бар. Бәдретдин ага 1924 елда Олы Мәрәтхуҗада дөньяга килсә, хатыны Гайшә – Олы Бортасныкы. Уллары Ильяс, Ринат та үзләре белән. Оныклары Рәфкать, Лилия, Равия дә рудникка тугры калалар.

Рудникта хезмәт куйган династияләр бик күп, шуларның тагын кайберләрен әйтеп китәм. Исфат Галиев. Аның улы Альберт, оныгы Сергейлар – бабаларының дәвамчылары. Шулай ук Хәсәновлар да 130 елны гипс руднигына биргәннәр. Кече Мәрәтхуҗадан чыккан Гаделҗан Хәсәнов, аның 1924 елда туган улы Шакир, оныклары Рамай (Татарстанның атказанган төзүчесе), төрле эшләрдә хезмәт куючы хатыны Хәвия – менә тагын бер династия! Шуларга уллары Альберт, кызлары Эльвираны да өстәсәң... Фидакарь хезмәт белән рудникның тарихын баеткан нәсел бу!



*Машинист Александр Мокшин.*



*Бораулаучылар Илсур Бикхуҗин белән Илдар Закиров.*



Тау эшчесе Ризилә Исламова.



Лаборант Рамилә Муллагалиева.

Бүгенге көндә дә гипс руднигы илебезгә хезмәт итә. Элеккеге кебек вакытыннан алда картайта, сәламәтлегеңне җимерә торган авыр кул эше юк инде биредә. Барысы да заманча техникага тапшырылган. Зыянлы производство саналса да, санитар таләпләрен үтәсәң, сәламәтлегең тәртиптә булачак! Син эшле, гаиләң ашлы, димәк!

Җитәкче Зөфәр Гарәфиев: «Рудник шахтасы бит ул кешене эшле, икмәкле итә. Район бюджетына да саллы гына өлешен кертә. Без җитештергән продукция, нигездә, илебез буйлап төрле төбәкләргә су юлыннан озатыла. Рудник техник яктан 2011 елдан кабат яңартыла башлый, чит ил төягече «Liebherrl – 556» (аның чүмече 3,5 кубометр таш ала), шулай ук таш бораулау җайланмасы – үз йөрешле шасси «УБШ – 501А», 20 тонна руда күтәрә торган «КамАЗ-6520»ләрнең мәгарәгә кайтарылуы, җитештерүнең күләмен арттырырга мөмкинлек тудыра.

Монда экологияне саклауга да зур игътибар бирелә. Су буйлары, тирә-юньдәге һава, табигать һәрдаим күзәтү астында. Шулай да иң зур игътибар – кадрларга. Экологиянең чисталыгы да, техниканың төзеклеге дә, гомумән, ныклы тәртип биредә эшләүче кешеләрдән тора. Иң авыр чорда – үткән гасырның туксанынчы елларында да шахта хезмәткәрләре гипс руднигына тугры кала. Биредә эштән үз теләге белән китүчеләр юк диярлек. Тәҗрибәле хезмәткәрләр пенсиягә чыккач та, үзләре теләп монда кала».

Миңа, шушы язманың авторына, бу шахта-мәгарәгә керергә иде дип, күптән күңелемдә йөрткән хыялымны быел гына тормышка ашырырга туры килде. Бөтенләй чит-ят планетага эләккәндәй тоясың үзеңне. Әгәр дә биредә адашып калсаң, мәңге чыга алмассың кебек. Чөнки аркылыга-буйга дистәләрчә чакрымнарга сузылган киң таш урамнар... Җир астының йортсыз-каралтысыз зур таш шәһәрчегендә күңелгә барыбер шом иңә. Тәҗрибәле белгечләрнең озатып йөрүе генә күңелне тынычландыра.

Рудник-шахтаның тарихына багышланган музей зур кызыксыну уята. Биредә кәйлә, көрәк, ломнан башлап, ат арбалары-дирбияләре, вагонеткалар, үз эшләрен башкарып, тарихи ядкарьгә әверелгәннәр. Каскалар, лампалар, киемнәр һәм башка җиһазлар мәгарәнең үткәнен күзалларга мөмкинлек тудыралар.

Шунда ук заманча куәтле техника таш кисә.

Рудник яши.

**Рәдиф СӘГЪДИ.**

*Фотолар  Кама Тамагы гипс руднигы архивыннан алынды.*

# ЯНЫП ЯШӘЛГӘН ГОМЕР

*Без һәммәбез җирдә берәү генә,*
*Беркемнең юк җирдә алмашы.*
*Кабатланмас үз язмышы белән*
*Туа җиргә адәм баласы.*

*Җыр калдырыйк җирдә, нур*
*калдырыйк,*
*Җырда калсын безнең гомерләр...*
*Безнең дөрләү, безнең януларны*
*Киләчәккә җырлар илтерләр!*
Фәнис Яруллин

Ул чакта мин Россия язучылары Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры булып эшли идем. Көннәрдән бер көнне Татарстан Язучылар йортындагы кабинетымның ишеген кемдер, барабан таякларын уйнаткандай, ниндидер сихри-серле аһәң биреп, матур гына шакыды.

Барып ишекне ачуга каршымда чал чәчле, зәңгәр күзле, ачык йөзле, таза-төз гәүдәле олпат затны күрдем. Әлеге ир-ат, дустанә елмаеп, күреште:

– Таныш булыйк: җәлилче Рушад абыең Хисаметдинов булам мин. Бирегә Кыргызстанның Ош каласыннан килдем. Казанда якын туганнарым яши... Сезнең янга мине Рафаэль абыең – фамилиядәш адашың җибәрде. Җәлилче легионерлар, макизарлар белән кызыксынасың икән. Вакытың булса, әйдә, шулар хакында иркенләп сөйләшик!..

Үзенең килеш-килбәте, сөйләме, зыялылыгы белән аерылып торган ошбу Ил агасы беренче күрешкәндә үк күңелгә ниндидер үзгә бер җылылык-яктылык өстәде. Өстәвенә ул нәсел тамырлары белән безнең якташыбыз да булып чыкты. Кукмара районы Югары Өскебаш авылы зиратында аның дүрт буын бабалары җирләнгән.

Бу юлы Рушад Мөхәммәтбилял улы Казанга бертуган апасы, Татарстанның атказанган зоотехнигы Кәшифә ханым Килеева балалары – танылган язучы-тәрҗемәче Азалия ханым Бадюгина, Казан дәүләт энергетика университеты доценты, техник фәннәр кандидаты Әнвәр Исмәгыйль улы янына Казанга килүеннән файдаланып, республикабыз башкаласында яшәүче җәлилче каһарман Әмир ага Үтәшевнең дә хәл-әхвәлен белешергә өлгергән.

– ...Франциядә чакта фашистларга каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәткән легендар легионер-макизар ул – Әмир абыең! – диде миңа Рушад ага. – Озак еллар дәвамында хаксызга рәнҗетелгән фидакарь җаннарның берсе ул... Әйдәгез әле, бергәләшеп, күтәрик әле, кайтарыйк әле илгә, халыкка данлы исемен!..

Хөрмәтле Рушад Мөхәммәтбилял улының хәер-фатыйхасын алып, Әмир ага Үтәшев белән соңгы елларда аралашуым-дуслашуым, андагы искитмәле тарихи язмалар, Франциядән җибәрелгән, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты (КГБ) архивларында дистәләрчә еллар яткан байтак документлар белән танышуым нәтиҗәсендә, мин кадерле якташымның батыр йөрәкле көрәштәше турында әйткән сүзләренең хак булуына ныклап ышандым.

Тугандаш Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында моннан бер гасыр элек – 1919 елның 15 сентябрендә дөньяга килгән Әмир Галимҗан улы жиде-

еллык мәктәпне тәмамлагач, Уфа кооператив техникумына укырга керә. Аннары дипломлы яшь белгеч Татарстанның Арча районы кулланучылар җәмгыятендә баш бухгалтер урынбасары, бераздан соң баш бухгалтер булып эшли. Өйләнеп җибәрә. Сугыш чыккач, армия сафларына да Арча хәрби комиссариаты тарафыннан алына. Алабугада политруклар хәзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлаган өлкән лейтенант Үтәшев 1942 елның июне азагында Курск өлкәсендә беренче сугышчан чирканчык ала. Хәлиткеч-җитди сугышларның берсендә ул, ике аягы да авыр яралану сәбәпле, берничә тәүлек бомба чокырында аңсыз ята һәм шул хәлдә дошман «тырнагына» килеп эләгә. 1942 елның 6 июленнән Әмир Галимҗан улы өчен газаплы әсирлек тормышы башлана...


*Әмир Үтәшев хатыны Рәйсә Йосыф кызы белән.*

Баштарак фашистлар Әмир абыйны Киевта, аннары Дарница, Владимир-Волынск лагерьларында яткыралар, соңыннан Польшаның Ченстохов лагерена күчерәләр. Яралары да төзәлеп бетмәгән Әмир абый биредә тифтан егыла. Немец офицеры, аның терелүенә өметен җуеп, токтынны мәетләр барагына чыгарып ташларга боера. Әмма дөньяда яхшы адәмнәр дә бар бит әле: бер таныш әсир-санитар Үтәшевнең документларын үлгән чуваш егете Александр Николаевныкы белән алыштырып куя да, Әмир абыйны авырулар ята торган баракка күчерә һәм тифтан дәвалау чараларын күрә. Шулай итеп, Әмир Үтәшев Александр Николаев (Франциядә «Александр Николас», «Капитан Александр») булып китә. Французлар биргән барлык документларда аның исеме алга таба «Әмир» дип түгел, «Александр» дип телгә алына.

1943 елның маенда Ә.Үтәшевне Польшаның Едлинодагы хәрби әсирләр лагерена – «Идел-Урал» легионына китерәләр. Монда ул Рәхим Саттар, Әкрам Мамлиев ярдәмендә, Муса Җәлил белән якыннан таныша һәм биредәге яшерен оешманың актив бер әгъзасы булып китә.

– ...Легионда синең яшерен эш алып баруыңның төп максаты – үзебезнең ватандашларны ничек кенә булса да партизаннар ягына алып чыгып, фашистларга каршы бергәләп көрәшү булырга тиеш! – ди Муса Әмиргә. – Мин сиңа ышанам: башлаган эшебезне дошманны тәмам җиңгәнчегә кадәр дәвам ит... Дөнья бит бу, безне алда нәрсә көтәчәген бер Алла үзе генә белә...

Күңеле дөрес сизенгән икән шагыйрьнең. Озак та үтми, 10 августта, фашистлар М.Җәлилне һәм яшерен оешма әгъзаларының бер өлешен кулга алып, зинданнарга ташлыйлар. 1943 елның августында «Идел-Урал» легионының Көнчыгыш фронтка җибәрү өчен әзерләнгән өченче (штаб) батальонын, ашыгыч рәвештә ике эшелонга төяп (писарь Әмир Үтәшев тә шунда була), немецларның көчле сагы астында, Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюи шәһәренә озаталар (чөнки баштагы беренче, икенче батальоннардагы легионерлар, фронт сызыгына килүгә үк, немец офицерларын юк итеп, Витебск өлкәсендә һәм Көнбатыш Украинада партизаннар ягына чыккач, гитлерчылар тирән пошаманга төшә). Җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы җитәкчесе буларак, Ә.Үтәшев тиз арада француз партизаннары – макизарлар белән элемтәгә керә һәм легионерларның, бераздан немецларны коралсызландырып, французларның Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә бердәм рәвештә кушылуларын тәэмин

итә. Бер үк вакытта Совет Армиясе офицеры да, Франция Эчке Көчләре капитаны да, татар һәм рус партизаннарының беренче төркеме җитәкчесе дә булган Әмир абый (французлар аны, хөрмәтләп, «Комбатан Волонтёр» дип йөртәләр, үзләренең иң зур орденнары белән бүләклиләр) ике меңгә якын легионерны, макизарны Туган илгә исән-имин кайтаруда да һәм җәлилчеләрдән Габбас Шәрипов, авылдашы, кан кардәше Нигъмәт Терегулов, француз патриоткасы Мария Дебиезе белән берлектә, дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре»нең беренчесен саклап калуда чын тугрылык-кыюлык үрнәген күрсәтә.

Әмма бу егетлек үз вакытында тиешенчә бәяләнми. 1945 елның 1 сентябрендә Әмир Галимҗан улын – Франциядәге ватандашларын Туган илгә алып кайтучы эшелон җитәкчесен – совет-герман чигендә армия контрразведкасы кулга ала. Тиешле тикшерүләрне үткәннән соң, аны ирекkә җибәрәләр, әмма озакка түгел. Дусты Нигъмәт Терегуловны төрмәдән коткарырга дип, Арчадан Казанга килеп йөргәндә, 1948 ел июлендә Әмир Үтәшевне яңадан кулга алалар. Хәрби трибунал башта аны «Ватанга хыянәте өчен» атарга хөкем итә. Бераздан бу карар 25 елга иректән мәхрүм итү – каторга белән алыштырыла...

Гаделлек, чын дөреслек тантана итсен өчен бик озак көрәшергә туры килә бу батыр йөрәкле, курку белмәс ир-атка. Үзеннән бигрәк, бер гаепсезгә төрмәләргә ябылган, лагерьларга озатылган сугышчан дуслары өчен борчыла, газаплана ул...

Шушы урында мөмкинлектән файдаланып, 2010 елда «Идел-Пресс» нәшриятында дөнья күргән «Ватанга тугры калдылар» дигән 528 битле саллы гына китап турында сөйләп үтик әле. Тугандаш Башкортстандагы талантлы каләмдәшләребез – әтиле-уллы Хәйдәр һәм Айдар Басыйровларның күп еллык эзләнүләренең, фидакарь эшчәнлекләренең уртак «җимеше» бу. Бөек Ватан сугышы чорында зур каһарманлык үрнәкләре күрсәткән данлыклы шәхесләребез – патриот-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның «Идел-Урал» легионындагы рухташ дуслары, аларның тормыш һәм көрәш юлларын өйрәнүче язучылар, галимнәр, эзтабарлар турында сөйләүче энциклопедик рухтагы әлеге китап тарихи материалларга, архив документларына, фоторәсемнәргә искиткеч бай. Монда Әмир ага Үтәшевка кагылышлы «Легендар шәхес» дигән бүлек тә бар. Шуннан кайбер өзекләрне укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәм:

*«...Әмир Галимҗан улының тормыш, көрәш юлы турында тагын да күбрәк белергә теләп, без Башкортстан морзалары мәҗлесе җитәкчесе Максат Шәрифҗан улы Мамлиевка мөрәҗәгать иттек. Максат морза Благовар районының Яңа Каргалы авылында туган – ягъни ул Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н туган илгә алып кайтучы Нигъмәт Терегулов белән Әмир Үтәшевнең авылдашы. Күптән түгел генә ул Рәшит морза Мамлиев белән берлектә «Каргалинские корни» дигән китап чыгарды. Анда, әлбәттә, Нигъмәт һәм Әмир морзалар турында да язылган.*

*Әмир Үтәшев үзенең тормыш юлы, дошман тылындагы көрәше, Җәлил һәм җәлилчеләр, Франциядә партизаннар сафында йөрүче татар һәм башка милләт егетләре турында бик күп документаль материаллар җыйган. Аларның бер өлеше әлеге көндә кайчандыр үзе укып чыккан Яңа Каргалы урта мәктәбендә, янә бер өлеше Башкортстан морзалары мәҗлесендә саклана.*

*Бу материаллар белән танышкач, Әмир Галимҗан улының искитәрлек кеше булганын тагын бер мәртәбә аңладык.*

*Мең үлемнән котылып, 1956 елда туган җиренә кайта ул. Аныкы кебек язмышка дучар ителгәннәрнең күбесе тыныч тормышка һәр көнне шатланып, җайлап кына көн күрәләр. Буйдаклары өйләнеп, балалар үстерәләр. Дөрес, КГБ, милиция органнары аларга тынгылык бирми – вакыт-вакыт әңгәмәгә чакырып торалар. Әмма болары гына, элек күргәннәр белән чагыштырганда, бик кечкенә мәсьәлә булып кала.*

*Ә менә Әмир абый тынып калмый. Ул үзенең хаксызга рәнҗетелгәнен исбат итәргә тели. Әмма СССРның, Русиянең куәтле бюрократик машинасына каршы көрәшү җиңел булмый. Алтмышынчы елларда, Җәлил һәм җәлилчеләрнең көрәш юлы ачыкланып та бетмәгән заманда, моны эшләү икеләтә-өчләтә авыр була.*

*Әмир Галимҗан улы иң югары баскычтагы түрә-чиновникларга мөрәҗәгать итә.*

*1961 елның 17 октябрендә Мәскәүдә Съездлар сараенда КПССның XXII съезды*

*ачыла. Ул чагында съезд Президиумы исеменә меңләгән кешеләр, үзләренең төрле проблемаларын хәл итүне сорап-үтенеп, хат белән мөрәҗәгать итәләр. Әмир Галимҗан улы да съезд исеменә хат юллый.*

*Аның хаты, күрәсең, бик кешелекле партия функционеры кулына килеп эләккәндер. Озак та үтми, Әмир аганың эшен яңадан карыйлар һәм 1962 елның 2 мартында түбәндәге документны җибәрәләр:*

**«СПРАВКА**

**Дело по обвинению Утяшева Амира Галимьяновича, до ареста – 21 июля 1948 года – работавшего главным бухгалтером Арской МТС в пос. Арске Татарской АССР, пересмотрено Военной коллегией Верховного Суда СССР 21 февраля 1962 года.**

**Приговор Военного трибунала Приволжского военного округа от 18 ноября 1948 года и определение Военной коллегии Верховного Суда СССР от 19 февраля 1949 года в отношении Утяшева А. Г. по вновь открывшимся обстоятельствам отменены и дело о нем, за отсутствием состава преступления, прекращено.**

**Утяшев А. Г. по данному делу реабилитирован».**

*Кулында рәсми документ булгач, ул инде күкрәген ныграк киереп йөри башлый. Әмма бу вакытта әле меңләгән элекке француз партизаннары, легиончылар «Ватанын саткан» дигән тамга белән йөри. Аларга пенсия бирмиләр, сугыш ветераннары кичәләренә чакырмыйлар, кайберәүләрен хәтта эшләгән җирләреннән дә чыгарып җибәрәләр.*

*1962 елда Әмир Галимҗан улы, мөгаен, реабилитация үтүче тәүге легиончыларның берсе булгандыр. Башкалар исә мондый бәхеткә шактый еллар үткәч кенә ирешкәннәр.*

*Әмир ага Үтәшев, җиңнәрен сызганып, гаделлек өчен көрәшне башлый. Ул төрле рәсми оешмаларга, партия-совет органнарына, аерым кешеләргә хатлар, гаризалар яза. Аның бу көрәше бик озакка сузыла...»*

Мөхтәрәм Әмир Галимҗан улының Казан шәһәрендәге фатирында булганда, без аның 1989 елда КПСС Үзәк Комитеты секретаре Г. И.Усмановка язган хаты белән танышкан идек. Менә ул тарихи документ:

*«Хөрмәтле Гомәр Исмәгыйль улы!*

*Мин Сезгә – СССР Верховный Совет депутаты һәм КПСС Үзәк Комитеты секретаре буларак, зур үтенеч бюелән мөрәҗәгать итәм. Фашистлар тарафыннан оештырылган татар легионыннан меңнән артык кешенең Франциядәге Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучылар ягына чыгуында күп француз иптәшләр зур роль уйнады. Аларның безнең Ватан алдындагы хезмәтләре зур һәм түбәндәге гражданнарны бүләкләргә кирәк:*

*1. Запальский Серж (псевдонимы – Жевольд) – подполковник, Француз Хәрби Көчләренең Югары Луара округы командующие. Дүрт ел подпольеда була. Иң элек партизаннар ягына 118 легионерның күчүен оештыра. Аннары, партизаннар җитәкчесе булып, барлык татар легионын әсирлектән коткара.*

*2. Капитан Сегель – партизан отрядларын оештыручы (җәзалап үтерелә).*

*3. Мишель Хнатышин – тәрҗемәче (үтерелә).*

*4. Мадам Мария Ильинишна һәм месье Эмиль Корк – партизаннар отряды командующиеның тәрҗемәчеләре.*

*5. Ижен Биго һәм аның әтисе Клемент Биго – коммунистлар, татар легионерларының партизаннар белән элемтәсен оештыручылар.*

*6. Минем элемтәчеләр Мария-Роза Рош һәм Келлерман батальонының штаб начальнигы Мишель Рош – легионны француз макизарлары ягына чыгаруда катнашучылар.*

*7. Майор Коален Согадан (псевдонимы Тайор) – капитан Сегель һәлак булгач, Келлерман батальоны белән җитәкчелек итте, татар легионының макизарлар ягына күчүендә булышты.*

*8. Савель – Франция Компартиясенең Югары Луара секциясе Генераль секретаре.*

*9. Мишель Кауфман – капитан Александрның партизан отрядындагы тәрҗемәчесе, хәзер Парижда яши.*

*Болардан тыш, Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендәге язган шигырьләрен саклап калуда түбәндәге иптәшләр катнаша:*

*1. Шәрипов Габбас – Моабит төрмәсендә шигырьләр дәфтәрен Муса Җәлилнең кулыннан ала, аны Франциягә алып килә һәм Нигъмәт Терегуловка бирә.*

*2. Терегулов Нигъмәт – шул дәфтәрне саклап, Туган илгә алып кайта һәм ТАССР Язучылар союзына тапшыра.*

*3. Мадам Мария Дебиезе һәм аның туганы Жозефина Барнау – Ле-Пьюи шәһәрендә М.Җәлилнең дәфтәрен яшереп саклап торучылар һәм безнең элемтәчеләр.*

*Шунысын да әйтик, М. Җәлилнең яшерен оешмасы башкарган эш Ватанга тугры булып калуда ярдәм итте. Татар легионерлары макизарлар ягына чыкты, аннары Туган илгә кайтты, фашизмны җиңүдә зур өлеш кертте.*

*М.Җәлилнең яшерен оешмасында катнашучыларның батырлыгы Ватан тарафыннан лаеклы рәвештә бәяләнде дип әйтеп булмый. Түбәндәге патриотлар дәүләт бүләгенә лаек:*

*1. Хисаметдинов Рушад Билял улы – Кыргызстанның Ош шәһәрендә яши.*

*2. Фәхретдинов Гарәф – Ташкентта яши.*

*3. Саттаров Рәхим Сөләйман улы, Мамлиев Әкрам (икесе дә – Башкортстаннан) – 1943 елның июнендә Польша җиреннән партизаннар белән элемтә урнаштыру өчен җибәреләләр (әмма алар, дошман засадасына эләгеп, батырларча һәлак булалар).*

*Капитан Аксёнов белән минем турыда сүз барса, 1945 елның 5 апрелендә Ле-Пюидан Парижга Совет Хәрби Миссиясенә җибәрелгән хатны игътибар белән каравыгызны үтенәм. Бу документ 1988 елның апреленә кадәр ТАССР КГБсы архивында яткан».*

Подполковник Серж Запальский (Җевольд) кул куйган әлеге тарихи гуаһнамә безгә күп нәрсәне ачыкларга ярдәм итте:

*«Париждагы Совет Хәрби Миссиясенә.*

*Немец армиясе подразделениеләрендәге хәрби әсирләр арасында Югары Луара партизаннары белән ныклы бәйләнеш тотучы кызылармиячеләр шактый иде. Аларның күбесе Татар легионын таркатуда булышлык күрсәтте. Соңыннан легионерларның бер өлеше француз партизаннарына кушылды.*

*Командирларын аеруча билгеләп үтәр идем:*

*1. Капитан Андрей Аксёнов – 1913 елның 13 декабрендә Мәскәүдә туган. Хатынының адресы: Москва-112, Дунашевская, 7–11. Рус партизаннарының беренче группасын оештырып, аны 1944 елның 28 июлендә Ружак шәһәре янындагы урманга алып килде. Отряды белән гаять кыю сугышып, Югары Луара округындагы (Көньяк Франция) Баинс шәһәре өчен немецлар белән бәрелештә 1944 елның 11 августында батырларча һәлак булды.*

*2. Капитан Александр Үтәшев – 1919 елның 15 сентябрендә Башкортстанның Благовар шәһәре янындагы Каргалы авылында туган, хатынының адресы: Татарстан Республикасы, Арча эшчеләр посёлогы, Интернационал урамы, 35нче йорт. Рус партизаннарының беренче группасын оештыручы һәм аның комиссары булды. Капитан Аксёнов белән берлектә ул группаны макизарлар янына урманга алып килде. Андрей Аксёнов һәлак булганнан соң, капитан Александр рус партизаннары группасын җитәкләде һәм сан ягыннан үстерде.*

*Үтәшев үз отряды белән Баинс шәһәре янындагы бәрелешләрдә катнашты һәм 22 рус солдатын әсирлектән коткарды. Аллегро, Монтан тирәсендә барган сугышларда да үзен уңай яктан нык танытты. Аннары Соги (Югары Луара округы) янында немец солдатларын һәм француз фашистларын эзләп табып, аларны кулга алуда турыдан-туры катнашты. Ле-Пьюи шәһәрен азат иткән көндә аның группасында 118 ирекле сугышчы бар иде. Алар һәммәсе дә тәртипле, сугышчан хәрәкәтләр алып бару өчен ныклы әзерлекле иде. Өстәвенә, командирларын да хөрмәт итәләр иде.*

*Капитан Александр Үтәшевның отряды һәрвакыт соңгы тамчы канынача сугышырга әзер булуы һәм кыюлыгы белән француз партизаннарына үрнәк булды.*

*Легионны таркатудагы тырышлыгы өчен, партизаннар отрядын искиткеч оста оештырганы һәм җитәкләгәне өчен, Совет Армиясе офицеры Александр Үтәшевка Француз Армиясе капитаны дәрәҗәсе бирелде (Франция Эчке Көчләренең Келлерман*

*батальоны буенча 1944 елның 2 августында игълан ителгән 2нче номерлы приказы нигезендә) һәм ул Франциянең Хәрби Тәре ордены белән бүләкләнде...*

*Курку белмәс батыр патриотларның ихлас ярдәме нәтиҗәсендә ирешелгән уңышларның аеруча мөһимлеген искә алып, Совет Армиясенең Югары командованиесенә шул хакта җиткерүегезне сорыйм.*

*Подполковник Запальский».*

* * *

...Әмир Галимҗан улы озак еллар буена Франциягә бару, фашизмга каршы бергәләп көрәшкән иптәшләренең намуслы исемнәрен кире кайтарырга булышу, инде вафат булганнарының якыннарына легионер-макизарлар турында чын хакыйкатьне белдерү уе белән янып йөри. Анда бару өчен теләк кенә түгел, кирәкле документларны тутырырга, юлга акча да кирәк була. Патриот-макизар Франция Президенты Франсуа Миттеранга хат яза. Шулай ук СССР сугыш ветераннары советына һәм Каршылык күрсәтү сугышчыларының Франциядәге халыкара берләшмәсенә дә мөрәҗәгать итә ул.

Бәхетенә, аңа ярдәм итәргә теләүчеләр табыла. Франциягә бару өчен барлык оештыру мәсьәләләре уңай хәл ителә. 1990 елның августында Әмир ага Үтәшев Казаннан француз теле белгече Надежда Татаренко белән бергә юлга чыга. Баинс, Ле-Пьюи шәһәрләренә барып, якташларыбызның каһарманлыкларын раслаучы үтә мөһим документларны алып кайта...

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтик: Франциядәге дуслары Әмир Галимҗан улын, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, милли Герой итеп каршы алалар. Бу илдәге матбугат чаралары да гадәти булмаган визитны җентекләп яктыртып баралар. Мәсәлән, Югары Луара департаментының «Трибуна» газетасы 1990 елның 3 август санында «46 ел узгач, Россия макизары Баинс янында сугышлар барган урында» дигән мәкаләсендә болай дип яза:

*«...Бу пәнҗешәмбедә Баинс шәһәренең мэры Мишель Декольн әфәнде Казан кунагы Александр Үтәшевне аэропортта каршыларга дип, Парижга китте... Ярты гасырга якын вакыт узганнан соң, Россия солдаты кайчандыр сугыш кыры булган урыннарга, өч ватандашы күмелгән Вержезак зиратына әйләнеп кайта. Аның кайтуы Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә, дөресрәге, Баинс янындагы сугышларга бәйле. Бу хакта, Фернан Буатенең «Түгелгән канның таш шаһитлары» дигән китабын укып, төгәлрәк мәгълүматлар алырга була.*

*...Ле-Пюига килеп урнашкан һәм Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучыларга каршы сугышырга тиешле немец гарнизонында хәрби рус әсирләре дә була. Дөресрәге, легионга көчләп кертелгән, җирле халык «монголлар» дип атаган татар әсирләре алар. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ныгый барган шул чорда йөзләп әсир, гарнизоннан качып, Ружак һәм Иссенжо районнарында капитан Сегель җитәкчелегендәге макизарларга барып кушыла. Немецларга каршы Баинс шәһәре өчен барган сугышта һәлак булган алты партизанның да өчесе – элекке легионерлар. Менә алар кемнәр: Андрей Аксенов – очучы, капитан; Газизҗан Зөбәеров һәм билгесез солдат...*

*Ул сугышта исән калганнарның берсе – Александр Үтәшев. Легионнан качып, ул Каршылык күрсәтү хәрәкәте алып барган көрәшләрдә бик нәтиҗәле катнаша...»*

Франция Хәрби көчләренең Югары Луара округы командующие Серж Запальский бу вакытта әле исән булып чыга. Дуслар, очрашып, 45 ел элек булып үткән хәлләрне исләренә төшерәләр.

1990 елның 11 августында подполковник С.Запальский Баинс шәһәре бәйрәменә СССРдан Ә.Үтәшевнең килүе хөрмәтенә үткәрелгән митингта болай ди:

*– Минем дустым Үтәшевка – капитан Александрга – без тиешле хөрмәтне күрсәтергә бурычлыбыз. Сугышчан дуслыкка тугрылыклы булып калуы белән, үзенең искиткеч кешелекле эш-гамәлләре белән ул безнең һәлак булган иптәшләребез турындагы изге хатирәләребезне яңартты... Нәкъ менә шушында, дөресрәге, Ружакта, 1944 елның 26 июне көнне вермахт карамагындагы рус солдатларын яңадан сафка кайтару стратегиясе эшләнде. Шуннан соң без Баинста немецларны тукмауга керештек. Франция Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә бу стратегия искиткеч зур*

*роль уйнады. (Тик шунысы кызганыч – бу хакта бездә аз беләләр әле.) Шушы уникаль стратегия ярдәмендә без макизарлар отрядларын короллы рус солдатлары хисабына тулыландырдык, дошманның сугышчан көчен киметтек, рухын сындырдык. Үзебез исә бик аз кеше югалттык. Әйе, без бу эшне оста башкарып чыктык. Немецларның Генштабы, аның вәкиле майор Шмелинг үзләренең җиңелүләрен танырга мәҗбүр булды... 1944 елның 12 августына чаклы рус әсирләреннән 188 кеше, безнең тарафтан бернинди басым ясалмыйча, үз теләкләре белән макизарлар ягына чыкты. Капитан Александр минем: «Партизаннарга каршы сугышудан баш тартсыннар!» – дигән әмеремне легионга җиткергәч, анда калган легиончылар бу фәрманымны берсүзсез үтәделәр. Немецларның армиясе таркала башлады. Легиончыларның макизарлар ягына авышуы хәлне бөтенләй үзгәртеп җибәрде. 1260 партизанга каршы 286 немец белән 36 француз полицае гына торып калды. Шуннан соң алар безгә әсирлеккә бирелергә мәҗбүр булдылар!..*

Әлеге митинг уңаеннан, «Трибуна» газетасының 13 августта чыккан санындагы «Баинс: 1944 елгы сугышны искә алу» дигән язмага да күз салып үтик:

*«...Баинста һәлак булганнар монументы янына ике йөзләп кеше җыелды. СССРдан капитан Александр Үтәшев килү сәбәпле, быелгы тантана аеруча истәлекле узды. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннары элеккечә олы кунак янәшәсенә туплапдылар...*

*Александр Үтәшев француз партизаннарының мөһим заданиеләрен үти – дошман турында тулы мәгълүматлар тапшырып тора. 1944 елның июль аенда ул, бик күп иптәшләрен ияртеп, макизарлар янына китә. Алар майор Когальон җитәкләгән отрядка барып кушылалар, бергәләшеп, немецларга каршы күп кенә бәрелешләрдә катнашалар...*

*Азатлык килгәннән соң, Франциянең Каршылык күрсәтү хәрәкәте җитәкчелеге бүләкләгән икенче Хәрби Тәрене дә алырга өлгермичә, Александр Үтәшев туган иленә – Советлар Союзына кайтып китә. Әмма анда аны, «хыянәтче» дип, 25 елга хөкем итәләр...»*

«Левэй» газетасы шул ук елның 14 август санында чыккан «Каршылык күрсәтү хәрәкәте сугышчылары Александр Үтәшев янында» дигән мәкаләсендә, Әмир ага турында сүзне дәвам итеп, түбәндәгеләрне яза:

*«...Ле-Пюидагы яшерен оешма җитәкчесе Үтәшев СССРда 8 ел буена лагерьларда утырып чыкканнан соң гына реабилитацияләнә. Хәзер инде ул үзенең көрәштәш ватандашларын аклау чараларын эзли...*

*Һәлак булган иптәшләренең каберләренә чәчәк бәйләмнәре куйгач, карт солдат күз яшьләрен тыя алмады...*

*Һәйкәл янында соңгы сүзне Генераль совет вәкиле Прориоль әфәнде әйтте. Ул Үтәшев әфәндегә, көчле рухлы, изге-якты күңелле шәхес булганы һәм Францияне дошманнан азат итүдә турыдан-туры катнашканы өчен кайнар рәхмәт белдерде.*

*«Сугыш Сезне бу якларга элек көчләп – мәҗбүри итеп китергән булса, бүгенге иминлек Сезне безнең департаментта олы кунак сыйфатында кабул итәргә ярдәм итте», – диде ул...»*

* * *

Франциядән куанып-канатланып кайтты Әмир Галимҗан улы. Биредәге көрәштәш дуслары ярдәмендә, ул француз макизарлары сафында булган 118 ватандашыбызның тиешле рәсми оешмалар тарафыннан расланып мөһер сугылган, имзалар куелган тулы исемлеген дә тапты. Киллерман батальонында капитан Александр Николас (ягъни Әмир Үтәшев – Ш.М.) җитәкчелегендәге ошбу легионер-партизаннарның 48е – мөселман, 2се – грузин; 68е рус фамилиясендә теркәлгәннәр. Мөселманнарның саны азрак күренүнең дә үзгә бер сәбәбе бар: татар-башкорт ир-егетләренең байтагы рус исем-фамилиясендә йөргәннәр.

Киләчәктә шул көрәштәшләрен тулысынча аклау өчен Әмир Галимҗан улына командир Серж Запальский (Жевольд) әзерләгән тагын бер мөһим документ бик ярап куйды. Гәрчә ул, хат буларак, тынгысыз җанлы олуг эзтабар-җәлилче Рафаэль

Мостафинга адресланган булса да, матбугат битләрендә басылып чыккач, бихисап күңелләрдә зур кызыксыну уятты.

*«Франциядәге «Идел-Урал» татар легионында антифашистик оешма бар иде, – дип яза Жевольд. – Аңа капитан Александр Үтәшев җитәкчелек итте. Без аны Александр Николас буларак беләбез. 1944 елның мартыннан башлап Үтәшев әфәнде безнең белән Александр Николас буларак хезмәттәшлек итте. Август башында, ягъни партизан отрядына күчкәч, ул шушы исемгә паспорт алды (немецлар туктаткан очракта күрсәтү өчен). Паспортны аңа мин үзем тапшырдым. Александр Франция гражданины булып санала башлады (моны раслаучы документлар хәзер дә Югары Луара департаменты архивларында саклана. Александр, эз яшерү өчен, «милләте буенча – алжирлы» булып теркәлде).*

*Әсирлектән азат ителгәч һәм 352 нче номерлы совет батальоны оешкач, ул ФХК (Франция Хәрби Көчләре) капитаны булып һәм батальон командирының сәясәт буенча урынбасары булып хезмәт итте...»*

Әмир Галимҗан улы үзенең эшчәнлеген 1990 еллар башында тагын да киңәйтебрәк җибәрде. Радио-телевидение тапшырулары, газета-журналлар битләре аша чыгышлар ясап, Идел-Урал төбәкләрендәге хәрби комиссариатлар, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты вәкилләре белән элемтәгә кереп, үзенең сугышчан дусларын, легионер-макизарларны ыклап эзләүгә кереште.

1991 елның 24 декабрендә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев белән дә очрашты ул. Бу көнне биредә Германиянең Плетцензее төрмәсендә 1944 елның 25 августында көндезге 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минуткача вакыт эчендә фашист гильотинасында башлары киселгән унбер татар каһарманын зурлап искә алу, шуларның унысына (дөресрәге, якыннарына) I дәрәҗә Ватан сугышы орденнарын тапшыру тантанасы үткәрелде.

Билгеле булганча, патриот шагыйрь Муса Җәлил «Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткәне өчен» СССР Югары Советы Президиумының 1956 елгы 2 февраль Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән мәртәбәле исемгә лаек булган иде инде. 1957 елның 22 апрелендә исә аңа дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр циклы өчен Ленин премиясе дә бирелде...

Ә менә М.Җәлил белән бер үк дәрәҗәдә каһарманлык үрнәге күрсәткән көчле рухлы шәхесләрдән Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров кебек фидакарь җаннар Советлар хөкүмәтенең бернинди бүләге белән дә билгеләп үтелмәделәр. Шушы гаделсезлек бик күпләрнең күңелләрен тырнап торды.

Заманында Татарстан Язучылар оешмасын җитәкләгән мөхтәрәм каләм әһелләреннән Зәки Нури, Гариф Ахунов, Җәлилнең якын дусты Гази Кашшаф һәм, әлбәттә инде, патриот-шагыйрь һәм аның көрәштәш дуслары турында гаҗәеп кызыклы, сискәндерерлек язмалары белән миллионлаган күңелләрне үзенә җәлеп иткән эзтабар әдип Рафаэль Мостафин гаделлекне торгызу, торгынлык чоры бозларын эретү буенча үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Аннары бу эшкә, җиң сызганып, 1984–1989 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булган киң колачлы, тынгысыз әдип-драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин алынды. Рафаэль Мостафин һәм милләтпәрвәр җанлы бер төркем зыялыларыбыз белән бергә, ул Татарстан Республикасы һәм СССР җитәкчеләренә М.Җәлил белән бер үк вакытта җәзаланган ун татарга да иң югары дәрәҗәле исемнәр бирүне яисә орденнар белән бүләкләнүне сорап, хат арты хат юллады. 1989 елда Т.Миңнуллин СССР Югары Советына депутат итеп тә сайлангач, аңа бу өлкәдә эшне тизләтү өчен шактый зур мөмкинлекләр дә ачылды.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев үзе дә каһарманнарыбызны бүләкләү кирәклеге турында, җай чыккан саен, СССР Президенты М.С.Горбачёвның исенә төшереп тора. Туфан ага да шушы мөһим мәсьәлә буенча һәр ике Президент Аппаратында булып чыга, Бүләкләүләр бүлегенең ишеген еш шакый...

Ниһаять, 1990 елның 5 маенда «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында актив катнашучыларны I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләү турында»

Совет Социалистик Республикалар Союзы Президенты Указы игълан ителде. Анда «фашистларга каршы яшерен группада актив патриотик эшчәнлекләре, ныклык һәм батырлык күрсәткәннәре өчен» ун каһарманыбызның исем-фамилияләре зурлап телгә алына...

Шул уңайдан «Социалистик Татарстан» газетасының 1990 елгы 6 май санында, беренче биттә, әлеге Указ белән бергә, СССР халык депутаты, язучы Туфан Миңнуллинның «Җәлилчеләр» дигән язмасы дөнья күрә. Биредә аны бернинди кыскартуларсыз, тулысынча бирәбез:

**«Зарыгып көткән көн, ниһаять, килде!**

**Бөек Җәлилебезгә батырлыгына тиң хөрмәт күрсәтелсә дә, көрәштәшләренең исемнәре күләгәдә кала килделәр. Ил, Халык, Ватан өчен гомерләрен биргән фидакарь җаннарның батырлыгын дәүләт югарылыгында танырга һәм тиешенчә бәяләргә ашыкмадылар.**

**Дистә еллар буе бихисап күп оешмаларга мөрәҗәгать итеп хатлар яздык. Карарга кирәк, диделәр... Карамадылар. М. С.Горбачёвка исемләп язылган хат нәтиҗәле булды. Менә ул Указ бүген дөнья күрә!**

**Андагы исемнәрне кат-кат укыгыз. Алар – изге исемнәр! Алар безнең халкыбызның йөз аклыгы, горурлыгы! Милләттәшләремә нинди генә ярлыклар такмасыннар, аның затлы уллары дөнья алдында һәрвакыт асыл булып калдылар.**

**Муса Җәлил һәм җәлилчеләр!**

**Мин аларның исемнәрен тагын бер кат олылап, горурланып кабатлыйм:**

**Абдулла Алишев, Әхәт Атнашев, Абдулла Батталов, Фуат Булатов, Галләнур Бохараев, Гайнан Курмашев, Фуат Сәйфелмөлеков, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хөснуллин, Гариф Шабаев...**

**Онытмагыз бу исемнәрне, кешеләр!..»**

* * *

Шулай итеп, Рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагы кадаганнан соң 45 ел вакыт үткәч, батырларыбызга карата, шактый соңлап булса да, җылы сүз әйтелде, кылган бөек гамәлләренә тиешле бәя бирелде...

1991 ел декабрендә Казан Кремлендә җәлилчеләрне искә алу тантанасында чыгыш ясап, Татарстан Президенты күңелләргә сары май булып ятарлык өметле сүзләр әйтте:

– Әле без батырларыбызның данлы исемнәрен, аларның якты образларын һәркемнең йөрәк түренә җиткерү буенча киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк шөгыльләнергә уйлыйбыз. Ышандырып әйтә алам: озакламый Муса Җәлил һәйкәле янына аның көрәштәш дуслары да, бронза барельефлар рәвешендә, сафка һәм сакка басар! Батырлык һәм Хәтер мәйданы булып әверелер ул изге урын...

Әмир ага Үтәшев тә, мөмкинлектән файдаланып, үзенең фикерләрен әйтеп калырга ашыкты:

– Җәлилчеләрнең, легионер-макизарларның истәлекләрен туплап, газета-журналларда бастырасы, аерым китаплар итеп чыгарасы иде. Аларга багышлап документаль кинофильмнар, видеофильмнар, теле-радиотапшырулар эшлисе иде. Вакыт көтми, вакыт ашыктыра! Берәү дә мәңгелек түгел...

* * *

1993 елның 21–24 апрель көннәрендә Ә.Үтәшев, Франциядә фашистларга каршы көрәшкән легионер-макизарларның Беренче халыкара конференциясендә дә эзтабар язучы Госман Гомәр белән бергә катнашып, эзләнүләрен тагын да тулырак җәелдереп җибәрү өчен зур мөмкинлекләргә ия булды. Шул ук елның 6 маенда, Татарстан Дәүләт милли музеенда җәлилчеләргә багышланган искә алу җыенында, Әмир аганың тырышлыгы белән, Каршылык хәрәкәтендә катнашучыларның «Кызыл ромашка» исемле ассоциациясе төзелде. Оешманың рәисе (президенты) итеп бертавыштан аның үзен сайлап куйдылар. Әлеге ассоциация Идел буе, Урал төбәге республика-

өлкәләрендә яшәүче элекке легионерларны, макизарларны, хәрби тоткыннарны, партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларны үзенә берләштерде.

Әмир Галимҗан улының турыдан-туры булышлыгы белән легионер-макизарлардан байтак кешегә намуслы исемнәре кире кайтарылды, хәрби бүләкләре тапшырылды. (Бу хакта тулырак мәгълүматларны тынгысыз эзтабар Михаил Черепановның «Татарстан» журналының 1994 елгы 1-2нче саннарында дөнья күргән «Капитан Үтәшев кем булган?» дигән күләмле документаль-публицистик язмасыннан табарга була).

Ниһаять, мәңге эремәс булып тоелган торгынлык бозлары ныклап җеби башлады. Җәлил белән бергә Мәңгелеккә күчәр алдыннан батырларның һәркайсы үпкән изге Коръән Казанга әйләнеп кайтты. Үлемсезлеккә атлауларына нәкъ ярты гасыр тулган көндә – 1994 елның 25 августында көндезге 12 сәгатьтә Муса һәйкәле янәшәсендә ун каһарманның һәркайсы барельефтагы сурәт рәвешендә (скульпторы – академик В.Е.Цигаль) торып басты! Җәлилчеләргә багышланган Хәтер җыенында Әмир ага Үтәшев тә чыгыш ясап:

– Бу көнне күрүем белән бик тә бәхетлемен! – диде. – Инде бүген Мусага һәм җәлилче дусларыма шатланып рапорт бирә алам: Едлинода сезгә биргән вәгъдәбезгә тугры калдык, башлаган изге, хак эшебезне ахыргача җиткердек – легионерлардан торган батальоннар ватандашларыбызга, французларга каршы корал күтәрмәде... Шуңа сөенәбез, горурланабыз: Сезнең батырлык онытылмый, йөрәкләрдән йөрәкләргә, буыннардан буыннарга күчә бара! Бу юнәлештә без дә – исән җәлилчеләр дә – көчебездән, сәләтебездән килгәнчә үзебездән өлеш кертәбез...

«Исән җәлилчеләр» дигәннән, биредә Гарәф Фәхретдинов, Фәрит Солтанбәков кебек олуг затларны истә тотып әйткән иде ул чакта Әмир ага...

* * *

1995 ел азагында Әмир аганың тормышында тагын бер истәлекле вакыйга булды: ул Франция хөкүмәте билгеләгән махсус пенсияне ала башлады! Идел-Урал төбәгендә яшәүче элекке макизарлар арасында беренчеләрдән булып... Әнә шулай, киң күңелле, олы җанлы французлар үз Ватаннарының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкән «Комбатан Волонтёр»ны – инде сугыштан соң күп еллар үтсә дә! – онытмыйлар. Әмир ага Үтәшев турында кайгыртып, 1995 елның апрелендә Казанга Франциянең Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Пьер Морель әфәнде махсус килеп киткән иде. Пенсия өчен кирәкле документларны да шул чорда хәзерләтеп алган иде ул. Рәхмәт үзенә – сүзендә торган!

Танылган журналист Борис Бронштейн шул уңайдан «Известия» газетасының 1995 елгы 23 декабрь санында «Пенсионер французского значения» дип исемләнгән күләмле язмасы белән дә чыгыш ясады. Анда Әмир аганың орден-медальләр тагып төшкән зур фоторәсеме дә бирелгән иде (Евгений Канаев эше). Аннары әлеге язманы «Татар иле» газетасы да, тәрҗемә итеп, үзенең 1996 елда чыккан 1 гыйнвар санында урнаштырды. Билгеле булганча, бу газетаны Россия Федерациясенең һәм элекке СССРның татарлар яши торган күп кенә төбәкләрендә алдыралар иде...

Үтәшевләрнең фронтовик-әдип Гадел Кутуй урамындагы 88 нче йортка урнашкан фатирларына еш килеп йөргәнлектән, аларның үтә тынгысыз, кайнап торган тормыш белән яшәүләренә исләрем китә иде. Легионер-макизарларны барлау һәм аларның күбесен аклау штабына әйләнгән иде бер бүлмәле, әмма «шушы мең-миллион мәшәкатьле дөньяны үзенә сыйдыра алган» хикмәтле бу фатир... Йөрәкләрдә дөрләп торган Хәтер утын сүндермәс өчен, әнә, Франциядә дошманга каршы иңгә-иң торып сугышкан якын дусты Рушад ага Хисаметдинов та үләр алдыннан Әмир агага үзенең хат-васыятьнамәсен язып калдырган:

*«Кадерле Әмир! Газраил минем җанымны алырга берничә мәртәбә омтылыш ясап карады инде. Шуңа күрә Сиңа – ихлас дустыма – үтенеч-теләгем зурдан: йөрәгең типкәндә, башың эшләгәндә, колагың ишеткәндә, аяк-кулларың йөргәндә, безнең легионер-макизар дусларыбызны (исәннәрен дә, үлгәннәрен дә!) барлаудан һәм аларны аклаудан, намуслы исемнәрен кайтару өчен көрәшүдән һич тә туктама! Мин Сиңа ышанам...»*



*Капитан Әмир Үтәшев җитәкчелегендәге легионер-макизарлар Ле-Пюи каласында.*

Рушад дусты да Муса Җәлил кебек аңа шундый зур ышаныч белдергәч, үтенечен җиткергәч, ничек тик кенә ятсын инде Әмир ага?! Һәм ул, «Татарстан» журналының 1993 елда чыккан 10 нчы санында, «Макизар дуслар, сезне эзлибез!» дигән язмасы белән бергә, үз группасы сугышчыларының Франциядәге рәсми оешмалар тарафыннан расланган исемлеген дә урнаштырды.

*«...Шушы көнгә кадәр отрядыбыздагы 45 кешенең генә язмышы ачыкланды. Калганнарыбыз белән дә табышсак иде. Түбәндә моннан 50 ел элек Франциядә булып, Каршылык хәрәкәтендә катнашкан кешеләрнең исем-фамилияләре бирелә.*

*Көрәштәшләрем, хәбәр итегез! Әлеге исемлектән танышларын танучылар, сез дә җавапсыз калмассыз, дип өметләнәм.*

*Җаваплар көтеп, Француз Каршылык хәрәкәте капитаны*

*Әмир Галимҗан улы ҮТӘШЕВ.*

*Адресым: 420128 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Гадел Кутуй урамы, 88 нче йорт, 90 нчы квартира. Өй телефоны: 76–71–82.»*

**Француз Эчке көчләренә (Келлерман батальоны, 13 нче хәрби округ, Франциянең Югары Луара департаменты, Ле-Пюи шәһәре) үз теләкләре белән кергән татар һәм рус сугышчылары (капитан Александр группасы):** Аксёнов Андрей, Үтәшев Әмир, Зөбәеров Газизҗан, Шәмсетдинов Усман, Потачкин Пётр, Җамалетдинов Абдулла, Ильин Николай, Асибәков Гомәр, Хәсәнов Газиз, Галимов Тәлгать, Фәхретдинов Гарәф, Әхмәтъяров Сәмигулла, Мусин Лотфулла, Хатипов Нурулла, Сәгъдиев Сәлах, Моратов Хәбибулла, Рәҗәпов Габделхак, Габдрахманов Мөхәммәт, Шурышев Андрей, Исламов Васил, Тивзадзе Александр, Гарифуллин Гариф (Чукаш), Галикәев Хәниф, Гаффаров Йосыф, Исламхуҗин Сәет, Сәлимов Фәхретдин, Галәветдинов Габдрахман, Фәхриев Феликс, Заһитов Әнвәрбәк, Иргизов Гәрәй, Минһаҗев Әкрам, Иксанов Әсәт, Пантелеев Василий, Мулашев Мишел, Низаметдинов Әлмөхәммәт, Уразмәтов Әнәс, Карандрашвили Григори, Щербаков Анатолий, Гатауллин Хаҗи, Фомин Иван, Моисеев Пётр, Азнин Николай, Аверкин Степан, Казадеев Матвей, Щербаков Иван, Яранов Василий, Васильев Иван, Кашин Сергей, Шәрәфиев Фәрит, Фәйзуллин Шакир, Дмитриев Пётр, Усманов Корбан, Шәйхетдинов Абдулла, Бариев Әмәт, Павлов Александр, Толмачев Иван, Аксашкин Евгений, Мучкаев Василий, Велпалов Михаил, Солдаткин Тимофей, Бариев Сәйфулла, Вәлиев Шакир, Башков Константин, Степанов Тимофей, Чурашев Солтан, Громов Иван, Кармилов Иван, Яковлев Василий, Николаев Зиновий, Васильев Семён, Леонтьев Афанасий, Иванов Семён, Музыка Илларион, Ефимов Иван, Кандиков Терентий, Быков Павел, Пульчиков Яков, Елеханов Арсентий, Давидов Тимофей, Фёдоров Василий, Шарайкин Иван, Пазаев Арслан, Бояркин Василий, Уланов Семён, Арсентьев Николай, Асташкин Семён, Карамчанов Павел, Бикбаилов Владимир, Кутчишев Егор, Асуфьев Алексей, Терегулов Нигъмәт (Николай), Кәлимуллин Ислам,

Абдалов Мирза, Закиров Фәйзи, Королёв Пётр, Каматкин Иван, Мурадов Тимофей, Стрелецкий Юрий, Гренский Иван, Иванов Пётр, Андрейкин Дмитрий, Содаскин Иван, Божанов Павел, Алексеев Арефий, Бихузин Ямуза, Изибанров Алексей, Карпов Иван, Мәхмүдов Сабир, Ефремов Иван, Мальзиев Семён, Нагалкин Пётр, Әсәнов Әмит, Хәбибрахманов Таһир, Тресканов Михаил, Юлдашев Базар, Хәбибуллин Газиз, Мәгатов Мөхәммәт, Дорофеев Теодор...

**Раслыйм: Югары Луара округы партизаннары начальнигы, Ле-Пьюи шәһәрендәге Француз Эчке көчләре командующие Жевальд (Запальский).**

* * *

Әнә шулай, Әмир ага, йокы-ялын онытып, көрәштәш дусларының язмышларын җиңеләйтү өчен югары оешмаларга бихисап хатлар да язды, аларның чын патриотлар икәнлеген раслаучы тарихи документларны да туплап җибәрде. Кирәк икән – теге яки бу төбәккә барып та кайтты. Әйтик, Татарстанның Буа районындагы Янтуган авылында яшәүче легионер-макизар – француз партизаннары отрядында данлыклы старшина булган Ибраһим Айнатулла улы Айнатулловны һаман да сугыш ветераны итеп санамауларын-санламауларын белгәч, ул, барлык эшен ташлап, 1992 елның март азагында – апрель башында юллар өзеклегенә, язгы ташуга карамастан, шул төбәккә барып чыкты. Биредә ул сугышчан дусты турында район һәм хуҗалык җитәкчеләре белән очрашып сөйләште. Авыл халкы, укытучылар һәм укучылар катнашында аңа багышлап мәктәптә зур кичә үткәрде. Шуннан соң гына Ибраһим аганың кәефе дә, абруе да бердән күтәрелеп китте. Гомере буе туган ягында шофёр һәм янгын сүндерүче булып намуслы хезмәт иткән, сөекле хәләл җефете – Хәтирәсе белән берсеннән-берсе булдыклы егетләр, уңган кызлар тәрбияләп үстергән ветеранның иңнәренә пар канатлар үскәндәй булды шул истәлекле, дулкынландыргыч очрашулардан соң...

Республикабызның Кукмара районындагы Зур Сәрдек, Ташлы Елга, Ятмас Дусай авылларында яшәүче Гаян Әхмәтшин, Нургали Шәйдуллин, Галимҗан Әхмәтҗанов, Әтнәдән Мөбарәкша Хәсәнов, Азнакайдан Гомәр Асибаков, Баулыдан Пётр Долгов, Буадан Фазыл Хәйруллин, Казаннан Ризван Мөхетдинов, Башкортстанның Туймазы, Октябрьск, Уфа шәһәрләреннән Фәйзерахман Закиров, Әлмөхәммәт Низаметдинов, Әкрам Минһаҗетдинов, Әстерханнан Хәбибулла Моратов кебек дистәләгән легионер-макизарларны аклау, аларның намуслы исемнәрен кайтару буенча да ныклап шөгыльләнде Әмир ага. Бу эшләрнең һәммәсендә аңа кешелекле һәм уңган хатыны – якын дусты һәм киңәшчесе Рәйсә ханым, үз мәктәпләрендә «Иң яхшы мөгаллимә» буларак танылган кызлары Әлфия, оныгы – яшь шагыйрә Кадрия бик теләп булыштылар.

Гомумән, бу күркәм гаилә бар яктан да күпләрне сокландырырлык иде. Заманында Әмир абый, аклангач, Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап, төзелеш оешмаларында баш бухгалтер буларак тырышып эшләгән, мактаулы исеме телдән төшмәгән. Рәйсә Йосыф кызы исә, дүрт дистә ел дәвамында балаларга төпле белем-тәрбия биреп, мәгариф өлкәсендә уңыш казанган. Инде күптән лаеклы ялда булсалар да, аларның һәр көне (кайчакта – төннәре дә!) адәм балаларына игелек кылып үтә иде. Әмир ага белән Рәйсә ханымга кешеләрне ярата белү таланты тумыштан бирелгән, күрәсең. Әтнәдә яшәүче һәм Үтәшевләрнең кунакчыл фатирына еш килеп йөрүче мөгаллимә Мәрзия ханым Хәсәнова (мәгълүм макизар М.Хәсәновның хатыны) бик хаклы әйткәнчә, «биредән җанга – җылылык, күңелләргә яктылык алып, хакыйкатьнең кайчан да булса бер тантана итәчәгенә ныклы ышаныч белән чыгасың!..»

Үләренә берничә ай кала, Әмир ага Казан – Чаллы – Азнакай – Баулы – Октябрьский – Туймазы – Бүздәк – Уфа – Казан маршруты буенча йөреп кайтты. Үзенең көрәштәш дуслары, легионер-макизарлар һәм аларның гаилә әгъзалары, якын туганнары белән очрашты ул. Аңарчы Әмир ага Франциянең Баинс шәһәре янында барган сугышларда батырларча һәлак булган коралдаш дусты, үз отряды сугышчысы Газизҗан Зөбәировның гаиләсе янында – Башкортстан Республикасының Кыйгы районында булып, алар белән рухи туганлашкан иде...

Франциядәге Каршылык күрсәтү хәрәкәте ветераннарының «Комбатан Волонтёр»

ассоциациясе Әмир Галимҗан улы Үтәшевне, сугыш елларында фашистларга каршы көрәштә күрсәткән зур батырлыклары һәм макизарларны аклаудагы тынгысыз эшчәнлеге өчен, 1995 елда үзләренең «Почёт Билгесе» белән бүләкләде. Әлеге илнең танылган фоторәссамы Нуак Каррау әфәнде, Париждан махсус килеп, Әмир ага белән Рәисә ханымны фоторәсемгә дә төшереп алды

«Комбатан Волонтёр» ассоциациясенең Мәскәүдәге оешмасы җитәкчесе Олег Озёров, җәлилчеләрдән Фәрит Солтанбәков (Казан), Гарәф Фәхретдинов та (Ташкент) атаклы макизарны зур бүләккә лаек булуы белән беренчеләрдән булып котладылар. Исән булса, Рушад Хисаметдинов та, изге аманәткә тугрылыгы өчен, Әмир дустына үзенең ихлас рәхмәтен белдерер иде. Ни кызганыч, ул әлеге тантананы күрә алмады – гүр иясе булды...

* * *

Әйе, бер кеше дә мәңгелек түгел шул. Әмир ага Үтәшевны да рәхимсез авыру (инфаркт-инсульт) 1996 елның 21 гыйнварында башка кузгала алмаслык итеп, урынга екты. Әҗәл белән соңгы сулышына чаклы көрәште ул. Бөтен гомере тоташ батырлыктан, ялкынланып янудан торган олпат ир-атның – Әмир Галимҗан улы Үтәшевнең күпне кичергән тынгысыз йөрәге изге Рамазан аеның 16 нчы көнендә (6 февраль) 17 сәгать 15 минутта тибүеннән туктады... 77 яшен дә тутырырга өлгермәгән олуг милләттәшебезне, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, Казан каласының Яңа бистәдәге мөселман зиратында җирләдек. *(Аның турында «Татарстан яшьләре» газетасының шул ук елгы 22 февраль санында, хушлашу сүзе итеп, «Үтәлгән васыять» дигән язмамны да бастырдым).*

Генерал-майор Юныс Ибәтуллин кебек фидакарь хәрби эшлеклеләр, Таҗи Гыйззәт, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Рәшит Ваһапов, Ильяс Әүхәдиев кебек халкыбызның олуг мәхәббәтен казанган әдәбият-сәнгать осталары, Гыйлем Камай, Рәфгать Таһиров кебек киң танылган галимнәр янәшәсендә ята хәзер Әмир Галимҗан улы. Мәрмәрдән эшләнгән кабер ташы да әллә кайдан ук күренеп, күңелләрне үзенә җәлеп итеп тора...

Кем ничектер, әмма мин һәр җәлилченең, фашизмны җиңүгә үзләреннән лаеклы өлеш керткән һәр легионер-макизарның кабер ташларына иң элек яшәүне, тормышны, бар тереклекне, табигатьне, һәр җан иясен өзелеп сөйгән ватанпәрвәр рухлы әдибебез Абдулла Алиш (1908–1944) сүзләрен мәңге җуелмаслык итеп, уеп язар идем:

**«...Килдем, көрәштем, киттем... Без соңгы сулышыбызга кадәр халкыбызга тугры булып калабыз!..»**

Билгеле булганча, әлеге юллар А.Алишның 1944 елның 28 гыйнварында хәләл җефете Рокыя ханымга, уллары Алмаз белән Айвазга, якын туганнарына, дусларына атап язган соңгы хатыннан алынды. Бу хатны төрмәдән Бельгия патриоты – антифашист Эмиль Мэйзон алып чыга һәм Казанга юллый...

1944 елның августында фашист гильотинасында башлары киселгән каһарман милләттәшләребез хөрмәтенә Казан Кремле каршында торгызылган мемориаль үзәктә дә әлеге сүзләр балкып янса, аларның рухлары шат, безнең күңелләр түгәрәк булыр иде. Күренекле җәлилче-мөгаллим Фәрит ага Солтанбәков та (1916–2002) үзенең «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» дигән китабында (Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2001 ел) шул хакта искәртеп, ассызыклап язып калдырды. Аларның үтенеч-васыятьләрен тормышка ашыру – без исәннәрнең изге бурычы!

**Шаһинур МОСТАФИН,**
*эзтабарларның Татарстан Язучылар берлеге каршындагы*
*«Хәтер Яктысы» экспедициясе җитәкчесе,*
*Россия Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы.*

# АЛТЫН УРДА ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ ҺӘМ АНЫҢ МИРАСЫ

XII гасыр ахырында – XIII гасырның беренче унъеллыкларында Бөек далада яшәгән күпсанлы төрки-монгол кабиләләре Чыңгыз хан (1155/1162 – 1227) хакимияте астында бердәм дәүләткә берләштерелә[1]. Соңрак Чыңгызыйларның һәм аларның гаскәр башлыкларының күп кенә яулары нәтиҗәсендә кешелек тарихында күләме буенча аңарчы тиңе булмаган зур империя (40 млн кв. км чамасы) барлыкка килә[2]. 1250–1260 елларда ул барлыгы 160 миллионлап кеше яшәгән Үзәк, Урта һәм Алгы Азия, Кавказ арты, Палестинага кадәр Якын Көнчыгышны, шулай ук Көнчыгыш Европаның зур өлешен колачлый.

750 ел элек, 1269 елда, Чыңгыз хан варислары – Җүчи, Чагатай һәм Һулагу Олыслары ханнары үз-үзен империянең Бөек ханы дип игълан иткән Хубилайны танудан баш тартып, үз биләмәләренең чикләрен билгелиләр, гаять зур бердәм дәүләтнең яшәешенә нокта куеп, аның таркалуын рәсмиләштерәләр[3]. Территориясе буенча иң зурысы Җүчи Олысы була (10 млн кв. км тирәсе), аны Монгол империясенең куәте сакланган төп этносәяси варисы, скифлар-саклар империясе заманыннан алып исәпләгәндә, бөек дала империяләренең соңгысы дип атарга мөмкин[4]. Әлеге дәүләт җәмгатьчелек хәтеренә төрле милли һәм тарихи традицияләрдә кабул ителгән Җүчи Олысы яки Олуг Олыс, Дәште Кыпчак яки Комания иле, Бәркә Олысы яки Мәмләкәте Үзбәк (Үзбәк дәүләте), Татарлар державасы яки Бөек Татария һәм, ниһаять, Урда яки Алтын Урда атамалары белән кереп кала. XVI гасыр уртасына нисбәтле Казан елъязмачысы әсәре тәэсирендә соңгысы фәндә һәм публицистикада аеруча киң таралыш ала, ул әлеге илнең бөеклеген һәм куәтен тулырак яктырта.

Монгол империясе кебек үк, Алтын Урда да, һичшиксез, хәрби экспансия нигезендә төзелә. Ташкын сыман ябырылган яулар, монгол-татарлар тарафыннан күп кенә илләрнең һәм халыкларның буйсындырылуы нәтиҗәсендә бик күп кешеләр – яугирләр һәм тыныч тормышлы халык кырыла, исән калганнар газапларга дучар ителә. Күп кенә шәһәрләр (Урта Азия, Кавказ һәм Көнчыгыш Европадагы кайбер шәһәрләрне генә искә алам, ягъни: Бохара, Сәмәрканд, Харәзем башкаласы Үргәнеч, Хаҗәнт, Гүргәнеч, Дәрбәнт, Самцхе, Эрзурум, Идел Болгары башкаласы Биләр, Болгар, Суар, Җүкәтау, Рязань, Владимир, Киев, Люблин, Краков), кирмәннәр һәм торак пунктлар җимертелә, яндырыла. Әмма, кытай ораторы Лу Цзя (б.э.к. III-II гасырлар), шулай ук Чыңгыз ханның киңәшчесе Елюй Чуцай (1189-1243) сүзләре белән әйткәндә, «атка атланып, империя яулап булса да, ат өстендә генә утырып идарә итү мөмкин түгел». Империяләр көч кулланып кына, озак яши алмый, тиз таркала. Алтын Урда яшәешенең фәкать корал көченә буйсындырылганнарның каршылыгын һәм ризасызлыгын рәхимсез рәвештә бастыруга, аларның яулардан соң көчсезләнүенә, җәза чараларының кабатлануыннан һәм һәлакәткә дучар булу ихтималыннан куркуларына нигезләнүе шикле (хәер, Алтын Урданың монгол-татарлардан мирас ителгән хәрби куәте чыннан да гаять зур була һәм мистик дәрәҗәдә курку сеңдерә, буйсынмаучыларга карата чаралар яшен тизлегендә диярлек һәм котылгысыз хәлдә гамәлгә ашырыла). Кагыйдә буларак, яулау һәм

[1] Хамидуллин Б.Л. Чингиз-хан – 850: Книга 1. Казань, 2002.
[2] Ускенбай К.З. Восточный Дашт-и Кыпчак в XIII – начале XV века. Проблемы этнополитической истории Улуса Джучи. Казань, 2013.
[3] Энхчимэг Ц.Ц. К изучению истории Таласского курултая // Материалы международной научной конференции «Монгольская империя (образование, расцвет, распад)». Улан-Батор, 2004. С. 327–335.
[4] История «скифов» глазами современников / Авт.-сост. Б.Л. Хамидуллин. Казань, 2001.

буйсындыруга караганда, империяләрнең барлыкка килү һәм яшәеш процессы күпкә катлаулырак. Алар берләшү, ягъни билгеле бер үзара ризалык җирлегендә мәҗбүрләү һәм тормыш рәхәтлекләре кушылмасы нигезендә төзеләләр. Җәмгыять өчен файдалы, тәртип, икътисад, мәдәният үсеше һәм башкалар өчен гарант булган очракта гына империячел дәүләт тотрыклылана. Нәкъ менә Алтын Урданың оешуы, аерым алганда, Үзәк Евразиядә һәм Көнчыгыш Европада күпкә ныклырак һәм тотрыклырак сәяси вазгыять урнашуга китерә. Яуланып, башта Монгол империясе, аннары Җүчи Олысы составына кергән халыклар һәм дәүләтләрнең күпчелеге элек даими кабатланган үзара низаглар һәм ызгышлар, эчке һәм тышкы бәрелешләр шартларында яшиләр. Алар арасында еш кына канкойгыч сугышлар кабына, шул сугышлар вакытында шәһәрләр җимерелә, торулыклар бушап кала. Чыңгызыйлар – Җүчиләр империясе составына кертелү элеккеге тотрыксызлыктан һәм таркаулыктан кискен аермалы чагыштырмача ныклы дәүләт тәртибе урнашуын тәэмин итә. Сугышлар, үзара низаглар һәм эчке каршылыклар нәтиҗәсендә көчсезләнгән күршеләре арасында Алтын Урда чыннан да гаҗәеп «тотрыклылык утравы» буларак таныла.

Монгол-татарлар үзәкләшкән хакимият идеясен алып киләләр, Дәште Кыпчакның аңарчы зәгыйфь дәрәҗәдә оешкан дала кабиләләрен берләштерәләр[5]. Көнбатыштагы яулардан җиңеп кайткан Бату, иярдән тәхеткә күчеп утырып, гаскәр башлыгыннан дәүләт төзүчегә әверелә (аның беренче башкаласы-резиденциясе хәзерге Татарстан территориясендәге Болгар шәһәрендә урнаша). Ул һәм Җүчи Олысының аннан соңгы идарәчеләре ил белән идарә итүнең төзек, катлаулы тармакланган, әмма шактый тотрыклы системасын төзиләр. Элеккеге кыпчак «кыргый даласы»нда хөкем сөргән кабиләара низагларга һәм дошманлыкка алмашка халык төгәл унлыкларга бүленгән олыслардан гыйбарәт төзек һәм ныклы дәүләт системасы килә. Алай гына да түгел, төбәктә чын социаль революция гамәлгә ашырыла, ягъни ыруг-кабилә мөнәсәбәтләрен шартлы (сөйургал) һәм шартлар белән чикләнмәгән (тархан) ярлыкаш мөнәсәбәтләренә нигезләнгән хәрби-феодаль тәртипләр (строй) алыштыра. Нәтиҗәле дәүләт механизмы төзелә. XIII гасырның икенче яртысыннан алдагы йөз ел дәвамында диярлек сугыш хәрәкәтләре, элеккеге кыпчак югары катлавының юк ителүе яки хакимияттән читләштерелүе аркасында туган буталчыклык урынын «куәтле дәүләттә чагыштырмача тыныч, тотрыклы тормыш били»[6]. XIV гасырның икенче яртысына кадәр Алтын Урданың эчке өлкәләрендәге шәһәрләренең кирмән диварлары һәм башка ныгытмалары булмавы да илдә хөкем сөргән иминлек һәм куркынычсызлык дәрәҗәсен күрсәтә.

Элеккеге төрки кабиләләр берлекләре таркатыла һәм Җүчи Олысының хәрби-административ һәм клан (ыруг) структурасына кертелә, аларның аксөякләре өлешчә юк ителә, өлешчә яңа аристократия составына кушыла. Җүчиләр хөкүмәте, салымнар җыюны һәм хәрби мобилизацияне уңайлаштыру мәнфәгатьләрен күздә тотып һәм халыкның үз ирке белән олыслар арасында күчешен тыеп, үзенчәлекле «крепостнойлык хокукы» урнаштыра. Элек төрле этносәяси берләшмәләргә таркалган кардәш төрки кабиләләр беренче тапкыр гомуми территориаль-сәяси пространствода туплана. Дәүләт чикләренең һәм кабиләара киртәләрнең юкка чыгуы, низагларның бетерелүе һәм сәяси бердәмлек аларның үзара якынаюына этәргеч бирә, таркау төрки кабиләләрнең бердәм халыклар булып оешуы өчен алшартлар тудырып, мөһим этник процессларга юл ача. Нәтиҗәдә Алтын Урда Евразиянең хәзерге күп кенә төрки халыклары өчен «этник бишек»кә әверелә, чөнки аларның килеп чыгышы процесслары «әлеге дәүләтнең төрле провинцияләрендә яшәгән халыклар нигезендә бара»[7].

«Татарлар» этнонимы белән аталган хәзерге субэтник бергәлекләрнең (Идел-Урал, Кырым, Себер татарлары һ.б.) килеп чыгышы да күп кенә очракларда нәкъ менә Җүчи Олысында башлангыч ала. Хәзерге вакытта ике милләткә (кырымтатар һәм татар) һәм ике этник төркемгә (буджак һәм Литва татарлары) карата кулланылучы әлеге атама нәкъ менә Алтын Урда чорында киң таныла. Үзәк Азиянең көнчыгышында

[5] Костюков В.П. Были ли Золотая Орда «Кипчакским ханством»? // Тюркологический сборник 2005: Тюркские народы России и Великой степи. М., 2006. С. 199–237.

[6] Трепавлов В.В. Степные империи Евразии: монголы и татары. М., 2015.

[7] Трепавлов В.В. Золотая Орда и татарские юрты в мировой истории // Золотая Орда в мировой истории. Коллективная монография. Казань, 2016. С. 922–926.

яшәгән кабиләләрнең берсе (соңрак – кабиләләр берлеге) исеме буларак, ул татар-монгол яуларына кадәр бик күп еллар элек Шәрекътә еш кына Үзәк Азия халыклары җыелмасын, шул исәптән монголларны атау өчен кулланыла. Шуңа күрә урта гасырлар чыганакларының күпчелегендә этник яктан чуар монгол гаскәрләре «монголлар» буларак түгел, «монгол-татарлар» яки «татарлар» буларак искә алына. Алтын Урданың күп кенә төрки халыклары, тарихта мәгълүм традиция буенча илбасар халык исемен кабул итеп, шул ук вакытта үзләренең кабилә атамаларын да кулланып, үзләрен «татарлар» дип атый башлыйлар.

Шулай итеп, Алтын Урда дәверендә бер үк вакытта этноним, политоним, соционим сыйфатында кулланылган «татарлар» төшенчәсе беренче тапкыр этник җәһәттә туплау мәгънәсенә ия булган. Дәүләтнең төп үзәге булган көнбатыш өлешендә (аны еш кына «Ак Урда» дип атыйлар) төркиләрнең бердәм татар бергәлегенә берләшүе башланган. Җүчи Олысы таркалуы аркасында бердәм татар халкы формалашу тукталып торган. Соңрак Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым һәм Себер ханлыкларында, өлешчә Нугай Урдасында, хәзерге Румыния, Польша, Литва һәм Белоруссия территориясендә аның нигезендә үзләренең этник бөтенлеген яхшы аңлаган локаль татар этник бергәлекләре (Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым, Себер татарлары, татар-мишәрләр, Добруджа һәм Польша-Литва татарлары һ.б.) оеша башлый. Төрле төбәкләрдәге татарларның этник тарихы процесслары Россия һәм башка дәүләтләр кысаларында дәвам итә.

Шул ук вакытта «Алтын Урданыкы» һәм «татарныкы» төшенчәләре арасында абсолют тиңдәшлек билгесе кую дөрес түгел. Хәзерге татар һәм кырымтатар милләтләреннән тыш, Россиядә һәм совет дәвереннән соңгы чордагы киңлекләрдә яшәүче төрки халыкларның күпчелеген Алтын Урданың этносәяси варислары дип исәпләү зарур, чөнки аларның килеп чыгышы һәм милли дәүләтчелек тамырлары шул дәүләткә барып тоташа. Соңгы елларда Үзәк Азия республикаларында, алар территорияләрендәге халыклар, дәүләтчелек барлыкка килүе һәм үсеше тарихында мөһим чор буларак, Алтын Урданы өйрәнүгә зур игътибар юнәлтелүе әлеге фикер файдасына сөйли. Аерым алганда, географик җәһәттә Алтын Урданың өчтән бер өлеше чамасы хәзерге Казакъстан Республикасы территориясенә туры килүеннән чыгып, казакъ галимнәре казакъ халкы һәм аның дәүләтчелеге килеп чыгышы мәсьәләсендә яңача караш тәкъдим итәләр. Шуның буенча фикер йөрткәндә, Казакъстан турыдан-туры Алтын Урда варисы булып тора, Алтын Урданың тарихы исә, элек исәпләнгәнчә казакълар өчен «тышкы» тарих кына булмыйча, аларның милли тарихының бер өлешен тәшкил итә[8]. Әлеге караш Казакъстанның югары сәяси даирәләрендә дә яклау таба. Ләкин мин үз фикеремне генә ассызыклыйм: Алтын Урда – күп кенә төрки (һәм төрки булмаган) халыкларның уртак тарихи казанышы.

Гаять зур территорияләрнең Җүчиләр империясе составында берләшүе, алар арасындагы чикләрнең һәм таможня киртәләренең юкка чыгуы, уңай сәяси һәм этник нәтиҗәләргә китерү белән бергә, элеккегә караганда күпкә киңрәк күләмдә чиксез зур матди ресурсларга үтеп керү һәм аларны ишәйтү мөмкинлеге биргән бердәм икътисади мәйдан оешуга алшартлар тудыра. Аерым алганда, Алтын Урдада үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы төрлелеге шартларында төрле табигый зоналарда (көньякта чүлләр һәм ярымчүлләр, төньякта далалар һәм урман-далалар, киң яфраклы урманнар, Себер тайгасы, шулай ук Кырымда һәм Кавказда субтропиклар) яшәгән һәм төрле хуҗалык-мәдәният типларына караган күпсанлы кешеләр төркемнәренең бер үк социаль-сәяси система кысаларында берләшүе аеруча зур әһәмияткә ия була. Алтын Урда территориясенең төп өлешен, үзәген далалар тәшкил итә; далаларда яшәгән халык элеккечә үк күчмә һәм ярымкүчмә тормыш алып бара, җәйләрдә көньяктан төньякка, кышларда киресенчә юнәлештә күченеп гомер кичерә. Шул ук вакытта Алтын Урданың үзәктән читтәге территорияләрендә һәм аңа бәйле җирләрдә (Харәзем, Төньяк Кавказ, Идел Болгары, Кырым һәм рус кенәзлекләре) традицион рәвештә хуҗалык нигезен утрак игенчелек, бакчачылык һәм аранлы-көтүле терлекчелек тәшкил итә. Халыкның хуҗалык шөгыльләре арасында чолыкчылык, балыкчылык һәм сунарчылык зур роль уйный. Алтын Урда икътисады күп укладлы рәвеш ала һәм, ахыр чиктә, болар

[8] Сабитов Ж.М., Кушкумбаев А.К. О новой парадигме истории происхождения казахского народа // Второй конгресс историков Казахстана. Астана, 2014. С. 274–283.

барысы да территорияләр арасында, бигрәк тә дәүләтнең үзәк төбәге булган Идел буенда үзара алыш-бирешнең аңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә интенсивлашуына китерә. Җүчи Олысы хакимлегендәге җирләрдә глобаль дәрәҗәдә гомуми акча әйләнеше системасын булдыру икътисади киңлекнең бердәмлеген саклауда һәм ныгытуда гаять зур әһәмияткә ия була, чөнки Урда составына кертелгән күп кенә территорияләрнең үзләрендә элек алга киткән акча сугу традицияләре күзәтелми. Илнең төбәкләрдәге акча сугу үзәкләреннән торган акча системасы торган саен ныграк бердәйләштерелә бара. Берничә акча реформасы барышында ул тәртипкә салына, бердәм төзек структура хәленә китерелә[9].

Халыкара сәүдә үсешендә Алтын Урда тагын да мөһимрәк роль уйный. Географик яктан гаҗәеп уңайлы урын биләве аркасында ул трансконтиненталь кәрван юллары кисешкән үзәккә әверелә. Бөек ефәк юлының төньяк тармагы әлеге юлларның иң әһәмиятлесе була, ул Кытайда башланып, Көнчыгыш Төркестан, Җидесу өлкәсе, Харәзем аша Идел буена, аннан Үзәк Европага сузыла. Урта һәм Якын Көнчыгышта барган сугышлар, хөкем сөргән тотрыксызлык шартларында отышлы билгеләнгән конъюнктура нәтиҗәсендә Кытайдан килгән товарлар ташкыны (аш тәмләткечләр, мамык, асылташлар, икмәк һәм коллар) Европага нәкъ менә тынычрак вазгыятьле Алтын Урда аша агыла[10]. Мөселман Шәрыгын Төньяк-Көнчыгыш һәм Төньяк Европа, Балтыйк буе белән бәйләгән Идел буе «Мех юлы» (төньяктан көньякка таба юнәлештә) да әһәмияте ягыннан калышмый. Шулай ук Кара диңгез – Идел (Кара диңгез буен Түбән Идел буе белән бәйләп, Урта Азия аша Кытайга һәм Һиндстанга сузылган) һәм транскавказ (Якын Көнчыгыш Көньяк-Көнчыгыш Европа белән бәйләнгән) юллары да Алтын Урдада башлангыч ала. Нәтиҗәдә Алтын Урданың сәяси һәм икътисади өстенлеге Евразиянең һәрьяклап глобальләшүенә булышлык итә.

Нәкъ менә сәүдә, беренче чиратта тышкы сәүдә, Алтын Урда белән бәйле тагын бер күренекле тарихи феноменга – аның күчмә халыклар иленнән шәһәрләр иленә әверелүенә сәбәпче факторга әверелә. Шәһәр халкының географиясе сәүдәнең әлеге процесстагы ролен аермачык күрсәтә – шәһәр халкы нәкъ менә төньяктан көньякка һәм көнбатыштан көнчыгышка юнәлгән кәрван юллары кисешкән җирләрдә, шул юллар буйлап аеруча тыгыз урнашкан. Урта гасырларга караган язма тарихи чыганаклардагы хәбәрләр һәм карталар буенча, шулай ук археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә Алтын Урда территориясендә 150 ләп шәһәр булуы мәгълүм. Иң эре шәһәрләр исәбенә Россия Федерациясенең хәзерге Әстерхан өлкәсе территориясендә урнашкан Сарай әл-Мәхруса һәм Хаҗитархан, Сарай әл-Җәдид һәм Билҗәмин (Волгоград өлкәсе, РФ), Үкәк (Саратов өлкәсе, РФ), Азак (Ростов өлкәсе, РФ), Болгар (Татарстан, РФ), Маҗар (Ставрополь крае, РФ), Дәрбәнт (Дагстан, РФ), Кырык Йорт һәм Кырым Солхат (Кырым, РФ), Сарайчык, Сыгнак (Казакъстан), Аккирмән (Украина), Үргәнеч (Үзбәкстан) һ.б. кергән. Әлеге исемлектә татар-монгол яулары вакытында яндырылган һәм таланган, таркалу хәленә килгән һәм бушап калган, халкы өлешчә кырып бетерелгән, өлешчә әсирлеккә алынган һәм коллыкка алып кителгән, әмма тиз арада торгызылып, Алтын Урда чорында да яшәүләрен дәвам иткән элеккеге шәһәрләр дә, актив рәвештә илнең төрле өлешләрендә калкып чыккан шәһәрләр дә очрый. Сәүдәдән тыш, шәһәрләрнең барлыкка килүе һәм үсеше буйсындырылган территорияләрне идарә итү өчен терәк пунктлар челтәре булдыру зарурлыгы белән дә бәйле була. Шуңа күрә Алтын Урданың күп кенә шәһәрләре эре административ-территориаль берәмлекләр үзәкләре вазифаларын да башкарганнар. Өстәвенә, ханнар һәм аксөякләрнең югары катлавы, кышлау өчен генә шәһәрләргә барып, вакытларының күп өлешен үзләренең күчмә станнарында уздыруны өстен күрсәләр дә, күпсанлы профессиональ чиновникларның бюрократик аппараты өчен стационар яшәү урыны таләп ителгән. Бәйле җирләрдән кергән бай ресурсларны һәм гаять зур керемнәрне үз кулларында туплаган, дәрәҗәле саналган күчмә тормыш рәвешен саклаган аксөякләрдә дә тора-бара шәһәрләрдәге зиннәтле утрак тормыш уңайлыкларына һәм рәхәтлекләренә омтылыш

[9] Фёдоров-Давыдов Г.А. Денежное дело Золотой Орды. М., 2003.

[10] Зимони И. Историческая роль Золотой Орды на Шелковом пути и в Восточной Европе // Золотоордынская цивилизация. 2017. № 10. С. 143–147; Лушников О.В. Золотая Орда на Великом шелковом пути: экономическое и культурное взаимодействие, как основа евразийской мир-системы средневековья // Золотоордынская цивилизация. 2017. № 10. С. 148–151.

үсә барган. Алтын Урда хөкемдарларының Бату тарафыннан ук алып барылган һәм XIV гасырның беренче яртысында Үзбәк һәм аның улы Җанибәк ханнар заманында аеруча киң колач җәйгән актив һәм максатчыл юнәлешле шәһәрләр төзү сәясәте нәкъ менә шул факторлар һәм сәбәпләр белән аңлатыла.

Алтын Урданың дәвамлы тарихи үсеш мирасы буларак барлыкка килгән шәһәрләре дә, ханнар әмере буенча тиз арада төзелгәннәре дә берничә дистә ел эчендә үзләренең мәһабәтлеге, зурлыгы һәм төзеклеге белән күрелмәгән үсеш дәрәҗәсенә ирешәләр. Күп кенә халыкларның шәһәрләр төзү традицияләрен үзләштереп, үзләренә сеңдереп, алар тиңдәшсез сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булалар, кабатланмас манзаралары белән таң калдыралар. Алтын Урданың төзек, су белән тәэмин ителгән, уңайлы һәм матур биналар, мәчетләр һәм төз, биек манаралар калкып торган, мунчалар һәм каналлар, бакчалар һәм сарайлар тезелеп киткән шәһәрләренең көнкүреше шул заманның югары стандартларына һәм таләпләренә туры килгән. Бу хакта сакланып калган яки археологлар тарафыннан табылган предметлар, шәһәрләрдәге интенсив, бай һәм имин тормышны шаккатып тамаша кылган чит ил сәяхәтчеләренең сокланулы хатирәләре шаһитлек итә. Җүчи Олысының 1240 елларда Бату тарафыннан нигезләнгән икенче (Болгардан соң) башкаласы Сарай әл-Мәхруса кунакларны үзенең мәһабәтлеге һәм зурлыгы белән хәйран калдыра. Урта гасырлар үлчәмнәре буенча ул, хәзергечә әйтсәк, шул дәвердәге Багдад һәм Каһирә, Константинополь һәм Рим белән чагыштырырлык чын мегаполис була: аның мәйданы (бистәләре белән бергә) 36 кв. километрга, халкы (замандашлары бәяләвенчә) 75 мең кешегә җитә. XIV гасырның беренче утызъеллыгында башкала Үзбәк хан идарәсе вакытында төзелгән Сарай әл-Җәдидкә күчерелә. Әлеге шәһәр Үзбәк ханның улы Җанибәк хан заманында чәчәк ату чоры кичерә, соңгысы хан сараен (даирәсен) шунда күчерә.

Җүчи Олысында шәһәрләшү нәтиҗәсендә «дәүләтнең аерым төбәкләре эшкәртелгән кыр-басулар белән әйләндереп алынган кечерәк шәһәрчекләрдән, бистәләрдән һәм аксөяк замокларыннан торган, күп чакрымнарга сузылган тулаем утрак торулыкларга әверелә»[11]. Алтын Урданың үзәк төбәгендә – уңайлы табигать шартлары (уңдырышлы тугай-үзәнлекләр, даладагы терлекчелек мәйданнары, суднолар йөргән һәм төп кәрван юллары кисешкән Түбән Идел буенда Сарай әл-Мәхрусадан Сарай әл-Җәдидкәчә өзлексез сузылган гаять зур шәһәр агломерациясе барлыкка килә. Әлеге өлкәдә, ике Сарайдан тыш, башка шәһәрләр дә – Хаҗитархан, Билҗәмин, Үкән, Гөлстан һәм Сарайчык урнашкан, алар үзләрен камаган дистәләрчә торулыклар белән бергә халык тыгыз утырган игенчелек оазисын хасил иткәннәр. Идел белән Дон елгалары арасында да шундый ук агломерация яшәп килгән.

Корылыклы төбәкләрдә сугару һәм күпсанлы шәһәр халкы өчен үсемлекчелек-игенчелек продукциясе (азык-төлек, техник культуралар) җитештерү мәсьәләләрен хәл итү белән бәйле рәвештә бер үк вакытта әйләнә-тирә мохитне үзгәртеп корудан башка әлеге гигант урбанистик организмнар барлыкка килә һәм яши алмас иде. Шәһәрләрне су белән тәэмин итү мәсьәләсе ясалма күлләр-сусаклагычлардан һәм катлаулы гидротехник корылмалардан (буалар, шлюзлар, дамбалар, арыклар, җир астындагы керамик торбалардан корылган сүүткәргечләр һәм канализация) гыйбарәт күптармаклы система булдыру юлы белән хәл ителгән. Икенче мәсьәләне чишү өчен «чирәм җирләрне күтәрергә» – игенчелек максатында даланы массачыл колонияләштерергә һәм шәһәрләрне авыл хуҗалыгы торулыклары белән әйләндереп алырга туры килгән. Моның ни рәвешле гамәлгә ашырылуы әлегә җентекләп һәм ахыргача өйрәнелмәгән, әмма проектның колачлары гына да Алтын Урда дәүләтенең югары оештыру потенциалын күрсәтә. Шулай итеп, Алтын Урда империясе яшәеше чорында һәм нәтиҗәсендә, мөгаен, тарихта аңарчы күрелмәгән-күзәтелмәгән цивилизацион үсеш-үзгәреш булган – халкының күпчелеге күчмә халыклардан торган ил нибары берничә дистә ел дәвамында шәһәр һәм күчмәнлек-игенчелек мәдәниятләрен берләштергән югары дәрәҗәдәге үсешле «оазис»ка әверелгән. Кыска вакыт эчендә далада күп кенә шәһәрләр үсеп чыгу – урта гасырлар тарихында уникаль күренеш[12]. Ул безгә, кабат искәреп үтик, янә Харәзем, Идел Болгары, Төньяк Кавказ һәм Кырымдагы төрки

[11] Егоров В.Л. Золотая Орда. М., 2005.
[12] Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994.

халыкларның Җүчи Олысы мәдәнияте барлыкка килүгә гаять зур өлеше кертүләре хакында сүз йөртергә мөмкинлек бирә.

Алтын Урда тарихында шәһәрләрнең аеруча зур роль уйнавы, сәүдә-һөнәрчелек һәм сәяси тормыш үзәкләре булу белән бергә, аларның интеллектуаль-рухи тормыш, Алтын Урда мәдәнияте формалашуы һәм үсеше үзәкләренә әверелүеннән дә гыйбарәт. Күчмә халыкларның тиз хәрәкәт итүгә сәләтле булулары сәбәпле, күпсанлы күршеләре белән еш очрашулары нәтиҗәсендә аларның мәдәнияте һәрвакыт ныграк баеган. Монгол-татар яулары һәм Җүчи Олысының барлыкка килүе тагын да киңрәк колачлы мәдәни-тарихи процессларны хәрәкәткә китергән. Империя буларак, Алтын Урда төрле мәдәниятләр вәкилләре яшәгән төбәкләрне бердәм сәяси яссылыкта туплаган, бу исә үзара социаль-сәяси тәҗрибә уртаклашудан һәм сәүдә-хуҗалык элемтәләре ныгудан тыш интенсив мәдәниятара багланышлар үсеше өчен җирлек хасил иткән. Евразиядәге күпсанлы халыкларның һәм кабиләләрнең мәдәни традицияләрен үзенә сеңдереп, Алтын Урда көчле үзенчәлекле феноменга әверелгән яңа мәдәният тудырган! Соңгысы XIII гасырның икенче яртысында, башлыча Көнчыгыш Европадагы җирле (болгар һәм кыпчак) һәм читтән килгән Үзәк Азия (кидан-чжурчжэн һәм татар-уйгыр) традицияләре кушылуы нигезендә формалаша башлаган. Килмешәк илбасарлар буйсындырылган халыклар мәдәниятен кабул иткәннәр, бер үк вакытта аңа үзләренең мирасыннан да өлеш керткәннәр һәм шул рәвешле Шәрекънең борынгы цивилизацияләре (мәсәлән, Кытай һәм Персия) йогынтысын да өстәгәннәр.


Глобаль тарихи үлчәмнәрдән чыгып фикер йөрткәндә, кыска вакытлы – 200 елдан артыграк яшәвенә карамастан, Алтын Урда күренекле эз калдырган. Аның гаять зур территориясе, хәрби куәте, халыкара колачлы киң йогынтысы, көчле дәүләт аппараты, югары үсешкә ирешкән күп укладлы икътисады, бай мәдәнияте булган; ул Евразиянең сәяси, икътисади һәм мәдәни картасына тирән һәм этрафлы юнәлешле йогынты ясаган. Үзенчәлекле сәяси, хуҗалык, мәдәни, социаль институтлары бердәм комплексының югары дәрәҗәдәге үсеше, вакыт һәм пространство җәһәтендә локальләшкән һәм тотрыклы, бөтенлекле иҗтимагый система буларак, үзенә бер төрле «Алтын Урда цивилизациясе» турында сүз йөртергә җирлек бирә. Алтын Урда составына кергәндә, төрле халыклар үсешнең төрле баскычларын билиләр: бер ишләре ыруг-кабилә мөнәсәбәтләрендә яшәп, натураль хуҗалык алып бара; икенчеләре югары мәдәниятка ирешә; өченчеләре өчен исә хәтта язу да ят була. Шуңа күрә, яулау һәм көч куллану юлы белән барлыкка килсә дә, киләчәктә Алтын Урда, һичшиксез, гаять мөһим мәгърифәтчел, цивилизацион роль уйный[13].

Төрле сәяси, социаль, икътисади һәм табигать-климат белән бәйле сәбәпләр аркасында XV гасырның икенче утызъеллыгында Җүчи Олысы бердәм дәүләт буларак яшәүдән туктый. Яшәеше тукталса да, Алтын Урда эзсез югалмый. Аның чиксез зур мирасы кала. Алтын Урданың таркалуы аның традицияләрен дәвам иткән, үсешләренең башлангыч чорында урта гасырларда хөкем сөргән бөтенлекле конфедерация хасил иткән дәүләтләр «йолдызлыгы» оешуга китерә. Алтын Урда олыслары җирлегендә яңа дәүләт-«йорт»лар – Җүчиләрнең Олы Урда (1441-1502), Кырым (1441-1783), Казан (1445-1556), Касыйм (1445-1681), Төмән/Себер (1446-1598), Әстерхан (1459-1556), Казах (1469-1718) һәм Үзбәк (1469-1510) ханлыклары, Идегәй варисларының Нугай Урдасы (1480-1613), шулай ук Үзәк Европадан Үзәк Азия һәм Себергә кадәрге территориядә төрле дәрәҗәдә Алтын Урда сәяси системасының, икътисадының һәм мәдәниятенең традицияләрен мирас иткән кечерәк дәүләти берләшмәләр барлыкка килә. Алтын Урданың таркалуы аның этносәяси «бишеге»ндә яралган хәзерге кардәш төрки халыкларның тулы бер «такыя»сы барлыкка килүенә этәрә. Аның аерым «энҗе бөртекләре» тарихын бәян иткәндә без, һичшиксез, бу хакта истә тотарга тиешбез.

**Булат ХӘМИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре кандидаты.*

[13] Хамидуллин Б.Л. «…окаянная дщерь Златой орды…»: очерки и историографические заметки по истории Золотой Орды и Казанского ханства. Казань, 2018.

# ЗАМАНДАШЛАРЫ СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ ТУРЫНДА



*Узган гасырның икенче яртысында халкыбызның әдәби-мәдәни мирасын тикшерүгә игътибар сизелерлек артты. Хәзер әдәбиятыбыз үсешендә «алтын дәвер» дип йөртелә торган XX гасыр башы классиклары мирасын текстологик өйрәнү юлында аеруча җитди адымнар ясалды. Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, текстологлары тарафыннан чагыштырмача кыска бер вакытта – унбиш-егерме ел эчендә Г.Тукай, Г.Камал, Г.Ибраһимов, М.Гафурилар әсәрләренең күп томлы басмалары әзерләнде һәм нәшер ителде. Шул ук вакытта әлеге чорның башка әдипләре иҗатын кайтару да актуаль төс алды. Алар арасында әсәрләренең үзенчәлекле лирик яңгырашы белән күренекле татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләй аерылып тора. Сталин репрессияләре чорында Соловкига сөрелеп, Ленинград өлкәсе УНКВДсы «өчлеге» нең 1937 ел, 9 октябрь карары белән атып үтерелгән бу танылган әдип мирасын барлау һәм, текстологик яктан тикшереп, укучыларга тәкъдим итү эше миңа тапшырылган иде. 1958 елда гаепсезлеге расланып, аклануы мәгълүм булгач, төзеп чыгарылган китабындагы (Сайланма әсәрләр. Төзүчесе – Шәриф Сүнчәләй. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1961. 112 б.) текстлар, Г.Халит, Ә.Еники, Р.Мостафин, Р.Мусабәкова, Р.Ишморат, Ф.Фәткуллин һәм башкаларның мәкаләләре белән танышканда, Сүнчәләйне шактый якыннан белгән, төрле вакытларда аның белән аралашып калган олуг шәхесләрнең кайберләре, шөкер, бакый дөньяга әле күчеп өлгермәгәннәр иде. Болар – безнең атаклы иҗатчыларыбыз: язучы Әмирхан Еники һәм рәссам, сынчы Бакый Урманче, драматург Риза Ишморат. Озак гомер кичерсәләр дә, аларның әле зиһеннәре бик яхшы эшләвен, хәтерләре кем дә сокланырлык булуын ишетеп тә, кайчан төрле чараларда чыгыш ясауларын тамаша кылып та белә идем. Һәм алар белән әңгәмә кору фикеренә килдем. Әмирхан Еники белән очрашуга мин хезмәттәшем, әдәбиятчы Заһир Шәйхисламов белән бардым. Бакый ага фатирына исә хатыным, университет профессоры, әдәбият галиме Резеда Ганиева һәм студент улыбыз Булат белән – өчәүләп барып чыктык, әңгәмәгә аның җәмәгате Флора ханым да кушылды. Әмирхан Еники белән корылган әңгәмә тулырак биреләде (мәчесен кулга алып, аны сыйпый-сыйпый сөйләште). Бу очрашу 1995 елның 6 декабрендә булган иде. Анда телгә алынган факт-мәгълүматлар, вакыйгалар шагыйрь әсәрләре томын баетуга, фәннилеген арттыруга хезмәт иттеләр (басылды: Сәгыйть Сүнчәләй. Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005. 367 б.; 2006 елның мартында туган авылы Иске Мостякта тәкъдим итү кичәсе дә уздырылды) дияргә кирәк. Билгеле ки, 1995 еллардагы бу очрашулардан соңра шактый гомер узды, ул арада Сүнчәләй тормышына, иҗади, иҗтимагый эшчәнлегенә караган яңа мәгълүматлар табылды (ниһаять, яңа чыгып килә торган «Татар әдәбияты тарихы»ның 4 нче томында аның иҗаты тикшерелгән махсус бүлекчә дә урнаштырылды). Укучыларыбыз, бу әңгәмәләр белән танышканда, аларның моннан 25 еллар элек үк алып барылганын истә тотсалар иде.*

**Зөфәр РӘМИЕВ,**
*профессор, филология фәннәре докторы.*

## Бакый Урманче белән сөйләшү

**Зөфәр Рәмиев.** Бакый ага! Сәгыйть Сүнчәләй мәсьәләсендә беркадәр мәгълүматыгыз бар дип беләм. Бераз беләсе килгән иде. Егерменче гасыр башында иҗат иткән Тукай чоры шагыйрьләренең әсәрләреннән бер җыентык әзерләп ятам. Сиксәнләп кешенең әсәре минем кулда. Гарәп шрифты белән чыккан газеталардан, журналлардан, китаплардан үзем яхшы дип тапканнарны җыеп, бер җыентык төзим. Күләм, билгеле, чикләнгән, 500 бит чамасы гына. Шунда Сәгыйть Сүнчәләй дә бар. Сүнчәләй ул елларда бик актив булган бит инде. Тукай белән аралашкан, яхшы мөнәсәбәттә булган. Башкалар белән дә. Ләкин соңгы чордагы язмышы, беләсез инде, томан эчендә.

**Бакый Урманче.** Томан эчендә шул.

**З.Р.** Фатих Сәйфи-Казанлы редакторлыгында чыккан «Матур әдәбиятта буржуаз милләтчелеге» (1930) дигән китапта Сүнчәләй «буржуаз милләтче», «солтангалиевче» булып бара...

**Б.У.** Чыннан да шулай инде ул. Ләкин буржуаз милләтче булу яманмы, яхшымы? Аннан соң солтангалиевче булу яманмы, яхшымы? Ул мәсьәлә дә бар бит әле. Мин Солтангалиев гаиләсендә күп була идем. Чөнки аның хатыны Фатыйманың энеләре безнең белән бер вакытта Мәскәүдә укыдылар. Ә без инде Фатыйма өендә очраша идек. Солтангалиев хатыны өендә торды. Фатыйманың фамилиясе Ерзина бит инде. Мәшһүр Ерзиннар. Аның өч катлы өе бар иде, ул өй һаман да бар шикелле. Шуның бер бүлегендә Солтангалиев яшәде. Ул «правительственный» өйгә күчмәде. Менә шулай инде, аны солтангалиевче диюне мин начар дип аңламыйм.

Үземнең бертуган энем Һади Урманче – Солтангалиевнең якын кешесе. Ләкин Солтангалиев зур кеше, Һади студент кына иде. Ул аның тарафдары гына түгел, алар фикердәшләр дә булганнар. Мин аны соңыннан гына белдем. Ул безнең Һади янына килеп, үзенең иптәшләренә белгертмәс өчен «инкогнито» керә икән. Һади инде ул кадәр билгеле кеше түгел, правительство кешесе дә түгел, ул укучы гына. Без бит Һади белән бер фатирда торган идек. Икебез ике бүлмәдә. Мирсәеднең безгә килеп йөргәнен мин белмәгәнмен дә. Фикердәшләр белән очрашулар безнең фатирда булган икән. Басым ясап, миннән сорау алганда, «Солтангалиевнең сезнең квартирда булганы бармы?» – дип сораганда, мин «юк», дидем. Аның монда булганын миңа сеңлем генә әйтте. Соңрак кайбер нәрсәләр искә төшкәләде. Мирсәед белән безнең сүзләр булгалады. Ул мине шул үзенең группасына тарта иде. Мин ул вакытта югарырак катлау кешесе исәпләнә идем. Ул вакытта мин – Казанның художество техникумы директоры. Мәскәүдә аның белән очрашмый идек. Бер очрашканда, ул миңа басым ясый башлагач, әйттем: «Мирсәед, мин үземнең гомеремнән разый. Менә минем кулымда зур эш. Сыннар ясыйбыз. Татар балаларыннан рәссамнар ясыйбыз. Аларны укытабыз. Техникумда бөтен эшне мин алып барам. Мин җаваплы. Шулай булгач, минем совет властена «поправкалар» кертергә хакым юк. Мин чын совет гражданины», – дидем. Мирсәед мине аңлады инде. Башкача аның белән бу турыда сөйләшмәдек. Һади бик кызу кеше, интересный малай иде ул. Ул Мәскәүдә «Коммунистический университет трудящихся Востока» бетерде. Аннан соң Үзбәкстанга барып эшләде, сәяси белемем җитми, бер специальность кирәк икән, дип, монда кайтты.

**Ф.Әхмәтова.** Сүнчәләйне сөйли идегез бит!

**Б.У.** Мин ни өчен әйләнеп сөйлим, чөнки соңгы тапкыр Сүнчәләйне дә, Солтангалиевне дә мин Соловкида күрдем. Мин Сәгыйть янына кереп йөри торган идем, чөнки Сәгыйтьнең бик әйбәт чәе була торган иде. Соловкида әйбәт чәй табу бик кыен иде. Шулай бер вакытны керсәм, моңарда Мирсәед тә утыра. Утырдык инде сөйләшеп байтак кына. Төрле сүз булгандыр инде анда. Соңгы күрүем Сәгыйтьне дә, Мирсәедне дә Соловкида булды. Әлбәттә инде, Сүнчәләй Мирсәед кешесе иде. Анда шөбһә юк. Сүнчәләйнең (элегрәк) үлми калуы да кызык бит. Сталин дипломатларны җыеп үтерде бит барысын да. Франциядә Раскольников котылып калды. Сәгыйть болар эченә керергә тиеш иде. Сәгыйть бит Төркиядә атташе булды. Димәк, Сәгыйть керергә тиешле. Керми калды. Ничектер, котылып калды.

**З.Р.** 1938 елда үтерелә ди бугай[1].

**Б.У.** Аны Әмирхан Еники төгәлрәк белә инде.

**З.Р.** Мин сораштым аңардан, Риза Ишмораттан да. Сәгыйтьнең Риза агайда хатлары бар икән... Аның бит хатыны актриса булган, Әминә Милүшева. Ул Азәрбайҗанның Гянҗә шәһәреннән. Сүнчәләй кулга алынганда, алар бергә тормаганмы – менә алары да билгесез булып кала.

**Б.У.** Сәгыйтьнең тормышында мин белмәгән дәвер бар. Мин бит 1929 елның башында кулга алындым. Шуннан соң 1959 елга кадәр Казанда булмадым. Татар халкыннан ерактарак булдым. Ә ул миңа ярдәм дә итте бит. Мәсьәлә болай тора иде. Безнең халыкның аралашуының хәвефле җирләре дә бар.

**З.Р.** Татар барда хәтәр бар бит.

**Б.У.** Соловкидан кайткач, монда инде паспортларны алыштырдым. 1933 елның ахыры бу. Минем гаебем булмаган, коллегия карары белән генә киткән кеше бит мин, следствие дә, протокол да юк, шул килеш. Әйткәннәр, Урманчене җибәреп карыйк әле дип *(көләләр)*. Остаханәгә берәү килеп керде. Мине техникумда эшләгән җиремнән «торжественно» алып киттеләр. Мине артка утыртты, үзе – кучер. Тарантаска җигелгән әйбәт сары җирән атка утыртып өйгә алып киттеләр. Аты яхшы булса да, халык бит тегенең формасыннан таный каян икәнен. Өйгә кайтып кергәч, бөтен кәгазьләрне җыеп алдылар. Аларның беренче эше шул икән – өйдәге бөтен кәгазьне җыеп алу. Үзе минем белән матур итеп сөйләшеп йөри. Мин инде гаебем юк икәнен беләм, ике көн тотарлар да чыгарырлар инде, дип барам. Ике көн үтте, өч көн үтте, шуннан соң Хандыгин дигән кеше (соңыннан Мәскәүдә зур кеше булды, Мейерхольдларны да утыртты) карары белән Мәскәүгә алып киттеләр. Укырга-нитәргә һичбер нәрсә юк абсолютно. Менә шулай бернәрсә укымыйча, син гел уйлап торырга тиешле. Шуннан соң мин аңладым. Анда бер-ике көн утырталар да китерәләр Бутыркага, яисә инде бөтенләй җибәрәләр. Минем Берлин университетында укыта торган шәрыкчы галим Галимҗан Идриси белән язышкан хатларым бар иде, шул сәбәп булды, ахры. Һадидан да сорашканнар Мәскәүдә. Сәгыйтьне белүем дә роль уйнаган, ахры.

Сәгыйтьне исәплидер идек Тукайның варисы дип. Сәгыйтьнең шигырьләрен укый идек. Ул бит «Мөхәммәдия»гә дә килеп йөри иде. «Әл-Мансур»ны (пьеса) чыгарганда, бик мәшһүр чагы иде аның. Ул резонанс алды. Аның теле – Тукай теле. Тукайдан соң зур шагыйрь була торган кеше – шушы Сәгыйть дип белә идек. Без аның белән Мәскәүдә дә очраштык. Аның ул дипломатия эшенә китә торган вакыты иде. Бу 1926 еллар иде.

Бутыркада Сүнчәләйнең барлыгын белә идем. Әмма анда камералар бит, бер-береңне күреп булмый. Һава суларга чыкканда күрү ихтималы бар иде, шунда гына очраштык. Мирсәедне ялгыз камерада тоталар иде.

Ә Соловки бит ул бик зур. Аның һәр станциясендә бушлат кигән кешеләрне очратырга була иде. Соловецкий монастыренең Кремле бар. Сәгыйть шушы Кремльдә бер җирдә торып, яхшы гына урында эшләде. Хуҗалык эшендә иде ул. Мәркәзгә барган вакытта без аның янына кереп, кайсы вакытта чәй эчә идек. Берсендә Мирсәед белән очраштык. Ул Сәгыйть янына кереп йөри икән.

Казанга кайтып, паспортлар алгач, Казан мине тынычлыкта калдырмаячак дип, Мәскәүгә китеп чумарга булдым. Союзга кердем, кергәндә, Соловкида булуымны да, мулла малае булуымны да әйтмәдем, «из крестьян» дип яздым. Муллалар бит аерым сословие түгел, барыбер крестьян. Сталин чорында яшәгән кеше бит мин. Шулай итеп, Мәскәү рәссамнары арасына кереп киттем, анда минем кайда булуым берәүгә дә кирәк түгел иде. Казанда булсам, атлаган саен төртеп күрсәтерләр иде.

## Әмирхан Еники белән сөйләшү

**Зөфәр Рәмиев.** Әмирхан ага! Җыентык әзерләү уңае белән Сәгыйть Сүнчәләйнең революциягә кадәрге иҗатын карап чыктым. Аның китапларының шактые сакланган. Бераз архивларында да булдым, Мәскәүдә егермеләп хатын таптым. Гриновская

[1] С.Сүнчәләй Ленинград өлкәсе УНКВДсының «өчлеге» 1937 елның 9 октябрь карары белән атып үтерелә.

фондында булып, аңа язган хатларның күчермәләрен алып кайттым. Ләкин аның Совет чорындагы язмышы томан эчендә кала.

Рафаэль Мостафин 1993 елда аның турында мәкалә язган иде. «Татарстан» журналында бастырды. Ул аны бераз шымчылыкта да гаепли. Мин үзем КГБ архивларындагы барлык документларны да карап чыга алмадым.

**Әмирхан Еники.** Мин ул мәкаләне укымадым шул. Ләкин монда ачыклык кертергә кирәк. Мин аны нинди чыганакларга таянып гаепләүләрен белмим. Солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынгач инде, төрмәләрдә яткан чакта пытка аркасында булган берәр эшме ул, яки, мин менә Ринат Мөхәммәдиевтән ишетүем буенча, аңа хәтле, кулга алынганчы, Төркиягә посольствога эшләргә җибәрелгәнче үк инде ул менә шундый информация бирүче булган, ди.

**З.Р.** Мостафин да шулай, ди.

**Ә.Е.** Дипломатия тирәсендә эшләүче кешеләр ул вакытта да, хәзер дә шул эш белән шөгыльләнәләр. Аларның вазифасына керә ул информация биреп тору. Сез беләсез инде, революциянең беренче елларында болар бит инде милләт эшләре буенча комиссарлар («народный комиссар по национальным делам» дип аталамы, «по национальному меньшинству» дипме, Сталин – иң өлкән комиссар, Солтангалиев шул ук комиссариатта эшләүче урынбасар була. Ул комиссариатта татарлардан Солтангалиев кенә түгел, башкалар да була. Ул милләт эшләре белән турыдан-туры шөгыльләнүче комиссариат бит инде. Автономияле республикаларны оештыручылар да алар. Башкортстанны да, Татарстанны да шул комиссариат оештыра. Сәгыйть Сүнчәләй беренче мәртәбә шушы комиссариат исеменнән китә, бәлки инде Солтангалиев ярдәме беләндер, чөнки Солтангалиев – Уфа кешесе, Сүнчәләй дә Уфада яшәгән, алар бер-берсен күпмедер дәрәҗәдә электән белгән булырга тиешләр...

**З.Р.** Ринат Мөхәммәдиев шулай дип әйтә дә. Аның тәкъдиме белән Сталинга керәләр дә, аны Кырымга җибәрәләр.

**Ә.Е.** Әйе, ул Кырымга шушы комиссариат вәкиле булып бара. Менә шунда инде ул Кырым хәлләре турында хәбәр биреп тора. Бу аның вазифасы, шуның өчен җибәрелгән ул. Миңа аның Сталинга язган отчётының копиясен дә күрергә туры килде. Тузып беткән иде инде.

**З.Р.** Әйе, Мәскәүдә мин дә ул отчётларны күрдем.

**Ә.Е.** Шунда ул Кырым хәл-әхвәлләрен яза. Бу шымчылыкка керми. Моны шымчылык дип атарга мөмкин түгел. Бу дипломатия эшендәге кешеләрнең турыдан-туры вазифасына керә торган бурыч. Менә хәзерге вакытта Россиянең теләсә кайдагы, теләсе кайсы илчелеге Мәскәүгә шундый ук информацияләрне, отчётларны биреп тора. Моны кеше өстеннән әләк формасындагы шымчылык дип әйтү һич тә урынлы түгел. Аннан соң бер елдан соң Сүнчәләйне Сәетгалиев алыштыра. Ул да шул ук эшләрне эшләгәндер, бик ышанычлы коммунист бит инде. Архивта Сәетгалиевнең Сәгыйтькә язган хаты да булырга тиеш. Мин күргән идем. Сәгыйтьнең архивында бар ул. Зарланып, Кырымда эшләве авыр, фәлән-фәсмәтән дигән шикеллерәк. Ә Сәгыйтьне, димәк, Төркиядәге илчелеккә җибәрәләр.

**З.Р.** 1926 елда.

**Ә.Е.** Ул анда бер елмы, ел ярыммы эшли. Илчелектә эшләгән кешенең дә бурычы – шулай ук андагы хәлләр турында информация-отчёт биреп тору. Ул аны бернинди шымчылык дип уйламагандыр да. Хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән кеше, аңа эш йөкләтелгән. Анда бит секретарьлар гына түгел, ГПУ кешеләре дә шул илчелек түбәсе астында эшлиләр бит. Сәгыйть инде ул вакытта – 1919 елда – коммунистлар партиясенә кергән. Алар бит үз бурычларын кирәкле эш дип үтәгән.

**З.Р.** Ул өч мәртәбә өйләнә бит инде. Беренче хатыны Сәлимә исемле була, ул үлә, икенчесе Фәридә исемлесе белән аерылыша. Аның Фәрит исемле малае була (1912, 1 август), ул сугышта үлгән. 1940 елда аны хәрби хезмәткә алганнар, шуннан кайтмаган. Кызы Наилә (1936) Казанда тора. Әлфия, Рөстәм, Лариса исемле балалары, оныклары бар. Өченче хатыны – Әминә. Аның турында бер мәгълүматым да юк. Артистка була, 1928 елда академия театрында уйный. Таһира исемле кызы була. Сезнең аның турында берәр хәбәрегез юкмы?

**Ә.Е.** Минем хәбәрем шул: ул вафат. Алар Азәрбайҗанда яшиләр. Гянҗә шәһәрендә. Әминә Милүшева Кырым татарыннан булса кирәк, яки инде Кырымда яшәгән безнең татар. Мин аны беләм. Уфада чакта ук күргән идем, Төркиядән кайткан чаклары иде. 1927 ел иде булса кирәк. Бик чибәр хатын иде. Менә шуннан соң 1928 елда Сәгыйть Сүнчәләй Татар мәдәнияте йортында гыйльми секретарь булып эшләп китә. Әминә театрда эшли. Ләкин шул вакытта алар аерылыша. Әминәне ул вакытта театрның директоры Мирза Заитов, җитәкче булуыннан файдаланып, үзенә буйсындыра. Казанда Сөнәкәй дигән шагыйрь яшәде шул елларны. Сөнәкәйнең бер гадәте – танышбелешләренә йөрү иде. Үзе генә йөрми, кемне дә булса ияртеп йөри. Бервакыт ул мине шул Мирза Заитовка ияртеп алып китте. Таныган-белгән кешем дә түгел иде. Шунда мин Әминә ханымны күрдем дә инде. Элек тә күргән бар иде, Сәгыйтьнең хатыны дип белә идем бит. Миңа да бик уңайсыз булып китте инде, үзе дә кыенсынды, минемчә. Мин дә бернәрсә сиздермәдем, ул да сиздермәде. Соңыннан гына аларның Сәгыйть белән аралары өзелгән дип ишеттем. Әмма ул өзелү озакка бармаган, күрәсең. Чөнки Сәгыйть Сүнчәләй кулга алынгач, ул төрмәдән язган хатларын Әминә ханымга юллый. Әминә ханым да Сәгыйтьне көтә. Ул вакытлыча бер саташу гына булган, ахры.

Әминә ханымнан Сүнчәләйнең кызы Таһира туа. Таһира 1921 елгы. Улы Таһир авырып үлде. Мин Дәүләкәннән Уфага баргач, туйга, аны күргән идем. Ул вакытта өйдән чыкмый иде инде.

Сәгыйть Соловкида вакытта Мәскәүдә аның абыйсы Шәриф Сүнчәләй яши, минем җизнә тиешле кеше. Әминә аларга «Здравствуйте, мои родные!» дип хатлар яза. 1948 елгы хаты бар. Яшәүләре авыр була.

**З.Р.** Яңадан кияүгә чыкмаганмы?

**Ә.Е.** Күрәсең, юктыр инде.

**З.Р.** Соловкидан язган хатларында ул Биги авылын искә ала. Биги авылы белән аның нинди бәйләнеше бар, белмисезме?

**Ә.Е.** Аларның туулары бер җирдә, үрчүләре икенче җирдә бит. Ульяновскиның татарлар яши торган районы Кулаткы тирәсендә.

**З.Р.** Иске Мостяк дигән авылдан.

**Ә.Е.** Алар шуннан Хволыньга, аннан Әстерханга күчкәннәр дип хәтердә калган. Бигине ишеткән юк. Сәгыйть Сүнчәләй партиягә яңадан кергән чагында – аны партиядән чыгарып тордылар, яңадан кабул иттеләр, пенсия дә билгеләделәр.

**З. Р.** Сәгыйтьнең үпкә авырулары да булган икән. Дәүләт архивында рецептлар бар.

**Ә.Е.** Ул вакытта яшьләрнең күбесе үпкә авыруыннан интеккән. Авыл китапханәсендә эшләгән. Скрипкада матур итеп уйнаган.

**З.Р.** Шәрифләрдән тыш, Сүнчәләйнең туганнары бар идеме, юкмы?

**Ә.Е.** Анысын ачык кына әйтә алмыйм. Сәмәркандта озак еллар гына Габдулла Сөләйманый дигән кеше яши иде. Бер елны кунакка килгәннәр иде. Габдулла Сәгыйтьләр белән бер яктан, бер авылдан чыккан кешеләр инде алар. Ул университетта татар башы белән үзбәк теле һәм әдәбияты укыта иде. Шуның хатыны, күпмедер ишетеп калуым буенча, Сүнчәләйләргә кайсыдыр яктан кардәш тиешле кеше булган.

Сүнчәләй бик симпатичный, бик сөйкемле кеше иде ул. Гуманный. Аның Такташ белән дуслыгының төбендә шул бит инде.

**З.Р.** Такташ белән дә дус булганмыни ул?

**Ә.Е.** Әйе. Такташ та шундыйрак булган бит инде. Алар бер-берсен бик яхшы таныганнар. Такташның Сәгыйть белән төшкән рәсеме дә бар.

Без бит бик таркау яшәдек. Күп нәрсәне югалттык инде. Үз кулы белән юкка чыгаручылар да аз булмады. Мин бер нәрсәне дә ертмадым да, яндырмадым да. Ләкин мин читтә йөргән чакта кемдер килеп, күп нәрсәне алып киткән. Китаплардан инде. Әмирхан кушты, дип, минем фатирга килеп. Бакый әйткән иде инде әрҗәләргә салып, лапас башына мендереп калдыр, дип. Теге менеп, шул китапларны актарып чыккан. Анда Троцкий китабы да, Каменев китабы да бар иде. Баш китәрлек. Иң мөһиме: иске әдәбият әйберләре бар иде. Бик кыйммәтле әйберләр. Шуларны алып киткән.

**З.Р.** Сез сугышта чактамы инде ул?

**Ә.Е.** Юк, мин Урта Азиядә чакта.

* * *

Чана юлы – ком. Кытыршы.
Шәһәр кышы. Кичке сигез.

Ул чак әле безнең ара
чана бавына тигез.

Кирелек – икебездә дә –
Аллага шөкер, байтак,

тартышабыз: кем соң
кемне бакчадан алып
кайта?

Ул чак әле мин синсез дә
юлны беләмдер кебек,

синең тизлектә кагыла
бүреккә шәһәр күге.

Адымнарыңа көйләнгән
шул еллар чанасыннан

төшеп калам – бик
курыксам, куып тотармын
сыман...

Шул чактагы берәр чатта,
кызык итмәкче булып,

син әле дә көткән төсле.
Шәһәр. Кыш. Чана юлы.

**Йолдыз МИҢНУЛЛИНА**



*Фәрваз Миңнуллин.*



*Фәрваз Миңнуллин –*
*язучылар Сабан туенда.*



*«Без – әдәбият иленнән!» Фәрваз Миңнуллин – сулдан беренче.*



*Галимҗан Ибраһимовны искә алганда.*
*Фәрваз Миңнуллин – икенче рәттә, уңнан беренче.*

*Фотолар* **МИҢНУЛЛИННАР** *гаиләсе архивыннан алынды.*

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН МУЗЕЕ

Авыл тормышына тугры калган, шәһәр ыгы-зыгысы кочагында югалмаган Туфан Миңнуллин милли әдәбиятыбызның олы хәзинәсе итеп тарих битләренә теркәлде. Шуңа күрәдер бөек шәхеснең тормыш юлын, иҗатын чагылдырган музей булдыру үзен озак көттермәде. 2012 елның августында драматургның туган ягы Кама Тамагы районында аның ишекләре ачыла. Әмма туып үскән Олы Мәрәтхуҗа авылындагы өч йорты да безнең игътибарга лаек. Нәкъ менә алар Туфан Миңнуллинның яшәешен, көнкүрешен күрсәтеп торучы конкрет мисаллар рәвешендә саклана, музей белән беррәттән киләчәк буынга аның татар дөньясындагы тулы образын тасвирларга ярдәм итә.

Драматург гомере буе туган җиргә, авыл тормышына якын булды. Бәлки шуңадыр Олы Мәрәтхуҗадагы өч нигезе дә традицион татар авылы йортына охшатып ясалган. Әти-әнисе өенең бусагасын атлагач ук, каршыга Туфан Миңнуллинның истәлекле җиһазлары, әйберләре күзгә чагыла, үзенә җәлеп итә. Тирә-юнь чиста һәм пөхтә, тәртипкә китерелгән. Ремонттан соң монда драматургның биографиясен, беренче хезмәт адымнарын, шөгыле даирәсен, гаиләсен, иҗтимагый эшчәнлегенә юнәлдерелгән экспозиция булдырыла. Бу проектны оештыруда туганнары, бигрәк тә кызы Әлфия Миңнуллина, дуслары, хезмәттәшләре зур өлеш кертә. Иске язмалары, басылып чыккан китаплары, газета-журналларда чыккан әсәрләре, мактау грамоталары, истәлекле фоторәсемнәре, иҗатына бәйле документлары – барысы да экспонат буларак беренче йортта саклана. Шулай ук элек бу йортта вакытлыча башлангыч авыл мәктәбе урнашуы да кызыклы факт.

Язу өстәле, кечкенә генә ятак, китаплар тулы киштә... Шушы күренеш икенче, бүрәнәле кечерәк йортка кергәч тә, кунакларны драматургның гади авыл ир-аты тормышы белән таныштыра. Туфан әлеге йортны үз куллары белән салып чыга. Монда вакыт туктап калган шикелле, чөнки бер җиһазда да пәрәвез челтәре күренми, бер тузан әсәре юк. Зур мич, чигелгән пәрдәләр үз урынында. Чорның көнкүрешен яңадан торгызырга җирле халык та ярдәм итә – кемдер өмәләрдә катнаша, ә кемдер драматург тормышына кагылышлы истәлекле әйберләр алып килә. Аларның күбесе язучы белән шәхсән таныш була. Бу йортка җәйләрен балалары һәм оныклары белән хатыны Нәҗибә Ихсанова кайтырга яраткан. Өченче йортны да Туфан Миңнуллин үз куллары белән торгыза. Ул мәйданы буенча да иң зурысы булып чыга. Шуңа күрә анда төрле чаралар, мәсәлән, әдәби кичәләр, китап бәйрәмнәре, төрле шәхесләр белән очрашу уздырырга уңайлы.

2016 елда «Таттелеком» компаниясе ярдәме белән өч йортка масштаблы ремонт уздырыла. Шуның белән беррәттән әйләнә-тирә территория – ишегалды, капка, койма, драматург исемен йөрткән бакча артындагы чишмә төзекләндерелә. Хәзерге көндә өч йорт драматургның авылдашлары һәм 79 яшьлек туганы Венера Сәмигуллина карамагында. Кызганыч, әлеге тарихи хәзинәгә әле дә музей статусы бирелмәгән. Кызы Әлфия Миңнуллина бик күп еллар элек өйләрне Кама Тамагы районына тапшырып, аларга музей статусы бирү теләген белдергән иде инде. Бу турыда май аенда район башлыгы Наил Вазыйховка да җиткерделәр, бу мәсьәлә кичектергесез хәл итүне сорый, халык та шуны көтә.

Кеше психологиясенең нечкәлекләрен сизү сәләтенә ия булган, спектакльләрендә заманчалыкны саклап калган, тормышның яхшы һәм яман якларын күрә һәм, иң мөһиме, әсәрләре ярдәмендә укучыга тапшыра алган Туфан Миңнуллин һәрберебезнең игътибарына лаек. Аның тормышы, иҗаты тарихын саклап торучы Олы Мәрәтхуҗа авылындагы өч йорты шул ук дәрәҗәдә искә алынырга тиеш. Яшь буынга салынган фикер киләчәкне билгели. Шуңа күрә әдәбият белән кызыксынган барлык кешене, бигрәк тә мәктәп укучыларын һәм студентларны драматург йортларына кунак итеп чакыру, экскурсияләр оештыру мөһим дип саныйм.

**Айзилә САБИРОВА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Юмор шундый буламы?

Төнге уникедә Марсель Гали чылтырата:

– Син Газинур Моратның юмор дип аталган язмасын укыдыңмы?

– Юк, – дидем мин, уңайсызланып.

– Син бәхетле! – дип кычкырды Баяныч. – Юмор шундый буламы?

– Белмим, – дидем мин, чиктән тыш уңайсызланып.

– Юмор андый булмы-ый, нәданым. Әйт дустыңа, язмасын юмор. Булмы-й! Юмор язар өчен Җәбраил фәрештәнең маңгайдан үбеп китүе кирәк. Күрәсеңме минем маңгайны? Ә? Бераз яньчелгән, күрәсеңме, мокытым?

Телефон аша маңгай күренми иде, ләкин мин:

– Бераз сизелә, – дидем.

– Күзеңне ачыбрак кара, купык. Һәм әйт Моратка – юмор язып көчәнмәсен.

– Олыгая бит, бәлки, аның прозага күчеп маташуыдыр...

Телефонда кыска гудоклар ишетелде.

Икенче көнне Язучылар берлегенә килгән Туфан Миңнуллин зарланып торды:

– Төнге бердә Марсель чылтырата. Газинур Моратны юмор язудан тыярга куша. Югары Советның карары белән... Татар юморы куркыныч астында, дип өркетте.

– Ни дип җавап бирдегез инде?

– Ни диим... Бездә сүз иреге, дидем. Демократия. Трагедияне дә комедия дип чыгаручылар бар.

– Марсель Галиев Шәймиевнең телефон номерын белмидер?

Туфан Миңнуллинның күзлеге өскә менеп китте.

– Булыр да... Ул бит Фәндәс Сафиуллин Мәскәүдә депутат чакта, аның памушнигы булып йөргән иде.

– Төннәрнең берендә БМОга чылтыратуы да бар әле, – дидем мин, Газинур өчен борчылып.

Ә Газинур Морат сәяси темаларга багышланган юмор-сатира әсәрләрен яза торды. Әле беркөнне берничәсен «Ватаным Татарстан» гәзитенә дә илтеп биргән. Сөенеп кабул иткәннәр.

Әле ярый корректураны укырга барган. Бакса, юмористик язмаларын сәяси мәкаләләр басыла торган «Фикер» рубрикасы астына урнаштырганнар...

– Бу бит юмог! – дип шаулаган Газинур. – Шуны да аңламадыгызмы? Татагда хәзер бөтенләй юмог хисе беткән икән.

Шауларсың да... Газинур юморын җитди кабул иткәннәр! Сөенергә иде югыйсә. Күпләрнең калын-калын романнарын да җитди кабул итмиләр бездә...

Бик озак баш ваткач, Газинур язмалары өчен «Уены-чыны бергә» дигән рубрика уйлап тапканнар гәзиттә.

**Ләбиб ЛЕРОН**

## Илһам Шакиров... көй бозучы?

Ике шагыйрь – Газинур Морат белән Ләбиб Лерон – бакчадаш күршеләр. Беркөнне тирләп-пешеп җир казып матавыкланган Ләбиб янына Газинур килеп:

– Тартырга бир әле, – ди.

– Нәрсә булды? Нишләп кәефең юк? – дип, Ләбиб дустына сигарет суза. Газинур авызыннан чыккан төтенне өрә дә болай ди:

– Бөтен эшне Илһам Шакиров бозды!

– Аңлатып сөйләле.

– «Татар радиосы»н тыңлап, ял итеп ята идем... Җыр арты җыр сузалар... Бүгенге «җондызлар» моңланганга кушылып, мин дә җыр сузам. Үзем җырлыйм, үзем: «Карале, мин дә шәп җырлыйм икән бит!» – дип, татлы хыялларга бирелеп алам... Әллә киләчәктә сәхнәгә чыгыйм микән, дип планнар кора башладым... Хыялымның иң югары ноктасына менеп җитеп, сәхнәдә җырлаганымны, халыкның ду китереп кул чапканын күз алдыма китереп ятканда гына... Илһам абый бөтен көйне бозды, нәгаләт!

– Ничек бозды?

– Ничек, ничек?! Илһам абый «Карурман»ны сузып җибәрде дә бөтен хыялларны челпәрәмә китерде. Бу «Татар радиосы»н әйтер идем инде! Бүгенге «җондызлар» гына җитмәгәнме?! Илһам Шакировны да җырлатмасалар...

## Тәрәзә

Көз. Әбиләр чуагы. «Салават күпере» журналханәсе.

– Тышта җылы. Бүлмәдә суык, – ди Зиннур Хөснияр, форточкасы ачык тәрәзә янына елышып. – Әллә тәрәзәне ачарга микән?

1946 елның октябреннән бирле, ягъни якты дөньяга аваз салган көннән алып суыкның ни икәнен дә белмәгән Мөдәррис Әгъләм:

– «Тәрәзәгезне ачыгыз!» дип, мин сезгә күптән әйттем бит инде, – ди. – Газинур Моратка багышлап язган шигыремне укымадыгыз мәллә?

Ачыгыз тәрәзәгезне,

Булса тәрәзәгез!..

Тирән мәгънә салып язган шигырьнең ошбу юлларын Газинур Моратка карап әйткәч, Мөдәррис Әгъләм:

– Хәер, сез язучылар бит әле, укучылар түгел, – ди дә башын кыңгыр салып, ишеккә таба юнәлә.

– Синең ул шигыреңә ышанып, тәрәзәне ачкан идем, – ди Газинур Морат аның артыннан, – мин эшкә китүгә, караклар кереп, радиоалгычны һәм шигырь язган вакытта гына кия торган чалбарны алып чыгып киткәннәр...

**Морад ДУСАЙ**

## Йомгаклау

Язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышында Газинур Морат, башта уң ягында утыручы Марсель Галиевкә, аннары сул ягында утыручы Мансур Вәлиевкә карап ала да, авыз эченнән генә үзалдына:

– Фатих Кәрими белән Фатих Кәримне дә бутаган халык җиде Галиев белән сигез Вәлиевне киләчәктә ничекләр генә аера алыр икән? – дип әйтеп куя.

## Хак нәтиҗә

Язучылар йорты ишегалдындагы «Сарман» кафесы янында бер төркем язучы тәмәке көйрәтә. Гәп әлеге дә баягы хәмер тирәсендә куера.

– Зоопаркларда, мәсәлән, филгә – аракы, маймылга сыра эчерәләр икән, – ди Газинур Морат.

– Нигә?!

– Иң акыллы хайваннар коллыкны бик авыр кичерә икән...

– Коллыкта яшәгән халыкның да иң акыллы затлары хәмер эчәргә мәҗбүр, – дип, үзенчә акыллы нәтиҗә ясап куя Ләис Зөлкарнәй.

– Димәк, үлгәнче коллыкта яшәячәкләр! – ди болар яныннан ашыгып кына үтеп баручы вегетариан Рәфикъ Юныс.

## Шагыйрь һәм прозаик

– Кичә минем бакча өстеннән кыр казлары очып үтте, – дип, горур гына әйтеп куя шагыйрь Газинур Морат.

– Һ-ә-й, кыр казлары пүчтәк ул, менә минем бакча өстеннән көн саен вертолётта Президент үзе очып уза, – ди күршедәге «Оптимист» бакчачылык ширкәтендә казынып ятучы прозаик Вакыйф Нуриев.

Рөстәм Миңнехановның Биектау төбәгендә яшәп яткан чагы инде бу.

## Буталыш

Узган гасырның 80 нче еллар башы. Казанның Бауман урамыннан җәт-җәт кенә атлап барганда... Газинурны берәү җиңеннән эләктереп ала. Борылып караса, университеттагы хәлфәсе Альберт Яхин икән.

– Син, җегет, нигә бер дә лекциягә йөрмисең? – дип сорый ул, ишетелер-ишетелмәс тыйнак тавышын күтәрергә тырыша төшеп.

– Мин укып бетердем бит инде, Альберт абый... – ди бу вакытта «Татарстан яшьләре» редакциясендә эшләп йөрүче Газинур Морат.

– Һ-ә-й, чукынмыш, алайса Ыркаил булып чыкты инде бу! – ди мөгаллим, ниһаять...

– Дөрестән дә Ркаил Зәйдулла белән мине гомер буе бутадылар, хәзер дә бутыйлар, – дип аңлата бүген Газинур үзе. – Ркаил дус үзе моңа ничек карыйдыр, ә мин – сөенәм генә!

## Биш дурак

Озак кына күрешми торганнан соң, Газинур Ркаил дустының хәл-әхвәлен белешергә дип, «Идел» журналы редакциясенә сугылып чыгасы итә. Барып керсә, Ркаил бүлмәдә берүзе тирләп-пешеп нидер язып утыра.

Билгеле инде, бер-берсен сагынышып та өлгергән ике ахири очрашу хөрмәтенә бераз кәефләнеп алырга уйлый.

– Карале, – ди Ркаил, өстәлдәге мул гына мәҗлес сыена ишарәләп. – Ничек уйлыйсың, икебезгә генә күңелсезрәк булмасмы соң? Бәлки, безгә, Разил Вәлиев әйтмешли, өченче дуракны да чакырырга кирәктер?

– Кирәкмәстер, – дип, аңа шундук каршы төшә Газинур. – Без икебез болай да биш дуракка торабыз ич инде.

## Тавыш – табигать бүләге

Көтмәгәндә-уйламаганда Рафаэль Сәхәби белән Ркаил Зәйдулла Газинур Моратның Матбугат йортындагы эш бүлмәсенә килеп керә. Керә-керешкә үк Ркаил, гадәттәгечә, вәкарь белән генә:

– Беләсең килсә, безне сиңа бик тә кәттә чит ил машинасында китереп куйдылар, – дип искәртеп куюны кирәк таба. – Рульдә бер эстрада җырчысы иде, Сәхәбине танып, үзе туктатып утыртты. Ләкин Сәхәби генә аны танымый булып чыкты.

Шунда Газинур, җырчының аркасыннан кагып:

– Әгәр Ходай Сәхәбигә затлы тавыш бирмәгән булса, ул да кәттә иномаркаларда гына җилдерер иде, – дип әйтеп куя.

**Газинур МОРАТ**

## Уенчак сүзләр

- Җиңел холыклы сәнгатьнең дә үз тәтәйләр йорты була.
- Исерек сәясәтче аек шагыйрьгә бәрабәр.
- Чиркәүләрне татар каберташлары да күтәрешеп тора.
- Салкын сугышта кайнар башлар җиңелә.
- Ат сыртын ата сырты белән дә бутыйлар.

*Сәхифәне* **Газинур МОРАТ** *әзерләде.*

## ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

Новосибирскида федераль Сабантуй үткәрелде. Ул ике көн барды. Аңа илнең 29 төбәгеннән һәм Казакъстаннан кунаклар килде. Бәйрәмгә җыелган халыкны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Новосибирск өлкәсе губернаторы Андрей Травников сәламләде. Алар ул көнне Татарстан Республикасы һәм Новосибирск өлкәсе арасында эшлекле хезмәттәшлек турында килешүнең яңа редакциясен, 2019-2021 елларда аны тормышка ашыру программасын имзаладылар. Р.Миңнеханов Новосибирск татарлары төбәк иҗтимагый оешмасына «Хендай» микроавтобусы бүләк итте, иң актив татарларга мактаулы исемнәр бирү турында таныклыклар тапшырды. Сабантуйда бәйрәм котлавын ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев белән өлкәнең губернатор урынбасары Александр Дубовицкий да ирештерде.

Федераль Сабантуй Новосибирск губернаторы призына ат чабышлары белән башланып китте. Халык ике көн буена төрле ярышларда, уеннарда катнашты, концерт карады, ял итте. Киләсе елда федераль Сабантуй Мәскәүдә узачак.

## БЮСТ АЧЫЛДЫ

Самара өлкәсенең Камышлы районы үзәгендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Самара өлкәсе губернаторы Дмитрий Азаров катнашында фронтовик-шагыйрь Әнвәр Давыдовка бюст ачу тантанасы булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, шагыйрьләр Ләбиб Лерон, Булат Ибраһимов, Йолдыз һ.б. катнашты. Аннары кунаклар Камышлыда үткәрелгән X Бөтенроссия авыл Сабан туен тамаша кылды. Бәйрәмгә җыелган халыкны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Самара өлкәсе губернаторы Дмитрий Азаров котлады. Р.Миңнеханов Самара татарларына – «Форд-Транзит» автобусы, Д.Азаров Камышлы районына «Нива» машинасы бүләк итте.

## ТР ПРЕЗИДЕНТЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕНДА

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Татар әдәбияты тарихы музеенда булды, шушында ук язучы Шәриф Камалның мемориаль фатирын карады. Аңа китап фондлары, балалар өчен махсус интерактив бүлмә, яшьләр өчен коворкинг залы, Ш.Камалның тарихи төгәллек белән торгызылган фатирының интерьерлары күрсәтелде. Шунда ук Президент бер төркем язучылар белән әңгәмә корды. Эльза Шакирова-Байгильдина Рөстәм Нургали улына үзенең туганы Шәриф Камал әсәрләренең яңартылган басмасын бүләк итте. Президент киләчәктә Татар әдәбияты тарихы музееның һәм аңа кергән Шәриф Камал мемориаль фатирының туристларны җәлеп итәргә тиешлеген әйтте. Татарстан Президентын ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова һ.б. рәсми затлар озатып йөрде.

## ТАТАРСТАНДА БЕЛОРУССИЯ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

2020 елның сентябрендә Татарстанда Белоруссия Республикасы мәдәнияте көннәрен уздыру планлаштырыла. Әлеге чара ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында узачак Бу хакта Санкт-Петербургта Россия һәм Белоруссия төбәкләренең IV форумында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтте.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Мәскәүдә Татар мәдәнияте көннәре булып узды. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министры урынбасары, Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев, Мәскәү шәһәренең милли сәясәт һәм төбәкара элемтәләр департаменты җитәкчесе Виталий Сучков катнашты һәм чыгыш ясады. Әлеге чара шагыйрь Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте. Анда

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим катнашты. Кичен Мәскәү Халыкара музыка йортында Татарстан сәнгать осталарының гала-концерты булды. Мәскәүдә Татар мәдәнияте көннәре кысаларында Коломенское музей-тыюлыгында Сабантуй үткәрелде.

### БӨТЕНРОССИЯ ШИГЪРИЯТ ФЕСТИВАЛЕ

Шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның туган көнендә Бөтенроссия шигърият фестивале булып узды. Ул Казанның Лядской бакчасындагы Державин һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте. Шушында ук шигъри митинг булды. Төштән соң фестиваль шагыйрьнең туган ягы Лаеш районында дәвам итте. Шәһәрнең үзәк мәйданында уздырылган бәйрәмдә Г.Державин исемендәге әдәби премиянең быелгы лауреаты игълан ителде. Дәрәҗәле бүләк Чыңгыз Айтматовның «Чыңгызханның ак болыты» повестен, «Без бер тамырдан» дип аталган Россия халыклары легендалары һәм мифлары җыентыгын татар теленә тәрҗемә иткән өчен Мөдәррис Вәлиевкә бирелде. Юриспруденция өлкәсендә премиягә РФ Юстиция министрлыгының ТР идарәсе башлыгы В.Демидов һәм РФ Прокуратурасы университетының Казан юридик институты кафедрасы мөдире Флер Баһаветдинов лаек булды.

### ХАЛЫКАРА ФОРУМ

Казакъстан башкаласы Нурсолтан шәһәрендә I Евразия халыкара язучылар форумы булып узды. Әлеге мәртәбәле җыенда 25 илдән язучылар катнашты. Каләм ияләре бүгенге әдәбиятның актуаль проблемалары, мәдәни бәйләнешләр, халыкара хезмәттәшлек турында фикер алышты. Дәүләт җитәкчеләре, Л.Гумилёв исемендәге Евразия Милли университеты ректоры белән очрашты. Әлеге чараларда язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

### КИТАП НӘШРИЯТЛАРЫ КУЛ КЫСЫША

Актанышка Татарстан китап нәшрияты һәм Башкортстанның З.Биишева исемендәге «Китап» нәшрияты директорлары Илдар Сәгъдәтшин белән Илһам Яндәүләтов килделәр. Алар ике нәшрият арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүне имзалады. Директорлар бу тантанага үзләренең хезмәттәшләрен дә алып килгән иде. Ике коллективның очрашуы матур бер бәйрәмгә әверелде.

### СЕМИНАР

Биектау районы Кече Битаман авылында Туфан Миңнуллин исемендәге II Бөтенроссия драматурглар семинары булып узды. Анда язучы-драматурглар, режиссёрлар, театр тәнкыйтьчеләре катнашты. Башкортстан, Удмуртия, Марий Элдан да кунаклар килгән иде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов сүзләренә караганда, семинарның төп максаты – драматургларны берләштерү.

### ЖУРНАЛИСТЛАРГА – БҮЛӘКЛӘР

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов нәтиҗәле хезмәт һәм әһәмиятле чараларны яктыртуда актив катнашкан журналистларны бүләкләде. Медиатармакның 53 хезмәткәре бүләкләнде. Айрат Ринат улы алда журналистларны яңа зур вакыйгалар – WorldSkills Kazan 2019 эшче һөнәрләре буенча дөнья чемпионаты, ТР Дәүләт Советына сайлаулар көтүен әйтте һәм бу чараларны да актив яктыртырга чакырды.

### «ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ»

Бөгелмә төбәгендә «Фәйзуллин йөзүләре» уздырылды. Ике көн барган чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, язучылар Газинур Морат, Алмаз Хәмзин, Шәмсия Җиһангирова, Марат Кәбиров, академиклар Индус һәм Энгель Таһировлар, җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Сафиуллин, журналист Римзил Вәлиев, галим Булат Хәсәнов, Әлмәттән имам-хатыйп Илдус Маликов, шушы төбәкнең аксакаллар шураларының җитәкчеләре һ.б. катнашты. «Карабаш диңгезе»ндә ярышларда өч чакрымга йөзүдә бу чараның «авторы» Равил Фәйзуллин беренче килде. Быелгы проектның башлап йөрүчесе Фазыл Вәлиәхмәтов, Әлмәттән Илдус Маликовлар икенче, өченче урыннарны бүлештеләр. Җиңүчеләр арасында Р.Фәйзуллинның җәмәгате Наилә ханым белән шагыйрә Шәмсия Җиһангирова да бар.

### «АЛТЫН КАЛӘМ» ФЕСТИВАЛЕ

Казанда 24нче тапкыр «Алтын каләм» балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивале үткәрелде. Бәйгедә Татарстанның 24 районыннан 120 яшь егет һәм кыз катнашты. Фестиваль яшьләрнең талантын ачу, аларга ярдәм итү максатында оештырыла. Гран-при бүләгенә Баулы районыннан Руфинә Гыймаева (рус журналистикасы) һәм Аксубай районыннан унынчы сыйныф укучысы Айназ Сөләйманова (татар журналистикасы) ия булды. Кызлар КФУда журналист булырга укыячак. Уку өчен акча Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә республика бюджетыннан бүлеп бирелә.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: фантастический роман Ф.ИМАМОВА «Неподходящее время...», повесть Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Космея», повесть Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «Сироты», десять притч «Ногайский дом» Л.ЗУЛЬКАРНАЯ; стихи Г.МУРАТА, С.АХМЕТЗЯНОВОЙ.*
*«Из литературы родственных народов»: стихи Г.АНДРОСОВА.*
*«Новые имена»: рассказ А.АБДРАХМАНОВОЙ «Ты – кофе».*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Моменты из жизни Г.Мурата: фотоархив.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ З.ХУСНИЯРА «Доктор Байчурин», рассказ Н.ГИЛЬМУТДИНОВОЙ «Четыре струны сердца».*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк Р.САГДИ.*
*«75 лет Великой Победе»: статья Ш.МУСТАФИНА.*
*«История»: Б.ХАМИДУЛЛИН. «Цивилизация и наследие Золотой Орды».*
*«130 лет со дня рождения Сагита Сунчелея»: Современники о поэте (с предисловием З.Рамеева).*
*«85 лет со дня рождения Фарваза Миннуллина»: стихотворение Й.МИННУЛЛИНОЙ; моменты из жизни Фарваза Миннуллина: фотоархив.*
*«Наши музеи»: А.Сабирова. «Музей Туфана Миннуллина».*
*«Страницы юмора»: подготовил Г.МУРАТ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: музей Туфана Миннуллина в селе Большое Мереткозино Камско-Устьинского района; писатель Амур Фалях.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: fantasy novel by F.IMAMOV «The Wrong Time ...», novel by F.ZAMALETDINOVA «Kosmeya», novel by R.SHAYDULLINA-MURAT «Orphans», ten parables «The Nogai House» by L.ZULKARNAY; poems by G.MURAT, S.AKHMETZYANOVA.*
*«From the literature of kindred peoples»: poems by G.ANDROSOV.*
*«New names»: story by A.ABDRAKHMANOVA «You are Coffee».*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*Moments of life of G.Murat: photo archive.*
*Competition «Healing Hands»: story by Z.HUSNIYAR «Doctor Baychurin», story by N.GILMUTDINOVA «Four Strings of Heart».*
*«Tatarstan. History. Personalities»: essay by R.SAGDI.*
*«75th anniversary of the Victory in the Great Patriotic War»: article by Sh.MUSTAFIN.*
*«History»: B.HAMIDULLIN. «Civilization and the legacy of the Golden Horde.»*
*«130th anniversary of Sagit Suncheley»: Contemporaries about the poet (with the preface by Z.Ramiev).*
*«85th anniversary of Farvaz Minnullin»: poem by Y.MINNNULLINA; moments of life of Farvaz Minnullin: photo archive.*
*«Our museums»: A. Sabirova. «Tufan Minnullin Museum».*
*«Pages of humor»: prepared by G.MURAT.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Tufan Minnullin Museum in the village of Bolshoye Meretkozino in Kamsko-Ustyinsky district; writer Amur Falyah.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Туфан Миңнуллинның туган авылы Олы Мәрәтхуҗадагы музее. *Р.Сафин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы Амур Фәләх.